ISSN 0206—418



# КАЗАН УТЛАРЫ

1. 1985

*Бөек Җиңүнең 40 еллыгын*



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

1

1985

КПССның ТАТАРСТАН өлкә КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН


## *Бу санда*


Р. ХАРИС. **Ант суы.** Поэма . . . . . . . . 3

Ә. ЕНИКИ. **Соңгы китап** . . . . . . . . . 18

Ш. ГАЛИЕВ. **Мәкерле миналар.** Шигырьләр . . 78

Ә. ГАЛИЕВ. **Асыл кошым минем...** Повесть . . 82

Ж. РӘХИМОВ. **Бурыч.** Хикәя . . . . . . . . 134

«БАТЫРЛЫК ДӘВАМ ИТӘ» КОНКУРСЫНА

К. КӘРИМОВ. **Көзнең тыныч төне. Хикәя** . . . 141

ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Т. ХАҖИӘХМӘТОВ. **Уральскида Тукай урыннары** . 147

Ф. ӘГЪЗӘМОВ. **Тукай — публицист** . . . . . 148

КПССның XXVII СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

М. ЗАРИПОВ. **Күңелләргә юл ярганда** . . . . 155

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

М. ВӘЛИЕВ. **Егермедәгеләр** . . . . . . . . 164

ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ

Н. ФӘТТАХ. **Татар шигърияте күгендә** . . . . . 176

А. ИБРАҺИМОВ. **Тирән фикерле әсәр** . . . . 177

**Тарихтан — киләчәккә** . . . . . . . . . . 178

ШӘЙХИ МАННУРНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Ш. ХАММАТОВ, К. ТӘХАУ. **Ин[illegible] дуслыгы** . 181

Х. МАКСУД. **Яшьлек истәлеге** . . . . . 185

Ф. БИКЧУРИНА. **Бәхет китерүче осталык (Азат Аббасовка 60 яшь)** . . . . . . . . . . 188

**Кызыклы хәлләр** . . . . . . . . . . . . . . 190

**Культура тормышы көндәлеге** . . . . . . . . . 191

**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*

РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия:*

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ

ӘХӘТ ГАФФАР

МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ

АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ

МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ

МӘДИНӘ МАЛИКОВА

САЛИХ МАННАПОВ
*(җаваплы секретарь)*

ТУФАН МИҢНУЛЛИН

ФЛҮН МУСИН

РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*

РӘФЫЙК НӘФИКОВ

НУРИХАН ФӘТТАХ

СИБГАТ ХӘКИМ

РИЗВАН ХӘМИД

НИЛ ЮЗИЕВ

АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Поэма **Р. Хариса** «Клятвенная чаша», посвященная к 1000-летию булгаро-русского соглашения. Стихи **Ш. Галиева.**
Повесть **А. Еники** «Последняя книга», повесть **А. Галиева** «Драгоценная моя», рассказ **З. Рахимова** «Долг».
На конкурс «Подвиг продолжается»: рассказ **К. Каримова** «Осенняя ночь».

К «100-летию Тукая»: рисунок **Т. Хазиахметова**, статья **Ф. Агзамова** «Тукай — публицист».
Навстречу XXVII съезду КПСС. Очерк **М. Зарипова** «Дорога к себе».

В рубрике «Литературная критика» статья **М. Валиева** о творчестве молодых поэтов. Отклик **Н. Фаттаха** о стихах **Э. Шарифуллиной.** В обсуждении нового романа **М. Хабибуллина** «Кубрат хан» участвуют читатели, известные ученые и писатели.

В номере отмечаются юбилеи Ш. Маннура (80 лет), А. Аббасова (60 лет).

«Занимательные истории». Дневник культурной жизни.

«На наших обложках»: творчество художника **К. Васильева.**

**Безнең адрес:** 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

**Телефоннар:** баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары — 53-07-09, җаваплы секретарь — 53-07-09, проза, поэзия, очерклар бүлекләре — 53-07-61, тәнкыйть, сәнгать, хатлар бүлекләре — 53-07-63.

Техник редактор *Р. Сөләйманова.* Корректорлар *Т. Сибгатуллина, Г. Салихҗанова*

Производствога бирелде 30.10.1984 ел. Басарга кул куелды 3.01.1985 ел. ПФ 02002. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 64149. Заказ К-400. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1985 ел.

## Ренат Харис

# АНТ СУЫ

ПОЭМА

*Болгар һәм Русь килешүенең 1000 еллыгына багышлана*

**985. И заключил Владимир мир с болгарами, и клятву дали друг другу, и сказали болгары: Тогда не будет между нами мира, когда камень станет плавать, а хмель тонуть.**

«Повесть временных лет»

1

Таш ташладым мин Иделгә...
Һәм, табигый, таш батты —
һәм тоташты Идел өсте төбе белән...
һәм ялганды бүгенге көн үткән белән...

Китте дулкын алка-алка агымга түбән —
ярышып вакыт агышы белән.
Китте дулкын агымга каршы —
карышып вакыт агышына...

Мин дулкыннар ирегендә.
Чумам,
тарих аккан улактан — Идел-болактан —
эзәрелеп калкам,
матур бүгенгемнән хәл алам да,
алка дулкыннарга ябышып,
тагын карышам вакыт агышына...

Мин кайнар уйларымда эрим —
мин суга кушылып дулкын булам,
җилгә кушылып — сүзле өн,
җиргә кушылып — хәтерле туфрак...
Археологлар! Күңелем катламнарын күтәрегез —
мең еллык эзләр табарсыз...
Сыйпап узды алка дулкын

Казанга кунаклар төяп килүче
  «Ленин» теплоходын;
уздык Свияжск күперен, Чабаксар ГЭСы шлюзларын;
шаулап калды Мәкәрҗә ярминкәсе;
менә Нижний — «сосед Москве ближний»,
менә инде Ока суы уйларымнан дулкынлана;
Илья Муромецны әкиятләргә
керткән кала артта калды,
артта калды Рязань, Кашира, Серпухов белән Калуга,
алда мәшһүр Угра суының
тарих шикелле бормалары.
Борынгы уклар эзеннән
очып үтә ярдан ярга
бәхет кошы сандугачлар.
Уграның да чишмәсенә җиттек —
дулкынга юл бетте.
Кая барырга дулкынга?
Аңа туктарга ярамый —
туктадымы — дулкын үлә,
хәтер өзелгәч, кеше үлгән кебек,
хәрәкәт беткәч, тормыш үлгән кебек.

Һәм мин
кайнар уйдан тирләп, дәрья булган
маңгай сырларымны Угра-Десна
арасына сузып салдым —
чапсын дулкын, алып барсын мине
агымга түбән, вакыт агышына каршы.
Мин яңадан дулкын эчендә...
Чумам... Тарих аккан улактан
әтәреләм дә янә калкам...
Матур бүгенгемнән хәл алам да
тагын чумам вакыт-болакка.

  Узылды Ельня... Калды Брянск
каек кебек җай чайкалып;
князь Игорьне тәхеткә
күтәргән шәһәр калды җемелдәп;
менә Чернигов — Днепрның талгын сулары
уйларымнан дулкынлана...
Һәм мәһабәт бөек Киев —
рус шәһәрләре анасы!
Дулкын кая килеп җиткән!
Карасам —
тарих мең елга артка чиккән...

**2**

Яр башында имән Перун,
ботак-кулында яшен ташы.
Владимир князь изге учакка
ташлады имән тумәре —
чәчрәп очтылар очкыннар,
Перунның көмеш битендә
дәһшәт шәүләсе уйнады,
алтын мыеклары очы
ялкын капкан төсле булды.

Каһарман ир Владимир
сүз башлады:
— Бөек Перун! Сиңа рәхмәт!
Мин биргән имән түмәрен
ялкының дәррәү ялмады.
Фатихаң дип кабул итәм —
яу чыгам Бөек Болгарга.
Фатиха бир Добрыняга —
дружинамның башлыгына,
фатиха бир дружинама —
ниятемне үтәүчегә,
фатиха бир ниятемә —
ниятем Киев бәхете!

Бөҗра-бөҗра баскан ирләр
селектеләр сөңгеләрен:
— Киев бәхете — Русь бәхете!
Атка атланган угызлар,
тетрәтеп Киев каласын,
кычкырдылар:
— Кузгалабыз! Кузгалабыз!

Йөзен борды Владимир
Стрибог дигән аллага:
— Син дә ярдәмеңнән какма,
давыл тынлы Стрибог!
Җилкәннәремә җил тутыр,
су агымыннан көчлерәкне —
агымга каршы йөзәсе бар
көймәләргә дружина төяп.
Торк җайдакларының да
аркаларыннан этеп бар,
атлары артык талмасын —
аласы бар Болгар каласын.
Болгар патшасы Мөхәммәт,
безнең купецларны хурлап,
барлык байлыкларын талап,
бистәләрен туздырган ди,
ә үзләрен кол иткән.
Суварның тәхетсез калган
бәге шундый хәбәр салды.
Русның пычратылган данын
кан белән юарга тиеш...
Гөрләшеп алды угызлар:
— Хәбәр хактыр — Сувар бәгенең
җәмәгате угыз кызы,
ул да безгә ирештерде...
— Туганнардан тапны юарга,
арттырырга князь данын,
байлыгы санын!

Стрибог изге учакның
ялкынына дәрт өстәде.
Дружинага борылды князь:
— Күрәсезме, Стрибог та
ниятләрне безнең хуплый.
Әйдә, Добрыня-воевода,

боерык бир көймәләргә —
җилкәннәрен киерсеннәр,
боерык бир җайдакларга —
атларының сыртларына
кайнар камчы тидерсеннәр,
йөгерсеннәр яр буйлата
көймәләр кәрванын саклап...

Днепрга төште князь.
Калканнар белән тышланган
ак чатырлы кызыл көймәгә
керде зур чуерташ тотып.
Бөтен Киев озата төште
князьне ерак походка,
аларга уңыш теләде,
ә Руська — байлык белән дан.

Көймәнең борнына басып,
имән атына тотынып,
ярга борылып кычкырды князь.
— Кулымдагы чуерташны
күрәсезме, туганнарым?
Ниятем шушы таштай нык,
вәгъдәм шушы таштай авыр.
Аны Днепрга салам:
әйткән сүз — суга баткан таш,
я әйткән сүзне үтәргә,
я ташны эзләп табарга...
Һәм Владимир селтәнеп
тондырды ташны дулкынга —
аһ итте ярдагы халык...

Кәрван кузгалыйм дигәндә
яр башында калкып чыкты
бөек князьнең анасы —
Малуша Любечанка үзе.
Сүзе карлыккан акчарлак
тавышыдай яңгырады:
— Барма, князь, син Болгарга,
чыкма, улым, син походка —
рус хатыннары куллары
сезнең канлы киемнәрне
юа-юа чи ит булды,
аларның күз төпләрендә
улларының, ирләренең
вакытсыз каберләре карасы.
Йөрәгемдә ничә еллар
атаң Святослав ярасы —
син аның хәтәр эзендә...

Нәкъ шул чакта Стрибог алла,
киндер җилкәннәрне киереп,
бар булган көчен өрде
һәм йөзеп китте көймәләр
дулкыннарда атына-атына.

Мин ул чакта яу тавышыннан
күтәрелгән бер шау идем —
яңгырап киттем Болгар ягына,
ишетмәдем бөек князьнең
анасына кайтарган сүзен...

3

Килә торсын Владимир,
елгадан елгага керә торсын...

Мин җитимче тизрәк Болгарга,
иңимче олы хәбәр булып,
юл ябыймчы бәрелешкә
һәм суешка — кан коешка...
Бәрелдем Болгар капкасына —
сакчылары сискәнделәр,
тик берни дә күрмәделәр.
Очып чыктым биек, калын
диварлар аша калага,
җилеп үттем халык тулы
урамнарны, мәйданнарны,
агач өйләргә, таш мәчетләргә,
биек манараларга бәрелә-сугыла...

Шәрыкның ефәк, көмешен,
төньякның кеш тиреләрен,
Балтыйк буе гәрәбәләрен
һәм мең төрле башка товар
җыйган шушы Ага-Базармы,
мең юлны төенләп торткан,
кешеләрне, халыкларны
кул кысыштырган Ага-Базармы
тапталуга дучар булачак?!
Чуен кою мичләреме,
фонтанлы шушы мунчалармы,
рус, әрмән бисталәреме
һәлакәткә дучар булачак?!

Әллә шулай кеше һәрчак
кемдер корган гүзәллекне
таптый-таптый ләззәт тапкан?!

Корбанга дип терелеккә,
каршысындагыга дип киләчәккә
таш аткан... ук аткан... грек уты...
дары... бомба... напалм... атом...
Тукта, уем, артык алга чаптың...

Мөхәммәт патша сараена
барып кердем һәм кычкырдым:
— Мөхәммәт патша! Болгар-йортның
һәм үзеңнең хәлләр хәтәр:
Киевтән сиңа яу калыкты.
Бу — куркынычның кечесе,

чөнки синең яуга каршы
яу әзерләр вакытың бар,
яу чыкмасаң, Владимирга
затлы бүләкләр төягән
кәрван юллар вакытың бар.
Ә куркыныч куен астында:
Сувар-йортның яңа бәге,
башыңны тәнеңнән аерып,
тәхетеңә менмәк тели.
Башың биек! Кулы кыска.
Сузылып җитмәсен белгәч,
Русьны өстергән Болгарга.
Бәланең дә иң зурысы —
Идел суына адәм каны:
руслар каны, болгар каны,
угыз каны, кыпчак каны
кушылыр, ярларга сеңәр,
Идел ярага әйләнер.
Бик күп гасырлар узгач та
халыкларның язмышына
саркып-саркып чыгар каны...

Тик бу нәрсә?! Тик бу нәрсә?! —
Мөхәммәт ибне Хәйдәр
сүзләремне ишетмәде —
болгари сафьян тәхеттә
кыңгыр ятып, мәрткә китеп,
бер шагыйрьнең көйләп әйткән
мәдхияләрен тыңлады...

Аһ! Аяныч! Бүгенге көннең
ямен арттырачак киңәшне
үткән чорга җиткереп булмый...
Ә киләчәкне бәхетле
итәчәк эш башлап була...
Ерактан олы яу килә —
мәкердән калкып чыккан яу,
ә Болгар патшасы йоклый.
Йоклый берничә халыкның
язмышына бәйле тарих...

Патшаның көндезге ялын
бүлеп чапкын йөгереп керде:
— Әй Болгарның илтабары!
Мин тургай булып гөмбәзнең
үзәгенә очып мендем —
күрдем: кояш батыш яктан
илгә тузан тавы килә,
бу, тәгаен, угыз явы.
Мин балык булып Иделнең
төбенә ятып тыңладым —
чит-ят ишкәкләр тавышы...

Бармак шартлатты Мөхәммәт:
— Яман хәбәр дә яхшы эш,
вакытында килеп җитсә.
Бүләкләгез бу чапкынны...

Чиру башын чакырыгыз,
ил агалары җыелсын
шәүлә карышка озынайганчы —
шәүлә озынайган саен
яшәү белән үлем арасы
кыскара бара... Ашыгыгыз!
Һәм шәүлә карыш ярымга
озынайганда, Мөхәммәт
ил агаларына, бәкләргә
җиткерде хәтәр хәбәрне
һәм сорады:
— Таш атканга
без дә әллә таш атыйкмы,
әллә инде аш атыйкмы,
әллә, илчеләр җибәреп,
сүз катыйкмы?

Беравык киңәшкәннән соң
ил агалары исеменнән
аксакал ир сүз башлады:
— Угызлар — кан кардәшләребез,
безләргә таш атмакчылар.
Туганына таш атучы
җансыз таш булып аунасын!

Аһ! Аяныч! Бүгендә яшәп үткәнгә
бер киңәш тә җиткереп булмый —
кисеп булмый үзара үтереш,
суешның әрсез тамырын.
Бер юләр башның киңәше,
чорлар аша шытым биреп,
акыллы башларның миен
боргычлап газаплый ала...

Сүз алды өлкән аксакал:
— Таш атучыга безнең дә
таш күтәрер чамабыз бар.
Урыслар — ерак күршеләр.
Ерак күрше якын дуска
әйләнүчән була, баксаң.
Русь белән безнең арада
ара өзек, юллар төзек иде,
күрешә идек, йөрешә идек.
Ни булды икән — белергә кирәк —
илче җибәреп сүз катыйк...
Ә эш күрмичә аш атсак,
ашсыз да калырбыз,
соңра башсыз да...

— Хак! — диде Мөхәммәт патша,—
раслыйсызмы, аксакаллар?
— Рас! Рас! — диде олы мәҗлес.

Һәм мин шушы алтын сүзнең
үлмәс кайтавазы булып
очып киттем һаваларга,

сеңдем җиргә, эредем суда.
Археологлар! Җиребезнең
катламнарын актарыгыз —
мең ел элек иңгән сузнең
бүгенге эзен табарсыз!

4

Идел ярында чатырда
Владимир белән Добрыня
угыз чирүе башлыгын —
Бога алыпны — тыңлыйлар.
— Орыш олыдан булмады,
болгарларның каравылын
тиз сындырдык, тиз тараттык,
кораллары шәп булса да,
барысы батыр торса да —
меңләгән сөңге каршында
йөзләгән кылыч нәрсә ул!
Күбе җанын җилгә бирде,
шактыен әсир төшердек,
калганнары төрле якка
сөрем кебек таралдылар.
Ярты көннән, төш авышкач,
кулыбызга төшкәннәре
алдыбызга тезләнерләр.
— Князь,— диде Добрыня,—
үлгәннәр куркыныч түгел,
әсирләре дә шулай ук.
Әмма ләкин сөрем булып
таралганнары бик хәтәр —
сөрем эчендә очкын була!
Иделгә ут кабуы бар —
ил теләсә су да янар!
Болгар калкып өлгергәнче
йолкыйк капка келәләрен.
— Дөрес! — диде Владимир.—
Торклар инде Русьның
Болгар таплаган намусын
юа башладылар, кайнар
каннарында аларның чайкап.
Юып бетерергә кирәк.

Мин шул чакта чатыр эчендә
искән бер җил-җиләс идем
һәм кычкырдым бар көчемә:
— Ялгышасыз! Ялгышасыз!
Сез бит мәкер ялчылары.
Сез бит тарих хуҗалары —
русьлылар да, болгарлар да,
угызлар да, кыпчаклар да...
Тамырыгыз төрле агач
тамырларыдай кочаклашып
бер урманда укмашканнар!
Сез русьлардан руслар туар,
украиннар, белоруслар,

болгарлардан татар туар,
бер тамырдан чуваш туар —
көрәштәш тә, хезмәттәш тә,
табындаш та, язмышташ та
булып яшисе халыклар.
Ә бүгенге яралардан
бик күп гасырлар узгач та,
саркып-саркып чыгар кара кан...

Аһ, аяныч! Беркемгә дә
заманалар аша тоташып
җиткереп булмый акыллы киңәш —
бүгенге көнгә кирәклене.
Тарихны кире борып булмый...
Ә киләчәкне менә
теләгәнчә корып була!

Владимир чатырында
пәйда булды ишек сакчысы:
— Бөек князь! Өч ук атыш
ераклыкта Болгарларның
йөз кешелек илчелеге,
ә илчелекнең башында
патшаның энесе Сәет.
Ул сиңа дип бихисап күп
бүләк-түләк алып килгән —
кырык арба тулы сандык.
Арбалар артында тагын
кырык җайдак тезелеп тора —
барысы да рус купецлар.
Йөзләре шат — Матур кояшны
күрәбез дип куаналар.
Һәрберсенең иярендә
олы калта, ә калтада
сиңа дигән күчтәнәчләр.
Ә алардан да арттарак
әрмән, грек купецлары...
Ни эшләтик илчеләрне?

Сикереп торды Владимир:
— Алдау!.. Алдау бу, алдау!
Я, бәхетсез, син алдыйсың,
я мәкерле Сувар бәге...
Минем кылыч күтәрүем
мәкер галәмәте булса,
кичерерме моны Перун,
һәм Стрибог та кичерерме?..
Кадерле агам... воеводам...
син, Добрыня, бар... белеп кер,
бар, күреп кер — дөресме бу?

Чыгарга дип чатыр чаршавын
Добрыня тартып ачуга,
тагын да бер чапкын керде:
— Бөек князь! Әсирләрне

бире китереп җиткердек —
олы әмерең күтәбез...
Владимир тагын әйтте:
— Берьюлы әсирләрне дә,
Добрыня, күреп-карап кер
һәм бир миңа төпле киңәш —
йөрәгемдә давыл купты
ачу белән курку катыш,
шул давылда акылым һич
үзенә юл саба алмый.

Русь хакына кылганнары
былиналарга керәчәк
олы батыр Добрыня
чыгып китте ак чатырдан...

Аның күзләрендә янган
кырыс чаткы ул мин идем,
ул күргәнне мин дә күрдем...

Сугышчылар арасында
шундый таныш йөзләр күрдем —
әйтерсең лә якташларым,
белешләрем бабаларының
ерак бабалары йөзен:
берсе күршем бабасы бугай,
тегесе — Сабирҗаннныкы,
бусы — коеп куйган Тукай,
әнә рәссам Бакыйныкы,
ә болары — слесарь Наил...
колхозчы Җәүдәт, физик Сәгъди,
мөгаллим һидият... химик Камай...
җырчы Илһам... шофер Илдар...
авиатор Асаф... композитор Салих...
драматург Туфан, генерал Якуб...
шагыйрь Хәким... табиб Еники...
чалымнарының чишмә башы.
Ягъни бүгенге Казаным
буйлап йөргән кебек булдым...
Яралы кулын уксыз садакка
асып торганы, садагыннан
итегенә кан тамганы,
зәңгәр күзле, сары чәчлесе,
өлешчә кыпчак, өлешчә болгар,
өлешчә бортас булганы —
минем, минем ерак бабам!

— Сәлам, сәлам, дәүәтием!
күз зәңгәрлегем өлгесе,
ватандарлыгымның алтын кыясы,
син барлык шатлыкларың,
яраларың тамыры белән
йөрәгемә минем сыйгансың.
Сәлам, сәлам, дәүәтием!
Мин бит синең киләчәгеңнән
бүгенгеңә килгән оныгың.
Шуңа сине ни күтәсен

алдан беләм, әйтеп бирәм:
бераздан сине ярлыкарлар,
яраларыңны юарсың,
авылыңа кайтып китәрсең,
ярлыкап булган хәлләрне,
яраңдагы кызыл канны
кара үчкә әйләндермичә —
үче озынның гомере кыска,
кешенең дә, халыкның да...

Әмма бабам мине ишетмәде...

Бөек князе катына
әйләнеп кайтты воевода:
— Әйе, князь, сиңа Сәет
ихлас илче булып килгән.
Илчелегендә йөз кеше,
кырыгы — рус купецлары,—
барысы да сине күрергә
ашкыналар, бөек князь.
Барысы да исән-имин.
Аларны Бөек шәһәрдә
беркем дә кыерсытмаган,
йорт-җирләрен җимермәгән,
мал-мөлкәтен таламаган,
хатыннарын хурламаган,
балаларын рәнҗетмәгән.
Барысы да яхшы атта,
өсләрендә затлы кием,
аякларында итекләр —
әйтерсең лә барысы да
князь я князь оланы!
Аларга ияреп килгән
әрмәннәр дә, чирмешләр дә,
греклар да, башкортлар да...
— Аңлашылды! Сәетне без
кабул итик намус белән!
Ә торклар кулга төшереп
бире китергән болгарлар?
— Алар һәммәсе яралы —
барыстай сугышканнардыр.
Шуны күреп гаҗәпләндем —
барысы да күн итектән.
Алар безгә дань түләмәс —
чабаталыларны эзлик...
— Димәк, Суварның яңа бәге
безне оятсыз алдаган.
Болгарга билен бөксә дә,
сөңгесен сындырмый калган,
ә сөңгесе сынмаганның
сындыралар иде сыртын...
Ә Сәет ибне Хәйдәрне
кабул итеп сүзен тыңлыйк —
шуннан чыгып эш кыларбыз.

һәм мин шушы сөйләшүләрнең
шаһите булып җиргә сеңдем,
суда эредем, җилгә кушылып
очып киттем киңлекләргә —
Днепрдан Уралгача.
Археологлар, эзләгез —
һичшиксез эзләп табарсыз —
халыклар өчен кирәк сүз,
дәверләр өчен кирәк сүз
хәтта утта да югалмый!

5

Сараенда Болгар патшасы
Русь князенә табын корган.
Гади табын гына түгел —
тәме җанга сеңә торган,
сүзләре летописьлардан
мәңгелеккә күчә торган.
Бу — килешү мәҗлесе,
ант эчешү мәҗлесе.

Берсен-берсе чаба-чаба
күпме-күпме кылыч сынган,
сөңге тишкән тишекләрдән
сызгырып җан чыгулардан
гасырлар колагы тонган,
Русь, Хазар, Болгар бер-берсен
өркетә-өркетә арган,
киләчәк җырга сусаган,
елмаюларга сусаган...

Хәзер, хәзер, тиздән булыр
ике ил дә көткән Килешү,
Русь илен дә, Болгар-йортны да
арка терәкле иткән Килешү,
илләрара татулыкның
кадерен арттырачак Килешү,
бер илне икенчесенә
кунак итеп кертәчәк Килешү,
ике халык арасында
йөз ел артык кылыч түгел,
кашык йөртәчәк Килешү,
соңыннан башка солыхларга
өлге булачак Килешү,
тевтоннарның «дуңгыз» танавын
Грюнвальдта изгәндә дә,
Ялган Дмитрийларны,
тәкәббер Наполеоннарны
Мәскәүдән себереп түккәндә дә
халыклар бердәмлегенең
җилемендә булачак Килешү,
гасырлар узгач, Тукайга
«рус белән гомер кичердек
сайрашып...» диеп әйтергә
биеклек биргән Килешү,

фашист юлбасарларының,
чиерткәч тә халыклары
таралыр да җыеләрләр,
дигән кара өметләрен
чәлпәрәмә китерешәчәк,
рейхстагның гөмбәзенә
Җиңү байрагы элешәчәк
тирән тамырлы Килешү
тиздән, тиздән, тиздән булыр —
Болгар патшасы һәм кнзязь
ак бүлмәгә чыксыннар гына,
болгарның көмешчеләре
өлгерткән ант тустаганын
кулларына тотсыннар гына,
йотсыннар гына изге суны —
гөмбәз-түшәмнәр астында
яңгырар хуплау гөрелтесе.

Һәм менә алар чыктылар.
Болгар патшасы утырды
үзенең затлы урынына,
һәм сулына утыртты ул
кунакка әйләнгән кнзязьне,
янәшәсенә — Добрыняны,
ә аның да күршесенә
дружинаның баһадирларын.
Ә уңына утыртты ул
үзенең патшабикәсен,
аның янына Сәетне,
ә аның да күршесенә —
Болгар-йорт шәһәрләренең
тезгенен тоткан бәкләрен.
Сувар-йорт бәгенең урыны
таза казнада сынган теш
урыны кебек каралып калды.
Бәк үзенең котыртучысы
Хазар каганы далаларында
эзсез, үле тузан булды.

Торып басты Мөхәммәт патша:
— Без бөек Владимир белән
олы килешү ясадык: —
кан коешып шаярмаска,
беребездән беребез ясак җыймаска,
сәүдәне тыймаска,
ил илгә кунак йөрергә.
Бу ант әгәр бозыла калса —
күк керсен, кызыл чыксын!
Шулай диеп, патша кылычын
Владимир табынына куйды.
Гөмбәз-түшәмнәр астында
хуплау шавы яңгырады:
«Күк керсен, кызыл чыксын...»

Торып басты Владимир кнзязь:
— Без Мөхәммәт патша белән
олы килешү ясадык —

кан коймаска, дань җыймаска,
сәүдә юлларын кисмәскә,
илгә ил кунак йөрергә.
Бу ант әгәр бозыла калса,
Перун ташы башны ватсын,
Стрибог аны тузан итсен,
илтеп сипсен диңгезләргә!
Шулай дип князь бакрачын
Мөхәммәт табынына куйды.

Гөмбәз-түшәмнәр астында
хуплау шавы яңгырады:
«Башны ватсын, тузан итсен...»

Мөхәммәт бармак шартлатты —
пулатның ян ишегеннән
җиде сылу килеп керде
чулпыларын чылтыратып.
Алда патшаның үз кызы.
Кеш калфагының астыннан
толымнары агып чыккан.
Нечкә билен көмеш очлы
кәмәр тагы да нечкәрткән,
кайма куныч читекләре
баскан саен җырлап тора.
Чигүле киң җиңнәреннән
аккош муенлыдай сузылып
чыккан ап-ак кулларында
алтын-көмеш Ант тустагы.
Мәҗлес күзе сылуга да,
тустакка да туктый алмый
бермәл аптырап уйнаклады...

Болгар патшасы иелеп
Идел суы тулы тустакны
кушучлап күтәреп алды,
киләчәген күтәргән күк,
ил бәхетен тоткан кебек.
Рәхәтләнеп йотты йотым —
һәм сугарды Идел суы
болгарларның тынычлыкка
сусаудан өтелгән җанын!

Ант суы тулы савытны
Мөхәммәт сузды князьгә.
Алды князь Ант тустагын
тынычлыкны тоткан кебек,
йотты йотым рәхәтләнеп,
терек суын йоткан кебек —
һәм сугарды Идел суы
русларның кайнаган җанын!
Ике патша белән мин дә
эчтем изге ул ант суын,
минем җаныма да сеңде
Ант суының мәңгелек дымы.
Тарихымның терек суы
мәңгеканымда ул минем!

Аның шаулы ташкыннары
горурлыгым аккошларын
исән-имин килеш тота,
ул хәтерем хәрәкәтенә
ярдәмчеллек һәм наз өсти,
дуслар белән исәнләшкәндә
учларымда җылы була,
илем уңышлары өчен
шатланганда күзгә тула...
Ул миңа
үткән белән киләчәкне
күрерлек үткер күз бирә,
бөек дуслыкка мәдхия
язарлык ихлас сүз бирә.
Тагын да —
улым, кызым канында
миннән соң да яшәячәк
мең ел элек эчкән ул ант!

Мөхәммәт патша кесәсеннән
чыгарды чаткы-чакма ташын
һәм ташлады ант суына,
һәм, табигый, таш батты.
Һәм әйтте Мөхәммәт патша:
— Таш суда йөзә башлаганда,
ә колмак бата башлаганда,
безнең арада да
тынычлык бетәр!
— Хак! — диде Владимир князь.—
Ант суындагы бу дулкын
Иделгә күчәр, Днепрга күчәр
һәм гасырларга китәр!

6

Таш ташладым мин Иделгә...
һәм, табигый, таш батты...
Һәм тоташты Идел өсте таба белән,
Һәм ялганды бүгенге көн үткән белән,
килерләрем киткән белән, көткән белән.
Идел — мәңгелек ант суы —
агып ята халыкларның язмышларын тоташтырып,
кешеләрне очраштырып, кочаклаштырып...
Казан портында да әнә
купты дулкын алка-алка...
Ант суында «Ленин» теплоходының
мәһабәт сурәте киалка,
аның янбашларын
алка дулкын сыйпап үтә.
Мин шул теплоходтан
кадерле кунаклар көтәм.

## Әмирхан Еники

# СОҢГЫ КИТАП

### Сәхифәләр

Үткәнгә кайтуны дәвам итәбез... Язманың бу өлешенә «Сәхифәләр» дип кыска һәм гади генә исем куясым килде. Чөнки кеше гомеренең һәр көне бер сәхифә. Билгеле, дөньяда озак яши торгач алар бик күп җыелган. Менә шуларны мин күздән кичермәкче булам, ләкин барсын да түгел — аңа вакыт та, көч тә җитмәячәк. Аларның бик күбесе бер-берсен кабатлыйлар (безнең көннәребез шикелле үк), арада үзем өчен генә кадерлеләре бар, шулай ук ачып карыйсы килмәгәннәре дә юк түгел. Әмма бөтенесендә дә — мин белгән кешеләр, мин күргән тормыш, мин кичергән заман. Әгәр шулай булмаса, ул саргайган сәхифәләрне актарып та тормас идем. Инде әнә шул кайчандыр күргән-кичергән тормышны һәм заманны азмы-күпме чагылдырганнарын сайлап алырга кирәк. Сайларга һәм берләштерергә... Бу да җиңел түгел. Берәүләргә ошар, берәүләргә ошамас... Хәер, табигый хәл, бәхәскә урын юк. Безнең эшебез исә — үзебез кирәк дип тапканны язу... Чөнки бу — истәлек, ә истәлекләр бары шулай гына языла да ул. Тапшырдык!

...Искә төшерик, бу китапның «Каргалы» өлешендә язылганча, минем атам 1910 елның көзендә Каргалыдан Дәүләкәнгә (искечә — Этколга) күчеп килгән. Мин бу вакытта әле бишектән дә төшеп җитмәгән яшь ярымлык сабый гына булганмын. Күз күрсә, колак ишетсә дә, миндә әле хәтер дигән нәрсә юк, мин әле һич нәрсә белмим — мин бары ашый беләм, йоклый беләм, көлә беләм, елый беләм. Әмма ничек итеп көләм яки елыйм — бусы да миңа билгесез... Кыскасы, дөнья миннән еракта, бик еракта әле, җиде диңгез артында!

Кеше бала чагында үзенең картлыгын күз алдына китерә алмаган шикелле, картайгач ул бала чагын да күз алдына ачык кына китерә алмый икән. Ә инде сабый чакны әйтеп торасы да юк — сабый чактагы хәлләрне без бары соңыннан, әти-әниләребездән яки якын туганнарыбыздан ишетеп кенә белә алабыз. Хуш, нәрсәләр ишетеп белдем соң мин Дәүләкән [1] белән бәйләнгән сабый чакларым турында?

[1] Хәзерге Дәүләкәннең ул заманда Эткол дигән авыл җирендә үсеп киткәнен күргән идек. Ләкин укучыны саташтырмас өчен мин моннан соң Дәүләкән исемен генә кулланачакмын. (Ә. Е.)

...Иң элек шуны әйтергә кирәк, безнекеләр башта Дәүләкәннең үзенә түгел, ә аңа терәлеп үк торган Яңа Көрмәнкәйгә килеп төшкәннәр һәм шунда яшәүче Муллый карт дигән бер башкортның өенә вакытлыча кереп торганнар. Бер генә урамлы бу кечкенә авыл Дим аръягындагы Иске Көрмәнкәйдән күчеп утырган булса кирәк, шуңа күрә аның исеме дә Яңа Көрмәнкәй дип аталган. Дәүләкәннең югары очы белән бу авыл арасында, мин үскәндә, бер сай чокыр гына иде. Хәзерге вакытта Яңа Көрмәнкәй юк, беткән, аны күптән инде Дәүләкән «йоткан».

Шул рәвешчә без башта күпмедер вакыт Муллый карт өендә торганбыз. Муллый карт ул минем бабакайның электән үк йөрешкән дус кешесе икән. Бай башкорт, күп җир биләгән, ишле мал асраган, шуның өстенә, Дәүләкәннең үзендә аның ике катлы тагын бер йорты да булган. Нәкъ базар күзендәге шушы асты таш, өсте агач зур гына йортын Муллый карт минем атакайга арендага биреп торган. Атакай бит Дәүләкәнгә, онытмаган булсагыз, сәүдә итү максаты белән килгән, аңа тизрәк эш башларга кирәк булган, ә кулында сумасы зур булмаган (әйтүенә караганда, бер 300 сум чамасы гына), шулай да ул тәвәккәлләп Муллый карт йортында «чәйни» (чәйханә) ачып җибәргән. «Аллага тапшырып эшне башлауда Муллый бабаем бик ярдәм итте»,— дип яза ул үзе дә. Күрәсең, «бабай» аренда хакын зур куймагандыр, ә бәлки әле акча да биреп торгандыр — ярдәм итүен шулай аңларга кирәктер инде.

Шулай итеп, Каргалыдан килгән яңа «сәүдәгәр» үзенә бөтенләй таныш булмаган бер эшкә тотына. Ярый, «тәвәккәл таш йоткан» диләр, ә без карап карыйк, нәрсә икән ул минем атай ачкан «чәйни»? (Бөтен җирдә чәйханә, ә Дәүләкәндә ни өчендер чәйни! Ахрысы, русның «Чайная»сыннан шулай үзгәреп киткәндер). Ул, ягъни мәсәлән безнең чәйни, гади генә бер ашап-эчеп чыгу урыны булган. Анда зур чуен чүлмәкләрдә турап салган куе итле, кулдан гына кискән эре токмачлы, өреле аш пешкән, чиләк сыешлы җиз самоварларда чәй өчен өзлексез су кайнап торган. Ә чәйнең үзен фарфор чәйнекләрдә пешереп биргәннәр. Бу эшләрне бер аш пешерүче (повар) белән бер ташып торучы (полавой) башкарган. Эш кызып киткәндә атакай үзе дә булышкан, ләкин ул күбрәк базардан кухняга азык ташыган, ә инәй гел генә савыт-саба юып, сөртеп торган. Чәйнидә бернинди хәмер заты сатылмаган һәм тәмәке тартып утыручы да булмаган.

Эшнең иң кызу, тыгыз чагы гадәттә базар көненә туры килгән. Бу көнне чәйнигә базарчы агайлар кереп тулган. Ашау, эчү арзан булган, мәсәлән, ике тиен түләп, чәйне теләсәң ни хәтле эчәргә яраган. Бер җамаяк куе аш та ун тиен генә торган шикелле — сөйләүләре буенча шулайрак хәтеремдә калган. (Гомумән ул елларда азык әйберсе арзан йөргән, мәсәлән, тере сарык ике сум илле тиен — өч сум тора, диләр иде.) Шуңа күрә дә агайлар чәйне күп эчәргә яратканнар. Кыш көне булса, каеры туннарын да салып тормыйча, тик бүрекләрен генә салып, шабыр тиргә батып, «агып киткәнче» чәйне эчәләр дә эчәләр икән. Ашаганнары ак калач яки юкә бауга тезгән йомшак клиндер, тик шикәр генә күп түгел — чәйне ун чәшке эчсә дә, шикәрне бер генә кисәк биргәннәр. Хәер, акчаларын җәлләмәгәннәр, базардан үзләре белән йөзем, хөрмә, халвә кебек тәмле-төмлене дә алып кергәннәр.

Базарсыз көннәрдә исә чәйнигә йөрүчеләр әллә ни күп булмаган. Төш вакытында яки кичен ялгыз приказчиклар, извозчиклар һәм ломовойлар, мәдрәсәдә ятып укучы хәллерәк шәкертләр кереп, ашап-эчеп чыга торган булганнар. Аннары безнең чәйнигә, ни сәбәптер, Дәүләкән саилчеләре дә ияләшкәннәр. Зур базарлы сәүдә җире саилчеләрне һәр вакытта үзенә тарткан — берәүләре гариплеге аркасында бүтән эшкә ярамаган, икенчеләре исә хәер сорашуны үзләренә кәсеп итеп тә алган-

нар. Менә шулай һәр көнне өй борынча урам йөреп, озын киндер капчыкларын сынык-санак белән тутырып, безнең чәйни янына кайталар икән дә, баскыч төбенә утырып, барлык җыйганнарын бушатып, сортировать итәргә тотыналар икән. Ап-ак оннан пешерелгән иң тәмле йомшакларын гына үзләренә калдырып, башка каты-котыларын минем инәйгә: «Мә, абыстай, сыерыңа ашатырсың!» — дип бирәләр икән. Аннары чәйнигә кереп, әйбәтләп чәй эчәләр дә, кайдадыр үзләренең куна торган җирләренә кайтып китәләр икән. Минем инәй дә аларны, ярым көлеп, ярым сагынып дигәндәй, вакыт-вакыт исенә төшергәли иде.

Менә шундый саилчеләрнең берсе бөтен авыр һәм хәтәр елларны (ачлык елында) исән-сау үткәреп, мин малай чакта да безнең Дәүләкәндә йөри иде әле. Тәбәнәк кенә буйлы, түгәрәк кенә битле, сакалмыексыз — ничә яшьтә икәнен бер ходай үзе генә белгәндер. Өстендә — итәкләрен этләр өзгәләгән, көрән төстәге кыска гына постау чикмән, аның астында кат-кат ямау салынган бик киң алача ыштан, аягында керле тула оек өстеннән киндерәсен чувашларча балтырына чаклы уратып бәйләгән, тузып, «мыегы да чыккан» чабаталар, иңендә озын киндер капчык, кулында шактый саллы таяк... Чын исемен белгән кеше юк, ләкин ул үзен: «Мин — Курапаткин!» — дип йөртә иде,— ягъни япон сугышы вакытында даны чыккан патша генералы, янәсе! Генералга охшар өчен ул ике колагы да өзек бүрегенең түбәсенә ап-ак куян койрыгы утыртып, чикмәненә түгәрәкләп кискән ак калай кисәкләре тагып йөри иде. Һәр йортның ишегалдына кергәч, «Курапаткин» балачага алдында кеше аңламас нindидер кыска гына такмак әйтеп, бер генә урында әйләнгәләп, тыпыр-тыпыр биеп тә ала торган иде. Аны милләте белән чуваш диләр иде. Бәлки, дөрес тә булгандыр, чөнки ул сәдаканы татарлар бирсә, ашыкмыйча гына дога кылып, руслар бирсә, бер-ике кат тиз генә чукынып, ишегалдыннан чыгып китә иде. Кыскасы, кешеләргә һич зарары тимәгән, алланың бер дивана бәндәсе иде— башын кайчан, кайда салгандыр инде бу «мәшһүр» Дәүләкән Курапаткины?!.

Муллый карт йортының ике катлы булуын әйткән идем бугай. Чәйни аскы катында, ә өске катында фатирчылар торган. Дөресрәге, өске катның такталар белән генә бүленгән берничә вак бүлмәсендә айлапеллап кешеләр яшәгән. Мәсәлән, безнең Каргалы кешесе Ибәтулла учитель, Солтанмораттан (Галимҗан Ибраһимов авылыннан) килгән Мөхәммәтша тегүче, тагын икеме-өчме ялгыз приказчик шунда торганнар. Учитель үзенең бүлмәсендә башкорт шәкертләрен русча укыткан, ә тегүче Зингер машинасында текер-текер чалбар, камзул, җилән тегеп утырган. Бүлмә өчен күпмедер акчаны безнекеләргә түләгәннәр, ашаучылары да бездән булган. Русчалап әйткәндә, аларны нахлебниклар диярга дә ярый! Барысы да буйдак яшьләр булганга күрәдер инде, алар кызык яшәгәннәр, гел генә төрле мәзәк, уен-көлке уйлап чыгарганнар — шулай исләренә төшереп сөйли торганнар иде минем атакай белән инәй.

Мин үзем, билгеле, бу чәйни заманын бөтенләй диярлек хәтерләмим, бик кечкенә булганмын әле,— әйтик, ике белән биш арасында гына... Аннары без чәйнинең үзендә түгел, ә күршедәге икенче бер йортта торганбыз. Шуның өстенә, бу йортка күчеп күпмедер торгач, мин өченче яшемдә кинәт кенә... аяксыз калганмын. Ягъни әйбәт кенә йөреп яткан җиремнән егылганмын да аякка баса алмас булганмын. Нинди чир, нинди зәхмәт аркасында — моны миңа атам-анам да бервакытта да әйтеп бирә алмадылар. Авырту-сызлану да булмаган шикелле. Һәрхәлдә, урын өстендә үрсәләнеп ятмаганмын, киресенчә әле мүкәйләп булса да йөрергә тырышканмын. Алар, әлбәттә, бик курыкканнар, тугыз баладан соң унынчысы да гарип калса — алла үзе генә саклый күрсен!.. Мине аякка бастыру өчен врачларга күрсәтү (ул чагында

ук Дәүләкәндә земский шифаханә булган), төрлечә дәвалап карау, имтомнар куллану, ниндидер бер зур ишанга илтеп өшкертү — берсе дә калмаган. Озакка сузылган бу тырышу, ә мин һаман идәндә шуышып кына йөрим икән... Әмма шулай да инәйнең күз яшьләре, ялварып сораулары, ниһаять, «алла бабайга барып җиткән» булса кирәк, көннәрдән бер көнне, кинәт аяксыз калган шикелле, кинәт кенә аягыма да басканмын! Ул болай булган: кемнеңдер киңәше буенча, зур түгәрәк тазда ниндидер шифалы үлән-чәчәкләрне кайнар су белән пешекләп, мине шуның пар-суына утыртканнар. Башымны гына ачык калдырып, өстемә калын юрган япканнар. Һәм иң гаҗәбе — атакай белән инәй мине шул хәлдә калдырып, үзләре мунчага киткәннәр. «Без кайтканчы утыр, балам!» дигәннәрдер инде. Ә мин кайтканнарын көтеп тормаганмын, үрмәләп таздан чыкканмын да, урындыкка тотынып әкрен генә аягыма басканмын! Кайтып кергәч, атакай белән инәйнең күзләре шар булган — бу нинди могҗиза!.. Тиз генә мине күтәреп алганнар, киендергәннәр, яңадан аякка бастырганнар. Һәм менә шул басудан мин йөреп тә киткәнмен.

Бала чагымда булып узган бу хәвефле хәлемне мин бары сөйләүләре буенча гына беләм, ләкин ни гаҗәп! — урындыкка тотынып басып торуымны үзем дә әзрәк кенә хәтерлим кебек... Инде шактый ук үскәч, мин колын шикелле нечкә, бик йөгерек аяклы бер малайга әйләндем. Бик ярата идем чабарга, узышырга... Дәүләкән малайларыннан берәүне дә уздырмый идем, тик кайчагында Арсланגәрәй агай малае Таһир гына мине узгалый торган иде.

Чәйнидә чакта да мин, әйтүләренә караганда, бөтиле түбәтәй киенгән, бик җиңел, бик тере бер малай булганмын (бигрәк тә аягыма басканнан соң). Бер генә минут та бер урында тик кенә утыра белмәгәнмен, каядыр китәм дә барам, чыгам да югалам — кайчагында чәйнидә торучылар күмәкләшеп мине эзләргә чыгалар икән. Еш кына әлеге саилчеләрнең берәрсенә ияреп китеп, өйдән-өйгә «хәер сорашып» та йөргәнмен. Бала җитәкләгән саилчегә сәдаканы мулрак биргәннәр... Мине таныган кеше очраса, ул шунда ук чәйнигә барып, инәйгә: «Хәдичә апа, улыгыз бер саилчегә ияреп йөри бит, шуны беләсезме?» — дип әйтә икән. Инәй, бичара, ах-вах иткән, ә атакай тиз генә артымнан барып, мине күтәреп алып кайткан. Ә миңа нәрсә, миңа кызык кына саилче капчыгына тотынып йөрү!..

Соңыннан, күп еллар узгач, атакай ниндидер бер уфтану белән миңа: «Улым, син малай чагыңа бер дә охшамагансың»,—дип әйтә торган иде. Гаҗәп түгел, бишектәге бишкә төрләнә дигәннәр, һәм мин моны үзем дә тоя идем. Һәрхәлдә, бик үзгәрдем мин — бала чактагы житезлек, җиңеллек, гамьсезлек күптән инде онытылды. Бик басынкы, бик сабыр (һәм чыдам), бик сак картларга әвереләдек без барыбыз да...

Әйткәнемчә, чәйнидәге тормышыбызны мин ишетеп кенә беләм — ул хакта атакай белән инәй әлек еш кына исләренә төшереп һәм күбрәк көлеп сөйли торганнар иде. Гүя, алар өчен дә ул «чәйни» дигән нәрсә очраклы һәм кызыклы әкәмәт бер урын булып кына исләрендә калган... (Атакай аны беренче герман сугышы башлангач ташлаган.) Ә йорты үз урынында һаман да тора әле. Искергән-тузганы да артык сизелми, яхшы карыйлар ахрысы. Хәзер анда ниндидер идарәме, конторамы урнашкан... Кайткан чакларымда мин һәрвакыт аның янынан узам. Бик истәлекле йорт — миңа кадерле булырга тиештер инде ул. Төрле уйлар, хисләр уятырга... Ләкин ни хикмәттер, мин аңа карап сагыну яки якын итүгә охшаган бер нинди дә тойгы кичермим. Чит, ят бер бина кебек ул минем өчен. Хыялым белән монда торган чагыбызга кайтырга тырышсам да, безнең базарчылары белән тулы бик гади генә «чәйни»ебезне нишләптер күз алдына китерә алмыйм. Бик күп еллар

узган шул инде... Гомер катламы өстәлә барган саен, үткәннәрнең һәммәсен дә искә төшерү дә һәм сагыну да мөмкин түгелдер, күрәсең.

Әйтергә кирәк, «чәйни» тоту атакай өчен очраклы гына бер кәсеп булган икән. Шуннан соң ул бер урында гына утырып, мәсәлән, кибет ачып, сату итмәде. Аның сәүдәсе гел йөрү белән бәйләнгән иде. Күптән түгел, Срур тутыкай миңа: «Атаң, мәрхүм, сәяхәт итәргә ярата иде бит»,— диде. Һәм чынлап та йөрергә бик һәвәс иде ул. Малай чагыннан ук бу һәвәслек аңа йоккан булырга тиеш. «Каргалы» өлешендә мин аның башта бабасы Әхтәм картка ияреп, аннары атасы белән бергәләп, башкортлар арасында тире-яры, йон-ябага җыеп йөрүләрен язган идем инде.

Егет булып өйләнгәч тә ул юл йөреп алыш-биреш итүдән туктамаган, тирә-яктагы базарларны һәм ярминкәләрнең берсен дә диярлек калдырмаган. Шул чакларын исенә төшереп сөйли башласа, мин бик гаҗәпләнеп тыңлый торган идем. Чөнки бик күп еллар узуга карамастан, ул кайсы ярминкә артыннан кайсы ярминкә килүен, һәркайсының аен, айның кай числосында указ укылуын (ярминкә ачылыр алдыннан гадәттә указ укылган) төп-төгәл белә иде. Мәсәлән, январьның искечә 25 ендә Уфа ярминкәсе ачылган, аның артыннан 15 мартта Эстәрле ярминкәсе башланган, аннан — Бәләбәй ярминкәсе, аннан — иң соңгысы Бөгелмә ярминкәсе булган икән. Тагы да гаҗәбе — атакай шул ярминкәләргә (мәсәлән, Бөгелмәгә) барган чакта узарга туры килгән бөтен авылларның исемнәрен белә иде. Алай гына түгел, кайсы авылдан соң кайсы авылга җитүләрен, кем исемле агайга кереп ат ашатуларын яки кунып чыгуларын бәйнә-бәйнә сөйли торган иде. Искиткеч хәтер иде үзендә!

Әнә шул бик яшьтән башланган йөрү һәвәслеген ул картайганчы диярлек ташламады. Миңа караганда ул дөньяны күбрәк гиздә, күбрәк күрде. Мәсәлән, Себер ягына йөри башлагач ул Иркутскига чаклы барып җитте, ә мин Чиләбедән дә уза алмадым. Билгеле инде, йөрү төп максат түгел, төп максаты аның — кәсеп итү, әмма йөреп, чөнки аңа шул күбрәк ошаган. Кыскасы, чәйнине ташлагач, минем атай, коммивояжер шикелле күн саквояжын күтәреп һәм уңышлы алыш-биреш өмет итеп, якын-тирә шәһәрләргә юл тота башлый.

Ул чагында безнең үз йортыбыз юк иде әле, шул сәбәпле без фатирдан-фатирга күчеп йөргәнбез. Болай йөрүебез 1918 елга чаклы дәвам итә. Шуңа чаклы, ягъни дүрт ел эчендә без өч тапкыр фатир алыштырдык. Унсигезенче елның җәендә атакай, ниһаять, чибәр генә йорт сатып ала. Истән чыгармыйк, «чәйни»не ташлап киткән елны герман сугышы башлана, ә без йортлы булганда инде бөек революция дә булып өлгерә. Кыска, әмма тыгыз заман! Минем биш яшьтән тугыз яшькә чаклы вакытым. Хәтерем инде ачылган һәм күп кенә нәрсәне күрергә дә өлгергән. Әмма күпмесе шуның күңелдә сакланган — моны әле сынап карыйсы бар.

«Чәйни» йортыннан без Арыслангәрәй тыкрыгындагы бер йортка күчкәнбез. Бу — зур урамнан Комач буена төшә торган бик кыска гына бер тыкрык иде. Аның бер ягында Арыслангәрәй башкортның каралты һәм абзарлары, икенче ягында ниндидер бер рус кешесенең амбаркуралары сузылып киткән иде. Ягъни тыкрыкта яр башына җиткәнче бернинди йорт-мазар юк иде. Бары тик тыкрык беткән җирдә, яр башыннан Комачка карап ике генә йорт тора иде. Шуларның берсе, Арыслангәрәй койрыгындагысы — тимерче Миңнегали агай йорты, икенчесе — рус койрыгындагысы — без күчкән йорт иде. Йортлар кеше коерыгында гына торсалар да, алар каршысында ачылган манзара гаҗәп тә матур, шагыйранә иде! Хәер, мин хәзер менә шулай дим, ә ул ча-

гында манзараның да, матурлыкның да нәрсә икәнен, әлбәттә, белмәгәнмен. Ләкин шулай да күз алдына китерик.

...Түбәндә — Комач. Бу — Димнең шактый озын һәм киң генә култыгы. (Элекке Этколның шушы култык буенда утырганын мин әйткән идем инде.) Комачның теге ягында кечерәк кенә тугай, тугайны үткәч Димнең үзенә барып чыгасың. Дим аръягында куе әрәмәлек башлана, аны ерып үтсәң, тагын Димгә килеп чыгасың... Тукта, нигә болай, Дим әллә икәүме дип гаҗәпләнергә мөмкин. Юк, ул берәү генә, ләкин хикмәт шунда, ерактан туры гына агып килгән Дим Дәүләкәнгә җитәрәк озын-озын өч борылыш ясый. Борылышларны ерымнар тоташтыра. Һәр ике борылыш арасында я кечкенә тугайлык, я куе әрәмәлек. Менә шулар барысы да — Димнең борылышлары, ерымнары, әрәмәлекләре, алардан да ары Көрмәнкәй тавына хәтле җәелеп киткән бик киң тугай, тугайдагы камышлы күлләр — әлхасил, минем әлеге манзара дигәнем безнең яр башындагы йорттан ап-ачык күренеп тора да инде. Гаҗәеп бер күреп тә бетермәслек киңлек ачыла каршыңда! Тагы да ераккарак — Димнең үренә таба карасаң, бу яшел, бөдрә, тип-тигез киңлек, чиге булмагандай, якты томан эченә китеп югала.

Яр кырыена салынган һәрбер йортныкы шикелле безнең йортның да аскы һәм өске каты бар иде. Аскы каты ярга кертеп таштан салынган, өске каты — бүрәнәдән. Тыкрыктан килгәндә, аның шушы өске каты гына күренә. Без менә шунда — өске катта тордык. Аста кемнәр торганын ачык кына хәтерләмим. Безнең белән янәшә, өйнең икенче яртысында, герман сугышы башлангач, каяндыр, Литва якларыннан күчерелгән бер немец гаиләсе тора иде. Мин аларны да бик аз беләм, бары минем чамадагы бер кызлары гына истә калган. Ул минем телне, мин аның телен белмим, ә шулай да бергә уйный торган идек. Кызык, песи балалары кебек телсез дә ничектер аңлаша алганбыз.

Без бу йортта озак тормадык. Шуңа күрә сөйләрлек истәлегем бик аз. Әмма бер нәрсәне бик ачык хәтерлим: безнең фатирның һавага чыгып торган иркен генә балконы бар иде. Җәйнең җылы иртәсендә яки кичкырын безнекеләр шул балконда еш кына чәй эчеп утырырга яраталар иде. Әтрафтагы манзараның матурлыгын әйтәсе түгел, сез моны беләсез инде, ләкин биек балконда чәй эчеп утыруның тагын бер хозурлыгы шунда иде ки, һәр көнне кояш баер алдыннан Комачта бакалар хоры башлана иде. Комач — акмый торган су, шунлыктан анда бакалар бихисап иде. Менә шулар, аеруча тын-җылы кичләрдә, көтүләре белән су читенә җыелып, тотыналар төрлесе төрлечә «сайрарга»! Бөтен су буе өзлексез яңгырап тора. Һәм әйтергә кирәк, төрле тавыштагы бу бакалар хорының үзенә күрә бер тәртибе бар, моңы-яме бар. Тыңлый торгач аңа күнегеп була, кайчагында исә күңелдә үзенә бер сагыш та кузгата иде ул!

...Кечкенә су өстенең тагын бер серле хәтердә нык калган. Шулай ук кояш баеган чакта гына аргы Димнән «бум... бум» дигән төслерәк өзеп-өзеп кычкырган калын бер тавыш ишетелә торган иде. Аны ишетүчеләр шунда ук: «Әнә, су үгезе кычкыра!» — дип әйтәләр иде. Чынлап та, тавыш шундый калын, шундый көчле ки — андый тавыш бары үгез шикелле зур бер җанвардан гына чыгарга тиеш иде. Һәм мин үсеп җиткәнче диярлек безнең Димдә дүрт аяклы су үгезе булуына ышанып йөрдем... Мин генә түгел, бик күп малайлар моңа ышаналар иде. Ләкин ни гаҗәп — үгезнең үзен күрүче генә юк. Бер вакытта да берәүнең дә: «Күрдем мин аны, малай!» — дип шаккатырып сөйләгәнен ишетергә туры килмәде. Әллә инде ул дәһшәтле үгез бер дә судан чыкмыйча ятамы?! Алай дисәң, көчле-калын тавышы аның шундый ерактан ничек ишетелә соң?

...Бары тик шактый вакытлар узгач кына дәү абыйлардан чын дөресен ишетергә туры килде: бернинди су үгезе безнең Димдә юк икән.

Аның каравы, ниндидер бер кечкенә кош бар, имеш. Менә шул хәтәр исемле өтек кенә кош кичке тынлыкта ялгызы гына йөзеп йөргән чагында башын суга тыгып «бум-бум» дигән төслерәк калын тавыш чыгара икән. Вәт сиңа хәтәр үгез! Хәзер бармы ул, белмим, ләкин кайткан чакларымда аның мәһабәт тавышын ишеткәнем юк.

Хуш, яр башындагы ике йортның берсе тимерче Миңнегали агай йорты дигән идем. Аның йорты да түбәннән караганда ике «катлы» иде. Тик түбән каты яр асты ягыннан өйне күтәреп торган бер подвал сыман гына нәрсә иде. Шуның өстендәге йорт үзе калай белән япкан булса да, шактый кечкенә иде... Янә тар гына ишегалларында такта алачыклары бар иде — шуннан көне буе диярлек зур чүкеч белән кечкенә чүкечнең алмашлап тимер чүкегәне ишетелеп тора иде.

Миңнегали агай — безнең мин белгән иң беренче якын күршебез иде. Гаиләсе аның ишле, шул чакта ук инде дүрт улы, өч кызы бар иде. Ике улы — Габдулла абзый белән Муллагали абзый җитеп килгән егетләр, алардан кечерәк Зөфәр дә миннән алты яшькә олы үсмер малай иде. Ә миннән күпмегәдер яшьрәге Әхтәм, ләкин мин аның балачагын белмим диярлек. Кызлары — Мәһирә, Рәхимә, Рәхилә, тагын соңрак Сания исемлесе дә булды. Болай санап чыгуымның бер хикмәте бар: шушы тимерче гаиләсе белән без озак еллар буена бик якын — дус яшәдек. Соңыннан терәлеп торган күршеләр булмасак та, бу якынлык бер вакытта да бетмәде, һәрвакыт аралашып, йөрешеп тордык.

Миңнегали агай үзе — кара сакаллы, таза, базык кына кеше — Дәүләкәндә хөрмәт казанган бер авторитет иясе иде. Аны белмәгән һәм аңа эше-йомышы төшеп бармаган кеше юк иде диярлек. Тимерчелек исә аңа нәселдән күчкән, гомере буена ул алачыгыннан чыкмады, кулыннан чүкечен төшермәде. Дәүләкәнгә килгәнче әле алар Эстәрле ягындагы бер боярда шактый вакыт эшләп торганнар. Миңнегали агай үзе тимер чүкегән, хатыны Сабирә җиңги сыерлар сауган. Кыскасы, тумыштан ук алар бары кул көче белән яшәп, һәр сыныкны тир түгеп, эшләп тапканнар... Ул үз гомерендә авызына бернинди эчемлек алмаган, тәмәкене өенә дә кертмәгән (һәм балаларын бу нәрсәдән катгый рәвештә тыйган), ризыкның кадерен белгән — валчыгын да исраф итмәгән, янә шулай ук чиста киенергә, чиста йөрергә тырышкан. (Корымга, тузанга буялып эшләүче өчен бусы, бәлки, аеруча кирәк булгандыр.)

Шуның белән бергә, бу диндар тимерче һич тә кара томана кеше түгел иде. Ул үткен акыллы, гаделлек яклы, сүзгә оста, бәхәсләшергә дә яратучы тынгысыз бер адәм булган. Аш мәҗлесләрендә карт хәзрәтне еш кына төрле сораулар биреп аптыраткан, бәхәсләшеп тә китә торган булган — үзенчә ислам шәригатен һаман ярлылар файдасына борырга тырыша икән. Шулай сөйлиләр иде аның турында. Эш хәтта ки шуңа барып җиткән, безнең хәзрәт аның белән бер мәҗлестә утырудан баш тарта башлаган.

Билгеле, Миңнегали агай үз балаларына да бик таләпчән булган, әмма бер вакытта да аларның ирекен бумаган. (Мәсәлән, берсен дә көчләп мәчеткә кумаган.) Карт алар өчен авторитет иде, бер сүзсез аңа буйсыналар иде. Уллары эшкә ярый башлагач та аталары белән бергә алачыкта тимер суктылар. Кызлары барысы да укыдылар, бер-берсен карадылар, үстерештеләр. (Сигез бала бит!)

Ишле баланың төрлесе була, арадан берәрсе бозылып-нитеп тә китә, ата-анасына хәсрәт тә китерә, ләкин боларның берсе дә бозык юлга кереп китмәде, берсенең дә яман аты чыкмады. Киресенчә, әдәп һәм әхлак ягыннан алар барысы да яхшы исәптәләр иде, шулай ук кыяфәтләре белән дә бер-берсенә бик охшаганнар иде; һәммәсе дә төскә

чибәр, төз буйлы, кара бөдрә чәчләр... Бәлки көнчелектәндер инде, кайчагында аларны «кара Миңнегали малайлары» диеп тә әйтәләр иде. Аталарына берсүзсез буйсынып торсалар да, алар шактый хөр үстеләр. Иң өлкәне Габдулла абзый 1917—18 елларда ук сәхнәдә уйный башлады, соңыннан аны Уфа театрына да чакырган булганнар. Миңа калса, ул чын артист булырга тиешле кеше иде, ләкин нишләптер Дәүләкәннән ычкына алмады... Кечерәкләреннән Зөфәр дә бер заман сәхнә һәвәскәре булып китте — шәп дикломатор һәм оста гына гармунчы да иде ул. Маһирә исә бик матур җырлый иде. Ике киленнәре— Галия апа белән Зөләйха апа да Дәүләкән сәхнәсендә күп уйнадылар. Һәм болар барысы да бер гаиләдән — Миңнегали карт өеннән!

Аннары килеп, Зөфәр Дәүләкәннең иң беренче комсомолы иде. Әйтүенә караганда, ачлык елдан соң ике егет — ул һәм тегермәндә эшләүче Әфтәх — татарлардан беренче булып комсомолга кергәннәр. (Әфтәх турында алда сүз булачак әле.)

Миңнегали агайның Габдулладан кала икенче улы Муллагали — кечеләре аны «бәләкәй абый» дип йөртәләр иде. Үтә тыйнак, йомшак, әдәпле бер егет иде ул... Үтә тыйнаклар күзгә бик ташланмыйлар бит, шуңадыр мин аның егет чагын бик аз беләм. Әмма шушы егет, бердән, Дәүләкәннең иң чибәр кызы Зөләйха апаны качырып ала, икенчедән, Ватан сугышы вакытында, ягъни иң авыр елларда Аюхан авылында колхоз председателе булып тора. Ул елларның газабын хәзер дә сөйләп бетерә алмый Муллагали карт!

Миңнегали бабайның миннән яшьрәк тагын бер кызы һәм бер улы турында әйтәсем килә: болар Рәхилә белән Әхтәм... Дәүләкәннән иртә киткәнгә күрә мин аларның бала чагын, ничек үсүләрен аз хәтерлим. Рәхиләне туташ булып җиткәч белә башладым, һәм яшерәсем килми, ул мине үзенә каратып та өлгергән иде. Рәхилә араларыннан иң матуры иде — күзләре сөрмәле, озын керфекле, кашлары нечкә, иреннәре алсу, ә коңгырт чәчләре күпереп, дулкынланып тора иде. Бәлки шушы матурлыгы аркасындадыр, ул шактый ук тәкәббер дә иде. Һәрхәлдә миңа игътибарын юнәлдермәде. Нишлисең, кызлар мәсьәләсендә минем бәхетем шулайрак булды инде: мин игътибар иткәннәр миңа карамадылар, мине җәлеп итмәгәннәр минем белән кызыксындылар. Ярый, хәерле булсын, бу мәсьәләне хәзергә калдырып торыйк. Миңнегали картның барлык сәләтле, зиһенле, уңган балалары арасыннан шушы Рәхиләсе бик югары күтәрелде. Калганнары, ни сәбәптер, Дәүләкән масштабыннан чыга алмадылар. Ә менә Рәхилә партия эшенә кереп китә. Башта ул Уфаның партия мәктәбен тәмамлый һәм КПССның Башкортстан өлкә комитетында эшли. Күпмедер эшләгәннән соң, аны Мәскәүдәге Югары партия мәктәбенә укырга җибәрәләр. Бу мәктәпне тәмамлагач, ул Казахстанга билгеләнә. Монда инде Дәүләкән кызының чын партия җитәкчесе булып үсүе һәм күтәрелүе башлана: партиянең Казахстан Үзәк Комитетында бүлек мөдире урынбасары, партиянең Көнбатыш Казахстан өлкә комитеты секретаре, Көньяк Казахстан крае башкарма комитетының председатель урынбасары, партиянең Чимкент өлкә комитеты секретаре — кыскасы, егерме ел буена диярлек ул әнә шундый зур һәм җаваплы эшләрдә. Шул вакыт эчендә аңа Л. И. Брежнев кул астында да эшләргә туры килә.

Сугыштан соң, илленче ел урталарында, мин Рәхиләне Уфада очраттым, аннары Дәүләкәндә дә бер үк вакытта булдык. Әйе, бу инде үз-үзенә нык ышанган, үзен кирәгенчә гади, әмма бәйсез тота белгән чибәр, тулы гына бер ханым иде. Уфада бер мәҗлестә дә булдык. Дәүләкәнгә кайткач, Дим буйлап көймә белән Көрмәнкәйгә дә бардык, ләкин яшьтән үк күрше булып үскән Рәхилә белән минем арада кешеләрчә гади, җылы мөнәсәбәт туа алмады. Нилдидер бер сынаумы, әллә сагаюмы, яшерен күзәтүче шикелле, безне рәсмирәк булырга, ди-

станция сакларга мәҗбүр итә иде. (Мин моны аеруча үземә карата сиздем.)

Әмма, ни кызганыч, Рәхилә барлык туганнары арасында иң гомерсезе булды (55 яшендә үлеп китте). Апасы Маһирә әйтә, эштә янып бетте ул, ди. Рәхилә үләреннән берничә ел элек кенә Хәбибрахман санаториендә ял иткән. Алар бик дуслашып киткәннәр, Рәхилә Хәбибрахманны врач итеп тә, кеше итеп тә бик яраткан булса кирәк. Хәзер сөйләшкәндә Маһирә дә моны раслый, Хәбибрахман аңа бик кулай кеше иде, ди.

Гаҗәп хәл, тулы бәхет бераүгә дә насыйп түгел, күрәсең. Рәхилә Дәүләкәндә чакта ук әле Солтанов дигән район прокурорына кияүгә чыккан булган. Ләкин сугыштан соң алар аерылышканнар. Рәхилә башка инде иргә чыкмаган, ялгызы ике бала үстергән... Барысы да бар лабаса — зур урын, дәрәҗә, материаль бөтенлек, тик менә шәхси бәхет чамалы да гомер генә кыска... Эх, бу тормыш!

Рәхиләдән кечеләре — Әхтәм. Ифрат тыйнак, юаш, тырыш бу сөйкемле-сабыр егет бөтен гомерен Дәүләкәндәге кирпеч заводында бухгалтер булып эшләп уздырды. Шул кирпеч заводыннан пенсиягә дә чыкты. Аның Уфа блән Бәләбәйдән башка җирне күргәне дә булмады шикелле.

Дәүләкәнгә кайтып йөри башлагач, мин Әхтәмнең бер кабилиятен (дөресрәге, талантын) күреп, исем китте. Ул художник булыр өчен туган икән ләбаса! Иң элек аның кулы агач эшенә гаять оста икән. Менә дигән резчик ул. Төрле-төрле нечкә-нәфис сырлар, бизәкләр салып, бик пөхтә итеп, тәмам җиренә җиткереп эшләгән буфетын яки шкафын мебель магазинына илт тә куй — шунда ук бәреп алачаклар. Бусы бер. Икенчедән, ул рәссам, ягъни буяу белән картиналар да яза. Стенага элгән кайбер эшләре миңа ошаган иде, ләкин мин аларга бәя биреп тормыйм. Ихтимал, профессиональ күзлектән караганда, аның картиналары гади бер һәвәскәр эше генә булып күренер. Ләкин бит Әхтәм бернинди махсус белем алмыйча, беркемнән дә өйрәнмичә, бары ходай бирмеш күзе һәм кулы белән эшләгән ич барысын да!.. Әгәр укытканда, өйрәткәндә, чын рәссам чыкмас идемени?!.

Әхтәмнең эшләрен күргәч, аның үзенә дә, туганнарына да ирексездән ачуым килде. Абыйлары-апалары нигә күрмәгәннәр энеләрендәге бу сирәк талант чаткысын, ник аңа дөрес киңәш бирә белмәгәннәр, ярдәм итмәгәннәр дип уйладым ачынып... Хәтта минем, соң булса да, нидер эшлисем, ниндидер чара да күрәсем килеп киткән иде. Әмма бик йорт җанлы, гаилә җанлы, аздан да канәгать Әхтәмдә мин дәрт тә, теләк тә сизмәдем. «Нишлисең инде, соң бит, Әмирхан абый!» — диде ул миңа сүлпән генә уфтанып. Ләкин хикмәт монда кадерле вакытның үтеп китүендә генә түгел, ә бәлки ваемсызлыкта, әһәмият бирмәүдә, кодрәт җитмәүдә иде. Әйе, талант өстенә характер да кирәк шул! Хәтта бик зур талантларга да!.. Хәлбуки, кайчагында таланты чамалы гына кеше дә, характеры булса, шактый ерак китә ала.

Хуш, булмаса, яр башындагы өебезгә кайтыйк әле — минем бәләкәй чагыма. Күршебез Миңнегали агайның ишле балалары арасыннан миңа иң якын торганнары Зөфәр белән Маһирә иде. Дөрес, алар икесе дә миннән олырак — Зөфәр алты яшькә, Маһирә ике яшькә. Ләкин шуңа карамастан, мин аларга бик ияләштем, алар янында үстем, егет чагым алар белән бергә үтте һәм икесе дә минем бертугандай якын кешеләрем булып калдылар. Шушы көнгә кадәр!.. Моның төп бер сәбәбе менә нидән гыйбарәт: минем атакай сәүдә эшләре белән читкә киткән чакларда инәй күршедән төн кунарга Зөфәр белән Маһирәне чакыра торган булган (билгеле, әти-әнисеннән сорап). Бу инде берен-

че герман сугышы башланып, дөньяның тынычлыгы китеп торган вакыт, ә без, ике малай бик кечкенәбез әле, билгеле, инәй ялгызы гына кунарга курыккан. 12 яшьлек малай белән 8 яшьлек кызчык — бу бит үзенә күрә бер терәк, өйдә һич югы җан иясе арту дигән сүз. Аларның безгә куна керүен бигрәк тә мин көтеп ала идем, чөнки алар кергәч өебез бөтенләй җанланып китә, бергә утырып чәй эчү дә күңеллерәк була, аннары минем өчен иң тансыгы — алар белән бергә, бер урында ятып йоклау иде. Алар бит мине гел генә урталарына алып яталар... Әнә шулай бала чактан ук туа безнең арада якынлык!

Ләкин еллар уза, без дә туктап тормыйча һаман үсәбез — алар алданрак, мин алар артыннан. Шулай үсә торгач берзаман Зөфәр — егет, Маһирә туташ булган, мин дә малайлыктан чыгып, егет булып киләм, имеш! Һәм шушы чорга кергәч, безнең арадагы яшь аермасы ничектер сизелми дә башлады, һәрхәлдә, без күпмедер дәрәҗәдә тигезләштек. Шуны да әйтергә кирәк, мин яшемә караганда күп кенә яктан шактый иртә өлгердем. Егет чакта дусларымның күбесе яшькә миннән олыраклар иде.

1925 ел белән 30 нчы еллар арасы — минем һәр җәйне Казаннан Дәүләкәнгә кайтып йөргән чагым. Менә шушы вакытта без Зөфәр белән егетләр буларак бик дуслашып киттек. Кем әйтмешли, без һаман бергә, һаман бергә! Бу биш-алты ел вакыт Дәүләкән яшьләренең иң оешкан, иң актив чагы иде. Җомга көн саен диярлек көймәләргә утырышып, Дим өстен җыр-гармун тавышлары белән яңгыратып йөрүләр, уникешәр атка төялеп, азыклар алып, арбага казаннар салып «Ачлыкүл» буена сахрага чыгулар, әзерләгән концерт-спектакльләребез белән татар һәм башкорт авылларына «гастрольгә» барулар — болар барысы да әнә шул вакыт эчендә булып калды. Зөфәр дә, Маһирә дә бу эшләргә иң якыннан катнашучы, җан өрүче, беренче башлап йөрүчеләрдән иде. Гомумән, ул чакта Дәүләкәндә яшьләр күп иде әле, китеп, таралып бетәргә өлгермәгәннәр иде. Әмма һәркемнең шул күп яшьләрдән аеруча якыны, күңелгә ошаганы, үзенә тартып торганы була. Зөфәр минем өчен әнә шундый иң якын, сирәк дусларның берсе иде. Ул яше белән дә, акылы белән дә күпләрдән өстен иде, ахрысы шуңадыр, мин химая эзләгәндәй гел аңа тартыла идем. (Ә химая миңа бик кирәк була башлаган иде инде.) Шуның белән бергә Зөфәр ачык, шат күңелле, туры сүзле һәм өстәвенә көяз бер егет тә иде. Көне буе атасы янында тимер чүкегәннән соң, ул бик әйбәтләп юынып, кара чалбар, ап-ак күлмәк киеп, кулына дирижер таягыдай нечкә генә чыбык тотып, кичкырын йөрергә чыга торган иде. Һәм без дә, читтән кайткан берничә егет, шулай ук киенеп-көязләнеп кичке йөрүгә чыга идек. Бергә очрашып, исәнләшеп, көлешеп алганнан соң, урам уртасыннан «күрәсезме безне» дигәндәй ашыкмыйча эре генә атлап китә идек. Иң элек вокзалга барып, берәр пассажир поездын үткәреп җибәрәбез — бу тамашага русы, татары шактый яшьләр җыела торган иде. Без яшь чакта поездларның килеп-китүе кызыклы гына бер тамаша иде. Иң тәү күрше разъезддан поезд чыкканын белдереп, кызыл фуражкалы дежурный вокзал ишеге янында асылынып торган җиз колоколны дәртле генә яңгыратып кага. Шуннан соң вокзал тирәсендә хәрәкәт көчәя, билет кассасы янында кысыш-сытылыш башлана. Бер 15—20 минут үтүгә семафор ягыннан күкрәгеп киереп килгән гайрәтле кара паровоз күренә — ул һәрвакытта поездны беренче юлга шап кенә китереп туктата. Вокзал бинасы алдыннан үтешли машинист белән дежурный сузылып кына жезлларын алмашалар Уртадагы вагоннарның берсеннән зур кокардалы фуражка, бөрмәле кыска кафтан кигән, иңбашына күн букча аскан, муенына шнурлы сыбызгы әлгән көрәк сакаллы баш кондуктор, поезд туктар-туктамас, егетләрчә генә сикереп төшеп кала һәм, халыкны ерып, вокзал бинасына эре генә кереп китә... Перронда ыгы-

зыгы башлана, бераүләр төшә, бераүләр менә, күп кенә пассажирлар калай чәйнекләрен шалтыратып, кипәтүккә йөгерәләр. Йомшак урынлы вагоннарның ачык тәрәзәләреннән тузган чәчле чибәр ханымнар, муекларын тәкә мөгезедәй бөтереп җибәргән ирләр тыштагы тамашага көлеп кенә карап торалар.

Скорый поезд гадәттә озак тормый иде... Бер биш минуттан дежурный чыгып колоколны ике тапкыр сугып ала, бераз гына көттереп, өч тапкыр суга, шуның артыннан ук сакаллы кондуктор сыбызгысын чырылдатып җибәрә, һәм очтагы паровоз, калын гына итеп кычкырта да, азрак гайрәтләнеп пошкырганнан соң, әкрен генә кузгалып китә. Вагоннар шома гына тәгәри, ачык тәрәзәләрдәге адәм башлары отыры кызурак уза башлыйлар. Состав, ниһаять, узып китә, тик әнә иң арттагы вагоннан яшел флагын сузган проводник кына бераз әле күренеп бара...

...Поезд китә, ничектер хыялны кузгатып, ияртеп китә, аңардан соң ямансурак та булып кала. Халык тарала, перрон бик тиз бушый, һәм без дә вокзал урамыннан ашыкмыйча гына Димгә таба атлыйбыз. Яр башына җиткәч туктыйбыз да кичке шәфәкъның алсу нурына манылып тын гына агып яткан Дим өстенә, аның Көрмәнкәй тавына чаклы җәйрәп яткан, инде аргы читләренә әңгер караңгылыгы иңә башлаган тип-тигез тугаена, андагы куе әрәмәлекләр, таллыклар уртасыннан тонык кына елтырап күренгән ерымнарга, күлләргә сүзсез генә карап торабыз. Һәр кичне диярлек без бу үтә таныш манзарага яр башыннан менә шулай карап тормыйча китмибез. Иллә мәгәр туйганыбыз юк, һәм бер кайчан туймабыз да шикелле... Комач ягыннан бакалар җыры ишетелә башлый, каяндыр Дим үреннән су үгезенең кичке тынлыкта «бум-бум» дип кычкырган калын тавышы ишетелеп куя... Тагын ашыкмыйча гына урам буйлап китәбез. Вакыт соң инде, ә көн һаман да сүнеп бетмичә тора, ләкин урам әкренләп кенә тына. Йөреп аргач, безнең капка төбендәге эскәмиягә килеп утырабыз. Сүз күп, сүз бетәрлек түгел,ниләр генә сөйләшми идек без, кайчагында таралыша алмыйча беренче әтәчләргә чаклы да утыра идек. Бу безнең зур хыяллар, зур өметләр белән янып яшәгән чагыбыз иде.

Әй еллар уза, нинди кадерле еллар уза, тик без аңа игътибар гына итмәгән булабыз. Шул арада заман безнең язмышларны үзенчәрәк, без көтмәгәнчәрәк хәл дә итеп куя һәм тормыш юлларыбызны да төрле якка аерып җибәрә. Бик озакка аера ул безне. Зөфәр, татар җанлы егетебез, көтмәгәндә генә бер чибәр рус кызына өйләнә, Дәүләкәннән китә, Башкортстанның төрле районнарында почта начальнигы булып эшли, соңгы гомерен Бәләбәйдә яшәп уздыра. Мин аны бер 35 ел чамасы күрмичә тордым. Алтмышынчы-җитмешенче елларда, Дәүләкәнгә кайтышлый, бары аны күрер өчен генә ике тапкыр Бәләбәйдә тукталдым. Без икебез дә бик үзгәргән идек, әмма бала чактан ук күңелләргә сеңеп калган якынлыкны бер дә югалтмаганбыз икән. Алтмыш яшемне бәйрәм иткәндә мин, телеграмма биреп, аны Дәүләкәнгә чакырдым. Килде, куандырды, бергәләп үзебез укыган мәктәпкә бардык (ул чагында татар мәктәбе эшли иде әле), малай чакта чана шуган тауны да барып карадык, боз өстенә дә төшеп йөрдек. Бу сөйләшеп йөрүләр вакытында Зөфәр миңа күп кенә нәрсәләрне искә төшерергә ярдәм дә итте.

Әйе, еллар уза, дусларны, туганнарны алып китә-китә уза!.. Картларыбыз күптән инде бу дөньяда юк, Габдулла абый да, Рәхилә дә, Зөфәр дә юк, мин дә бер үзем генә калдым. Шулай да исәннәребез арасында бәйләнешләр өзелмичә һаман да дәвам итә. Дәүләкәнгә кайткан саен мин 81 яшьлек Муллагали абзый янына керәм, Әхмәт белән очрашам, ә Маһирә белән ел саен диярлек очрашып торабыз. Бала-

лыктан картлыкка килеп җиткән бу бәйләнешләргә инде 70 ел тулып узды.

Хуш, сүз нәрсәдән башланып киткән иде?.. Чәйни йортыннан яр башындагы йортка күчүебез һәм шундагы беренче күршебез тимерче Миңнегали агай турында сөйли башлаган идем дә, күбрәк сөйләп ташладым бугай, ләкин зарар юк, шушы гомергә чаклы онытылмаган күршелек моңа лаектыр дип беләм. Чөнки иске мәгънәдәге күршелек, ягъни якыннан аралашып, хәл-әхвәл сорашып, йомышка йөрешеп, кирәк чакта ярдәмләшеп яшәүче күршеләр хәзерге заманда, бигрәк тә шәһәр шартларында, бетеп бара диярлек. Халык унар катлы, йөзәр квартиралы йортларга кереп тулды, бер җиргә тупланды, үзара якынайды да кебек, әмма шул ук вакытта бер ишектән кереп, бер баскычтан менеп йөрүчеләр дә бер-берсен юньләп белмиләр... Күршелек нәрсә ул хәзер? Очрашканда исәнләшеп узу да бик сирәк кенә йомыш төшеп керү (мәсәлән, телефонга) — бары шул гына!

Ярый, тагын ерактагы үткәнгә кайтыйк әле булмаса. Яр башындагы Дим буйлары күренеп, бакалар җыры ишетелеп торган балконлы һәм бик күңелле йорттан без ни өчендер икенче йортка күчкәнбез. Ахрысы, хәвефсезрәк урын эзләптер, чөнки яр башындагы йортка бер-ике тапкыр караклар керә язган иде.) Бусы инде Дәүләкәннең төп урамында, түбән очка табарак шактый чибәр зур гына йорт иде. Миңа 6—7 яшьләр чамасы, хәтер-зиһен ачыла барган чак, шулай да бу йорт турында исемдә калганнар күп түгел. Иң әлек шуны хәтерлим, аның ишегалды бик бәләкәй иде, иркенләп йөгереп-чабып уйнарлык түгел иде. Аннары аның коймалары да бик биек иде, биек койма артында бер генә катлы таш тегермән эшли иде (аны Зайцев тегермәне диләр иде), шуннан көнозын диярлек кешеләр шаулаган, атлар пошкырган тавышлар ишетелеп тора иде.

Бу йорт белән бәйләнгән янә ике вакыйга хәтердә саклана. Берсе — нәмаеш дигән нәрсә, ягъни хәзергечә әйтсәк, демонстрация була. Карлар эри башлаган кояшлы көнне мин Дәүләкән мөселманнарының яшел һәм кызыл байраклар күтәреп, урам буйлап безнең турыдан узганнарын исем китеп карап калган идем. Моңарчы һич күренмәгән гаҗәеп бер тамаша иде бу. Патша төшерелгән көн булган икән ул!.. «Нәмаеш» дигән сүзне дә беренче мәртәбә шул чакта ишеттем.

Икенчесе — шул ук унҗиденче елның мартында Срур тутакай белән Шәриф җизни һәм Сәгыйть абый Уфадан безгә кунакка килгәннәр иде. Бу хакта мин «Дәүләкән» өлешендә язып узган идем инде. Шулай да кабатлап әйтәсем килә, алар килгәч, бездә үткәрелгән зур мәҗлес, шул мәҗлестә җизни белән Сәгыйть абыйның скрипка һәм гармунда өздереп уйнаулары, мөхтәрәм кунакларның буе-сыны, өсте-башы бик чибәр, бик көяз бу шәһәр егетләренә исләре китеп, сокланып, елмаешып карап утырулары — менә шулар барсы да ниндидер бер якты бәйрәм иртәседәй күңелдә гомерлеккә сакланып калды.

Яңа урында яңа күршеләр — әкренләп алар белән дә танышырга туры килде. Уң ягыбыздагы кечерәк кенә йортта Зариф исемле бер тегүче абзый тора иде — мин менә шуларга кергәли идем. Чөнки тегүченең минем чамадагы Гариф исемле малае бар иде, керүем, билгеле, шуның белән уйнар өчен булгандыр инде. Тик ни гаҗәп, безнең икәү бергә уйнап йөрүебез юньләп хәтердә калмаган, ә менә кергән саен бер үк тамашаны күрүем бик нык истә сакланган. Бу шактый кызыклы тамаша иде: Зариф абзый — каны качкан ак чырайлы, кара мыеклы, үтә арык кеше — гел генә я бөкерәеп аяк машинасында текер-текер нидер тегә, я идәндә бер аягын чәнчеп тезләнгән килеш зур кайчысы белән кием кисә. Буш чагын белмим, сөйләшкәнен, күтәрелеп карага去ын да хәтерләмим — эше күп булгандыр, ахрысы. Ләкин ул бик авы-

ру иде бугай, муены неп-нечкә, калак сөякләре беленеп тора иде. Ә хатыны, киресенчә, тулы-таза иде, бите дә тулы-түгәрәк иде, зур соры күзле, сөйкемле хатын иде, ләкин өйдә берни дә эшләми иде шикелле. Ничә кермә, бу абыстай идәндәге ак киез өстенә юан аякларын сузып утырган, янына улы Гарифны да шулай әйбәтләп утырткан булыр. Урталарында зур калай тәлинкә белән әстерхан чикләвеге, сары күрәгә, кара йөзем. Абыстай менә шул эре чикләвекне бөкләп салган тастымал өстендә ике кадаклы гернең чокыры белән бәреп вата да, төшен чүпләп күрәгә һәм йөзем белән кушып, кыстый-кыстый малаена ашата... Көн саен диярлек болай сыйланып утыруны минем берәүдә дә күргәнем юк иде әле. Чикләвек белән җимеш безгә дә бик сирәк кенә эләгә торган иде. Күрәсең, Зариф абзый акчаны яхшы төшергәндер инде. Әмма моның ахыры ни булып бетте — анысын алдарак күрербез.

Бездән бер йорт аша зур урамны аркылы кисеп, тыкрыктай тар гына урам үтә. Бер башы аның базар мәйданына, икенче башы Дим ярына барып чыга. Дәүләкән урамнарына кайчан исем бирелеп, чаттагы йортларга тар калай сукканнардыр, әмма бу урам мин малай чакта ук Тукай урамы дип атала иде. Менә шушы Тукай урамының Димгә табарак очындагы бер йортка мин еш кына барып йөри идем. Коймадан әчкәрәк бүрәнәдән алты почмаклы итеп салынган кечкенә өч тәрәзәле, тәбәнәк кенә йорт, урамнан такта түбәсе дә ике морҗасы гына күренеп тора, ләкин әнә шундый авылча гади генә булуына карамастан, бу йортның капка-коймалары, каралты-куралары бик таза эшләнгән иде. Амбары тимер белән япкан, ат-сыер абзарлары тоташтан такта түбәле, мунчасы да бәләкәй генә өй кебек ак мунча иде.

Бу — итче Гали абзый йорты. Тук йорт, һәрвакыт итле бәлеш исе килеп торган йорт. Гали абзыйның минем белән бер яшьтәге Мәхмүт исемле һәм энем белән бер чамадагы Миңнеәхмәт исемле ике улы бар иде. Шулай ук нәфис ак чырайлы, нечкә, зифа сынлы, буй җитеп килгән Гайникамал исемле кызы да бар иде .

Гали абзый белән минем атакай күптән таныш һәм эшнә дә булганнардыр ахрысы, чөнки бер заман без алар белән якыннан аралашып, йөрешеп яшәдек. Аңа инде күп еллар узды, мөнәсәбәтләр дә бик күптән өзелде, әмма ләкин барыбер бу күптән таралып, югалып беткән гаиләне бер вакытта да онытып бетерә алмадым. Тирән кереп калган алар минем күңелгә...

...Мәхмүт белән без бик дуслашып киткән идек. Кече малай чактан алып, үсмер егет булганчыга кадәр гел бергә йөрдек, бер-беребезгә бик ияләштек, үсмер чакта гына була торган самими күңел якынлыгы безне бәйләгән иде, шуңа күрә безнең серләребез дә гел бергә, уртак булды. Малай буларак, мин беренче мәртәбә Мәхмүт белән сугыштым. Икебез дә җирдә аунадык, икебез дә гарьлегебездән җыладык — әнә шулай сугышудан башланган дуслык кайчагында бик көчәеп китә икән ул!..

Мәхмүт буйга миннән кайтышрак, бик аз гына шадрасы да бар, ләкин күзләре зур, керфекләре озын иде. Сөйкемле, матур малай иде. Уналты яшебездә без икәү янәшә утырып, иң беренче мәртәбә фоторәсемгә төштек. Ике ахирәт-дус, әмма һич тә бер-беребезгә охшамаганбыз. Мәхмүтнең йөзендә уй бар, нindидер сагыш та бар кебек, ә минем чырайда бер нәрсә дә юк — тырпаеп торган зур колаклар да тар гына күзләр... Бик кадерле бу фоторәсем минем өчен!

Мәхмүт, чынлап та, яшьтән үк уйчан-моңлы малай булып үсте. Нindидер бер тирән яткан хәсрәт, язмышыннан канәгатьсезлек, бетми-үтми торган төшенкелек аңа гүя тумыштан ук бирелгән иде. Еш кына ул кайгылы җырлар җырлый иде. Ашыкмыйча әкрен генә моңлы итеп җырлый иде:

Әнкәй мине тапкачтын да
Ак биләүгә биләгән,
Ак биләүләргә биләгән,
Бәхте булсын димәгән...

Бу зарлы-моңлы җырның сәбәбе дә билгеле иде — алар бик иртә әниләрен югалттылар... Әниләре Мөгълифә җиңги бик юка, бик арык хатын иде. Бөтен хәлсез кыяфәтеннән аның күптән инде авыру икәнлеге күренеп тора иде. Ахырда балаларын бик иртә ятим калдырып, чахоткадан үлеп тә китте. Бу вакытта Мәхмүткә ун яшьләр булгандыр — адәм баласының зур хәсрәтне иң авыр кичерә торган чагы. Күпне аңлый, күпне тоя, әмма акылы, әмма бәгыре бер дә ныгып җитмәгән әле.

Ә аталары Гали абзый — үгездәй таза, кызыл чырайлы кеше — балаларына һәр вакытта каты бәгырьле, каты куллы булды. Дөрес, ул аларны ашау-эчү, кием-салым җәһәтеннән бер вакытта да кысмады — мул ашатты, әйбәт киендерде. (Итчеләр, гомумән, таза ашап яшиләр иде.) Әмма инде үз ихтыярына буйсындыруга килгәндә, аның сүзе-хөкеме һәрвакытта бик коры-каты булды. Балалары каршы әйтү түгел, аңа күтәрелеп карарга да куркалар иде. Өстәл әйләнәсендә җыйнаулашып ашарга утыргач, табында беркем бер нәрсә сөйләми, авыз шапылдатудан башка тавыш та юк, инде малайларның берәрсе ни өчендер шыңшый башласа, аталары аңа күзенең агы белән бер генә карап куя — малай, җаны табанына киткәндәй, шунда ук тып-тын була. Шулай сөйли торган иде Мәхмүт атасы турында.

Гали абзый җәмәгатен җирләгәч озак та тормыйча үз авылыннан Мәликә исемле яшь, чибәр, таза хатын алып кайтты. Балалар өчен ятимлеккә үгилек тә өстәлде. Мәликә апаның ул балаларга мөнәсәбәте бәлки начар да булмагандыр, карагандыр да, әмма сынык күңелле балалар өчен ул инде барыбер үги ана иде. Мәхмүттәге төшенкелек, моңаюның да бер сәбәбе атасының бик яшь, чибәр хатынга өйләнүе булды түгелме икән!? Күзе ачылган ир бала мондый хәлне бик авыр кичерә торгандыр ахрысы.

1918 елның кара көзендә, ягъни гражданнар сугышы иң көчәйгән бер чакта, бер-ике гаилә — вакытлыча Уфага күчеп тордык. Күрәсең, безнең атайлар зур калада җан саклавы җиңелрәк, хәвефсезрәк булыр дип уйлаганнардыр инде. 1919 елны кызыллар Уфаны алгач та без кире Дәүләкәнгә үз йортыбызга кайттык. Ә Гали абзый ни өчендер ашыкмады, калып торды. Ачлык елны да уздырып, дөньялар рәтләнгәч, ялгышмасам, 23 нче елны гына ул үзенең йортына кайтып керде. Бу вакытта инде Гайникамал апа буй җиткән зифа кыз иде. Аның Уфада яратып йөргән егете дә булган икән, озак та үтми, шушы Сәхип исемле егет Гайникамал артыннан Дәүләкәнгә килеп чыкты. Шул чакта мин аны күргән дә идем. Түгәрәк йөзле, күксел зур күзле, кечкенә колаклы, үзенә күрә чибәр генә егет иде ул. Ләкин Гали абзый ни өчендер бу егетнең исемен дә ишетергә теләми, өнә дә аяк бастырмый. Гайникамал апаны да очрашудан катгый рәвештә тыя. Ахрысы, шактый күпне күреп өлгергән иркә кала егетен мужик табигатьле итче абзыйның күңеле кабул итә алмагандыр инде. Хәтеремдә, кышкы салкын көннәр, Сәхип егет айлы зәңгәрсу кичләрдә Дәүләкән урамында Гайникамал апаны сагалап, шыгыр-шыгыр атлап йөри — максаты аның кызны ничек тә качырып алып китү булган икән. Кемнеңдер ярдәме белән, алар шулай да, кайдадыр аулакта очрашалар, сөйләшәләр, качу турында сүз дә куешалар. Ләкин егет бер ахмаклык эшли: ат яллап, кызны качырып алып киткән төнне ул бер уңайдан Гали абзыйның капкасын да дегеткә буяп китә. Бу инде бик зур хурлык, тискәре

атаны гына түгел, сөйгән кызын да ил-күз алдында мәсхәрә итү — моны ул, Сәхип, ахмак булмаса, әлбәттә, белергә тиеш иде. Гали абзый кызның качканын сизгәч тә, иртә таңнан атын җигеп, артларыннан куа чыга. Ләкин, тегеләрнең бәхетеннән диеп әйтик инде, ул ялгыш юлдан китә һәм таба алмыйча караңгы төшкәндә генә кире борылып кайта. Әгәр ул артларыннан җитә алса, кала егетен «эһ» тә димичә күсәк белән сугып үтергән булыр иде. Көч-гайрәтне ходай аңа биргән инде, ә ачу-ярсуы, билгеле, ташып чыккан булырга тиеш. Кайткач, шушы дәү-таза кеше капкасына буялган дегетне җылый-җылый кырган, имеш — күргән кешеләр шулай сөйләгәннәр иде. Бәгырь дигәнең берәүдә дә таш түгел...

Кыска гына гомерле НЭП вакытында Гали абзый Дәүләкән базарында әүвәлгечә ит белән сату итте. Аның йонлач бәкәлле, озын кара яллы йомры гына туры аты бар иде, шуны җигеп ул авыллар арасына чыгып китә иде дә, тимер ходлы арбасына бер-ике сарык салып, я булмаса, тәртәсенә берәр печкән үгез яки тана бәйләп, алып кайта иде. Базар мәйданында ит рәте Кәримовлар бакчасы буенда иде, Гали абзыйның да шул рәттә, такта кыек астында, өстәле белән юан бүкәне тора иде. Алып кайткан терлеген суеп, шунда чыгара, күбрәк үзе сата, ләкин еш кына Мәхмүтне дә сатуга куя иде. Әйтергә кирәк, Мәхмүт бу эшкә, ягъни түшкәне белеп чабарга һәм дөрес үлчәргә шактый ук өйрәнеп өлгергән иде.

Ләкин, мәгълүм булганча, ирекле сәүдә озакка бармады. Егерменче елның урталарыннан инде сәүдәгәр малайлары таралыша да башлады. Язмышыннан аеруча канәгатьсез дустым Мәхмүт тә башын алып кая да булса чыгып китү турында еш кына хыяллана торган иде. Әмма аңа атасының каты кулыннан ычкынуы җиңел түгел иде. Мин менә атам-анамның ризалыгы белән җиңел генә киттем дә бардым, ә ул киндер алъяпкычын бәйләгән килеш ит рәтендә торып калган иде әле... Ләкин озакка бармаган аның да бу күңелсез һәм өметсез эшкә бәйләнеп торуы — ничектер кыюлыгы җитеп, бөтенесен ташлап, ниһаять, ул да атасы йортыннан чыгып киткән. Мин икенче җәйне Казаннан кайткан чакта Мәхмүт Дәүләкәндә юк иде инде.

...Тагын берничә тынгысыз ел үтә, сәүдә эшләре әкренләп сүнә, аннары бөтенләй бетерелә, шуннан соң Гали абзый үзе дә яшь хатынын һәм аңардан туган ике кызын алып, яңадан Уфага күчә. Кайткан чакларымда мин һәр даим Гали абзый йорты яныннан әкрен генә карапып узам. Ләкин кайчандыр, моннан бик күп еллар элек миңа бик таныш йортның танырлык бер җире дә калмаган — бөтенесе башка, йорт үзе дә, капка-коймасы да, торган кешесе дә... Кем ул — белмәдем, сорашып та тормадым.

Мәхмүт белән без үсмер чакта никадәр дус-сердәш булып йөрсәк тә, Дәүләкәннән икебез ике якка чыгып китү белән безнең бәйләнешләр үзелде дә куйды. Очрашу да, хат язышу да булмады. Бары 1938 елны Оренбурга, якын туганнарыма кунакка баргач, мин Мәхмүтне шушы шәһәрдә очраткан идем. Кайда, кем булып эшләгәнен хәзер онытканмын инде, ләкин без берничә тапкыр күрештек, бергә ашапэчеп тә утырдык, үткәннәрне сагынып искә дә төшердек. Бу безнең соңгы очрашуыбыз булды... Шуннан... юлларыбыз бөтенләйгә аерылды. Әмма мин аны гомерем буе диярлек онытып бетермәдем, күңелнең ниндидер бер яшерен почмагында ул һаман да яшәде, хәтта сирәк кенә булса да төшләремә дә кергәли иде. Ихтимал, ул да мине онытып бетермәгәндер — күргән төшләрем, аның да мине исенә төшергән чакларына туры килгәндер?!

Мин аның хәрби хезмәт кешесе булып киткәнен ишеткәнем бар иде, шулай ук сугыштан соң Кишинев шәһәрендә төпләнеп калуын да ишеткән идем. Шунда гаиләсе белән утыз елдан артык яшәгән ул, әмма

бер генә тапкыр да Уфага яки Дәүләкән тирәсенә кайтмаган. Гаҗәп, Дәүләкәнне ташлап китүчеләр ни сәбәптер туган-үскән җирләренә кайтырга яратмыйлар. Югыйсә, без бит барыбыз да Дәүләкәнне бик ярата идек.

Мәхмүт моннан бер-ике ел элек кенә вафат булган. Уфага баргач, Гайникамал апа миңа аның соңгы рәсемен күрсәтте. Билдән генә зур итеп төшерелгән бу фоторәсемдә Мәхмүтнең йөзе-кыяфәте бик ачык чыккан. Хәрби киемдә, яланбаш, күкрәгендә орден-медаль колодкалары, погоннарына караганда, подполковник булган. Ләкин рәсемдәге Мәхмүтне тануы читен, җитмештән узган карт ул, йөзе-бите бик үзгәргән, тик менә чыгыбрак торган зур күзләре генә мин белгән Мәхмүтнеке. Һәм иң гаҗәбе — бу күзләрдә үсмер-ятим чагындагы моңсу уйчанлык һаман да сакланган икән... Сугышларны үтсә дә, подполковник булса да, сакланган... Менә шулай очраштык без... Я, нәрсә дип дәшим, дустым, мин сиңа?!.

Гайникамал апага мине 1981 елның җәендә Маһирә алып барды. Бер үк шәһәрдә, хәтта бер үк урамда күптән торсалар да, алар да яңарак табышканнар. Ә мин күрмәгәнгә күпме булыр? Гайникамал апа 1924 елның кышында Сәхипкә ияреп киткән иде. Ә хәзер җир шарында 1981 ел — күпме җилләр исеп, күпме сулар аккан шуннан соң! Нәкъ 57 ел икән — менә нинди ул очрашулар арасы!.. Ләкин мин Гайникамал апаны күрү белән таныдым. Җитмеш алты яшьлек карчык булса да, ул аз үзгәргән. Аннары әнисе Мөгълифә җиңгигә бик охшаган икән. Әнисенеке кебек озынча ак йөз, туры гына борын, нечкәрәк иреннәр — һәм җыерчык та басмаган үзен.

...Илле җиде елдан соң очрашкан кешеләр ни кичерә? Әлбәттә, гаҗәпләнү, сәерсенү, ышанып бетмичә һәм сүзне дә нидән башларга белмичә тору... Хәер, бу хәл озакка бармады, күпме генә еллар узмасын, без бик борыннан якын кешеләр — тиз кайттык без шул борынгы якын чакларыбызга. Билгеле, Гайникамал апа башта үз хәле турында сөйләде, аның Сәхибе күптән үлгән икән инде, атасы Гали абзый да үлгән, энесе Миңнеәхмәт тә Мәхмүткә чаклы ук үлгән булган. Кыскасы, берүзе генә калган, бер малай үстергән, анысы күптән өйләнгән, үзләренә башка торалар икән. Үзе менә шушында, озынча тар бүлмәдә, ялгызы гына яшәп ята, күпмедер пенсиясе бар, ара-тирә эшләштергәли дә икән (урамда лотошница булып, диде). Без килүгә үзенчә әзерләнгән, берничә төрле камыр ашлары пешергән, «сухой виносын» да өстәлгә чыгарып куйды. Сүзен булә-булә кыстый безне.

Әмма ул сөйләгәннәрдән минем өчен иң гыйбрәтлесе — Гали абзый турындагысы иде. Баштарак әйтергә онытканмын — Гали абзый эчә торган кеше иде бит... Малай чактан ук әле мин аның эчүдән гел кыпкызыл булып йөргәнен, еш кына безнең ишегалдына кызмача килеп кергәнен һәм кәефле-дорфа гына: «Кайда син, Каргалы төмәне!» — дип атакайга кычкырганын хәтерлим. Дөрес, ул заманда татарлар бал эчәләр иде, койган баллары мичкәсе белән җылы мич башында кымырҗып, әкрен генә шаулап утыра торган иде. Бал янында табак тулы пешкән ит, кыскасы, таза эчкәннәр, таза ашаганнар — бигрәк тә итчеләр. Ләкин Гали абзый, мәрхүм, эчүен соңгы гомеренә чаклы ташламаган. Базар капкасы төбендә утырып, көнбагыш сатып тапкан тиеннәрен дә аракыга тотып бетергән. Яшь хатыны Камилә апа аны күптән ташлаган булган. Ялгыз тилмереп йөрергә калган ятим карт ахырда кызы Гайникамалга барып сыенган. Әнә шундый ачы язмыш! Ләкин язмышы ачы булса да һәм гомере буена эчсә дә, Гали абзый 92 яшенә җитеп, сукыраеп, Гайникамал апа кулында вафат булган... Әйе, Ишле авылыннан чыккан бу татар абзыена табигать тазалык белән куәтне биргән дә икән — исең-акылың китәр!

Белмим, атакай бер урында озак торырга яратмаганга күрәме, әллә бүтән берәр сәбәптәнме, без тагын фатирыбызны алыштырдык. Соңгы өч-дүрт ел эчендә бу инде өченче йорт. Җитмәсә, бусы да аерым йорт, ягъни бары үзебез өчен генә... Хәзергә кадәр аңлый алганым юк, мондый буш торган йортлар Дәүләкәндә ничек табылды икән? Хуҗалары кайда, кемнәр алар? Вакытында сораша да белмәгәнмен... Ләкин фараз кылуымча, Дәүләкәндәге буш йортлар мотлак якын-тирә хуторларда торучыларныкы булгандыр, шулар мөгаен арендага бирә торган булганнардыр.

Шулай итеп, без яңадан Қоман буена күчтек, ләкин яр башына түгел, яр астына. Монда, су буена сөзәк кенә төшкән тигезрәк җирдә, бер урам бар иде, аны Набережная дип йөртәләр дә иде — безнең йорт менә шул урамның беткән җирендә, бездән соң бүтән йорт юк, чөнки тигез җир бетеп, текә яр башлана...

Бу йорт та, әйтергә кирәк, әйбәт-төзек кенә иде. Калай белән япкан, такта белән тышланган, күк төскә буялган — аны шулай «күк йорт» дип атыйлар да иде. Урамга чыга торган кунаклар ишеге дә бар, ишегалдына караган верандасы да бар, һәм безнең өчен иң күңеллесе — ишегалды белән янәшә зур гына бакчасы да бар... Дөрес, анда җимеш агачлары үсми, анда койма буйлап карт тирәкләр генә үсеп утыра, ә арткы коймасы су читенә тиеп үк тора. Безгә уйнар өчен бик әйбәт «площадка». (Хәзергечә әйтсәк).

«Күк йорт»та без бары бер җәй дә бер кыш кына тордык. Атакай үзенең сәүдә эшләре белән һаман читкә китеп йөрде, безнең янга «иптәшкә» әүвәлгечә Зөфәр белән Маһирә куна киләләр иде, ә көндезләрен әлеге бакчада бергә уйнарга Мәхмүт белән Миңнеахмәт килеп җитәләр иде. Қыска гына вакыт торганга күрәдер инде, минем бу йорт белән бәйләнгән истәлекләрем бик аз, булган кадәресе дә онытылып беткән диярлек. Бик яшь идек шул әле, миңа нибары сигез генә — ятып йоклаудан, торып ашаудан һәм көне буе уйнап йөрүдән башканы белмәгәнбез дә, зур дөнья, зур вакыйгалар бездән читтә иде әле. Хәлбуки, бу инде унҗиденче елның җәе иде, дөньяның бик кайнап башлаган чагы, өченче ел инде бөтендөнья сугышы бара. Дәүләкән турысыннан көн саен диярлек атлар, туплар, солдатлар төягән кызыл эшелоннар тукылдап үтеп тора, тик боларны аңлабрак күрү өчен безнең тагын азрак үсә төшүебез кирәк булган.

Әмма шулай да бу йортның «истәлеге» буларак бер вакыйга минем бала күңелемдә бик нык уелып калды. Әйтергә кирәк, хәзергә кадәр ачык сакланган бик сирәк хатирәләремнең берсе ул... Беләсез инде, җиде-сигез яшьлек малайлар өйләре тирәсендә генә уйнап йөрү белән чикләнмиләр, кызык эзләп алар ераккарак — авыл читенә, кырга-яланга, тау-чокыр буйларына китеп йөри башлыйлар. Менә без дә, өч малай, бер көнне тоттык та тимер юлына киттек. Куркырга ашыкмагыз, без үзебез дә үткән-сүткән поездларга якын бармыйбыз, аның тавышыннан-җиленнән үк әле шүрлибез. Аннары безнең теләк тә юл буенда йөрү түгел, ә юлны аша үтеп кырга чыгу иде. Анда, илибатыр (элеватор) артындагы кырда, руслар күп итеп көнбагыш үстергән — менә шунда таба инде безнең юлыбыз да... Читтәге такыр сукмактан Яңа Көрмәнкәйгә таба күпмедер атлагач, без тимер юлына күтәрелеп, каршы якка чыктык. Шунда ук алдыбызда, бик ерак та түгел, сап-сары түгәрәк башларын иеп, яшел-зифа урмандай үсеп утырган көнбагыш кырлары ачылды. Без тимер юлыннан йөгерешеп төштек тә киттек шунда таба! Барырга, тиярга ярамый дип, яки каравылчысы-мазар булыр дип уйлый белдекме икән? Юктыр, ахрысы. Ничектер куркып та, икеләнеп тә тормыйча көнбагышлар арасына барып та кердек. Эчкә узмыйча гына читтәге көнбагыш башларын кабаланып өзәргә дә то-

тындык. Бөгелеп төшкән бик зурларына безнең көчебез җитмәде. Шулай да нечкәрәк сабаклы кечерәкләрен боргалый-боргалый өзеп алдык. Инде нишләргә? Беребез хәйләсен тапты — күлмәген ыштан бөрмәсенә кыстырды да көнбагышларын изүе эченә салды. Без дә шулай эшләдек. Хәзер тиз генә моннан сызарга кирәк иде. Ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, көнбагыш сабаклары арасыннан чыгуга безгә таба якынлашып килгән бер марҗа түтәен күреп алдык. Янында бездән олырак малае да бар... Бу хәлдән бер мәлгә каушап калдык, хәтта туктарга мәҗбүр булдык, аннары сүз куешкандай бердән кубып, табаннарны ялтырата-ялтырата түбән таба элдерттек. Марҗа түти безнең арттан йөгермәде, малаен да куа җибәрмәде, бары боерык биргәндәй татарчалап кычкырды гына:

— Туктагыз!

Һәм мин туктадым, ә иптәшләрем юк, борылып та карамыйча чаптылар гына... Марҗа-түти кулын изәп кенә мине янына чакырды:

— Малайка, кил әле монда, кил!

Мик бик каушап, курка-курка гына аңа якынлаштым.

— Курыкма! — диде ул миңа, малае кизәнмәкче иде — аны да тыйды, суктырмады. Түти гәүдәгә зур иде, тулы-таза иде, мөлаем да кебек иде.

— Күлмәк эчеңдә нәрсә, чыгар әле! — диде.

Мин изүдән өч баш көнбагыш чыгардым.

— Ват вит, бәләкәй генә башың белән урлашырга да тотынгансың,— диде ул гүя ачусыз гына.

Мин дәшмәдем, колакларыма хәтле кызардым, елап җибәрергә авызым да җаелә башлады, ләкин ничектер тыелып калдым. Марҗа түти әллә кызганып, әллә нидер уйланып, беравык минем өстемә карап торды — мин ул чакта чебештәй арык, нечкә генә бер малай идем.

— Кем малае син? — дип сорады ул.

Мин көчкә генә:

— Хәдичә апаныкы,— дидем.

— Кайда торасыз?

— Күк йортта.

— Кайда ул «күк йортыгыз»?

— Комач буенда.

Марҗа түти аз гына дәшми торганнан соң миңа:

— Итәгеңне тот әле,— диде.

Мин аңламадым, ул тагын кабатлады:

— Итәгеңне күтәр диләр сиңа?

«Нигә икән?» дип аптырап, мин кыюсыз гына ике куллап күлмәк итәгемне күтәрдем, ә марҗа түти әлеге өч баш көнбагышны минем тотып торган итәгемә салды. «Биреп җибәрә ахрысы»,— дигән уй килде миңа шунда ук, һәм мин берьюлы җиңеләеп киткәндәй булдым. Ләкин мөлаем түти тыныч кына:

— Инде өегезгә барабыз, әйдә, атла! — диде.

...Өчәүләшеп авылга таба кузгалып киттек. Барган җиремнән: «Озатып куймакчы була микәнни, мин бит болай да кайта беләм»,— дип уйлыйм, тик бу турыда түтинең үзенә әйтергә кыюлыгым гына җитми, билгеле... Ә ул мине туры гына «озатасы» урынга, ни өчендер шактый урау ясап, Дәүләкәннең төп урамына алып чыкты. Озын урамның иң очыннан төшеп, безгә таба атлыйбыз — уртадан, көнбагыш тулы итәгемне күтәреп, мин барам, ике ягымда ике сакчыдай таза марҗа түти белән аның дәү генә малае бара... Очраган кешеләр «бу ни тамаша» дигәндәй безгә карап калалар. Кайберләренең йөзендә: «малайны эләктергәннәр икән» дигән төслерәк әче генә елмаю да чагыла, һәм бу хәл мине оялту гына түгел, чынлап торып борчый да башлый.

Ахырда безнең «күк йортка» килеп җиттек. Парадный ишектән барып кердек, туп-туры өйгә дә уздык. Керсәк залда өч-дүрт хатын чәй эчеп утыра. (Атакай өйдә юк чакта инәй күрше хатыннарын шулай чәйгә дәшәргә ярата иде.) Ләкин кунаклар өстенә килеп керү маржа түтине бер дә борчымады, ахрысы, ул каты итеп, кычкыра биреп сорады:

— Хәзәйкә, сезнең малаегызмы бу?

Инәй аның соравын ишетмәгән дә шикелле тәмам коелып миңа текәлде:

— Балам, сиңа ни булды?

Билгеле, минем сүз әйтерлек тәкатем калмаган иде, аның каравы маржа түти шунда ук:

— Без аны көнбагыш урлаган җирендә тоттык! — диде.

— Булмас ла!

— Әнә бит итәгендә көнбагышлары!

Инәй, бичара, бер сүз дә әйтә алмады, йөзе сытылып, агарып киткәндәй булды, авыру күзләренә мөлдерәп яшьләр дә килде. Мин көнбагышларымны төшереп җибәрдем дә аның итәгенә барып капландым. Һич тыелгысыз үксүдән бизгәк тоткандай бөтен тәнем белән калтырана да башладым. Түрдә ашау-эчүләрен бүлеп, аптырап утырган хатыннар да, ахры, түзмәделәр:

— Бала гына бит әле ул, көнбагыш башы өчен генә шулай рисвай итәргә ярыймыни?! — диештеләр.

Маржа түти бармагын туп-туры миңа төртеп, тагы да катырак итеп:

— Менә, менә, бала чактан ук тыярга кирәк аны урлашудан,— диде.— Үскәч соң була ул... Шуның өчен китердем дә мин аны сезгә... Сабак булсын дидем! Ә көнбагыш безгә жәл түгел, пажалыста, ашасын!

Шулай диде дә, малаен ияртеп, каты басып чыгып та китте. Көнбагыш башлары идәндә сибелеп калды. Инәй бераз исен җыйгач, аларны юынтык су чиләгенә чыгарып ташлады.

Әнә шундый сабак алдым мин сигез яшемдә! Гомер бакый онытылмаслык сабак! Һәм... файдалы сабак! Моның өчен маржа түтигә хәзер рәхмәт тә әйтергә ярый торгандыр. Әмма ул чакта инәйне бик кызганган идем. Ни сәбәптер, ул минем «урлашып» тотылуымны бик авыр кичерде. Кунаклары киткәч тә сүздән калып, боегып йөрде. Мине дә үгетләп-нитеп тормады, бары аркамнан сыйпады да йомшак кына «әйдә, балам, ачыккансыңдыр» дип ашарга утыртты. Күрәсең, кунаклар алдында «рисвай булуым» да җиткән дигәндер инде һәм үзенең йөрәге дә бигрәк шуның өчен сызлангандыр — шулай уйладым мин соңыннан бу «истәлекле» көнне исемә төшергән чакларда.

«Күк йорт»ка бәйле тагын нәрсә күңелемдә саклана? Әллә ни кызыклысы юк шикелле, булганнары да бала-чага уеннары гына, ә уеннар турында соңрак сүз булыр әле. Әмма шулай да бер мөһим вакыйганы искә төшермичә үтү ярамас. Без моңарчы сыер белән кош-корттан башка нәрсә асрамый идек. Бәлки, кирәге дә булмагандыр, ә бәлки хәлебез җитмәгәндер —мин ул кадәресен белмим. Ә менә шушы йортта торганда атакай тотты да бик шәп бер ат сатып алды. (Димәк, бу вакытта инде аның хәленнән килгән.) Ат — зәһәр, тимер күк яшь айгыр. Гәүдәгә биек кенә, буйга да озын гына, ялы белән койрыгы да куе-озын, колаклары уйнаклап, күзләре янып тора. Әйе, әйтәсе дә түгел, сылу хайван! Җигеп йөрер өчен махсус өйрәтелгән юртак икән ул үзе. Бер дилбегә кагу белән, нечкә-озын аякларын эре-эре ташлап, ләкин һич тә сикереп чабуга күчмичә, җилдәй очып кына бара икән. Нинди-дер боярның зат нәселле асыл сөяге булган, диделәр аны.

Энем белән без икәү Тимеркүктән күзләребезне алмасак та кыюланып янына барырга курка идек әле. Кушмыйлар да, белмәссең хайван-

ның холкын, диләр. Ә дәртле айгыр гел башын чайкап, пошкырып, алгы тоягы белән җирне тырнап кына тора. Аны күбрәк аранда гына тоталар. Атакай өйдә чакта үзе карый, киткән чакларында инәй карый торган иде. Айгыр аранда торып, бик тынычсызлана башласа, ишегалдына чыгарып, берәр баганага таза бау белән бәйләп куялар. Әйткәнемчә, безнең ихата Комач читенә терәлеп үк тора, язгы ташу вакытында су ишегалдына да үтеп керә иде. Бәйләп куйган айгыр да, якындагы су исен сизепме, әллә аръяктагы яшел болынны күрепме, баскан җирендә һич тыныч кына тора алмый, өзлексез әйләнә-тулгана, чигенә-тартыла, я булмаса башын күтәреп, танавын киереп һаваны иснәргә тотына, шул чагында еш кына бөтен су буен яңгыратып кешнәп тә җибәрә. Кыскасы, хөрлек, иркенлек таләп итә иде ул!..

Атакай хайваннарга карата йомшак күңелле кеше иде, сыерга, сыйпарга, дәшәргә ярата иде. Күк айгырның да хәлен аңлап булса кирәк, бер көнне ул аны ишегалды белән янәшә бакчага, йөгәнен салдырып, кертеп җибәрде. Айгыр читлектән ычкынган коштай бакчаны бер итеп, артын уйната-уйната, әллә ничә кат чабып әйләнде, аннары күңеле хушлангандай ашыкмыйча җирне иснәп кенә йөрде, бер җирдә ятып, аякларын күтәреп, аунап та алды, торгач, бөтен тәне белән калтырана-калтырана селкенде, шуннан соң нидер сизенгәндәй бакча түренә барып, койма өстеннән аргы якка карап тора башлады. Ә анда, ерак тугайда, елкылар көтүе йөри иде. Безнең айгыр шуларны күрде, күрү генә түгел, ничектер исләрен тойды бугай, башын күтәргән килеш колакларын кайчыдай торгызып, уттай күзләрен тасырайтып, карап торды-торды да, кинәт койма аша суга сикереп, аргы якка йөзеп чыгып та китте... Без «ах!» итеп кенә калдык. Ярый әле, атакай ишегалдында йөри иде, бу хәлне күргәч бик хафаланып: «Өер айгырлары белән сугышып, харап кына булмаса ярар иде!» — диде дә тиз генә йөгән электереп, күрше көймәсендә аргы якка ашыкты. Ул каршы ярга барып туктаганда Тимеркүк әллә кайчан бияләр көтүенә барып та җиткән, андагы өер айгырлары белән чыйнашып, тешләшеп сугыша да башлаган. Яхшы әле, якында гына печән чабучы башкорт агайлары бу тамашаны күреп алганнар. Бары шулар ярдәме белән генә атакай Күк айгырны бияләр көтүеннән көчкә-көчкә аерып алып кайтты. Я, шыр тиле түгел диген син аны, житмәсә әле яудан кайткан батыр шикелле эре генә басып тора, тешләнгән, яраланган җире дә күренми үзенең. Атакай әйтә: «Аңа чыдыйлармы соң, вак айгырларны шунда ук куып бетергән»,— ди... Ләкин шулай да бу вакыйгадан соң инде Тимеркүкне тезгенсез бушлай гына бакчага җибәрү бетте.

Атакайның соңгы елларда «эше» әйбәт барган булырга тиеш — югыйсә, мондый шәп ат безнең йортка кайчан керер иде әле... Бу вакыт 1917 елның буталчык хәвефле җәе булса да, ул үзенең сәүдәсе эшләре белән йөрүдән туктап тормады. Ләкин, шуңа да карамастан, аны чын «купич» диеп танымыйлар иде әле, чөнки ул йортсыз кеше, ул һаман да «фатир күчеп» йөрергә мәҗбүр... Ә йортсыз «купич» булырга мөмкинме? — әлбәттә, юк. Мондагы эре сәүдәгәрләр генә түгел, вак сатучылар да йортлы-җирле кешеләр. Хәтта энә тимерче Миңнегали карт яки тегүче Солтан абзый кебек хәллерәк һөнәрчеләр дә үз йортлары белән торалар. Йорты барның абруе бар — ул ышанычлы кеше. Җиккән атың нихәтле генә шәп булмасын, әгәр синең үз нигезең, үз йортың юк икән, син әле төпле, ныклы хуҗа түгелсең.

Билгеле инде, безнең атакайның да бөтен хыялы йорт алу, йортлы булу иде. Шуның өчен йөри, шуның өчен тырыша һәм шуңа омтыла да иде. Ләкин ни сәбәптер ул бу эшне һаман суза да суза. Акчасы җитмиме, йорты очрамыймы — сәбәп нәрсәдә?

Кыскасы, без 1917 елның тынгысыз җәен дә, явымлы пычрак көзен дә шул «күк йорт»та уздырдык. Кышка да кердек... Мин икенче ел

инде мәчет каршындагы мәдрәсәгә укырга йөрим. Монда ул чакта парта дигән нәрсә юк иде әле, тәбәнәк өстәлләр артында идәнгә җәйгән киезләргә тезләнеп утыра идек. Хәлфәбез читтән килгән коръәнхафиз — бик усал кансыз бер кеше иде. Янында утырган шәригеңә дәшү түгел, борылып карарга да ярамый — шунда ук хәлфәнең өчтән үргән талчыбыгы сызгырып өстеңә төшә. Күп кенә малайлар дәрестән юеш балакларын ләштердәтеп өйләренә кайталар иде. (Бу хәлфә турында мин күп еллардан соң «Коръәнхафиз» дигән хикәя дә яздым.)

Безнең башлар әнә шулай кыйнала-кыйнала укып азапланган бер заманда ерак пайтәхеттә тагын бер инкыйлап булган дип ишеттек. Бусын үктәбер инкыйлабы диделәр. Аның хәбәре безнең Дәүләкәнгә соңрак килеп житте. Бик алама вакыт иде, кар-яңгыр, сыргак-салкын, Дәүләкән урамнары тездән пычрак, шуңа күрә патша төшерелгән чактагы кебек урамнарга чыгып, нәмаеш ясап йөрүләргә дә мөмкин булмады. Әмма шушы кечкенә җиребездә дә тыныч түгел, шомлы-киеренке, кешеләр тыннарын кысып, гүя зур тайфун килеп житкәнен көтеп торалар. Безнең атакай да йөрүеннән туктады, өйдә генә ята.

Ләкин озакка бармады бу хәл, бу көтеп яту. 1918 елга керү белән вакыйгалар, бөтен җирдәге шикелле, бездә дә бик тиз куерып, кискенләшеп китте. Нәкъ ел башында Уфадан килгән кораллы отряд ярдәме белән Дәүләкәндә дә, ниһаять, совет власте урнаштырылды. Әмма озак та үтми Дәүләкәнне чехлар басып алды. Шуңа ялганып, аклар-кызыллар сугышы башланып китте. Халыкка шик-шөбһә, талаш-тартыш, курку-өркү килде. Бу зур сугыш Дәүләкәнне дә, билгеле, читләтеп узмаячак иде.

...Дөньяның нәкъ шушындый кызган, буталган бер чагында безнең атакай тотты да йорт сатып алу хәстәренә керешге. Хәзер дә гаҗәпләнәм, нәрсә мәҗбүр итте икән аны болай ашыгырга?.. Ахрысы, ул чактагы буталчык шартларда берәүләргә артык мөлкәттән тизрәк котылырга, ә икенчеләргә кулындагы акчасын ничек тә мөлкәткә әйләндерергә кирәк булгандыр. Әнә шундый ситуация, хәзергечә әйтсәк.

Ничек кенә булмасын, атакай чарасына керешә, йорт сатучыны таба һәм сөйләшүләр башлана. Йортның хуҗасы — хуторда яшәүче бер рус бае. Сөйләшүләр авыр бара, хуҗа сайлана, юри суза, чөнки йортны сатып алырга теләүче бүтәннәр дә табыла. Шуның өстенә тагын икенче бер кыенлык та килеп чыга. Хикмәт шунда, йорт үзе русныкы булса да, утырган җире гадәттәгечә башкортныкы. Аның да ризалыгын алырга кирәк. Җир хуҗасы Сәлимҗан агай үз таләбен китереп куя: ерең бөтәһен дә бирмәем, яртыһын үземә калдырам, ди... Шулай итеп, берьюлы ике хуҗа белән сөйләшүләр алып барырга туры килә.

Бәлки тырышып йөрүләр нәтиҗәсез дә беткән булыр иде, ярый әле бу эштә безнең атакайга әлеге тимерче Миңнегали карт бик нык булыша. Ул акыллы, абруйлы һәм сүзгә оста кеше иде. Атакай аны күк айгырга утыртып, берничә мәртәбә хуторга алып бара. Ахырда ул өч якны да килештерә: атакай йортны ала, килешенгән хакын түли, ә җиргә килгәндә, аны Сәлимҗан агай белән бүлешергә риза була. Бары шуның аркасында гына йорт безнеке булып кала, чөнки башка сатып алырга теләүчеләр йорт ихатасын бүлешергә риза булмыйлар... Зур эш әнә шулай төгәлләнә. Хәере белән булсын, диләр, утырып дога кылалар, соңрак хәзрәтне чакырып коръән дә укыталар.

Мактанудан булмасын, йорт үзе дә, утырган җире дә бик әйбәт. Күрү белән яраттык без аны. Төп урамның уртарак бер төшендә, мәчет-мәдрәсәгә дә якын, базардан да ерак түгел, каршыда гына тимер юлына илтә торган кыскарак тагын бер урам башлана (исеме — Холодный переулок.) Йортыбыз калай белән япкан, ике катлы, түбәнге каты җиргә кертеп таштан, ә өске каты бүрәнәдән салынган. Урамга өч тә-

рәзәсе карый, парадный дигән ишеге дә бар. Капка-коймасы кызылга буялган, шуңа күрә аны «кызыл йорт» дип тә йөрткәннәр.

Ихатабыз бик киң булмаса да ишегалды түренә таба шактый озын иде. Әлеге килешү буенча, аны нәкъ уртасыннан бүлеп, киртә тоттылар: уң ягы безгә, сул ягы Сәлимҗан агайга. Безнең якта йортыбыздан башка тагын тәгәрмәч чыгырлы кое торып калды. Ә Сәлимҗан агай өлешенә кайбер каралтылар белән бергә матур гына бакча да эләкте. Без бигрәк тә бакчаны кызгандык. Сәлимҗан агай үзенең «пәрилә» очындагы өен соңыннан шул бакча урнысына күчереп куйды.

Ихатаны бүлүнең исә көтелмәгәнрәк бер кыенлыгы да чыкты. Ишегалды түреннән тотыла башлаган киртә урам капканың нәкъ уртасына туры килде. Бер яртысы безнең якка, икенче яртысы Сәлимҗан агай ягына ачыла торган булып калды. Шул сәбәпле, киртәне капкага китереп җиткермичә туктаттылар һәм вакытлыча бер капкадан йөреп торырга булдылар. Соңыннан ике хуҗа да үзләренә аерым капка эшләтергә тиеш иде. Ләкин айлар узды, еллар узды, сугышлар да үтеп китте, ачлык елын да уздырып җибәрдек, әмма яңа капка тәки эшләнмичә калды. Сәлимҗан агай холера вакытында үлеп китте, йорты башка кулларга күчте, ә безнең атакайның ике катлы йорт сатып алырга көче җитсә дә, тактадан гади генә капка эшләтергә хәленнән килмәде. Шулай итеп, безнекеләр Дәүләкәннән киткәнчегә кадәр, ике күрше бер капкадан йөрделәр. Безгә килүчеләр киртәнең уң ягына, күршегә килүчеләр сул ягына узалар иде.

Яңа йортка — инде үзебезнең йортка без 1918 елның июнь башында күчендек. Үзебезнеке! — бу кодрәтле сүз безнең малай җаныбызны да биләп алырга өлгергән иде. «Минеке», «безнеке» дигән аңмы, тойгымы адәм баласына сабый чактан ук керә торгандыр. Сабыйның нәни кулыннан әйберсен алып кара — ул да бит шунда ук «разбой» сала башлый. Хәзерге заман кешеләренә карап та моңа әле гаҗәпләнергә туры килә.

Без, әлбәттә, бик шат идек. Тизрәк күчәргә атлыгып кына тора идек. Беренче мәртәбә атакайга ияреп баргач, без энем белән икәү йортның бөтен җирен — эчен-тышын һәм ишегалдын карап чыктык. Түбәнге катында кайчандыр пекарни булган икән. Ишектән кергәч нәкъ каршыда тәбәнәк-киң авызлы галәмәт зур мич, стена буенда ак тактадан таза эшләнгән лар-әрҗәләр, мич кырында сөяп куйган озын саплы көрәк һәм пумалалар... Почмакларында он кунган пәрәвезләр һәм... бөтен җиреннән күпергән камыр исе килеп тора кебек. Монда ак калач белән йомшак клиндерләр пешергән булырга тиешләр. Ак калачның нәрсә икәнен без дә әзрәк беләбез... Бәлки әле бу әкәмәт мичтә безнең үзебезгә дә ак калачны пешерергә туры килер, дип уйладым мин бала хыялым белән.

Пекарнине тиз генә карап чыктык та ашыгып югары катка мендек. Монда инде иртәгәдән дә калмыйча без үзебез тора башлаячакбыз. Менә зур гына өйалды, сулда такта ишек — анда чолан булса кирәк, уңда урам (парадный) ишегенә төшә торган, сарыга буяган баскыч... Әйбәт!.. Ярый, зур таза ишектән өйгә үк кердек. Каршыда коридор, сулда кухняга уза торган аралык, ә уңда ике якка ачылмалы ак ишек. Без иң әлек әнә шул шәһәрчә шәп ишекне сак кына ачып, түр якка (залга) кыяр-кыймас кына атладык һәм керү белән авызыбызны ачып, бер мәлгә аптырап калдык: бу якның стеналары бүрәнә дә түгел, ышкатур да түгел, ә түшәмнән идәнгә чаклы ниндидер эре, матур бизәкле, ачык зәңгәр төстәге буй-буй калын кәгазь белән ябыштырылган иде. Кара, мондый стена да була икән дип гаҗәпләндек без, тик соңыннан гына ул бизәкле калын кәгазьнең обой дип аталганын белдек. Аннары монда тагын моңарчы без күрмәгән кайбер җиһазлар да бар иде. Мәсәлән,

каршы стенада иданнэн алып, түшэмгэ чаклы сузылган зур көзге... Аңа карагач та бераз аптырап киттек: без ике яланаяк малай, гүя каршы яктан килеп кергэндэй көзге эчендэ янэшэ басып торабыз, экэмэт! Кеткелдэп кенэ бер көлешеп тэ алдык. Тагын монда сырлап эшлэгэн зур сары шкаф белэн бөгеп эшлэгэн түгэрэк артлы урындыклар да тора иде,— боларның барысын да атакай йорт белэн бергэ сатып алган икэн. Бик эйбэт, бик шэп, һэм без моңа бик тэ шат идек!

Без, ике малай, энэ шулай яңа йортыбыз белэн танышып чыктык. Билгеле инде, бөтен ихатасын эйлэндек, бер почмагын да калдырмадык. Ихата эле уртадан бүленмэгэн иде, шуңа күрэ ул безгэ бик иркен — зур булып күренде... Эйткэнемчэ, без яңа йортка июнь башында күчендек. Иң элек, йола кушканча, инэй йортыбызның түренэ бер бөтен икмэк белэн бер чирек сөт китереп куйды. Монда да тормышыбыз тук, мул булсын өчен иде бу... Аннары күк айгырда эйберлэребезне ташыдык. Дэүлэкэндэ безнең якын туганнарыбыз Зэкия тутакай белэн Хэсэн җизни торалар иде — күченгэндэ шулар иртэдэн кичкэ кадэр безгэ булыштылар. Көн яктысында ашап-эчкэннэн соң, туганнар да киткэч, без беренче мэртэбэ яңа урында, догаларыбызны укып, йокларга яттык. Лэкин бик арган булуыбызга карамастан, беребез дэ тиз генэ йокыга китэ алмадык. Эллэ шатлыктан, эллэ татлы хыялдан... Атакай белэн инэй шыпырт кына һаман нидер сөйлэшеп яттылар. Миңа да бит инде тугыз яшь, хыяллана башлаган чагым. Хэер, йоклый алмыйча нилэр уйлап ятканымны белмим, бэлки тизрэк үсү, матур булу, матур киенү турында уйлаганмындыр. Эйе, бу төнне хыяллар йокыдан татлырак иде.

Күпмедер вакыт без яңа йортыбызга урнашу җайлашу, иялэшү чорын кичердек. Эмма бу бик кыска бер ара булып калды. Баштарак эйткэнемчэ, унсигезенче елның җэе — Гражданнар сугышының көчэйгэн чагы иде, шуңа күрэ безнең Дэүлэкэндэ дэ вакыйгалар бик тиз үзгэрэ башлады.

Энэ шулай нилэр булыр икэн дип көтеп йөргэн арада мин эле ике ягыбыздагы күршелэр белэн дэ эзрэк кенэ танышырга өлгердем. Уң ягыбызда рус ихатасы иде. Калай белэн япкан кечерэк кенэ йорт, бер сарайдан башка бүтэн каралтылары да юк, лэкин зур гына ишегалларында төрле яшелчэлэр утыртылган түтэллэре күп иде. Тик ни гаҗэптер, бу йорт кайчан гына карама гел буш тора, анда уйнап йөргэн бала-чага да, хуҗага охшаган ир-ат та күренми, бары түтэллэр арасында бер марҗа түти генэ иелеп, эшлэп йөри торган иде. Соңыннан белдек — бу йортның хуҗасы Дэүлэкэннең иң беренче революционерлары — бертуган Иван белэн Николай Кириченколар икэн. Бэлки, вакыт бик киеренке — куркыныч булганга күрэ алар өйлэрендэ юньлэп тормаганнардыр да... Николай атлысы бит 1918 елның башында Дэүлэкэндэ оештырылган Совет властеның беренче председателе булган кеше — димэк, ул чакта аның бу тирэдэ ни өчен күренмэве хэзер менэ аңлашылса кирэк. Аннары инде соңрак безнең белэн Кириченколар арасына Сэлимҗан агай килеп утырды.

Эмма мине иң кызыктырганы сулъяк күршебез Борһан абзый йорты иде. Борһан абзыйның кем булуын хэтерлисездер — ул Дэүлэкэннең зур бер купецы иде. Йорты урамга буй салынган, шактый тэбэнэк, тэрэзэлэре дэ кечкенэ, шуңадыр ахры, тыштан эллэ ни зур да, матур да түгел иде. Лэкин аның каравы, ишегаллары бик иркен, күп җире яшел чирэм, сарай-амбарлары да бүрэнэдэн салынган. Менэ шул зур ишегалдында бик пөхтэ киенгэн бер көтү вак бала-чага шаулап, уйнап йөрилэр. Мин аларны бик кызыксынып койма ярыгыннан күзэтэм. Алар бер дэ диярлек урамга чыкмыйлар һэм үзлэренэ дэ беркемне дэ кертмилэр бугай — капкаларының аркылы агачы һэр вакытта шылдырып

куелган була. Шуңа күрә миңа койма буйлап ярык эзләп йөрергә туры килә дә. Оятрак булса да әйтим инде, ишегалдын тутырып, уйнап йөрүче бу шат балалар арасыннан бер кыз башта минем күземне, аннары күңелемне үзенә тартып өлгергән иде. Хәер, барысы да чибәрләр, барысы да матур киенгәннәр, араларында тездән генә бәрхет чалбар кигән ике малай да бар, ләкин барыбер минем күзем әлеге шул кара толымлы кызда гына... Бу кыз сезгә таныш булырга тиеш — ул Һаҗәр, Борһан абзыйның уртанчы кызы, арада иң чибәре, һәм минем беренче мәхәббәтем... Соңыннан миңа аларның барсы белән дә танышырга да, якыннан аралашырга да туры килде. Әмма Һаҗәргә гашыйк булуым койма ярыгыннан карап йөргән чакта ук башланган иде инде!..

Ләкин, әйткәнемчә, хәлләр бик тиз үзгәрде. Июнь ахырлары булды микән, көннәрдән бер көнне Дәүләкәнгә сугышмыйча-атышмыйча гына чехлар керделәр. Бу инде Дәүләкәнне алган беренче кораллы гаскәр иде. Алар кергән көннәреннән алып, чыгып киткәнчегә кадәр, станциядә запас юлга куелган үзләренең эшелонында тордылар. Солдатлары авыл арасына чыгып, таралып та йөрмәделәр. Халык та аларга чит-ят бер кавемгә караган шикелле карый иде.

Бу вакытның тагын бер вакыйгасы истә калган. Дәүләкән станциясендә чехлар безнең Шәриф җизни Сүнчәләйне кулга алалар. Шәриф Сүнчәләй Уфадагы революция вакыйгаларына актив катнашкан кеше, большевиклар тарафдары, чехлар кулына эләкмәс өчен Уфадан вакытлыча киткән дә булган. Ләкин Дәүләкәндәге чехлар да нидер сизепме, белепме, бу бик интеллигент кыяфәтле кешене камап, тикшерә башлыйлар. Әлбәттә, җизни өчен зур куркыныч туа. Озак та үтми, Уфадан Срур тутакай да килеп җитә. Аларны күрештерәләр.

Минем күз алдымда шундый бер күренеш саклана: урам уртасыннан рессорлы шәп пролеткага җигелгән, үзе эре сөякле, үзе бик сылу, бәкәлләрен кысып ак чүпрәк ураган чем-кара айгыр атлап кына китеп бара. Пролеткага җизни белән Срур тутакай янәшә утырганнар. Җизнинең иңендә кара накидка, башында киң читле эшләпә, Срур тутакайның башында да бик матур, бик килешле җиңел эшләпә — Дәүләкәннеке түгел икәнлекләре әллә кайдан күренеп тора. Кучерда чех солдаты, ә пролетканың ике ягында атка атланган ике сакчы. Ни өчен кулга алынган кешене болай шәп ат җиккән пролеткага утыртып йөртәләр икән, дип бик гаҗәпләнгән идем, тик соңыннан гына зурлардан ишетеп белдем: безнең җизни үткән ел учредительный собраниегә сайланган булган, ул депутат кеше, шуңа күрә аңа менә шундый аерым игътибар, аерым бер мөнәсәбәт икән һәм шул собраниенең депутаты булганы өчен аны бик озак тотмыйча азат та итәләр.

Чехлар үзләре дә Дәүләкәндә озак «кунаклап» ятмыйча, килеп кергәндәге шикелле сугышсыз-нисез генә чыгып та киттеләр. Эшелоннары белән, ахрысы, төнлә кузгалып киткәннәрдер — без, малай-шалайлар, сизмичә дә калдык. Шуннан соң артларыннан ук диярлек Бәләбәй ягыннан Дәүләкәнгә җәяүләп тә, атка атланып та, тупларын һәм обозларын ияртеп, икенче бер зур гына отряд килеп керде. Болар инде кызыллар иде. Сафларга тезелеп, кызыл байракларын күтәреп, бөтенесе бер тавыштан җырлап, чын гаскәрләрчә төп урам буйлап уздылар. Бөтен халык урамга сибелеп чыкты. Болар инде чехлар түгел, болар инде үзебезнең шанлы кызыл гаскәр! Аларны шунда ук йорт саен төркем-төркем фатирларга урнаштырдылар. Безнең ишегалды да атлар белән тулды, күрше Борһан абзыйның да гел бикта торган капкасы ачылды, кыскасы, тазарак, баерак йортларның барысына да кереп тулдылар. Дәүләкән бердән җанланып китте. Кая карама, кызыл йолдызлы, мылтыклы солдат, араларында кылыч аскан, наган такканнары

да бар — боларын кызыл командир яки комиссар дип атыйлар икән. (Искечә эфисәр дип әйтү юк, тыелган, имеш.) Дәүләкәннең кызылларны әле беренче генә күрүе, шуңадыр инде бөтен яшь-җилкенчәк, бала-чага гел алар тирәсендә. Аннары бу отрядта татар, башкорт егетләре дә күп иде. Алары безнең бик тыйнак, бик әдәпле кызларыбызга ошаган булса кирәк, чөнки соңыннан кайбер «мәхәббәт маҗаралары» да мәгълүм булды.

Шулай да кызыллар кергәч, Дәүләкәндә нинди үзгәрешләр булганын менә хәзер мин язарга кыенсынам. Җитди нәрсәләрне күрергә, белергә артык яшь булып калганмын. Минем өчен — уйнап йөрүдән башканы белмәгән малайга — барысы да искечә кебек иде. Хәзергә әле безнең Дәүләкәндә тыныч кына, андый-мондый куркыныч вакыйгалар да ишетелми, ләкин шулай да нидер көтү, борчылып, шомланыбрак тору сизелә иде. Зурларның сөйләнүенә караганда, Дәүләкәнне бер генә сугыш та читләтеп узмаячак, агы да, кызылы да тимер юл өстендәге бу зур, бай авыл өчен аяк терәп сугышачак, имеш! Һәм чынлап та, күпмедер вакыт үтүгә, аклар Уфаны алганнар, Дәүләкәнгә якынлашып киләләр, дигән хәбәр дә таралды. Инде чат саен кешеләр авызында бер генә сүз — Дәүләкән өчен каты сугыш булачак, кызылларның чигенергә һич тә исәпләре юк!.. Чын сугышны күрмәгән халыкның бер өше моңа әллә ни исе дә китмәгән шикелле, әмма йорт башы өлкән агайлар шактый ук куркуга да төшкәннәр иде. Ничек кенә булмасын, якынлашып килгән сугыш берәүне дә тынычлыкта калдырмады, кайберәүләрне исә котылу чарасын күрүгә дә мәҗбүр итте. Атлы-тынлы кешеләрдән бала-чагасын төяп читтәгерәк авылларга китүчеләр дә күренә башлады. Безнең атакай белән итче Гали абзый да үзара сөйләшеп, сугыш узганчы Дәүләкәннән читкәрәк китеп торырга булдылар.

Мин үзем бу курка-курка көтелгән сугышның кайчан килеп җиткәнен дә белмим, якында туп, мылтык тавышлары ишетелгәнен дә хәтерләмим, ләкин көннәрдән бер көнне иртән иртүк атакай безне тәмле йокыбыздан кабаланып торгызды да җигелеп куйган күк айгырга утырып, каядыр алып чыгып та китте. Йортыбызны саклап торыр өчен Зәкия тутакай белән Хәсән җизни килгәннәр икән — шулар безгә хәерле юл теләп, озатып калдылар.

Яңа Шәрип турысында Дим күперен чыккач, без Гали абзыйны куып җиттек. Ул да хатыны белән балаларын читән тарантаска төягән, үзе кучерга утырып, ашыкмыйча, безне көтә-көтә бара икән. Очрашкач аз гына сөйләшеп алдылар да, дилбегәләрен кагып, кызу гына юрттырып та киттеләр. Атлар шәп иде. Шулай итеп, сугыштан качып барабыз. Юлыбыз Имай Карамалысына... Бу Дәүләкәннән 20—25 чакрым чамасы ераклыкта бер татар авылы. Тимер юлыннан шактый читтә булгач, аңа сугыш кагылмыйча узарга тиеш, янәсе. Һәм чынлап та, без анда чакта, сугышның җиле дә кагылмады бу авылга.

Дөресен генә әйткәндә, без Имай Карамалысында күп тә тормадык. Искә төшерерлек нәрсә бик аз: тып-тын авыл, ерак түгел нечкә генә манаралы агач мәчет, урамы киң, яшел чирәм, шул чирәмдә башларын сыртларына салып утырган каз бәбкәләре. Тагын нәрсә?.. Без төшкән хуҗаның малаена ияреп, кечкенә инеш буена баруыбыз, шуннан ак каурыйлар җыеп кайтуыбыз — мондагы малайлар шул каурыйларны ничектер очыртып уйныйлар икән — менә хәтердә бераз сакланып калганы шулар гына. Хуҗабыз кем иде дә, малаеның исеме ничек иде — күптән инде онытылган. Атна-ун көн үтүгә, Дәүләкәннән сугыш узып киткәнен ишеткәч тә, без кире кайтырга да чыктык. Юлыбыз Дим буйларына таба булгач атларыбыз җилдерә генә — хәзер инде озын юлләр менәсе юк. Бер җирдә без әле төлке дә күрдек. Атакай: «Әнә, төлке, төлке!» — дип чыбыркысы белән алга төртеп күрсәт-

те, аннары «өлелүү!» дип бер кычкырып та җибәрде. Без энем белән очардай калкынып, ялт-йолт карана торгач, озын койрыклы, кара колаклы сап-сары бер җәнлекнең юл аша шым гына үтеп киткәнен күреп калдык. Ул заманда юлга чыксаң берәр төлке җәнлек очрамыйча калмый торган иде.

Кайтсак, Дәүләкәндә власть алышынган: биредә хәзер аклар булырга тиеш. Ләкин кайда алар, бармы алар — һич белерлек түгел. Дәүләкән бик тын да, бик буш та кебек, өйләрдә дә солдатлар юк. Әллә килеп җитмәгәннәр, әллә үтеп киткәннәр — баштарак мондый хәлне аңламыйчарак та тордык. Ә бәлки кайткан мәлгә без шундый бер сәер вакытка туры килгәнбездер. Сугыш артыннан кыска гына тынлык булып ала түгелме соң?!

Миңа, тугыз яшьлек малайга, Дәүләкән аша узган чын сугышның берсен дә күрергә туры килмәде. Сугыш якынлашкан саен атакай безне кая да булса читкә алып китә иде. Шул сәбәпле мин күргәннәрдән бигрәк ишеткәннәрне язарга мәҗбүрмен. Ә күрү белән ишетү арасында, үзегез беләсез, аерма бик зур.

Хәзер мәнә шул чактагы вакыйгалар турында сөйләүчеләрдән ишетсәм яки газета битләрендә басылган истәлекләрне укысам, исем китә — безнең Дәүләкән дә күп хәлләрне башыннан кичергән икән. Иң элек ул 1918—19 нчы еллар дәвамында берничә мәртәбә кулдан-кулга күчә: башта чехлар, аннан кызыллар, аннан аклар, тагын кызыллар, тагын аклар... Дәүләкән өчен сугыш та отыры катырак була барган. Кара-каршы атышу нәтиҗәсендә Дәүләкән кешеләре арасыннан яраланучылар, хәтта үлүчеләр дә булган. (Каһарман карт өенә тигән снарядтан безнең шәриктәш Хөсәен җиңгәсенең бер аягы өзелгән иде. Соңыннан бу чибәр хатын агач аякта йөрде.)

Аклар бик кансыз кыланганнар. Әле чех фетнәчеләре Дәүләкәнне калдырып чыгар алдыннан унсигез кызыл гвардеецны атып киталәр. (Район газетасы «Знамя», 1 май, 1960 ел.) Колчак гаскәре килгәч тә шул ук хәл — тоталар, аталар, кызыллар яклы берәүне дә аяп тормыйлар. Җирле большевикларның да бер өлеше шушы канлы сугышлар вакытында дошман кулына эләгеп һәлак була. Аларның кабере вокзал янындагы кечкенә бакчада — Дәүләкәнгә килгән һәр кеше кереп, күреп, туфракларына баш иеп чыга ала.

Билгеле инде, Дәүләкән халкының күпмедер өлеше үзе дә «акка», «кызылга» бүленә. Яшьләр арасыннан кызылларга иркле язылучылар булган шикелле, акларга язылучылар да табыла. Рус байларыннан Самсонов һәм Антемонов малайлары акларда офицер булып йөриләр. Ә татарлардан Муллаҗан дигән бер талчукчы абзый үзенең Носрулла исемле улын көчли-көчли акларга биреп җибәрә. Шуның өстенә Дәүләкәннең күп кенә яшьләрен аклар мобилизовать итеп тә алалар. Нишлисең, болар арасына хезмәт иясе һәм ярлы-ябагай балалары да эләгеп китә. Җамалетдин бабайның Вәлетдине, тимерче Миңнегали картның Муллагалие, Сафа купец ялчысы Кәфи картның Хәйретдине әнә шундыйлардан. Ләкин Муллагали абзый белән Хәйретдин абзый чигенә башлаган аклардан качып, кире кайталар. Әмма бик күпләр шул китүдән гаип тә булалар. Кыскасы, безнең Дәүләкәндә вакыйгаларның төрлесе — гыйбрәтлесе дә, аянычлысы да аз булмаган ул бик катлаулы, бик киеренке хәтәр елларда...

Имай Карамалысыннан кайткач, без яңа йортыбызда тагын үзебез генә тора башладык. Безнең бит әле үз йортыбызда юньләп тора да алганыбыз юк. Ә йортка ияләшәсе, йортның кадерен белеп кенә торасыбыз килә... Инде җәй дә үтеп бара. Тиздән көз, аннары кыш, ләкин алда нәрсә булачагы билгесез. Каядыр бездән еракта сугыш дәвам итә — яңадан безгә әйләнеп килерме ул, юкмы?.. Кешеләрнең уе-кайгысы әнә шуңа юнәлгән.

Шушы вакыт эчендә без зур гына казалы да булдык. Атакай һаман да күк айгыр өчен куркып тора иде. Айгыр — шәп, күрә калсалар, һичшиксез, алып китәрләр дип, ул аны абзарда гына бикләп тота иде. Юньләп беркая җигеп тә чыкмый иде. Үзебездә торучы кызыллар, билгеле, айгырны күрделәр, өстенә сокланып та карадылар, әмма тимәделәр. Аклар вакытында атакай аны бик сакларга тырышты, ләкин барыбер саклап кала алмады. Көннәрдән бер көнне ул күк айгырны җигеп, Әлшәй базарына барып кайтыр өчен чыгып китә. Ләкин Дәүләкәннән ерак та китәргә өлгерми, аңа акларның ниндидер бер отряды очрый. Каршыларына нечкә аякларын эре-эре ташлап, җиңел генә «очып» килгән айгырны күрү белән, солдатлар мылтыкларын югары күтәреп атакайны, туктаталар. Бу асыл сөякне карап торасы да юк дигәндәй, шунда ук тугарырга да кушалар. Атакай тугарырга ашыкмый, нидер аңлатмакчы була, ләкин отряд башлыгы аңа җикеренеп: «Без бер сүзне ике тапкыр кабатларга яратмыйбыз, тиз бул!» — дип кенә кычкыра. Шуннан соң атакай, чак еламыйча, күк айгырны тугара, башыннан, ял астыннан сыйпап-сыйпап сөя, ә тегеләр шунда ук айгырны иярләп тә алалар. Буш тәртәләр янында аптырап, басып торган атакайны кызганыпмы, әллә кирәге булмаганга күрәме, алар шулай да айгыр урынына сыртты чиләнгән бик өшән, бик арык бер атларын калдырып китәләр. Атакай менә шул мәхлүкне тарантаска җигеп, атланып кына өйгә кайтып керә.

Күк айгыр өчен без барыбыз да бик кайгырыштык. Гүя кеше шикелле үк бик кадерле җан иясен югалттык, йортыбызның ничектер берьюлы яме китте һәм, билгеле инде, талап алып китүчеләргә гаять ачуыбыз да килде. Күк айгыр кебек асыл сөякне безгә инде бүтән күрергә туры килмәячәк иде — без моны алдан ук белеп тордык. Аяк урынына тояк дигәндәй, атакай әлеге арык карт алашаны карарга, ашатырга, җәрәхәтен дәваларга тотынды. Һәм озакламый ул безгә бик кирәк тә булды.

Әйткәнебезчә, көз кергән иде инде, тагын сугыш якынлашып килә, дигән сүзләр ишетелә башлады. Кызыллар Бәләбәй тирәсендә генә, имеш, ә Бәләбәй белән Дәүләкән арасы, күп булса, 60—70 чакрым чамасы булыр. Кайчан килеп җитәрләр? Бәлки, бик тиз... Ләкин аклар Дәүләкәнне бирергә җыенмыйлар, каты торачаклар, яңа көчләрен монда тарттыралар, дип сөйлиләр. Чынлап та, Дәүләкәндә кинәт солдатлар бик күбәйде, станциягә килгән ачык вагоннардан туплар да бушаттылар, аннары «нимеч ягында» лазарет ачып, шунда яралы солдатларны ташый башладылар. Күренә ки, нык хәзерләнәләр, бу тирәләрдә каты сугышлар булуы бик ихтимал икән.

Кыскасы, урман янгыны шикелле дөрләп безгә тагын сугыш килә, һәм безнекеләрнең башына тагын «нишләргә?» дигән кайгы төшә. Хәер, мондый курку һәм борчылу күпләрнең башына төшкән булса кирәк. Безнең күрше Борһан абзый да, ишле бала-чагасын төяп, Уфага китеп барды. Аңа хәтле Шәймәрдән абзыйның да китүен әйткәннәр иде. Ә безнең атакай һаман икеләнә иде әле — йортны ташлап китү дә җәл, әмма җан дигән нәрсә дә газиз. Бигрәк тә ул безнең өчен борчыла иде шикелле... Мондый чакта төрле шомлы хәбәрләр күп тарала, кешеләр юри бер-берсен куркытудан гүя ләззәт табалар... Әмма иң нык куркытканы, билгеле, сугыш үзе иде. Иң элек атыш-кырылышлардан башны сакларга кирәк иде.

Ә көннәр уза — таң ата да кич була. Борчылып һәм өметләнеп көткән кызылларыбыз ни сәбәптер һаман әле килеп җитә алганнары юк. Сугыш кайда бара, Бәләбәйдәме, Әлшәйдәме — анысын да юньләп белгән кеше юк.

Һәм менә шундый тыныч көннәрнең салкын бер иртәсендә инәй

безне хәвефле-әкрен тавыш белән генә: «Торыгыз, балалар!» — дип тәмле йокыбыздан уятты. Үзләре күптән торганнар булса кирәк, ашаганнар-эчкәннәр, киенгәннәр, зур-зур төеннәрне дә бәйләп куйганнар. Хәсән җизни белән Зәкия тутакай да килгәннәр икән... Йокыдан айнып җитмәсәк тә өйдәге бу күренештән, бигрәк тә зурларның җитди-киеренке кыяфәтләреннән аңлап алдык: димәк, китәбез!.. Димәк, сугыш килеп җитәргә тора. Хәер, монысын безгә әйтеп тә тормадылар, тиз генә юынып, чәйгә утырырга куштылар. Ашыгырга кирәклеген үзебез дә белә идек. Әзерләп куйган ризыкны кабалана төшеп ашаганнан соң безне, ягъни энем белән икебезне, таза гына итеп киендерделәр. Шул арада төеннәрне, кәрзиннәрне дә арбага чыгардылар. Аннары барыбыз да утырып, озын гына бер дога кылдык. (Минем инде ятлаган бер-ике догам да бар иде.) Шуннан соң кузгалдык, соңгы теләкләрне әйтә-әйтә җыйнаулашып өйдән чыктык. Ишек төбенә тарттырып куйган җигүле атка башта инәй белән безне әйбәтләп утырттылар, аннары атакай дилбегәне кулына алып, итәкләрен җыеп, иске бишмәт салган кучерга менеп утырды. Хәсән җизни капканы ачты, һәм без атлатып кына, канау күперен дөбердәтеп, йортыбыздан чыгып киттек. Юньләп торырга өлгермәгән йортыбызны шул ук җизни белән Зәкия тутакай саклый калдылар.

Бу чакларда атакайның гел аралашып, киңәшеп йөргән кешесе әлеге шул итче Гали абзый иде. (Һәр яктан бер чамадагы кешеләр.) Күрәсең, алар бу юлы да бергә китәргә алдан ук сөйләшеп куйганнар — Дәүләкәнне чыгуга Гали абзыйның тулы аты безне куып та җитте. Тимер хутлы ящик арбасына төеннәрен салган, яшь хатыны белән өч баласын утырткан, үзе исә күчәр башына менеп урнашкан. Атакай аңа алга чыгарга кушты, чөнки аты да безнең өшән алашадан шәбрәк, аннары Гали абзый юлны да яхшырак белә икән. Шулай итеп, ике ат та туңгак юлдан дыңгыр-дыңгыр кояш чыгышына таба карап киттек. Ә сәфәребез бу юлы Уфаның үзенә үк икән! Ләкин ни өчен Уфага? Чөнки Уфа — зур кала, әллә ни ерак та түгел, ә зур калада сугышны хәвефсезрәк үткәреп җибәрергә була торгандыр инде. Аннары Уфада безнең якын туганнарыбыз тора бит, димәк, барып керер, сыеныр кешеләребез бар дигән сүз. Бусы бик мөһим... Ниһаять, сугышлар үтеп киткәч (әйтик кызыллар Уфаны алгач), безгә яңадан Дәүләкәнгә кайтуы да ансат булачак... Шулай уйлаган булырга тиеш минем атам. Башкача уйлавы мөмкин дә түгел, чөнки бу китү вакытлыча, җиңелчә генә — без, әлбәттә, кире үзебезнең яңа гына тора башлаган йортыбызга кайтачакбыз.

Дәүләкән белән Уфа арасын туксан чакрым диләр. Көзге салкын, шәрә, эчпошыргыч бу озын юлны ничек үтүебез бер дә ачык кына, хәтердә калмаган. Көн өстендә генә барып җитә алмадык, билгеле. Шулай да бер нәрсәне ачык хәтерлим: инде караңгы иңгәч зур, калын урманга кердек. Тып-тын урман эченнән күпмедер баргач, бер бик тирән чокырга җиттек. Атларны туктаттылар. Бу чокыр юлның иң хәтәр җире икән. Шушы чокырда еш кына юлчыларны тотып талыйлар икән. Электән үк яман аты чыккан урын, ә хәзер бигрәк тә куркыныч диләр — җыен качаклар шушында, имеш. Атакай белән Гали абзый үзара шыпырт кына нидер сөйләштеләр дә арбаларга сузып бәйләгән озын күсәкләрне чишеп алдылар. (Гали абзый аю сыманрак нелә төшкән калын җилкәле ир, таза кеше — бер үзе биш кешегә каршы торырлык.) Шуннан соң атларның тезгеннән тотып, тыя-тыя гына, бөтен ягын куе агачлык каплаган тирән чокырга төштеләр. Төптә тоныкына челтерәп аккан сай чишмәнең чуер ташлары өстеннән шыбырдап уздылар да, инде тәҗегә тотынып, атларга булыша-булыша каршы якка мендeләр. Тирә-юньдә шылт иткән тавыш та юк, сискәндереп селкенгән ботак та юк, юлга чыккан карачкы да күренмәде — кыскасы, бик

хәтәр булып тоелган бу тирән чокырны без, мең шөкер, әнә шулай исән-имин генә үтеп китә алдык. Бераздан инде урман сирәгәя башлап, ахырда ачык кырга да килеп чыктык. Кыр өсте шактый яктырак булса да, кук зәңгәр төн бихисап йолдызлары белән дөньяны каплап алган иде. Тагын күпмедер киткәч, без бер зур гына авылга барып кердек. Авыл бөтенләй ук тынып бетмәгән иде әле, этләр өргәне дә ишетелгәли, сирәк кенә тәрәзәләрдә утлар да күренә... һәм безнең атайлар шушы авылда куныл чыгар өчен атларын кемнеңдер капкасына борып туктаттылар.

Нинди авыл иде бу, кемһә кердек — мин боларның берсен дә белмим. Каты юлда килә-килә бик ватылган идек, арбада ук инде йоклый да башлаган идек, шуңа күрә җылы өйгә керү белән безне (вак балачагаларны) чишендереп урынга да салдылар. Хәер, башта нидер ашатып алдылар шикелле, ләкин анысы да юньләп хәтердә калмаган — йокы шулкадәр баскан иде ки, без ятар-ятмас гүя тирән чоңгылга чумдык.

Хәзер менә уйлыйм — ул авыл Келәш булмады микән? Чөнки Уфага җитәрәк, юл өстендә башка бер зур татар авылы барлыгын белмим һәм ишеткәнем дә юк. Утырган җире дә тигез ялан түгел иде бугай, әйләнә-тирәсендә калкулыклар, сай чокырлар бар кебек иде. Каян беләсең, бәлки, без чынлап та мәшһүр шагыйрьләр авылында куныл чыкканбыздыр. Хәер, мәшһүр шагыйрьләрнең берсе ул чакта тумаган да булган әле.

Икенче көнне караңгыдан ук торып, чәйләр эчеп, юлга чыктык. Уфа инде якын, 20—25 чакрым чамасы гына диләр. Хәл алып өлгергән атлар җиңел юырттылар. Күзләребез гел алда — еракта. Уфаның ачылганын тизрәк күрәсебез килә, ләкин офыкны, үч иткәндәй, авыр-салынкы ала-кола болытлар каплап алган. Аннары бер заман юлыбыз калын урман эченә кереп китә, ике яклап сузылган куе-таза агачлар арасыннан берни күрмичә озак кына барабыз. Шулай да төш вакыты җитәрәк без ахырда Уфа каршысына килеп чыктык. Менә ул биек тау башындагы зур кала!

Чынлап та биекме соң Уфа таулары?.. Әлбәттә, биек! Миңа, тугыз яшьлек малайга, моның кебек үзе зур, үзе биек тауны моңарчы әле күрергә туры да килгәне юк... Әнә бит аның өстендәге ак таш биналар, чиркәү гөмбәзләре, мәчет манаралары әллә кайлардан ук күренеп тора. Ә тауның битләренә, чокыр-чакырларына сырышкан агач йортлар, кош ояларыдай, әнә ничек вак кына булып күренәләр.

Ләкин каршыбызда ачылган бу күренеш каланың тау башындагы чите генә иде әле. Чын кала үзе каядыр эчтәрәк булырга тиеш. Без аны, чын каланы дим, Агыйдел күперен чыгып, тавына күтәрелә башлагач кына күрдек. Йомры чуер таш түшәлгән һәм сөзәк кенә югары күтәрелгән бер озын урам буйлап дыңгыр-дыңгыр әкрен генә менгән чакта гел уңга-сулга каранып бардык. Монда да йортларның күбесе агачтан, әмма матур-бай йортлар, ике катлылары да шактый, өчәр катлы таш йортлар да очрады. Бер зур бакча яныннан да уздык, бакча эчендәге галәмәт зур чиркәүне күреп, аңа да исебез китте... Бара торгач, бу озын урам (ул хәзерге Фрунзе урамы) татар зиратына барып житә язды. Ахырда ике катлы агач йорт каршында туктадык — монда безнең Шәриф җизниләр тора икән. Без менә шуларга килеп төштек, ә Гали абзый үзенең белгән кешеләренә китте.

Шәриф җизниләргә безнең әле беренче килүебез. Алар инде чын шәһәр кешеләре — үзләре дә, тормышлары да шәһәрчә. Безне яхшы каршы алдылар. Фатирлары шушы чибәр генә йортның икенче катында. Иркен генә зал, берничә бүлмә, зур гына балконнары да бар — аңа залдан пыялалы ишек чыга. Монда җизни, Срур тутакай, алар-

ның бер яшьлек балалары һәм янә җизнинең энисе — куе кара кашлы, озын-чандыр гына карчык — Һаҗәр әби белән Сәгыйть абзыйның (Сәгыйть Сүнчәләйнең) миннән кечерәк Таһир исемле улы да тора иде. Һаҗәр әби нәкъ җизни төсле икән. (Дөресрәге, әлбәттә, җизни энисенә бик охшаган.) Карчыкның кыяфәте генә түгел, тавышы да, сөйләшүе дә улларын бик нык хәтерләтә иде. Сәгыйть абзый бу вакытта кайда булгандыр, белмим, ләкин без аны монда күрмәдек. Улы Таһир авыру бала — йөзе күксел, үзе үтә ябык иде. Әмма акыллы, әдәпле бала булгандыр инде, бер дә ятсынып тормыйча безгә якынлашты, самими бер гадилек белән бөтен булган нәрсәләрен күрсәтергә тотынды. Авыру сәбәпле мәктәпкә йөрмәсә дә, ул инде укый да, яза да белә, рәсем дә ясый белә, өстәвенә мине шашка дигән уенга да өйрәтте. Алгарак күчеп әйтәсем килә: зур үкенечкә каршы, Таһир гомерсез булды, 12—13 яшенә җиткәндә ул үлеп тә китте. Әтисе Сәгыйть абый аның үлемен бик авыр кичергән булырга тиеш. Егерменче елларның уртасында, улы хатирәсенә «Әбү Таһир» имзасы белән ул башкорт телендә берничә кечкенә китап та бастырып чыгарды. Шулай ук соңыннан Әминә Милюшевадан туган кызына да «Таһирә» дип исем куштырган иде. Әмма ни үкенеч, аның бу кызы да гомерсез булды, бик авыр шартларда үсеп, туташ булып җиткәч кенә дөньядан китеп барды [1].

...Шушында торган чакта миңа тагын бер шагыйрьнең улы белән танышырга туры килде. Бу Мәҗит Гафури малае Әнвәр иде. Минем чамада булыр, шактый тере, сүзгә дә юмарт малай иде. Ул чагында Гафурилар шул ук урамда, җизниләргә каршырак бер катлы сары йортта торалар иде. Әнвәр белән ничек танышып китүемне ачык кына хәтерләмим, өйләрендә булмадым, бәлки Әнвәр үзе Таһир янына кергәндер дә шунда танышып киткәнбездер. Ничек кенә булмасын, мин Әнвәргә ияреп, Уфа тавының якын-тирәдәге чокыр-чакыр буйларында бераз йөреп калган идем. Ләкин безнең бу танышлык озакка бармады, җизниләрдән икенче фатирга күчеп киткәч, өзелде, һәм янадан инде беркайчан да ялганып китмәде.

...Кунак булып яту күңелле, әмма торыр өчен үз куышың булырга тиеш. Шуңа күрә тиздән үзебез фатир табып, шунда күчеп киттек. Күченеп барган урамыбыз җизниләрдән шактыйеракта, Спасская дип атала иде (хәзер Новая Мостовая урамы). Аулак кына, тыныч кына, яшеллеккә дә бай гына бер урам. Уфаның башка урамнары белән чагыштырганда артык озын да түгел һәм урамыбызга бер ямь биреп, аның бер башында ак чиркәү, икенче башында ак мәчет күренеп тора иде. Ләкин чиркәү үзе Большая Казанскаяда, ә мөфти мәчете — Тукай урамында — безнең урам исә ике очы белән нәкъ әнә шул ике гыйбадәтханә каршысына барып чыга иде. (Большая Казанская — хәзерге Октябрь революциясе урамы, тик анда мин әйткән мәһабәт ак чиркәү генә юк хәзер.)

Без күчкән йорт та чиркәүгә якын гына иде. Такта белән тышланган күк йорт, асты таш, өске катының зур гына балконлы чардагы да бар. Бай-таза тормышлы кешенең йорты булгандыр ахрысы — ишегалдындагы бүрәнәдән салган, калай белән япкан каретнигы да, ак мунчасы да шуны әйтеп тора сыман. Бу күк йорт хәзер дә әле исән-сау, Уфага кайткан саен мин аның яныннан карап узмыйча китмим. Кайчандыр ачык, якты, матур гына йортны, кызганычка каршы, бозганнар, урамга караган тәрәзәләрнең берсен ишеккә әйләндереп, гади такталардан ямьсез генә болдыр ясап куйганнар. Без күчкән чакларда аны Иблия-

---

[1] Әминә Милюшева — актриса, егерменче елларның ахырында безнең театрда да уйнап китте. С. Сүнчәләйнең хатларын Әминә ханым миңа җибәргән иде. Бу хатлар хәзер Риза Ишморат кулында. Әминә Милюшева — Кировабад шәһәрендә вафат. (Ә. Е.)

мин Әхтәмов йорты дип әйткәннәр иде кебек, әмма Сәлимгәрәй Җантурынныкы булмады микән дип уйларга нигез бар иде. Болар икесе дә ул заманда Уфаның бик билгеле кешеләре иде. Җәмәгать хадимнәре һәм Дума депутатлары. Ләкин борынгырак кешеләрдән күпме сорашып карасам да йортның хуҗасы кем булганын миңа тәгаен генә белеп әйтүче табылмады.

Яхшы хәтерлим, без килеп кергәндә бу йорт буш иде. Барлык бүлмәләрендә җиһазлары тора, ә хуҗалары юк. Димәк, яңарак чыгып киткән булырга тиешләр, билгеле, сугыш аркасындадыр инде. Хәзер уйлыйм, бәлки әле хуҗалар үзләре үк йортларын бөтен җиһазлары белән безнекеләргә вакытлыча тапшырганнардыр — югыйсә башкача без бу яхшы йортка ничек килеп керер идек?! Кыскасы, унсигезенче елның хәвефле кара көзендә, кемнеңдер ашыгыч калдырып киткән йортында без әнә шулай хуҗа сыман тора башладык. Йорт иркен, бүлмәләр зур, җиһазлар шәп — барсы да затлы таза агачтан. Монда чибәр туташлар да торган булырга тиеш — зур көзгеле кием шкафларында алардан ниндидер вак-төяк кием-салым, төрле чүпрәк-чапрак, ефәк тасмалар, нәфис челтәрләр, матур-матур тартмалар, кечкенә ислемай шешәләре дә торып калган иде. Ниндидер ят бер тормышның ватыклары булып күренә иде безгә аз гына хуш ис аңкыткан нәфис вак әйберләр...

Билгеле, мондый йортны үзебез генә биләп, барысын да саклап тору читен булгандыр инде, озакламый ике янәшә зуррак бүлмәгә итче Гали абзый да бала-чагалары белән килеп керде. (Ә без зур зал белән кечерәк бер бүлмәдә калдык.) Шулай итеп, ике семья бергә килгән идек, бергә тора да башладык.

Ләкин бу йортның тагын бер күз-колак булып торучысы бар иде. Ул — дворник Хәйретдин абзый. Кара сакаллы, караңгы чырайлы, авызыннан сүзе чыкмас бер кеше. Әмма йорт-җирне гүя үзенекедәй бик уяу саклый, капкадан чит кешене түгел, ят этне дә кертми, һәр көнне иртә таңнан ишегалдын, урам якны кыштыр-кыштыр себереп, җыештырып кына тора, хәтта безнең кебек вак малайларга да ихатада иркенләп уйнарга ирек бирми иде. Аны, хуҗаларына бик бирелгән, бик тугрылыклы кеше, тизрәк шуларның әйләнеп кайтуын гына көтеп тора, дип әйтәләр иде. Мөгаен, ул ниндидер Нигъмәтҗан, итче Гали кебек билгесез вак сатучыларның Дәүләкән шикелле базарлы саладан килеп, Уфаның атаклы кешеләре йортына хуҗа сыман кереп утыруларын бер дә яратмагандыр — моны аның бөтен кырыс-караңгы кыяфәтеннән ничектер сизеп тә була иде.

Бу абзыйның тәбәнәк, тулы гына хатыны (исеме онытылган) һәм Маһинур исемле бик чибәр җиткән кызы да бар иде. Алар таштан салынган аскы катның ишегалдына караган башында торалар иде. Сугышлар беткәч тә, йорт дәүләт кулына күчкәч тә Хәйретдин абзый шул подвалыннан чыкмаган — моны миңа күп еллардан соң ишетеп белергә туры килде.

Ә без чардаклы йортта тыныч кына торып ятабыз. Кышка да кердек, урамнарны, йорт түбәләрен ап-ак, йомшак кар каплады (ул чакларда Уфа карлары бик чиста була торган иде). Ләкин безне урамга чыгармыйлар, хәвефле вакыт, диләр. Чыксак та капка төбеннән ерак китмибез, шәһәр белән таныш түгелбез, урамнарын белмибез, китсәк, адашырбыз дип тә куркабыз... Минем бит әле мәктәпкә дә йөри торган чагым. Укуны бер дә калдырасым килмәгән иде. Җизниләрдән күчмәс борын мине Сабир хәзрәт мәдрәсәсенә илтеп тә биргәннәр иде, ләкин бирегә күчкәч, ара бик ерагайды (бөтен шәһәр аша барырга кирәк), өстәвенә суыклар да башланды, шулай итеп укырга йөрүдән туктарга туры килде. Хәзергә исә без «дөньяны» күбрәк тәрәзәдән генә күзәтәбез. Сугышның әле килеп җиткәне юк. Шомланыбрак булса да без аны бик кызыксынып көтәбез, чын сугышны якыннанрак күреп, һич югы

тавышын ишетеп каласыбыз килә, тик зурлар гына бик хәвефләнеп, көн дә догаларын укып, аның бәла-казасыз тизрәк үтеп китүен теләп торалар.

Һәм менә яңа (1919) елның нәкъ беренче көнендә Уфага кызыллар кергәнен ишеттек. Бәй, кай арада, ничек болай ансат кына? Без бит бернинди атыш тавышлары да, «Ура» тавышлары да ишетмәдек. Баксак, алар кичә үк кергәннәр икән. Аклар сугышмыйча гына сыздылар микәнни?!. Зурларның тыеп маташуына карамастан, тизрәк киенешеп урамга чыктык. Ә урам буш, урам тып-тын, бернинди кызыл солдат та күренми... Тик бераздан гына каядыр шәһәр үзәгендә тынлы оркестрның дәртле генә уйнаган тавышын ишеттек тә Большая Казанская буйлап шул якка таба бер төркем атлы солдатларның тупыр-тупыр чаптырып узганнарын күреп калдык. Әһә, әнә кайда икән ул тамаша!.. Әгәр без әз генә зуррак булсак, атайлардан куркып тормасак, ике дә уйламыйча тизрәк шул тарафка чапкан булыр идек... Юк, бер дә әйбәт түгел икән мондый «кызык» чакларда бәләкәй булып калуы... Күп ме нәрсәне күрмәдек һәм белмәдек без.

Уфада кызыллар... Бу зур вакыйга булырга тиеш. Аны без дә әзрәк сизәбез. Кышның үзәге, каты суыклар башлануга карамастан, урамнарда кешеләр бик күбәйде. Бик ашыгып, бик эшлекле кыяфәттә йөриләр... Аклар вакытында каядыр югалып торган безнең Шәриф жизни дә өенә кайткан. Ләкин Срур тутакайның әйтүенә караганда, аны без түгел, үзләре дә юньләп күрә алмыйлар икән. Эшләре гаять күп, көне буе митингларда йөреп, төннәрен редакцияләрдә уздыралар, ди. Ә безнең өчен тормыш һаман искечә кебек, безнең тирәдә хәзергә бернинди дә үзгәреш юк.

Ләкин шулай да бер вакыйга минем хәтердә саклана, чөнки ул вакыйга нәкъ менә без торган йортта булды. Кызыллар кереп, күпмедер вакыт узгач, дворник Хәйретдин абзыйның әлеге чибәр кызын — Маһинур апаны бер гаскәригә кияүгә бирделәр. Кияү тиешле абый түгәрәк ак битле, зур соры күзле, көләч, сөйкемле генә бер егет иде. Ул заманда гади солдат белән командирны аеруы ансат түгел, бу егет тә гади солдат кынамы, әллә берәр командир-мазар идеме, ачык кына белмәдек. Әмма туена, аскан коралларына һәм тотыш-кыланышларына караганда, шактый зур кешеләр җыелган иде. Тагын истә шунысы калган: егетне бик шәп итекче диделәр. Командирларга иң әгъләә итекләрне ул гына тегә, имеш. Ләкин шуның өчен генә бирегә зур кешеләр җыелмагандыр инде. Егет үзе бәләкәйләрдән түгелдер, ахрысы...

Ә туен безнең буш торган зур залда үткәрделәр. Ашау-эчү дә вакытына күрә ярыйсы гына иде шикелле — кияү үзе тапкан, үзе китергән, дип әйттеләр. Минем инәй туй ашларын әзерләшкән иде шул чакта. Бу чын мәгънәсендә хәрбиләр туе иде. Зал тулы кызыл гаскәриләр, һәммәсе дә бер чамадагы какча ирләр, араларында берничә генә хатынкыз, ләкин алары да хәрби киемнән. Тик Маһинур апа үзе дә булышырга килгән бер-ике ахирәте генә алар арасында ак күгәрченнәрдәй аерылып тора иде. Әмма шундый бер генә төрле кунаклар җыелуга карамастан, мәҗлес бик җанлы узды. Күрәсең, мондый туй мәҗлесен бик сагынганнардыр инде, саратский гармунны өзелгәнче уйнатып, тәмам биһуш булганчы җырладылар, биеделәр, ара-тирә ялкынлы нотыклар да әйттеләр. Тик шунысы гаҗәп, кыз ягыннан бу мәҗлестә хуҗа тиешле кеше юк иде. Кызның атасы Хәйретдин абзый туйның башында да, ахырында да бөтенләй күзгә күренмәде. Чакырып карасалар да, менмәгән, кулын гына селтәгән, имеш! Нигә мондый тискәрелек, сәбәп нәрсәдә?.. Ул, янәсе, башта никах укытуны таләп иткән булган, ә кияү буласы егет, хәзер аның кирәге юк, бик теләсәгез, миннән башка гына укытырсыз дип әйткән, имеш. Бәлки бүтән сәбәпләр дә булгандыр, ләкин туй әнә шулай кызның атасыннан башка гына дәвам итте. Хәер,

аңа карап кына мәҗлес бер дә сүрелеп, тукталып тормады. Шул ук хәрбиләрдән постау френч кигән кара мыеклы берәү, ике якның да ага тиешле кешесе дәй, озын өстәлнең түр башында аягүрә торып, мәҗлесне бик матур алып барды. Дәрәҗәсе белән дә өстенрәк булгандыр инде, чөнки ул боера, ул куша, котлау сүзләрен дә күбрәк ул әйтә иде. Аның кушуы буенча кызның әнисен дә чакырып керттеләр — ак батист яулыгын йөзен яшерә төшеп бәйләгән йомры-тулы гына абыстайны иң түргә уздырып, кунаклар берәм-берәм каршысына чыгып, бик түбәнчелек белән аңа ниндидер зур мактау сүзләре әйттеләр. Абыстай яулык чите белән яшьләрен сөрткәләп, аларны тыңлагач, әкрен генә рәхмәт әйтеп, шунда ук кире чыгып та китте. Югалыбрак калган кыяфәтенә караганда ул шатланырга да, кайгырырга да белмәгән бер хәлдә иде шикелле...

Без туйның бары тышкы, шау-шулы ягын гына күрдек, эчендәге хәлләрне, туйга кадәр һәм туйдан соң нинәр булганын белми дә калдык. Бер төркем хәрбиләр бер кич шаулап утырдылар да таралдылар, ә икенче көнне егет Маһинур апаны каядыр алып та китте. Һич көтмәгәндә, уйламаганда! Сугыш вакыты бит әле, җитмәсә!.. (Хәер, сугыш дип тормаганнар, җае чыкса өйләнешә биргәннәр.) Ләкин шулай да соңыннан, күп еллар узгач инде, төш шикелле генә булып калган ул сәер туйны искә төшергән чакларда мине, нигәдер борчып, һаман бер нәрсә уйландыра иде: кем булды соң ул егет, кая алып китте икән чибәр кызны, өйләнешүнең ахры ни булып бетте икән?..

Әлбәттә, егет командирларга итек тегүче гади солдат кына булмагандыр инде. Булса, бәлки элек итекче булгандыр, әмма хәзер ул ниндидер зур гына хәрби урын биләп торучы булырга тиеш. Моны аның үз-үзенә нык ышанган тәвәккәл кыяфәте дә, хөр сөйләшүе, иркен хәрәкәтләре дә, хәтта өстендәге кием-каешлары да күрсәтеп тора иде. Кунакларының да бит күбесе командирлар да комиссарлар иде, димәк, ул үзе дә шулар дәрәҗәсендәге кеше булгандыр инде.

Аннары Маһинур туташ, ай-һай, гади солдатка гына чыгар идеме икән? Ул бит ни җитте генә кыз түгел иде. Күзгә бәрелеп торган бер сылу, матур иде. Шәһәрдә үскән, һичшиксез, мәктәп күргән, ниндидер матур гадәтләрне дә отып алган — үзен бик мөлаем тота да белә, каушамый-кызармыйча сөйләшә дә белә. Туйда да бит аңа һәммәсе бөгелә биреп, «туташ» кына дип дәштеләр. Юк, Маһинур туташ кемгә чыгуын бик яхшы белеп чыккан булырга тиеш.

Кызыллар ул чагында Уфаны кулларында озак тота алмадылар, ташлап чыгарга мәҗбүр булдылар. Шәһәрдә тагын аклар... Дөрес, озакка түгел, берничә айдан кызыллар аларны яңадан сөреп чыгардылар. Бу юлы инде бөтенләйгә!.. Маһинур апа кияве белән Уфага кире кайттылармы-юкмы — белмим, һәрхәлдә, безнең тирәдә күренмәделәр. Ә сугыш дәвам итә, кызыллар акларны куалар, сугыш Себергә, аннары ерак Көнчыгышка барып җитә. Безнең яшьләр дә бәлки шул юлларны узганнардыр... Исән булсалар, бер кайтырга тиешләр.

Ә монда Хәйретдин абзый юаш-сабыр карчыгы белән икәү генә үзенең шул ярымподвалында торып ята. Киндер алъяпкычын бәйләгән, себеркесе-көрәге кулында, һәркөн караңгыдан торып, кыштыр-кыштыр урам себерә, ишегалларын көри. Гүя, дөньяда яшәүнең мәгънәсен дә ул бары шушы ялгызак эшеннән генә таба иде.

Аклар Уфаны яңадан, ялгышмасам, мартның урталарында алдылар. Кояшлы көннәр иде, челтәрләнеп, уалып карлар эри, түбәләрдән шабырдап тамчылар коела. Менә шундый көннәрнең берсендә, иртән торсак, шәһәргә аклар кереп тулган. Урамга чыксак, бездән ерак та түгел, урам уртасында карга йөзтүбән капланып бер кеше ята. Барып карадык. Өстендә бер кат эчке күлмәк тә зәңгәр галифе, итекләрен

салдырып алганнар, ак чолгаулары гына торып калган. Яланбаш, куе бөдрә чәчләре кан белән укмашып каткан. Башына атканнар... Мин күз генә салдым да тизрәк кире чаптым. Кем булгандыр инде ул, ләкин гади солдат кына булмаска тиеш, кызылларның шәһәрдән китеп өлгермәгән берәр зуррак кешесе булмады микән?..

Әнә шулай, кешене ансат кына үтереп ташлаганнар. Мине бу куркытты — үтерүнең җиңел, гади генә эш булуы куркытты. Менә ни өчен илбасарлар кан коюдан туя алмыйлар икән... Чөнки кызгану юк, чөнки үтерү ансат, шуңа күрә кешеләр бер-берсен никадәр күбрәк кырсалар, шулкадәр үзләрен көчлерәк саныйлар! Белмим, мин болай уйлый алдыммы икән ул чагында, әмма куркуымның төбендә кемгәдер түгел, ә сугышның үзенә нәфрәт яткан булырга тиеш дип әйтә алам.

...Инде җәйгә дә кердек. Урамдагы агачлар, чокыр буендагы карт тирәкләр ямь-яшел яфракта. Алма бакчалары бер атна буена ак күбеккә күмелгәндәй, чак кына бал исе аңкытып, күпереп утырдылар. Койма буйлары, канау читләре яшь үләнгә күмелде, юлдагы таш араларыннан да төртеп чыкты — ул чакта безнең урамда асфальт дигән нәрсә юк иде. Без инде көне буе тышта, урамда, чокыр буйларында йөрибез, кайчагында чит малайлардан куркып тормыйча Спасский урамының аргы башына Мөфти мәчете каршысына ук барып чыгабыз. Мәчет үзе иркен ихата эчендә, ә урам буйлап аның яшел калай түбәле озын таш коймасы сузылган. Бик матур, шактый киң урам, нәкъ уртасыннан тар гына бакчалар тезелеп киткән. Менә шуларның берсеннән икенчесенә әйләнмәле капкаларын үтеп бара торгач, Иделнең текә яры өстендәге үзенең чокыр-чакырлары, борылмалы юллары, биек агачлары һәм куе куаклары белән гаҗәп кызыклы, күңелле, ямьле икенче бер зур гына бакчага барып керәсең... Бу бакчаны ул чакта Случевский бакчасы дип йөртәләр иде, ә аңа илтә торган киң урамны ул чакта ук инде Тукай урамы дип атыйлар иде (хәтеремдә шулай саклана). Аннары безнең үзебездән ерак та түгел тагын бер бакча булган әле — без җәйгә чыккач аны «таптык». Бу хәзерге Луначарский бакчасы... Карт бакча булса кирәк, ул чагында ук инде агачлары юан, биек, очлары бер-берсенә тоташып, бөтен җирне күләгәләп тора иде. Аның бер коймасы безнең урамга да карый, без шуның тактасы каерылган җиреннән кереп йөри идек. Эчендә агачтан эшләнгән матур-матур корылмалар бар, бер читтәрәк кечерәк кенә тымызык күле дә бар, әмма бакча үзе көндезләрен бөтенләй буш, тып-тын, беркем, бер адәм заты да күренми иде. Шуңа күрә анда кергәч, безгә ничектер шомлырак та булып китә иде... Ләкин кышны сукыр тычкан шикелле йорт тирәсеннән китмичә үткәргәнгә күрә, безнең хәзер җәйге хөрлектән файдаланып, күбрәк йөрисебез дә, күбрәк күрәсебез дә килә иде. Мәсәлән, синтральный урамны! Әле Дәүләкәндә чакта ук минем: «Уфа диләр, Уфа диләр — Уфаны күрсәң иде, Синтральный урамында подручка йөрсәң иде!» — дип җырлаганны да ишеткәнем бар иде. Баксаң, ул «Синтральный» бездән ерак та түгел икән. Большой Казанский буйлап, берничә чат кичкәч тә нәкъ уртасына барып чыгасың. Нәрсә күрдек без анда? Зур-зур таш йортлар күрдек, урам уртасыннан шак та шок чаптырып узган извозчикларны күрдек, аннары бик әкәмәт киенгән хатын-кызларны һәм көяз эфисәрләрне күрдек. Алар, үтеп-сүтеп йөрүче гаскәриләр, шактый күп иде монда, ләкин безнең иште малай-шалай бөтенләй юк диярлек — күрәсең, иртәрәк әле безгә синтральный урамнарда йөрергә.

Әнә шулай зур кала белән чынлап таныша башлагач кына тагын хәбәр таралды: кызыллар, имеш, Уфага якынлашып киләләр! Бик яман киләләр ди, Дәүләкәнне алганнар, инде Чишмәгә җиткәннәр, имеш!.. Бу юлы да акларның гомере кыска булып чыкты, март урталарында кергәннәр иде, ә хәзер июнь башлары,— димәк, өч ай да торырга өлгер-

мәгәннәр. Сугышның якынлашуын бик тиз сизә дә башладык. Шәһәрдә ыгы-зыгы көчәйде, солдатлар күбәйде, кичләрен урамнарга чыгып йөрүләр бетте (катгый рәвештә тыелган дип әйттеләр), ә бер ике-өч көннән каядыр еракта тонык кына күк күкрәгәндәй туп тавышлары да ишетелә башлады. Ул да булмый, калага яралы солдатларны да ташый башладылар. Большой Казанскийдагы өч катлы зур гына таш йортка аяклары, куллары, башлары ак марля белән чорналган, күбесенең каннары да саркып торган яралыларны арбалардан бушатканнарын мин үзем дә күреп тордым.

...Тагын бер нәрсә минем күз алдымда: кызыллар килеп керергә икеме-өчме көн калгач кына безнең ишегалдыннан ике туташның бер генә ат җигелгән тарантаска янәшә утырып, ерак сәфәргә чыгып китүләрен карап калдык. Икесе дә бер чамадагы җиткән кызлар иде, икесе дә тоташ карадан бер төсле үк киенгәннәр иде. Алар бу йортта тормыйлар иде һәм моңарчы күренгәннәре дә юк иде. Шул көнне генә каяндыр килделәр дә, әзер атка утырып, Чиләбе ягына китеп тә бардылар. Дворник Хәйретдин агай туташларны әйбәтләп утыртып, төеннәрен дә иплән урнаштырып, капканы киң ачып, кучердагы абзыйга нидер боерып, озатып калды. Һәм иң гаҗәбе — (бәлки шуңа күрә истә дә калгандыр) — бу туташларны морза кызлары диделәр.

Кызыллар Уфага бик тиз килеп җиттеләр. Июньнең беренче атнасы булды микән — бик матур кояшлы озын көннәр иде, җылы, җилсез, йомшак төннәр, шәһәр бакчаларында сандугачлар да «чут-чут» сайрый иде әле — менә шул чакта Идел ягыннан туп тавышлары гына түгел, кабаланып такылдаган пулемет тавышлары да ишетелә башлады. Димәк, сугыш якын, сугыш каядыр Идел буенда гына!.. Көндез үк Срур тутакай, Һаҗәр әби (җизнинең әнисе) кечкенә Равилне күтәреп, авыру Таһирны җитәклән безгә килделәр. (Җизни үзе юк, аклар кергәч, каядыр яшеренгән.) Алар зират тавына якын гына торалар, түбәндә Идел күпере, кызыллар шуннан киләләр, шәһәргә дә шуннан торып аталар — бик куркыныч икән анда. Ә без шәһәр эчендә, еракта, анналы без торган йортның бик таза подвалы бар — билгеле, монда хәвефсезрәк.. Кичкә таба мендәр, юрганнар күтәреп барыбыз да шунда төштек. Ату көчәйде, каядыр гөрселди, ухылдый, «шап» иттереп тә куя— без «ләхәүлә»не укып, тыңлап кына ятабыз. Төн буе дәвам итте бу мәхшәр!.. Безнең тирәгә снаряд төшеп шартлаганын сизмәдек, әмма шәһәрне тетрәткән бер көчле шартлау котыбызны алды алуын... Нәрсә булды, нидер ишелеп төштеме, әллә күккә очтымы — аптырадык, тик соңыннан гына акларның Идел күперен шартлатканын белдек.

Без, ваклар, атышларның кайчан туктаганын белми дә калдык — төеннәр өстендә йоклап киткәнбез. Иртән торсак, дөнья тынган, кояш күтәрелгән, зурлар күптән аяк өстендә, мәш килеп нидер эшләп йөриләр... Аклар чыгып киткәнме, кызыллар кергәнме — белүче юк. Зал якка табын әзерләгәннәр, һәммәсе бергә чәй эчәргә җыеналар. Сугыш әз генә тындымы, кеше үзенең гадәттәге эшенә тотына икән. Мин моны соңыннан, Ватан сугышы вакытында күреп тә гаҗәпләнгән идем. Әйтик, немецлар бер станция тирәсен бик каты бомбага тотып китәләр, йортлар җимерелә, яраланучылар, үлүчеләр дә була, ә тере-исән калганнар аз гына исләрен җыйгач та үзләренең эшләренә тотыналар — мичен яга, ашын пешерә, керен юа, дуңгызын, тавыкларын карый... Әнә шулай кеше дигәнең, үлем-һәлакәт дип тормый — һаман да яшәвен белә!

Мәгълүм булганча, Уфаны легендар Чапай дивизиясе азат итә, шәһәргә дә беренче булып Чапай дивизиясе керә. Ләкин кайсы числода, кай вакытта? Мин моны бары хәзер генә язма чыганакларга (мәсәлән, «Уфа тарихы» дигән китапка) карап ачыкладым: Чапай дивизиясе Уфага 1919 елның 9 июнендә, кичке сәгать 8 дә кергән! Ә без моны ба-

ры икенче көнне генә белдек — икенче көнне инде шәһәр терелгән, халык урамнарга сибелгән, йортларга кызыл флаглар эленгән иде. Бу инде якты, күәшле чын бәйрәм көне иде!

Уфаны аклардан азат итү әнә шулай шактый тиз тәгәлләнде, сугыш каядыр Урал эченә таба китте, без дә, ниһаять, тынычландык диярга ярый. Хәзер инде сугыш якынлашкан саен башны саклар өчен андамонда китеп йөрергә туры килмәс, алла бирсә! Бик әйбәт, хәзер тотарга да Дәүләканебезгә кайтып китәргә!.. Ләкин без тиз генә кайтып китә алмадык. Сәбәбе — атыбыз юк, безнең яктан атта килүчеләр дә юк, ә поезд белән кайтырга тимер юл күпере ватык... Шулай итеп, җәйне ирексездән Уфада үткәрергә туры килде. Торуыбыз һаман шул ук күк йортта, тик без аның икенче катыннан югарыдагы иркен чардагына күчтек. Бу чардакта безнең шикелле үк башын саклар өчен Бөредән килгән Мостафа исемле кеше бала-чагалары белән тора иде — менә шулар, Уфа тирәсендә сугыш беткәч тә үзләренең шәһәрләренә кайтып киттеләр. Шулай ук икенче катның янәшә ике бүлмәсендә торучы Гали абзый да гаиләсе белән башка фатирга чыгып китте. Зур йорт берьюлы бушап калды. Түбәндә, подвалда дворник Хәйретдин абзый, югарыдагы чардакта без, ә менә уртадагы бушап калган зал белән бүлмәләргә кемнәр кергәндер — һич кенә дә хәтерли алмыйм. Әллә инде контора иттеләр? — юк, белмим! Тик бер генә нәрсәне беләм, бу йортта энем белән миннән башка бүтән бала-чага калмады.

Ә уйнарга малайлар кирәк. Җәйнең иң матур айлары, көннәр дилбегәдәй озын, вакытны кая куеп бетерерлек түгел. Күрше-тирәдә дә безгә тиң татар малайлары күренми — нишләргә, кайдан табарга?!

Қайчагында, ара ерак булса да, Таһирны күрергә дип җизниләргә баргалый идек. Безне монда бик әйбәт каршы алалар, бигрәк тә Таһир янына килүебез өчен куаналар, чөнки ул, бичара, авыру бала, урамга чыгып йөрерлек хәле юк, гел диярлек өйдә генә утыра. Җизнинең әнисе һаҗәр әби дә бәрхеттәй йомшак тавышы белән: «Менә, Таһирымның дуслары килгән, рәхмәт төшкерләре, әйдә узыгыз, уз, сөеклеләрем!» — дип каршы ала иде.

Таһирның уенчыклары да, китаплары да күп. Без аларның иркен балконнарына чыгып, шуның чиста идәнендә рәсемле китаплар актарабыз, шашка да уйнап алабыз, эре шакмаклардан биек йортлар да өябез. Таһир бик юмарт малай иде, теләсә нәрсәсен үзе үк безгә көчләп бирергә тырыша иде. Билгеле, аның безне бер дә җибәрәсе килми, ә без таза малайлар, безне урам тарта, урамга чыгып, Идел тавының чокыр буйларында йөрисебез килә. Таһирның хәтерен саклап һәм һаҗәр әбидән дә уңайсызланып түзә алган кадәр утыргач, без шулай да кузгалабыз. Нигә болай бик тиз, дип гаҗәпләнәләр һаҗәр әби дә, Срур түтәкәй да, ләкин барыбер безне чәй эчермичә җибәрмиләр. Ә Таһир боек, бер сүз дә әйтми, гүя үз хәлен аңлый, без чыгып киткәндә әбисенә тотынып, ишек төбендә басып кала. Бәлки, соңыннан әкрен генә җылый да торгандыр... Менә хәзер искә төшкәндә үкенү хисе бәгырьне сыкратып куя: ник без, ике юньсез, Таһир мәрхүмне шулай нәүмиз калдырып киттек икән?!.

Уфада электән үк торучы Каргалы халкы күп, шулар арасында безгә бик якын туганнар да бар. Аларның берсе Мортаза җизниләр, икенчесе — Ибраһим абзыйлар. Дәүләканнән килгәч, без һәркайсында кунакта булган идек, ләкин кышкы айларда барып йөрергә туры килмәгән иде. Ә хәзер җәйгә чыккач һәм сугыш куркынычы да үтеп киткәч, без ике малай аларны да искә төшердек.

Мортаза җизниләр Иске Уфада торалар, житеп килгән ике кызлары бар (Рәкыя апа белән Суфия), тик малайлары гына юк. Шулай да без, ара ерак булуга карамастан, берме-икеме тапкыр аларга да бардык. Әйтергә кирәк, безнең халык бала җанлы, төче тел белән сөеп (без-

неңчә, сүэп) каршы ала, янәшә утыртып сыйлый, сораша, мактый, ә озатканда изге теләкләр теләп кала. Әле ялгыз гына җибәрмиләр дә — кичерәге Суфия апа безне җитәкләп дигәндәй өебезгә чаклы китереп тә куя иде. (Бу туташлар турында алда сүз булачак әле.)

Икенче якын кардәшебез Ибраһим абзыйлар бездән ерак та тормыйлар иде. Әнә безнең урамның аргы очында Мөфти мәчете күренеп торамы — менә шул гөмбәзле мәчетнең артындагы Бельская дигән урамда аларның йортлары. Бу йортка инде без бик теләп барабыз, чөнки анда берьюлы өч малай — Хәбибулла, Идиятулла һәм Хәсән. Янә ике кызлары да бар — иң олысы Мәхмүзә тутакай, иң кечесе Рәисә. (Төпчек кыз, бик чибәр иде ул, соңыннан, Казанга килгәч, профессор Хәмит Мөштәринең җәмәгате булды.) Өч малайның миңа тиңрәге Идиятулла — бөтен уенбыз, йөрүебез аның белән иде. Урамнары Уфа тавының нәкъ кашыннан уза. Тау биек, текә, чокырлы-чакырлы, ак ташлар чыгып тора, тар сукмакларда кәҗәләр йөри, түбәндә Агыйдел ялтырап ята. Иделнең аръягы кара яр, тар аланлык, шуны үткәч тә куе урман башлана: үнда челтәрле тимер күпер, сулда тәбәнәк кенә агач күпер — шуны чыккач та калын урманны кисеп, еракка-еракка озын юл китә. Бу юлны Ырынбурга чаклы барып җитә диләр. Иделнең аръягын ул чакта «чегәннәр аланы» (цыганская поляна) дип йөртәләр иде. Ләкин без, әле бәләкәй булганга күрә, ул якка чыгып йөрергә курка идек, әмма бу яктагы су читенә текә, ташлы сукмаклардан көненә ничә төшеп, ничә генә менми идек — кош йөрәге кебек булган ул чакта безнең йөрәкләр.

Әйе, без әле уйнау, шаяру, чабудан башканы белмибез, ачыккач кайтып ашыйбыз, арыгач ятабыз да йоклыйбыз. Без зурлар дөньясыннан читтә, без үзебезнең кечкенә дөньябызда яшибез. Шулай да зурлар дөньясыннан бер «кызык» безгә дә кучте, бу — сугыш! Без дә, берничә малай җыелып, зурлар кебек «аклар», «кызыллар» булып атышабыз, куышабыз, егылып үләбез яки плен төшәбез. Әлбәттә, җиңүче бары тик «кызыллар» гына!.. Уфа урамнарында кызыл йолдызлы, корал аскан хәрбиләр бик күбәйде, гомумән, шәһәр бик җанланды, хәрәкәт, шау-шу көчәйде, әмма кайда ниләр эшләнә — анысыннан без хәбәрсез. Ләкин шулай да бер бик мөһим вакыйганы мин үз күзләрем белән күрдем. Әлеге аклар ваттырып киткән тимер юл күперен Уфа эшчеләре ничектер тиз арада гына яңадан торгызганнар иде. Агыйдел ярында менә шул күперне ачуга багышланган тантана булды. Халык күп җыелган иде. Без, малайлар да, шунда чабышып бардык. Күпернең бер башы белән яр читенә җимерелеп төшкән челтәр торыгын (пролетын) калын бүрәнәләрдән киң-таза бура итеп өелгән терәк өстенә күтәртеп куйганнар. Юлны ялгаганнар. Хәзер шуны сынап карау булырга тиеш.

Уфа станциясе ягыннан ком-таш төягән берничә ачык платформаны артыннан этәреп, кара паровоз килде. Күпер алдында бераз гына туктап торды. Аннары, зәһәр генә кычкырткannan соң, платформаларын этәреп, бик әкрен генә күпергә керә башлады. Халык тын да алмыйча карап тора — нишләр, бүрәнәләрдән өелгән терәк күтәрерме, исән генә үтә алырмы? Ә паровоз һаман әкрен генә керә-керә, ниһаять, күпернең хәтәр җирен үтеп китте. Каты итеп гудок бирә-бирә, аргы якка кызу гына барып та чыкты. Бу якта тынлы оркестр дәртле генә марш уйнап җибәрде, халык кулларын болгый-болгый кат-кат «Ура!» кычкырды. Бик кызыклы, бик күңелле булып калды бу тамаша безнең өчен дә... Әмма кызыклы гына түгел, гаять әһәмиятле дә булган ул тамаша. Менә шуны күрергә туры килде безгә!

Әнә шундый вакыйгаларга бай «кызыклы» җәйне үткәреп, көз кергәч тә без үзебезнең Дәүләкәнебезгә кайтып киттек. Алып кайтучылар — очраклы юлаучылар иде. Агыйдел аша агач күпердән дөбердәп чыкканнан соң биек тау башындагы зур калага һаман борылып карый-

карый бардык. Бик әкрен һәм бик озак ераклаштык без аңардан... Аерылышу һәрвакытта ямансу!.. Без аның төз озын урамнарына, биек таш яки матур агач йортларына иялəшкəн идек, үзебезне инде чын шәһәр малайлары итеп тә тоя башлаган идек — кайткач, бәләкәй генә Дәүләкәнебезгә тиз генә күнегә дә алмабыз кебек иде... Хуш инде, хуш, биектәге ак кала! Син безне онытсаң да, без сине онытмабыз беркайчан да!

Һәм әйтергә кирәк, Уфа чынлап та минем исемнән бер вакытта да чыкмады. Мин аңа һәрвакытта бик теләп, сагынып кайтам. Егет чагымда да һәм менә картайгач та... Асылда бит Уфа — ул минем туган калам. Уфага якын җирләрдә мин туып-үскәнмен. Иң якын туганнарым да Уфада яшиләр. Мин үзем дә Уфага кайтып яшәү турында күп уйландым. Иң элек аның коры тау һавасы миңа килешә, авыру йөрәккә сулавы җиңелрәк анда. Соңгы елларда мин моны аеруча ныграк сизә башладым... Һәм, гомумән, Уфа таза шәһәр, яшеллек тә күп, чиста да ул.

Бик табигый рәвештә укучыда:

— Нигә алайса Казанга киттегез, нигә Уфада гына торып калмадыгыз?— дигән сорау туарга мөмкин.

Моның бер сәбәбе шунда ки, мин кече яшьтән диярлек татар әдәбиятын укып үстем. Казан ул минем өчен кәгъбә сыманрак бер җир иде. Әдәбиятка керәсе килгән һәркем шунда барырга тиеш кебек иде. Аннары Казан — элек-электән үк үзенең уку йортлары белән танылган шәһәр. Анда белемнең, һөнәрнең төрлесен алырга була. Революциядән соң уку йортларының төрле милләт яшьләренә кайчандыр бикле ишекләре, ниһаять, киң итеп ачылды. Егерменче еллар белән утызынчы еллар арасында бер Башкортстаннан гына күпме яшьләр шәһәри Казанга укыр өчен агылып килмәде? Менә шул агымга ияреп мин дә киттем. Минем дә төп максатым, билгеле, уку иде. Хәер, дөресен генә әйткәндә, Казан һәрбер белем эстәп килүчене кочагын җәеп каршы алмады. Берәүләр максатларына тиз ирештеләр, икенче берәүләргә ирешүләре шактый авыр булды. (Ул чакларда социаль чыгыш дигән нәрсә еш кына кешенең язмышын билгели иде.) Әмма ничек кенә булмасын, мин дә шушы бик теләп, бик хыялланып килгән каламның шактый ук комлы туфрагына азаплана торгач тамыр җибәрә алдым, кәкрәеп булса да үстем, әчерәк булса да җимешләр дә биргәләдем... Мин инде карт агач, ә карт агачны, үзегез беләсез, күчереп утыртырга ярамый — бөтенләй корып китүе бар.

Шулай да, яшерә алмыйм, Уфа мине тарта. Ничектер менә яшьтән үк мәхәббәтем төшкән бу калага. Бигрәк тә Уфаның иске үзәге, шул үзәккә килә торган төз урамнары, шул урамнардагы капка-коймалы, алма бакчалы җыйнак кына матур йортлары әле дә булса исемнән чыкмыйлар. Бигрәк тә мин күп йөргән Тукай урамы, «Госмания» мәдрәсәсе тирәләре, текә яр өстендәге «Случевская» (хәзер Крупская) бакчасы ничектер аеруча җанга якын урыннар булып хәтердә сакланалар. Әгәр кодрәтемнән килсә, мин шушы «Госмания» мәдрәсәсе белән Аксаков йорты урнашкан мөешне бер дә кул тидермичә саклаткан булыр идем. Иске Уфаның үзенә күрә бер кабатланмас почмагы, шунда кайчандыр Аксаков яшәгән, шунда ук безнең шәкертләр укып йөргәннәр... Кызганычка каршы, мин «Галия» мәдрәсәсе урнашкан тирәләрне яхшы белмим (без аннан ерак тордык), хәлбуки, Уфаның демократик яшьләре шунда тупланган, халыкка кирәк чын мәгърифәт тә шуннан таралган булырга тиеш.

Уфа соңгы бер утыз ел эчендә искиткеч үзгәрде, галәмәт үсте, зурайды. Иң күп өлеше бер, ике катлы агач йортлардан гыйбарәт иске

кала сүтелеп бетте дияргә ярый. Хәзерге Уфа ул тоташы белән диярлек зур-зур биек йортлардан торган таш кала. Озынлыгы аның, чын булса, 100 километрга җитә диләр. Шуңадыр инде Уфада метро төзү чарасына да керештеләр.

Уфада торучылар Уфаны бик яраталар. Билгеле, аларга хәзерге Уфа ошый, хәзерге Уфа кадерле, шуңа күрә минем «искесен» сагынуымны, ихтимал, аңлап та бетермәсләр. Әмма хатирәләр бит үзләре искермиләр — хатирәләр шуның белән кадерле дә.

...Менә без яңадан үзебезнең Дәүләкәндә! Йортыбыз исән-сау торган, кызыл сыерыбыз да исән-сау, күршеләр дә сау-сәламәт. Дәүләкәннең үзенә дә берни булмаган. Диме, тугае, күлләре дә әүвәлгечә җәйрәп ята — шәп иттек без өебезгә кайтып!

Хәзер инде сугыш Дәүләкәннән ерак китте, яңадан әйләнеп килмәскә тиеш. Кызыллар акларны Себер буйлап куалар дип сөйлиләр. Бусы бик әйбәт. Ләкин шулай да вакыт хәвефле, талау-үтерүләр дә ишетелгәли (авыллар арасында ниндидер кораллы бандитлар йөри, имеш), яшәү шартлары да авыр, ачлык, бөлгенлек, һәртөрле чир-зәхмәт хөкем сөрә. Дөньяны бет басты, аны бетерергә һич әмәл юк, тифның котырган чагы. Менә без дә Уфадан кайтып, күпмедер торырга өлгермәдек, өй эчебез белән тифтан егылдык. Башта инәй, аннары мин, аннары энем өч-дүрт атна ут эчендә яттык. Инәй мескен тифны бик авыр үткәргән, саташкан чакларында урын өстеннән торып-торып китә икән. Тик атакай гына ни хикмәттер, авырмыйча калды, ул безне көне-төне карады, өсләребезне алыштырды, урыннарыбызны җыештырды. Тифның эчендә кайнаса да аның үзенә берни дә булмады, ни гаҗәп!.. Ә без өрәкләр шикелле агарып, нечкәреп, тәмам хәлдән тайдык. Бик әкренләп кенә рәткә кердек. Тифтан соң адәм баласында ашыйсы килү бик көчәя икән. Нәфес анысын тели, монысын тели, ләкин кайдан табарга?.. Кибетләр ябык, алу-сату юк, атнага бер килә торган базар да бик ярлы, агайлар азык-төлекне качып-посып итәк астыннан гына саталар. Сыерыбызның да сөтне киметкән чагы. Шәптән түгел эшләр. Шулай да мин ул чактагы тормышыбызны бик үк начар димәс идем. Һәрхәлдә ризыктан аерылмадык. Миңа калса, безнең атакай ул чакларда да тик ятмагандыр, якын-тирә авылларда аның танышлары күп иде, анысын алып, монысын биреп дигәндәй, кирәк нәрсәне тапкандыр, ахрысы. Аннары Ташлыкүлдән Кашшаф җизни дә бәрәңгесен, онын китергәли иде, алар ягы азык-төлеккә һәрвакытта мул булып торды, үзләре дә бик ярдәмчел туганнарыбыз иде.

Тагын безне борчыган бер мөһим мәсьәлә — ул да булса уку мәсьәләсе иде. Күргәнсездер инде, бу елларда безнең укуның бер дә рәте-юне булмады. Бер генә кышны мин тоташ укып үткәрдем. Икенче кышым бер өзелеп, бер ялганып ничек җитте шулай үтеп китте. Уфага баргач, тагын шул сугышлар аркасында өйдә генә утырырга туры килде. Гаеп атайларда да булды шикелле. Сабир хәзрәт мәдрәсәсенә илтеп биргәч, мине сабакка йөрүдән туктатмаска иде. Имеш, минем әле укырга вакытым узмаган. Ә уку елын югалтуы җәл, мин моны чамалый идем инде.

Ахырда менә, шактый соңга калып булса да, без энем белән икәү Дәүләкән мәдрәсәсенә йөри башладык. Энемнең киндер букча тагып беренче баруы, ә бит аңа да инде сигез яшь!.. Укулар һаман да әле мәчет каршындагы иске мәдрәсәдә бара. Иркен генә ихата эчендә ике йорт, берсе — зуррагы — такта белән тышлап, сарыга буялган, икенчесе — кечерәге — гади авыл ызбасы кебек кенә. Икесен дә Искәндәр ахун мәдрәсәсе дип йөртәләр. Зурысында рөштиләр (урта сыйныфлар), кечесендә иптидаи (башлангыч) сыйныфлар укыйлар. Без менә шул кечесенә йөрибез.

Әйтергә кирәк, ул кышны (бу 1919—20 уку елы) ике мәдрәсә дә шәкертләр белән тулы иде. Бигрәк тә сары мәдрәсәгә Дим буе авыл-

ларыннан буй житкән башкорт егетләре килеп тулган иде. Аларның күбесе кайчандыр монда укып, сугышлар вакытында бер-ике кыш аерылып торучылардыр, ахрысы, ләкин араларында солдатка алынмас өчен килеп кергәннәре дә бар дип сөйлиләр иде. Болар барысы да диярлек кайры ак тун, ак ката, кама читле хәтфә бүрек кигән, муеннарына ак шарф ураган шактый мут һәм көяз шәкертләр. (Күренеп тора, хәлле кеше малайлары.) Аларның яту-тору, ашау-эчүләре дә мәдрәсәнең үзендә үк — көндезләрен ахун хәзрәттән дәрес алалар, ә кичләре... кичләрен, белмим, нишләгәннәрдер. Без, бәләкәйләр, сары мәдрәсә тирәсенә барып йөрми идек, чөнки андагы мыеклы шәкертләр безне гел генә: «Кайнеш, нихәл?», «Кайнеш, апаңа миннән сәлам әйт!» — дип үртиләр иде. Кайчагында кичләрен сары мәдрәсәдән курай уйнаган, жырлаган тавышлар да ишетелә иде. (Бусын тыңламыйча түзеп булмый, бусы күңелләрне әллә нишләтә!) Әйтәләр иде, мондый кичләрдә шәкертләр Шәймурат бичәсеннән койган бал китереп эчәләр, мич авызына чүгәләп кенә фифируз да тартып жибәрәләр дип... Булыр да, алар бит инде, кем әйтмешли, үгезне мөгезеннән тотып егарлык егетләр иде.

Ул кышны әле дин сабагы белән дөньяви дәресләрне укыту бергә алып барыла иде. Берүк хәлфәдән без әфтиякне дә, башлангыч шәригать кагыйдәләрен дә һәм тел, хисап, жәгърафияне дә укый идек. Шулай ук безнең кечкенә мәдрәсәдә дә якын-тирә авыллардан килеп, укып ятучы малайлар бар иде. Шулардан ике малай тазлар Дәүләкәненнән. (Бу зур Дәүләкәннең Дим түбәнендә аерылыбрак торган бер өлеше генә, ни өчендер аңа әнә шундый «матур» исем кушканнар.) Аталары бик иске кеше булгандыр, ахрысы, аның таләбе буенча хәлфә абзый аларны кадимчә укытып маташты. Мескеннәрдән бик көләләр иде, кемдер ике малайның да бишмәт аркасына акбур белән «таз» дип язып та куйган иде.

Еш кына без, Дәүләкән малайлары да, култык астына мендәр кыстырып үзебезнең мәдрәсәгә куна бара идек. Анда кызык, анда уен-көлкє, мендәр сугышы, урлашып ашау — тик шулай да зур мич артында йоклап ятучы кизү бабай бар, бабайның матчага кыстырган озын чыбыгы да бар, әгәр артык онытылып китсәк, бабай мич артыннан кашына-кашына чыга да, бер сүз әйтмәстән, зәһәр тал чыбыгы белән чыжлатып безне тәртипкә утырта иде.

Әмма иң кызыгы һәм куркынычы — идәндәге киезгә тезелешеп яткач сөйләнә торган әкиятләр!Ниләр генә сөйләнми иде! Жен, пәри, албасты, абзар иясе, мәчет өрәге, кабердән чыгып, очып йөргән ут шары, яшь кыз кыяфәтенә кергән юха жылан — берсе дә калмый иде. Монда билгеле, иске китаплардан отып алган падишалар, шаһзадәләр, хан кызлары турында да күп сөйләнә, ләкин малайларның үзләре уйлап чыгарган уйдырмалары да житәрлек. Һич тузга язмаган булса да, ант итә-итә безне ышандыралар һәм без ышанабыз, без куркудан юрган астында калтырана башлыйбыз, йоклап китә алмыйча азапланып бетәбез... Инде төнлә тышка чыгасың килсә — бәла!.. Кысталудан шартлардай булсаң да, караңгы ишегалдына чыгу юк. Бердәнбер чара — әкрен генә торып, мич алдына барып, тезләнеп кенә шуның эченә жибәрү — йомшак көлгә тавышсыз-нисез сеңә дә куя. Анда да әле моржа пәрие әләктереп алмагае иде дип куркасың...

Әнә шулай үтеп китте безнең малай чакның авыруларга, бөлгенлеккә карамастан тагын бер кызыклы, ваемсыз кышыбыз. Иске мәдрәсәдә ята-тора дин белән фәнне бергә укып йөрүебез дә шул кышта тәмам булды. Икенче кышны инде без Мөфәххар картның маржа базары каршындагы озын-карсак йортында бары дөньяви фәннәр генә укыдык. Шулай итеп, безне диннән аердылар, ләкин бөтенләй үк түгел. Егерме икенче елның көзеннән башлап, дин сабагын укытуны мәчеттә оештырдылар. Без әле коръәннәребезне күтәреп, кичләрен мәчеткә дә йөрдек.

Намаз булмәсенең йомшак киезенә тезләнеп, зур түгәрәк ясап утырган килеш карт хәзрәтнең үзеннән һәм аның чатан мәхзүменнән сабаклар алдык. Ләкин бу укып йөрүнең бер дә ата-анасы булмады. Ник дисәң, малайлар бик усалланды, хәзрәт килгәнче мәчет эчендә тузан куптарып сугышалар, бер-берсенең каталарын, итекләрен яшерәләр, азгынлык хәтта шуңа барып җитте ки, тыныч кына укып утырганда малайларның берәрсе күршесенең салып куйган бүреген алып, түгәрәк уртасына «шап» иттереп ыргыта. Мескен хәзрәт куркуыннан сискәнеп, агарынып китә, ә малайлар берни булмагандай башларын түбән иеп, китапларына төртелеп утыра бирәләр. Ник берсе тынын чыгарсын, ичмасам! Хәзрәт кем бүрке, кем ташлады дип сорап та тормый, чөнки барыбер беркем дә бер сүз әйтмәячәк. Һәм бүрек дәрес беткәнче түгәрәк уртасында ятачак.

Билгеле, мондый сансызлык, йөгәнсезлек дин сабакларының дәрәҗәсе төшүдән, дин укып йөрүнең килешмәгән, кирәкмәгән бер эшкә әйләнүеннән, бары атайлар мәҗбүр иткәнгә күрә генә йөреп маташудан килә иде. Шул ук вакытта малайлар барысы да көндез совет мәктәбенә йөриләр, анда фән дәресләре үтәләр, ә фән ул диннең капма-каршысы, фән алланы да, динне дә инкарь итә. Дин ул иске дөнья калдыгы, изүче сыйныфларга хезмәт иткән, хәзер исә эшче-крестьянга яңа тормыш корыр өчен белем кирәк, фән кирәк... Әйтәсе дә түгел, бу үзе бик гади, үзе аңлаешлы өйрәтүләр малайлар күңеленә көннән-көн ныграк сеңә бара иде. Аннары 1923—24 елларда Дәүләкәндә комсомол хәрәкәте дә көчәеп китте. Татар һәм башкорт яшьләреннән дә комсомолга керүчеләр күбәя башлады. Бер үк вакытта мәктәпләрдә пионерлар хәрәкәте дигән өр-яңа бер нәрсә барлыкка килде. Барабан, быргы, кызыл галстук, кыска ыштан — болар барысы да бик кызыклы, бик мавыктыргыч иде. Кая монда дин сабагы?! Оят ул хакта уйларга да!.. Атай йодрыгы да инде куркытмый. Кыскасы, ике кыш малайларны көчләп азаплаганнан соң, мәчеткә йөреп уку үзеннән-үзе диярлек тукталды, бетте.

Инде иске мәдрәсәдән аерылган чагыбызга — егерменче елның язына кайттык. Миңа шушы язда унбер яшь тулды. Балалыктан чыгып барам, ләкин яшүсмер түгел әле (дип уйлыйм). Һа, баксаң, миңа Дәүләкәннән чыгып китәргә бары биш кенә ел калган икән ләбаса?! Үз юлымны табарга, үз көнемне күрергә!.. Ә бит минем бер нәрсә көтмәгән, уйламаган иң ваемсыз чагым әле... Нинди тиз өлгерә икән адәм баласы! Ә шулай да бу калган биш ел турында күпме язасым бар. Сугыштан соңгы кырык елыма караганда да күбрәк һәм минем өчен әһәмиятлерәк тә диясем килә.

...Без бик күп уйный идек. Хәер, бөтен җирдә дә бала-чага күп уйный, ләкин Дәүләкәндә аеруча, чөнки мондагы малайларга уеннан башка эш тә юк. Күбесенең аталары я сәүдәгәр, я хезмәткәр, я һөнәрче — берсендә дә крестьян эше белән бәйләнгән хуҗалык юк, ишле мал-туар да юк, шул сәбәпле аларның малайлары вакытларын урам таптап та уйнап уздыра. (Безнең тирәдә крестьян эше белән шөгыльләнүчеләр Арыслангәрәй агай да Гатаулла карт, тагын мөәзин абзый — менә аларның улларына җәйге эш өсләрендә уйнап йөрергә туры килми иде. Кешене эшкә өйрәткән иң шәп «мәктәп» ул крестьян хуҗалыгы.) Һәм без, эшсез малайлар, шактый күп идек. Урамга чыктык исә, өч-дүрт йорттан унлап малай җыелабыз. Нишләргә, кая барырга, нәрсә уйнарга?

Уеннар, уеннар... Нинди генә уеннар уйнамый идек без!.. Алар күп, һәр вакытның үз уены, мәсәлән, җир туңгач, шар сугу башлана. Бу уенга кызыгып китеп, хәтта бичәле ирләр дә чыгып кушыла иде. Каты тамырдан ясалган йомры шар, кулларда карама яки имән кәшәкә, малайлар, егетләр урамның буеннан-буена кара-каршы торып басалар.

Иң очтагы берәү шарны сугып җибәрә, аңа икенчесе, өченчесе өсти, ә каршы якта торучылар очып килгән шарны туктатып, бу башка таба сугып җибәрәләр. Әнә шулай, кара-каршы торып, шомарып беткән шарны урамның бер очыннан икенче очына таба куалар. Монда үзенә күрә каты көрәш бара — шарны ничек тә каршы якка таба куарга кирәк. Әлбәттә, хоккей түгел бу, шулай да шар артыннан чаба-чаба кара тиргә батасың!..

Кышын кар утыргач, билгеле, күбрәк чана шуу — Арысланголрәй тыкрыгының яры биек, текә, без шуннан буран уйнатып шуабыз. Түбәндә тип-тигез, ап-ак Комач өсте — безнең чаналар карны ерып, әллә кая хәтле китәләр. Монда да без узыша-узыша шуабыз.

Кар китеп, җирләр кипкәч, йөгертмә туп, чокыр туп уйнау... Шәп уеннар, бигрәк тә йөгертмә туп — күпме чослык, өлгерлек, тизлек кирәк бу уенда! (Хәзер уйныйлар микән бу уенны, шәһәр эчендә күргәнем юк, аңа иркен мәйдан кирәк, без, мәсәлән, кырга чыгып уйный идек.)

Безнең әле «мөгъли» дигән бер уеныбыз да бар иде. Бу уен башка җирдә бәлки юктыр, шуңа күрә аны кыскача гына аңлатып китәргә кирәктер, ахрысы. Кулда таяк, түбән очы кыеклап киселгән, янә җирдә ике башы да очланган, нечкәрәк таяк ята. Менә шул җирдә яткан түгәрәк таяк кисәген кулыңдагы таягың белән әйләндереп чөясең дә сугып җибәрәсең. Янында басып торган иптәшең очып киткән таяк кисәген шунда ук «мөгълиии» дип кычкыра-кычкыра барып алырга һәм син сугып җибәргән урынга китереп ташларга тиеш. Монда хикмәт тынны өзмичә китереп җиткерүдә. Әгәр тыны җитмәсә, өзелсә, ул туктап калган җирдән син бәләкәй таякны тагын чөеп алып, сугып җибәрәсең — иптәшең яңадан «мөгълиии» дип суза-суза таяк артыннан чаба. Инде китереп җиткерсә, ул сугып очыра, ул сине «мөгъли» кычкырта башлый. Бу уенның тынны озак саклый алуга файдасы тимәде микән дип уйлыйм мин.

Кузна уенын бөтен җирдә беләләр. Без дә аны, язын җир сарыккач, күп уйный идек. Аның турында бәлки язып тору да кирәкмәстер. Ләкин ике нәрсәгә игътибарыгызны тартасым килә: беренчедән, кузнаны (сарык аягының тубык сөяген) сеңердән тәмам чистартыр өчен без аны мич башына ташлый идек. Мыеклы тараканнар шундый итеп чистарталар ки, кузналарыбыз ялап алгандай шоп-шома була торган иде. Икенчедән, кузнаның бит әле бәрә торганы була. Бездә аны нәлти диләр. Ул авыр булырга тиеш. Ә авыр итәр өчен без башта кузнаның төбен үткен пәке очы белән кыра-кыра тишәбез дә шуннан соң чүмеч белән утлы күмер өстендә эреткән кургашны чүпрәккә урап тоткан кузна эченә иплэп кенә коябыз. Менә шул кургашын тутырылган авыр-саллы кузна бәрә торгаң нәлти була да инде. Аны ун адымнан бик туры ыргытсаң, парлап тезелгән кузналарны кырып кына саласың!

Бик оста уйнаучылар була торган иде. Кайчагында бөтен кузна бер кулга кереп бетә — откан малай ыштан бөрмәсенә кыстырган күлмәгенең эченә тутырып кайтып китә. Кузна бит ул акча бәрабәренә йөри диярлек. Оттырып бетергәч, син аны берәүдән дә бушка ала алмыйсың. Сатып яки әйбергә алыштырып кына алып була. Шуңа күрә кузнаны бер вакытта да ташламыйлар, киндер капчыкка яки зуррак тартмага тутырып, киләсе язга чаклы очырмада саклыйлар.

Инде тагын бер уен турында сөйләп үтәсем килә. Уенның тагаен исемен онытканмын, ләкин ул җәя белән укка бәйләнгән иде. Җәйгә чыктык исә без үзебезгә җәя белән ук ясый торган идек. Дим тугаенда таллыклар күп, юанрак талдан җәя бөгәбез, туп-туры нечкәсеннән ук ясыйбыз. Каеннан да бөгә идек, ләкин тал яхшырак бөгелә, сынмый, нечкә, ә үзе таза сүс бау белән бөгеп бәйләгәч, кыл шикелле тартылып тора, атар өчен дә каты була. Ук өчен нечкә талны кайрысыннан

әрчибез, киптерәбез, турылыйбыз, аннары бер очындагы йомшак үзәгенә башак утыртабыз һәм барып кадалганда әчкә кереп китмәсен өчен укның башак утыртылган җирен нечкә тимер чыбык белән бик каты урап куябыз... Ук башагы ике төрле була — без башак һәм балта башак. Без башак тишеп керә, ә балта башак кисеп төшерә. Без башакка калын энә дә ярый, ә менә балта башакны махсус ясарга кирәк. Моның өчен без дага кадагын поезд үткәндә рельс өстенә куеп таптатабыз, аннары бик әйбәт иттереп тигезлибез һәм үткерлибез. Исеменнән күренгәнчә, ул чынлап та балта йөзенә охшап тора.

Хуш, ә уен үзе нидән гыйбарәт?... Әйтик, дүрт-биш малай бергә җыелабыз, индә — җәя, кулда берничә ук. Шуннан илибатыр (элеватор) артындагы кырга чыгып китәбез. Барып җиткәч, бер-беребездән читтәрәк торып тезелешәбез дә, берәр укны һәммәбез бергә һавага атып җибәрәбез. Һәм карап торабыз — кемнең угы биегрәк оча?.. Шул арада уклар төрлесе төрле җиргә төшеп кадалалар. Иң биек менгәне, билгеле, аз гына соңга калып төшә. Менә шул укның хуҗасы инде ату хокукын ала, ягъни үзенең угы төшеп кадалган җирдән торып, башкаларның утырып торган укларына төзәп ата башлый. Тидерсә — ук аныкы, тидермәсә — хуҗасына кала.

Бу уен берничә мәртәбәләр кабатлана. Берәүләр укларыннан язалар, икенчеләр ук башагы җыеп алалар. (Сынган ук кирәкми, анысын ташлыйлар.) Монда малайларның ике төрле сәләте сынала: беренчедән, укны һавага мөмкин кадәр биегрәк ату өчен көч кирәк, икенчедән, төшеп кадалган укларга тидерер өчен бик үткен күз кирәк. Шәп, кызыклы уен!.. Миңа калса, бу уен бик борыннан сакланып килгән булырга тиеш. Хәзер юк инде ул, күптән онытылган.

Ниһаять, Дәүләкәнгә... футбол килде. Егерме дүртенче елның җәендә булды бу шаккатыргыч вакыйга!.. Моңарчы һич күргән, ишеткән нәрсәбез түгел иде. Кемдер, каяндыр (билгеле, зур шәһәрдән) күреп кайткан булырга тиеш. Башта рус малайлары күннән теккән зур тупны тибеп уйный башладылар. Без авыз ачып карап торабыз, аңларга тырышабыз. Ике төркемгә бүленеп, кара-каршы торып уйныйлар, үзенә күрә ниндидер тәртип-кагыйдәләре дә бар, ахрысы...

Әйтергә кирәк, ул елның кышында, элекке гимназия бинасында безне, бишенче сыйныфтан башлап, рус балалары белән бергә укыттылар. Бергә укуның безгә, һичшиксез, зур файдасы тиде — моңарчы бик интектергән рус телен яхшырак белә башладык. Шулай ук рус малайлары һәм кызлары белән класста гына түгел, уйнаганда, йөргәндә дә әкренләп аралаша башлаган идек. Кыскасы, туп тибү белән безнең бик кызыксынганны күреп, алар, ниһаять, безне дә уенга катнашырга чакырдылар. Без инде сикерә-сикерә риза! Арадан берсе — бу уенны бик белгәне — безгә төшендерде; ике команда булырга тиеш, без менә үзебезгә команда төзедек, сез дә үзегезгә аерым команда төзегез. Унбер кешедән,— артык ярамый. Яшь ягыннан да бер чамарак булсын — бик кечкенәләрне яки бик зурларны алмаска. Аңладыгызмы?.. Арадан бер толковой иптәшегезне капитан итеп сайлагыз.

...Кызу кулдан тотындык без команда төзергә... Теләүче күп, талашызгыш китте, чак сугышып та китмәдек, ләкин Таһирдан барыбыз да курка идек. Менә ул күкрәккә төртә-төртә исемнәрне әйтеп чыкты һәм үзе үк капитан да булды. Унбер бәхетле арасына мин дә эләктем.

Икенче көнне урыс малайларына әйттек, безнең команда әзер, уйнарга да була, дидек. Теге барысын да белүче малай (ялгышмасам аның фамилиясе Маслов иде бугай) бездән сорый: командагызның исеме бармы, булмаса, кушарга кирәк, ди. Нинди исем? Безнеке менә «Искра» дип атала, сез дә табыгыз, ди. Алай икән диештек без, я, нинди исем кушабыз? Арадан берәвебез кабаланып әйтте: «Ә безнеке

очкын булсын» диде. Рус малае сорый: «Нәрсә ул учкун?» Аңлаттык. Юк, ярамый ди, безнекен алгансыз, ди... Таба алмыйча аптырап беттек, уебыз һаман ут, ялкын, төтен кебек берүк төрле исемнәр тирәсендә әйләнә дә әйләнә. Ахырда бер зирәкнең башына һич уйламаган исем килде: Әйдәгез, байрак кушабыз!.. Без шунда ук моны эләктереп алдык: «Шәп! Кызыл байрак булсын!». Мактана биреп рус малаена да әйттек, ләкин күпне белүче егет безгә, исем кыска булырга тиеш, диде: или кызыл, или байрак!.. Шулай итеп, без «Байрак» кына булып калдык.

Хәзер инде кайда уйнау мәсьәләсен хәл итәргә кирәк иде. Гимназия күршесендә ак чиркәү, аны узгач тигез чирәмлек — барыбыз да шунда киттек. Баш булып йөрүче малай җитәкчелегендә бер зур гына мәйданның чикләрен билгеләдек, аның ике як башына ташлар өйгәләп «капка» ясадык. Аннары җитәкчебез үзе мәйданның нәкъ уртасын билгеләде — уен шуннан башланырга тиеш икән. Уенның төп максаты — каршы якның капкасына туп кертү. Һәр команда шуңа омтыла — үз капкасын саклый, каршы якка һөҗүм итә. Уенны дөрес алып бару өчен судья булырга тиеш икән әле — ул сыбызгы кычкыртып башлата, ул туктата, кагыйдәне бозган өчен штраф та «түләтә» (ягъни, каршы якка тупны типтерә).

Хуш, егетнең сөйләгәннәрен аңлаган шикелле булдык, инде тизрәк уйнап карыйсыбыз килә. Ләкин көтелмәгән бер нәрсә килеп чыкты: футбол уйнар өчен өстә җиңсез күлмәк, кыска ыштан, аякта ботинкалар булырга тиеш, имеш!.. Билгеле, андый махсус кием безнең беребездә дә юк иде (сабый чакта төпсез ыштан кигән бар, әмма балаксыз ыштанны күргәнебез дә юк әле). Нишләргә? Шуннан уйлаштык та әйттек: юкны таба алмыйбыз, күлмәкләрне салып ташлыйбыз, ыштан балакларын сызганабыз, и... ялан аяк уйныйбыз, дидек. Урыс малайлары ни әйтергә белмәгәндәй безгә бераз карап тордылар да: «Чурт с вами, уйнагыз!»— диделәр... Һәм менә ике көннән соң микән, «Искра» белән «Байрак» арасында чын уен башланды. Өйрәтүчебез үзе үк судья да булды. Башта ике капитан шөбага тотышты, «Искра»ныкы өскә чыкты — уенны алар башлаячак. Без урта сызыктан арткарак чигендек, «судья» өреп тутырган зур тупны җиргә куйды, сыбызгысын кычкыртты һәм уен башланып та китте... Һәм бер минут та үтмәгәндер, рус малайлары тупны безнең капкага илтеп тә керттеләр. Капкада торучы теге... ничек әле үзе, аты коргыры?— голкипер Гыйззәтулла селкенергә дә өлгермичә авызын ачып кына калды. Хәзер инде без уртадан башладык. Уен бик тиз кызып китте, судьяның сыбызгысын ишеткән дә, тыңлаган да юк, тупны кем эләктерсә, шул алга таба куа да куа, калганнар барысы да аның артыннан өерелешеп чабалар гына... «Пас» дигән нәрсәне белүче дә юк, киресенчә, безнең малайлар тупны күбрәк үзенә генә эләктерергә тырыша, чөнки аның да куасы, аның да капкага тибәсе килә. Безнекеләр арасында бик шәп йөгерүчеләр бар иде, мәсәлән, Таһир белән Шакир, мин дә ул чакларда бик шәп йөгерә идем. Менә шуның аркасында без дә «Искра» капкасына берничә туп керттек. Ләкин уен барыбер «Искра» җиңүе белән бетте. Һәм ул шулай бетәргә дә тиеш иде, чөнки рус малайларының беренче уйнаулары гына түгел, аннары барысының да аякларында ботинка... Ботинкага каршы яланаяк уйнап кара әле син! Ул көнне без барыбыз да диярлек көчкә-көчкә генә басып, аксый-туксый кайттык... Соңрак инде без дә остара төштек, акыллырак уйный башладык, тупны эләктергәч ак-кара күрмичә алга чапмыйбыз, «пас» та биргәлибез, шулай иткәч, капкага да тизрәк барып җитәбез. Ә ботинкага каршы без чабаталар киеп алдык. Үзе җиңел, үзе нпле, ботинкадан куркып тору да юк, тик бер генә кимчелеге бар — тупка катырак типсәң, аяк чабатадан бүселеп килә дә чыга, хәерсез!.. Ләкин аңа каршы да әмәлен тап-

тык — киндерәне бәйләгәндә чабата башына да кидереп ала торган булдык. Кыскасы, эшләп туздыра алмаган чабаталарны мин шул чакта туздырып бетердек.

...Дәүләкәннең яшел чирәмендә мин ике генә җәй футбол дигән бу гаҗәеп мавыктыргыч уенны уйнап кала алдым. Казанга киткәч, билгеле, туп тибеп йөрүләр бик тиз онытылды, яшь кенә башка шунда ук бүтән уй, бүтән кайгылар кереп тулды. Дөресен генә әйткәндә, без барыбыз да уен яшеннән тиз чыктык. Бер-ике ел үтүгә минем яшьтәшләрнең күбесе укырга киттс, калганнары эшкә керде — алар өчен дә башка чор — тормышка керү чоры башланды. Ә без уйнаган уеннарны безнең арттан килүче малайлар дәвам иттерергә тиешләр иде. Тик мин белмим, нинди уеннарны сайладылар икән алар?.. Уеннар да бит искерә, үзгәрә, онытыла. Шартлары да үзгәрә — әйтик, без үскәндәге иркенлекләр юк инде алар. Әмма уен ул бетә торган нәрсә түгел, уен ул — мәңгелек! Мәхәббәт кебек, җыр кебек, тормышның үзе кебек... Уйнаучылар да килә тора, үтә тора, китә тора бу дөньяда!

* * *

Зур су буе бала-чага өчен һәрвакытта куркыныч. Дим дә әнә шундый елгалардан — зур су, тирән су. Бигрәк тә немецлар елганы нәкъ Дәүләкән турысында буып, биш катлы таш тегермән салгач, Димнең өске ягы бик тирәнәеп-киңәеп киткән, түбән ягы исә тау шарлавыгы сыман котырып ага торган булып калган. Ә без, Эткол малайлары, барыбыз да елганың өске ягында торабыз. Монда кечкенәләр өчен генә түгел, зурлар өчен дә су керер урын табуы читен — елганың яры стена шикелле тирәнгә төшә дә китә. Йөзә белмәсәң, син дә, керү белән таш шикелле, төпкә төшәсең дә китәсең. (Әти-әниләр, Дим ул бала-чаганы үзенә тартып ала дип, юкка гына безне куркытмыйлар иде.) Ләкин, шуңа да карамастан, без көнозын диярлек су буеннан кайтып керми идек. Яшерә алмыйм, бу башбаштаклыгыбыз белән без инәй бичараны күп саргайттык. Тугыз баладан соң күргән «ике бөртек» өчен ул, билгеле инде, кан калтырап тора иде. Еш кына яр башына килеп, кулын маңгаена куеп, зәгыйфь күзләре белән түбәндә чупырдаучы балаларга карап тора, судан менеп килүчеләрдән «күрмәдегезме минекеләрне» дип сорап та карый һәм күп вакытта бер нәрсә белә алмыйча борчылып, сызланып кайтып та китә. Әлбәттә, инәйнең борчылуы бик урынлы булган — мин, мәсәлән, өч тапкыр Дим төбенә чак-чак кына китмичә калдым. Ләкин уйлый белү дә юк, инәйнең хәленә керү дә юк, урамга чыктык исә малайларга иярәбез дә китәбез. Баштарак, әле кечкенә чагыбызда, өйдән ерак китмичә, Арыслангәрәй тыкрыгыннан гына төшеп, Комач суында җыен бала-чага быкырдана торган идек. Монда тирән түгел, хәтәр чоңгыллар да юк, әмма төбе бик алама — тубыктан батарлык мәте генә... Баскан саен богыр-богыр өскә эре күбекләр калка. Аз гына чапырдауга су тәмам болгана, дегеттәй карала, коенып чыкканда борын төпләренә «кара мыек»лар утыра... Әйтергә кирәк, Комачның төбе буеннан-буена әнә шундый мамыктай калын мәтеле, зурраклар аның бер төшендә дә су керми торганнар иде. Нигә ул алай дисәгез, мин моның сәбәбен соңрак аңладым: Комач буена утырган бөтен йортларның мал абзарлары, бәрәңге бакчалары суга карый, менә шунлыктан бөтен абзар сулары, тирес-туфраклар Комачка агып төшә дә. Ничәмә еллар буена ул шулай килгән һәм шулай Комачны пычратып та бетергән. Кыскасы, Димдә су күп, ә коеныр урын аз иде.

Үсә төшкәч без дә, билгеле, Комачта быкырдауны ташладык. Әйбәт урын эзләп ераккарак китә башладык. Иң әйбәт урыннарның бер-



*Т. Хажиәхмәтов рәсеме.*

се ул каршы яктагы Комач белән Димне тоташтырган ерым иде. Озын гына бу ерымның Димгә барып чыккан җире шактый ук тирән, суы да чиста, әмма яры сөзәк, төбе такыр комлык — рәхәтләнеп коена торган урын инде. Ләкин анда барыр өчен иң элек көймә белән аргы якка чыгарга кирәк. Ә көймә сирәк кешедә генә, чылбырын казыкка урап, бикләп куелган, безнең ише малай-шалайга сорасаң дә бирмиләр. (Күрше Борһан абзый үзенең буяулы яхшы көймәсен улларына да алып китәргә рөхсәт итми иде). Шулай да берәрсенең батып яткан ташландык «тагарагын» суыннан бушатып, такта белән ишә-ишә аргы якка чыгып китә торган идек. Аннары инде тугай буйлап, күлмәкләрне өстән сала-сала ерым тамагына чабабыз. Һәм барып җитү белән ыштаннарны төшереп кенә җибәрәбез дә чаптыр-чоптыр суга кереп тә китәбез. Монда тәмам күгәреп беткәнче коена торган идек.

Безнең су керергә йөри торган янә берничә урыныбыз бар иде. Шуларның берсе һәм иң кызыктырганы — Димнең буадан түбән җире иде. Әмма буа асты су керер өчен бик хәтәр урын — без энем белән икәү беренче баруыбызда ук шунда харап була да яздык. Бик яшь идек шул әле — энемә тугыз, миңа унбер яшьләр чамасы булгандыр — зуррак малайларга ияреп, алар ни эшләсә, шуны эшләп йөри торган чагыбыз. Ә алар буа астында да су керүдән курыкмыйлар иде.

...Искә төшергәч, хәзер дә әллә нишләп китәм!.. Шактый биек буа өстеннән шарламадай ишелеп төшкән су котырып-дулап, яман шаулап ага. Монда суга керү түгел, янына бару да куркыныч. Әгәр, әйтик, таза ат керә калса, бу котырган агым аны да мәтәлдереп алып китәчәк. Ләкин берничә йөз адым түбәнрәк төшкәч, елганың читләрендә агым беркадәр әкренәя — менә шул төшләрдә инде кыю малайлар батыраеп суга керәләр. Монда комлык, вак ташлык, су бик чиста, хәтта бераз салкынрак та кебек. Тик шулай да бик сак булырга кирәк — эчтәрәк агым ифрат көчле, элэксәң, йомычка урынына ала.

Хәер, кем аны уйлап тора?.. Барысы да керәләр, без дә керәбез!.. Йөзәбез, чумабыз, уйныйбыз, һәм... эчкәрәк керүдән дә сакланабыз. Ләкин барыбер саклану җитмәгән, күрәсең, менә бер вакытны каты агым энемне эләктереп, бөтерә-бөтерә алып та китте. Аны тотыйм дип кенә үрелгән идем, мин дә йомычкадай актым да киттем. Эш харап!.. Алдан бата-калка энем бара, аның артыннан мин... Ләкин таш шикелле төпкә китмибез әле, чөнки көчле агым үзе безне күтәреп, уйнатып кына илтә дә илтә. Тик кайчанга хәтле?.. Ычкынып чыгуны уйлаган да юк... Ә алда, ерак та түгел Дим күпере. Яр буеннан кемнәрдер, безгә нидер кычкыра-кычкыра, шул күпергә таба йөгерәләр. Әллә аларны ишетеп, әллә үзем белеп, мин дә энемә кычкырдым: баганага ябыш, күпер баганасына!.. Башта ул, күпергә җитеп, баганаларның берсенә ябышты, аннары мин, килеп җитеп, икенчесенә тотындым. Бу минуттагы хәлебезне мин аңлата алмыйм, тик шуны гына беләм — без җыларлык та, сүз әйтерлек тә хәлдә түгел идек... Шул арада яр буйлап йөгерешкән кешеләр, күпергә кереп, безне кул сузып кына баганалардан тартып алдылар. Әнә шулай коткардылар безне. Ләкин моңа бер дә гаҗәпләнмәгез. Башкорт агайларының баганалар өстенә аркылы-торкылы чыбык-чабык салып күп итеп салам түшәп салган күперләре әнә шулай бик тәбәнәк була, тар гына була, бер башыннан җигүле ат керсә, икенче ярдагысы көтеп тора — гомерем буена оныта алмадым мин шул ястык кебек йомшак Дим күперләрен!

Без инәйгә бу хәлне сөйләмәдек, билгеле. Гомумән, андый куркыныч хәлләрне һәрвакытта яшерә торган идек, чөнки без үзебезнең «ике генә бөртек» булуыбызны аңлый идек инде. Әмма ләкин кемдер соңыннан инәйгә безнең икәүләп агып китүебезне җиткергән. Күрәсең, инәйнең курку-тетрәнүе артык көчле булгандыр инде: безгә сүз әйтергә, безне тиргәргә аның тәкате җитмәде, бары өстебезгә карап җылады гына ул...

Белмим, калган батуларым турында сөйләп тору кирәк микән? Мәсәлән, яңа гына туңган, әле сыгылыбрак та торган боз өстендә кызык өчен юри чабып йөргәндә уелып төшеп китүемне (ярый, малайлар озын колга сузып, тартып алдылар) яки Димнең иң киң җиреннән, күлмәкыштаннарны башка урап, йөзеп чыкканда хәлдән таеп чак-чак кына батмыйча калуымны — юк, кирәкмәстер ахрысы... Зур су буенда торгач, аның ише хәлләр була инде ул.

Әмма, мәгълүм ки, һәрбер азапның тора-бара бер рәхәте яки яхшы нәтиҗәсе дә булып куя. Менә без дә, инәйне җылата-җылата булса да, бата-калка маташа торгач, ниһаять, бик шәп йөзәргә өйрәндек. Хәзер безгә диңгез тубыктан — Димнең бер төшеннән дә куркып тору юк. Бигрәк тә энем Илдархан бик шәп, бик матур йөзә иде. Ул тәз буйлы, киң күкрәкле малай иде, Димнең иң тирән җиреннән дә чумып мәте ала торган иде. Аңа кушаматны да малайлар «күкен» дип бирделәр. Бу — балык исеме. Кечкенә үзе, әмма бик тере — җитез балык. Хәзерге заман кибетләрендә сатыла торган килька дигән мәшһүр балыкны белмәгән кеше юктыр инде — Димдәге күкен дә төсе, кыяфәте, зурлыгы белән нәкъ менә шул гаять популяр килька төсле үк иде. Ихтимал, алар берүк токымнандыр да әле — исемнәре үк туры килеп тора бит!

Ничек кенә булмасын, без чынлап та суда күкен шикелле җиңел генә йөзәргә дә, чумарга да өйрәнеп беткән идек. Кайларга гына бармый идек тә кайларда гына коенмый идек. Җәйләр эссе, көннәр озын, суга шул хәтле ияләштек ки, мин хәтта бер вакытны су өстеннән атлап кына китүемне дә хәтерлим. Ышанмыйсыз, көләсез?.. Ә мин ышандым, чын-чынлап ышандым! Хәлбуки тип-тигез су өстеннән җиңел генә атлап китүем ул, билгеле инде, бары төш кенә булган, әмма шулкадәр ачык, шулкадәр чын төш булган ки, мин аны ирексездән өнем итеп кабул иткәнмен, өнемдә йөрдем дип, шуңа сөенә-сөенә ышанганмын да. Малай чакның төшләре дә әнә нинди була икән ул!

Хәер, ни гаҗәп, агымсу белән бәйләнгән төшләр хәзергә кадәр миңа һаман кергәли торалар. Төшемдә я берәр елга ярларыннан чыгып ташый башлый, я шәһәр урамнарыннан котырып-шаулап су ага, я чиксез зур дәрья уртасыннан капланып китәргә торган кечкенә көймәдә барам, имеш — барысы да әнә шундый хәтәр-куркыныч төшләр... Әйткәнемчә, шушы яшемә хәтле кабатлана торган төшләр!.. Ләкин кайдан бу төшләр, ни өчен алар озак еллар дәвамында һаман кергәли торудан туктамыйлар?.. Бу сәер хәлнең серен мин бераз сизенсәм дә ачык кына белми идем. Тик 1979 елны «Юматау» санаториясендә бер врачның йокы һәм төшләр турында сөйләгән лекциясен тыңлагач кына эшнең сере, ниһаять, ачылган кебек булды. Баксаң, кешенең кайчан да булса үтә көчле, тирән кичергән берәр вакыйгасы, гомерлеккә җуелмаслык булып, баш миендә «язылып» кала икән. Һәм шушы язылып калган вакыйга, гәрчә онытылып бетә язса да, төрле вариантларда аның төшенә дә кергәли тора икән. Димәк, минем дә төшләремә кергән куркыныч су ташулары әлеге шул малай чакта берничә мәртәбә Димдә бата язуымның нәтиҗәсе икән ул!.. Булыр, врач сүзенә ышанмый мөмкин түгел.

Бер тирәдәрәк торучы бер тиңрәк малайлар без шактый идек. Күршедә генә Борһан абзыйның Зәкәриясе белән Яхъясы, алар янәшәсендә Арыслангәрәй агайның Таһиры. Каршыда гына — Габдрахман, аның күршесендә Мөхәммәтгали белән Муллагали, ә алар күршесендә Габделбарый белән Гомәр, тагын Гыйззәтулла, инде безнең яклап, аз гына түбәнрәк — Хәкимҗан белән Шакир... Күрәсез, якын күрше-тирәдә генә күпме малай! Инде шуларга энем белән мине дә кушарга кирәк. Һәм без, шушы малайлар, урамга чыктык исә гел бергә — көтүебез белән бергә йөрибез, бергә уйныйбыз. Әмма бер төсле генә малайлар түгел идек — һәр җәһәттән без бик нык аерыла торган идек. Дәүләкән халкы

бик чуар булган шикелле, без дә бик төрле-төрле идек. Безне саф авыл малайлары да дип булмый, шулай ук чын шәһәр малайлары рәтенә дә кермибез. Безнең бер ишеләребез ярлылыкта, бөлгенлектә яшәсә, икенчеләребез тук-таза тормышта яши идек. Шулай ук безнең арада атасыз яки инәсез калган ятимнәр дә бар иде. Менә ни өчен без тәрбия җәһәтеннән һәм характерларыбыз белән бер-беребездән бик нык аерыла идек. Мәсәлән, Зәкәрия белән Яхъя көн озын малайлар көтүенә ияреп, бөтен уеннарга да катнашып йөрмиләр иде. Чөнки аталары каты тота. Хәтерлисездер, аларны кичерәк чакларында ишегалларыннан да чыгармыйлар иде. Шулай ук Мөхәммәтгали белән Муллагали дә урам уеннарына аз катнашалар иде. Мөхәммәтгали чатан малай, үзе бик нәүмиз-юаш — күбрәк су буенда ялгыз гына балык тотып йөрергә ярата иде. Ә Муллагалинең бар белгәне атлар, уен аның күзенә дә күренми, бөтен вакытын кеше атлары тирәсендә чуалып уздыра иде. Сафиулла абзыйның Габделбарые да сирәк катнаша — ул әдәпле һәм тыйнак, малайларның кайвакытта артык башбаштакланып китүләрен яратмый иде, ахрысы, андый чакта ничек тә читтә торырга тырыша.

Иң хөр — йөгәнсез малайлар Таһир, Габдрахман, Гыйззәтулла, Шакир иде. Алар төркеменә, билгеле, мин энем белән үземне дә кертәм. Без эшсез малайлар идек, безнең бөтен «гамәлебез» урам таптау, бертуктаусыз уйнау, каядыр китеп югалу һәм ачыккач кына өйгә кайтып керү иде. (Дөрес, мин кулыма кызыклырак китап эләксә, урам уеннарын онытып та тора идем.) Малайлар һәр заманда да шул ук берүк малайлар инде — мәнсезлек тә, шуклык та, ызгыш та, рәнҗеш тә җитәрлек булган. Яраган белән ярамаганны еш кына аерып та тормаганбыз. Шулай ук әхлак-әдәп ягыннан да, әйткәнемчә, бер төсле генә булмаганбыз. Менә Габдрахманны гына алыйк — акыллы, сүзгә тапкыр малай, әмма бик хәйләкәр һәм мәкерле!.. Ул бүтәннәрне берәр ямьсез эшкә котырта, ә үзе гел читтә торып кала. Нәтиҗәдә ул яхшы, ә теге начар. Шулай оятка кала торганнар иде аның коткысына бирелгән малайлар... Миңа Габдрахман белән күп йөрергә туры килде, аның әнә шул әшәке гадәте, әче теле, мыскыллап көлүе еш кына ачуымны китерсә дә, ни сәбәптер, мин аны ярата идем. Бәлки, бүтәннәрдән аерылып торганга күрәдер?! Әче теле өчен без аны «Черки» дип йөртә идек. Үзенчә сәләтле малай иде ул!..

Габдрахман тик берәүдән көлүдән тыела, берәүне котыртудан саклана — бу Таһир иде. Арыслангәрәй агайның Таһиры турында язган идем инде. Бик кыю, көчле һәм... гарьчел малай! Кагылсаң — тукмый да ташлый. Без барыбыз да аңардан курка идек.

Ә менә Шакир, киресенчә, бик тиз коткыга бирелеп китә, шунда ук алдын-артын уйламыйча эшли дә ташлый. Аңа тик кызык кына булсын! Шуның белән бергә, ул да бик кыю, гайрәтле һәм сугышырга да бик чос малай иде. Үзеннән шактый олыраклар белән дә бәрелешүдән һич куркып тормый ул — яшь үгез шикелле башын иеп, акны-караны күрмичә ташлана. Бу җәһәттән Шакир белән Таһирны бертигезләр дияргә дә ярый, шуңадыр ахрысы, алар беркайчан да бер-берсенә кагылмадылар. Әгәр аларга сугышырга туры килсә, икесенең берсе беткән булыр иде дип уйлыйм мин әле хәзер дә.

Шакир көләргә һәм көлдерергә ярата торган бик шук малай иде. Ниндидер балаларча беркатлылык һәм эчкерсез самимилек бар иде аңарда. Кайчагында җитди күренергә тырышса да, сүзе-кыланышы барыбер көлке килеп чыга иде. Һич онытасым юк кечкенә бер вакыйганы.

1926 елның җәй башында без Фәтхелислам белән икәү беренче мәртәбә Казаннан Дәүләкәнебезгә кайттык, Фәтхелислам — студент, ә мин китап кибетендә курьер булып эшләүче. (Дәүләкәндә курьерның нәрсә икәнен белмиләр.) Казан хәтле Казаннан кайткач, безнең дәрәҗә зур

һәм игътибар да безгә зур. Ул чакларда инде без барыбыз да малайлыктан чыкканбыз, берәүләребез егет булып җиткән, икенчеләребез менә-менә булырга тора.

Икенчеме, өченчеме көнне үк без әнә шул бергә уйнап үскән күрше дусларыбыз белән имәнлеккә барырга булдык. Имәнлек тау ягында, тимер юл аша чыгып барырга кирәк... Киттек, тимер юлына да җиттек, шул чагында каяндыр каршыбызга Шакир килеп чыкты. Без әле аның белән күрешмәгән идек. Менә ул ашыкмыйча гына янызыбга килде дә үзенчә җитди-әдәпле генә итеп башта Фәтхелисламга дәште:

— Исәнмесез, Фәтхелислам туташ!

Без егылып китә яздык: туташ, ха-ха-ха!.. Белеп дәшәме, әллә белмичәме, бу чукынган?!. Әлбәттә, белептер, әмма ник бер уңайсызлану әсәре яки көлү галәмәте чыксын ки аның йөзенә! Гүя бик дөрес һәм бик урынлы дәшкән ул Казаннардан кайткан студент егеткә! Зурлаган, янәсе!.. Әнә шулай үчләребезне катырган иде, мәрхүм! Мәрхүм дим, чөнки шул ук елның көзендә, без киткәч инде, Шакирны Смолин дигән бер пацан мәктәп коридорында атып үтергән. Низаг нәрсәдән чыккандыр — хода белсен! Җинаятьне тикшереп тору да, үтерүчене хөкем итү дә булмаган — шау-шусыз гына үткән дә киткән. Шакирның атасы аның үзеннән алдарак үлгән иде бугай... Бергә үскән тиңдәшләрне югалтулар әнә шулай бик иртә башланды.

Инде янадан малайчакка чигенсәк, шуны әйтергә кирәктер: безнең бер дә урамнан кермичә көнозын билә мдә югалып йөрүебез атакай белән инәйне бик борчый, хәвефләндерә иде. Билгеле, алар безнең берәр бәлагә таруыбыз өчен генә түгел, эшсезлектән, күп йөрүдән азып-тузып китүебез өчен дә куркалар иде. (Аларча әйткәндә, безне төрле «эткоштан» бик саклыйсылары килә иде.) Әмма нихәтле генә борчылсалар да, вакыт-вакыт берәр гаебебез өчен ачулары бик килсә дә безгә сукмыйлар иде. Инәйне инде әйткән дә юк, хәтта атакай да кул күтәрми иде. Тик бер генә тапкыр, мин көн буена каядыр югалып торып, кич кырын гына кайтып кергәч, ул, ниһаять, түзмәде бик җилле генә минем яңагыма салып җибәрде. Шуннан башка аның миңа бүтән чирткәне дә булмады. Ләкин алар икесе дә безне бик каты үгетли торганнар иде. Каршыларына утыртып, әйбәтләп, аңлатырга тырышып, яхшы сүзләр белән ялвару катып, шелтә катыш, инәй исә җылый-җылый да без ике юньсезне үгетлиләр иде. Һәм бу кечкенә намусыбызга тия торган үгетләүләр миңа, мәсәлән, бик авыр тәэсир итә иде. Еш кына мин эчемнән, ник кыйнамыйлар — кыйнасалар гына иде ичмасам, дип үрсәләнеп тели дә торган идем... Кул җәзасы бит авырттырса да ничектер тиз онытыла, ә менә сүзнең тәэсире, юк, тиз генә онытылмый икән ул... Белмим, ата-ана нәсихәте ул чагында безне күпме генә төзәткәндер, әмма соңыннан, еллар узгач, искә төшергән чакларда, вөҗдан авазы шикелле, җанны борчый, үкендерә һәм уйландыра... Әйе, без, кызганычка каршы, ата-ана борчылуын еш кына бик соңга калып аңлый башлыйбыз.

Ләкин шулай да бичараларны борчый-борчый безнең күп йөрүебез файдага да булгандыр, ахрысы... Без бозылмадык та, азмадык та (димәк, үгетләүләр бушка китмәгән), әмма инде бөтен Дәүләкән әтрафын айкап йөрүдән дә туктап тормадык. Иртә яздан башлап, кара көзгә чаклы!

...Менә берзаман Дим кузгала, Дим ярларыннан чыгып ташый башлый. Мәһабәт күренеш! Бер-ике көн тоташтан боз китә, боз өстендә печән чүмәләсе, тирес өеме, берәрсенең кара мунчасы китә. Су артаҗаела торгач, каршыдагы Көрмәнкәй тавына барып җитә. Тугайдагы әрәмәлекләрнең нечкә очлары гына күренеп тора. Җәен-кышын тар

ярларында бормаланып тын гына аккан елгабыз ташу вакытында әнә шундый мәһабәт — көчле бер дәрьяга әйләнә!

Водокачка янындагы чат кояшка караган яр башы саркып кибә башлагач та без шунда кузна уйнарга тотына идек. Бу — язгы уеннарның беренчесе, шуңа инде тиздән бүтәннәре дә ялганып китәчәк... Водокачка яры үзе дә минем өчен бик истәлекле урын — малай чакта гына түгел, үсеп егет булгач та миңа бу урынны күп таптарга туры килде. Иң элек мин шуны хәтерлим әле — революциягә чаклы монда «каталашка» дигән алама гына бер ызба да тора иде. Дәүләкән «төрмәсе»— сукбайларны, хәерчеләрне, вак каракларны шунда китереп яптаннар. Революциядән соң «каталашка»ны туздырып ташладылар. Аннары мондагы яр башы Дим буйларына, аның киң тугайларына карап торыр өчен бердәнбер диярлек иркен-ачык урын да иде. Без инде ак күлмәк, кара чалбар киеп, билне зинар яки тар каеш белән буып йөрүче көяз егетләр булгач, башта вокзалга барып, берәр пассажир поездын озатып җибәргәннән соң, ашыкмыйча гына шушы водокачка ярына килеп, каршыбызда ачылган, еракларга җәелеп киткән тын, якты, гүзәл манзарага сүзсез генә күпмедер вакыт карап тора идек. Мин бу гадәтебезгә хәзер дә гаҗәпләнәм: көн дә диярлек шушы урынга килеп, яр башыннан карап тору безне ничек туйдырып бетермәде икән?.. Күрәсең, туйдырырлык булмаган Димкәй буйлары, күрәсең, үзенә тартып, бәйләп торган бу сихри манзара! Хәер, без моны шул чакта ук инде аңлый да идек — аерылып китәчәгебезне, әмма мәңге онытa алмаячагыбызны белә идек.

Шулай ук җомга көннәрен егетләр-кызлар Дим өстендә гармун тартып, җырлашып йөрер өчен дә көймәләргә төялеп шушы ярдан кузгалып китә идек һәм әллә кайлардан әйләнеп, тәмам арып, әйтеп биргесез шатлык-канәгатьләнү кичереп, янадан шушы ук яр читенә көлешә-көлешә кайтып төшә идек. Кайда калды ул чаклар? Кая китеп, таралып, югалып бетте ул егетләр белән кызлар?.. Кайткан вакытларымда япа-ялгыз водокачка ярына барып, Дим өсләренә тик кенә карап торам — сүз катар, искә төшерер өчен янымда көймәдә йөрүчеләрдән берәү дә юк, берәү дә калмаган...

Тукта, сүз малайчак турында иде бит әле... Язгы ташу турында иде.

Назланып, сазлар чиртеп,
Уйный-җырлый яз килә.
Яз килә!
Ямьләр ягыннан илгә
аккош, каз килә...[1]

Кызганыч, Димгә аккошлар килми иде. Ә кыр казлары бик биектән каңгылдашып уза торганнар иде. Безнең тугай күлләренә кыр үрдәкләре килә, сазлыклырак түмгәкле урыннарга тәкәрлекләр килә — ефәк «мөгезле», нечкә тәпиле бик нәфис кош. Күп иде алар — килүче кошлар!.. Һавада, җирдә, суда — тик күрә бел дә ишетә бел!

Ә яз артыннан, шул тынгысыз кошлар белән бергә, безнең өчен дә бик озын җәй киләчәк. Безгә дә күпме «очарга», суларга чумарга, ялан-кырлар таптарга туры киләчәк... Ул заманда спорт-физкультура дигән нәрсәне белгән юк иде. Әмма шушы яшькә хәтле житүне мин барысыннан элек әнә шул малай чакта кошлар шикелле өзлексез хәрәкәттә булудан күрәм. Һәм нинди һавада бит әле?!. Эльбрус түбәсендә яткан кардан да чистарак — исе юк, төсе юк, белми идек без һаваның нәрсә

[1] Т. Ченәкәй шигыреннән.

икәнен дә! Саф тирес исен яратыбрак исни идек, чөнки аны тоеп-белеп була иде.

Аннары без җәй буена күпме поливитамин ашый торган идек. Җир ачылганнан алып, беренче кар төшкәнчегә кадәр. Иң элек ташу китеп, тугайлар кибә төшкәч тә каршыдагы болынга чыгып, букча тутырып, төче юа җыябыз. Юа яшь, йомшак, әчесе юк, без аны болай да ашыйбыз, кайткач ипи белән дә, куаска турап та ашыйбыз. Юадан соң кузгалак чәйнәргә тотынабыз. Әчкелтем-сусыл тәмле. Кызганыч, ул чагында безнең инәйләр ашын пешерә белмәгәннәр (әллә теләмәгәннәр). Кузгалак артыннан бер-бер артлы төрлé үләннәр китә, исемнәре инде онытылып та бетә язган, ләкин без аларны ашарга яраганнан-ярамаганыннан бик әйбәт аера белә идек. Ул арада какы, балтырган өлгерә. Имәнлеккә менеп, шуларны кочак-кочак җыеп кайтабыз. Ул да булмый, тугайдагы әрәмәлектә карлыган (карагат) һәм бөрлегән дә пешеп җитә. Аз гына алданрак җир җиләге дә өлгерә. Кайсына барырга, кайсын җыярга? Әлбәттә, башта җиләккә, чөнки җиләк вакыты иртәрәк үтеп китә. Ә карлыган белән бөрлегәнгә соң түгел, куак төбе саен ишелеп ята, аларны ашый-ашый да авызлар камашып бетә иде. Тагын бер бик шәп витамин — бу әлморын (башкортча), ягъни гөлҗимеш! Ул көзгә таба гына өлгереп җитә, бик озак кызара, ә беренче кыраулар өтеп алганнан соң балланып та китә. Хикмәтле җимеш! Без Дим өсте тунгач, шуа-шуа аргы якка чыгып, гөлҗимешне куагыннан өзеп ашый идек. Җыеп бетергесез күп була торган иде. Кадерен белмәгәнбез. Җыеп киптермәгәнбез, әмма гомерлеккә җитәрлек итеп ашап калганбыз.

Шушы өч нәрсә — саф һава, өзлексез хәрәкәт һәм табигать җимешләре безне үстерде, саклады, чыныктырды. Мин моны сабый чактан исән калып, хәзер дә әле саф-сәламәт яшәүчеләргә карата әйтәм. Әмма моның өчен безгә сабый чакта «сират күперен» кичәргә, ягъни һәр төрле йогышлы авырулардан котылып калырга кирәк булган. Хәер, соңрак та безне сагалаган төрле хәтәрләр аз булмады, әмма иң куркыныч-әшәкесе безнең ныгып өлгермәгән малай чагыбызга туры килде.

* * *

Менә 1921 елга да кердек. Елның башы — таза кыш. Ап-ак кар, юлдан чыксаң — тездән батарлык, чиллә вакытында гадәттәге каты суыклар да булды, февраль-март бураннары да котырып узды, әлхасил, елның килеше бер дә хәвефләндерерлек түгел иде кебек... Шулайрак саклана минем хәтердә егерме беренче елның кышы.

Кәтеп алган яз да кичекмичә килеп җитте. Вакытында кары да эреде, бозы да китте, ташуы да булып узды, ялан-кырлар да яшәрде. Табигатьтә берниндн тайпылыш юк, һәммәсе үз нәүбәтендә елдагыча килеп тора. Шулай хәтерлим... Халык чәчүгә төште, маллар көтүгә чыкты. Тик шушы вакытта беренче яңгырлар булып узды микән? Мөгаен, булгандыр, булмыйча калмагандыр... Чәчү өстендә бит еш кына суытып та җибәрә, салкын яңгыры да килеп җитә, хәтта кайчагында апак кар да җирне каплап китә. Бу язын андый карны хәтерләмим, әмма салкыны белән беренче яңгырлары булып узгандыр — һәр иртә язын булмыйча калмый ул.

Ләкин шулай да халыкта елның килешеннән хәвефләнү кайчанрак башланды икән?.. Әйтүе бик читен, чөнки хәвефләнү алай тиз генә һәм кинәт кенә килми ул... Халык сабыр, халык көтә белә... Соңгы чәчүләр дә бетте, майда үтеп китте, җәйгә дә кердек. Беренче иртә яңгырлардан соң айга якын вакыт узды. Май аяз булды диярлек, июнь дә аяз тора,

әгәр шуннан июль дә аязга китсә?.. Халык көтә, сораша: чувашлар нәрсә әйтә, төрле елларны исенә төшерә — бу инде чынлап борчыла башлау иде. Эткол урамының әле бер очында, әле икенче очында бала-чага, яшь-җилкенчәкләр куыша-куыша су сибешәләр, узып баручы мөхтәрәм абзыйларның да өстенә берәр чиләк суны тондыралар — ачуланган кеше юк, тик яңгыр гына килсен!.. Ә кайбер авылларда халык, хәзрәтләре белән бергә, тәкбир әйтә-әйтә кырга чыгып, ятимнәргә карга боткасы пешереп, ничәдер рәкәгать намаз укып, ходайдан яңгыр сораганнар, имеш... Шуннан соң, ходаның хикмәте, ботканы ашап бетерүгә, кинәт гарасат купкандай, күкрәп-яшенләп яңгыр килгән ди дә, бөтен дөньяны иңләп, ишеп-ишеп яварга да тотынган, ди... Хәзрәтләр читеккәвешләрен салып, ыштан балакларын сызганып, чапаннарын башларына каплап, манма су булып кайтканнар, ди... Әнә шулай ышанып сөйлиләр, сөйлиләр дә, аннары тыналар. Чөнки андый яңгырның якынтирәдә генә түгел, бөтен өяздә дә булмавы иртәме-соңгы ачыклана торган иде.

Ниһаять, июльгә дә кердек, яртысына да җиттек... Җәй уртасы, чиллә башланды, күк йөзе әллә нинди кургашын төсендә, атналар буенча анда бияләй хәтле генә дә болыт әсәре күренгәне юк. Кояш иртәнге сәгатьтән башлап кыздырырга тотына, көнозын аяусыз яндыра, көйдерә, ә кичен, җирнең канын эчкәндәй, кызарып-бөртенеп, ялкау гына тагын аязга бата. Димәк, иртәгә дә шушындый ук мәрхәмәтсез көн булачак.

Хәзер инде быелгы җәйнең тоташтан корыга китүе һәркемгә ачык иде. Бик хәтәр, бик шомлы!.. Бу инде ачлык килә, ачлык якынлаша дигән сүз. Аның галәмәтләре дә күз алдында: айларга сузылган корылыктан җир кара чуен шикелле яргаланып катты. Үләннәр күптән саргайды, кипте, корыды — көтү йөргән җирләр тузанга әйләнде диярлек... Ач сыерлар көтүдән күзләре тонып, өйдәге азмы-күпме ризыкка йөгерә-йөгерә кайталар. Сарыкларның авызлары кара туфрак — алар җир кимерәләр. Әмма иң хәтәр-хәвефлесе — бу чәчкән игеннәрнең тәмам харап булуы иде. Берсе дә юк — көзге арыш та, язгы бодай да, арпа белән тары да. Сипкән орлыкны да алып булмас, диләр агайлар. Мин бик яхшы хәтерлим, бодай, мәсәлән, сирәк кенә чыгып, кашык буе үсәрүсмәс катып калган иде. Җитмәсә, аның һәрбер ач башагын саранча сырып алган... Бу хәшәрәт шул җәйдә генә каяндыр болыты белән килеп, кырларны тоташ баскан иде. Үзе эре, үзе соры, үзе һичнидән курыкмый — узып барышлый чыбыркы белән суксаң, башак белән бергә сынып төшә, әмма очып китәргә уйламый да... Аннары шушы кипкән, беткән басуларны да чүп үләне басып киткән иде. Дәүләкән тирәсендәге күп кенә басуларны аерып та булмый — әллә чәчелгән җир, әллә кысыр яткан кыр?!. Тик кайбер кырларны гына танып була, чәчелгән кадәресе болай чиста гына, ләкин барыбер сирәк, ач башаклы... Кыскасы, ипекәй булмаячак, ачлык һәр йортның капкасы төбенә килгән иде инде.

Бәхетсезлек җитәкләшеп йөри дигән сүз бар. Бу бигрәк тә быелгы шикелле афәтле елларга туры килә дә икән. Авылларда әледән-әле янгыннар чыгып торуы шуның бер мисалы. Ут ялап кына алды — якынына барырлык та булмады, дип сөйлиләр. Һәм гаҗәп тә түгел. Җитмәсә менә шушы коточкыч эссе корылыкка ияреп, моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән гаять куркыныч бер үләт — ваба (холера) чире безнең Дәүләкәнгә каяндыр килеп керде. Ярый әле артык озакка бармады, шулай да күп кенә йортларга кереп чыгарга өлгерде. Безнең әбекәйне алып китте, күршебез Сәлимҗан агайны, Габдрахманнар этисе Хәсән абзыйны алып китте. Көн дә мәчет ихатасында җеназа укыйлар, көн дә салмак кына чиркәү сугалар. Әмма гаҗәбе шул — бу үләт ни сәбәптер гел олыларны, карт-корыларны чүпләде, ә менә безнең ише

малайларга тимәде диярлек, һәрхәлдә мин белгәннәрдән берәү дә китмәде.

Әнә шулай үтте яки үтеп тә бара иде бу һич онытылмас фаҗигале җәй! Тарихта үзенең кара урынын алган, халык хәтерендә гомерлеккә сакланып калган «егерме беренче ел ачлыгы»ның башы иде инде бу! Ләкин ачлык үзе ни дәрәҗәдә көчле, каты булачак — ул кадәресен әле берәү дә белми иде бугай... Ел нинди генә булмасын, җәй бит әле, яланнардан нидер табып була, азмы-күпме бәрәңгесе, яшелчәсе бар, сыерлар чәйлек, аш пешерерлек кенә булса да сөт бирә, тавыклар күкәй салгалый, әле чынлап ачыккан кеше дә юк... Мин моны үзебезнең хәлдән дә беләм. Дөрес, безнең бер таяк та чәчкән, утырткан нәрсәбез юк, ләкин без дүрт кенә тамак, сыерыбыз бар, тавык, үрдәкләребез бар. Билгеле, атакай да тик ятмый. Хосуси сәүдә тыелган булса да, базарлар элеккечә һаман булып тора, анда кулдан гына нидер саталар, алалар... Атакай күбрәк менә шунда анысын алып, монысын сатып дигәндәй хәрәкәт итә... Хәрәкәттә — бәрәкәт, диләр бит...

Быелгы урып-җыю әллә булды, әллә юк — аны күрми дә калдык. Элекке еллардагы шикелле арбаларга төялеп уракка китүләр, ындыр табакларына фурман тутырып көлтә ташулар бөтенләй булмады да... «Игеннәр» урак белән дә, машина белән дә урып алырлык түгел иде. Аны күп урында кул белән йолкып кына алдылар. Кайбер утарларда косарқы тавышы ишетелгәләде — анда ашлык чалгыга эләгерлек булган дип сөйләделәр. Аларның кырлары бушагач та кайбер хатын-кызлар капчык алып, шунда башак җыярга йөри башладылар. Башак җыю беренче мәртәбә бәлки шул елны башлангандыр да, чөнки элек мондый эшне ишеткән дә, күргән дә юк иде.

Бу җәйнең һич көтелмәгән тагын бер хикмәте — ул да булса, шушындый корылыкта алабута котырып үсте. Бер нәрсә юк, бөтенесе янды-көйде, хәтта читән буендагы кычытканнар да, ә ул, хөрмәтле алабута, бөтен ташландык кырларда урман-урман булып утыра! Гүя табигатьнең адәмнәргә күрсәткән соңгы шәфкате иде бу... Һәм адәмнәр аңа шунда ук игътибар иттеләр, тизрәк җыеп алдылар, орлыгын уып киптерделәр, җилгәрделәр... Элек халык мәкале: «Алтын-көмеш таш булмас, алабута аш булмас»,— дип әйтә торган иде. Хәзер исә шул ук халык моны йакъ киресенә әйләндерде дә куйды: алтын-көмеш таш, имеш, алабута аш, имеш!.. Әйе, шушы кара яшькелт, әче бөртек ул елны бик күпләр өчен бердәнбер ризык булды.

Чын ачлык әле килеп җитмәгән иде, ул тик көннән-көн якынлаша, аңардан котылып булмаячак — инде нишләргә?.. Ничек итеп алдагы елның икмәгенә чаклы җан асрарга?.. Башак җыеп, алабута киптереп кенә торып булачакмы?.. Бигрәк тә бала-чагасы ишле семьяларның хәле бик мөшкел. Нинди котылу чарасы бар... Ярый, нидер чәчкән кешеләр бик аз гына булса да бөртек җыеп алдылар, бәрәңге утыртканнарның күпме-азмы бәрәңгесе булыр, аяклы малы барлар, көннәр суыткач малларын суярлар... Ләкин бит Дәүләкәндә берни чәчмәгән, утыртмаган, бер кәҗәсе дә булмаган кешеләр дә аз түгел...

Шундыйларның берсе — тимерче Миңнегали карт. Дөрес, аны фәкыйрьләрдән санап булмый, эше күп, алачыгында чүкеч тавышы тынып тормый, димәк, яшәрлек килере бар. Әле күптән түгел, яр башындагы йортын сатып, безнең каршыдагы урамда яңа йорт та торгызып керде. Ялгышмасам, сыерлары да бар иде шикелле. Ләкин картның гаиләсе зур, бала-чагасы күп иде. Өчесе әле бик яшьләр — ачлык алар өчен аеруча куркыныч булачак. Хәзер инде тимерчелек эше көннән-көн бетә бара, акча юньләп керми, берниндн запаслары юк, билгеле. Миңнегали карт нидер уйларга тиеш иде. Аның зур улы Зөфәр белән зуррак кызы Маһирә җәй ахырыннан ук немец басуларына башак җыярга

йөри башладылар. Ләкин бу инде, бичарадан ни чара дигәндәй, бушка әлсерәп йөрү генә иде. (Ач башактан нәрсә чыксын, ходаем?!).

Без элек тә алар белән якын күрше идек, хәзер дә күршеләр дип әйтерлек, һәрвакыт бергә аралашып яшәдек. Ике гаиләнең дә йорт башлары бер-берсен хөрмәт итәләр һәм еш кына үзара киңәшләшә дә торганнар иде. Һәм шушы бик хәвефле чакта Миңнегали карт, тәмам аптырауга төшеп, үзе безнең атакай янына килде: «Нишлибез, Нигъмәтҗан, эшләр харап бит!»— диде ул, чал йөгергән кара сакалын уч-лап.

— Әйе, эшләр шәптән түгел, Миңнегали абзый,— диде атакай да авыр көрсенеп.— Ни күрергә язгандыр инде?!

— Күрәчәгебез — ачык. Тик шуңардан ничек котылырга, ә, күрше?! Шуны әйтсәң иде син миңа!

Алар безнең бакча рәшәткәсе буена чүгәләп, әнә шулай сөйләшеп киттеләр. Мондый чакта күпме генә уйлама-сөйләшмә, дөрес бер карарга килүе бик читен булырга тиеш. Чынлап та, юкны кайдан табарга? Шулай да атакай, сөйләшә торгач, ахырда Миңнегали картка әйтте: «Әйдә, булмаса, Себергә таба барып карыйк, анда әле туклык, азмы-күпме азык алып кайтырбыз»,— диде.

Билгеле, минем атакай күп йөргән кеше, Себер ягын да яхшы белә, аңа ерак юлга чыгып китү әллә ни хәтәр эш тә түгел. Әмма Миңнегали картның үз гомерендә Дәүләкәннән беркая да атлап чыкканы юк, хәтта туксан чакрымдагы Уфаны да барып күргәне юк, шул сәбәпле аның өчен Себер хәтле Себергә чыгып китү бик зур тәвәккәллек сорый торган гадәттән тыш бер вакыйга булырга тиеш иде. Ул, әлбәттә, шунда ук ризалык белдермәде, тирән уйга төште, торып-торып авыр сулады, кайтып, карчыгы, балалары белән киңәшеп карарга булды. Ләкин барыбер күпмедер вакыттан соң, башка чарасы калмагач, ниһаять, тәвәккәлләде карт!..

Әйбәт кенә җыендылар, бар кадәренчә ризыкларын алдылар, азыкка дигән кадерле акчаларын ерак яшерделәр, шуның өстенә капчыкларына иске-моски киемнәр дә салдылар. Шулай итеп, ике күрше шәрә көзнең салкын бер көнендә узгынчы товар поездына эләгеп, Себер тарафларына китеп тә бардылар. Ул чакларда йөрүләр әнә шулай иде: кайчан, ничек, нәрсә туры килсә, шуңа утыралар да китәләр. Юлда ни була, исән-сау барып җитәләрме, бәла-казасыз гына кайтып керәләрме — моны алдан белүче юк. Өйдә калучылар, күпме вакыт үтмәсен, сабыр гына көтәргә тиешләр. Без инде моңа өйрәнгәнбез. Ләкин Миңнегали карт семьясы ут эчендә иде бугай... Гомерендә Әлшәй[1] базарына да чыкмаган кеше әллә кайдагы Себергә китеп «югалсын» әле!.. Шулай да алар Ікеме-өчме атна йөреп, Петропавловскига хәтле җитеп, шуннан исән-сау Дәүләкәнгә кайтып төштеләр. Юл азабын күп күргәннәр, эмма барулары бушка китмәгән — үзләре белән күтәрә алган кадәр ит һәм карындыкка тутырган куй мае алып кайтканнар иде. Әйтәсе дә түгел, атайларның шундый кадерле ризык белән исән-имин кайтып керүләре ике гаилә өчен дә зур бәйрәм булды. Бигрәк тә Миңнегали карт өендә корбан гаетендә дә мондый бәйрәм булмагандыр, шәт! Киң сәке түрендә көрәк сакаллы карт үзе, ике яклап тезелешкән җиңдеме-сигезме уллары һәм кызлары, каршысында карчыгы Сабира җиңги, ә табын уртасында зур шава белән хуш исләр тараткан симез итле, кара чумарлы шундый тәмле тансык аш!— Йә: моның ише сыйны

[1] Әлшәй — Дәүләкәннән 18 чакрымдагы базарлы авыл. Станциясе Раевка дип атала. Район үзәге. Элек Әлшәй базары дүшәмбе, ә Дәүләкән базары сишәмбе көн була торган иде.

кайчан күрерләр иде әле алар?! Нигъмәтҗан абзыйга рәхмәт инде — тәки йөртеп кайтарды бит картны!.. Ә карт Себернең туклыгына, ит-маенның күплегенә шулкадәр хәйран калган — балаларына сөйләп кенә дә бетерә алмый икән. Һәм бу ерактагы туклык аны харап та итә язды. Ул, баксаң, Себергә семьясын алып китү нияте белән кайткан икән. Билгеле, семьяда бу турыда сүз күп була. Себернең итен-маен авыз иткән һәм аталарының мактап сөйләвен ишеткән балалар моңа бик шатланып риза, хет бүген үк чыгып китәргә әзер торалар. Әмма картның зуррак уллары, алай ашыгып ризалыкларын белдермиләр. Бигрәк тә карчыгы борчыла, икеләнә, аңа янарак кына тора башлаган өе жәл,— итәк тулы балалары белән җылы оядан бер дә чыгып китәсе килми. Карт үзе дә чамалый, аңа Себердәме яки кире монда кайтыпмы, янадан йорт-җир торгызуы җиңел булмаячак. Шуларның барысын да исәпләп, карт, ниһаять, соңгы сүзен әйтә: йортын хәзергә сатмаячак, уллары Муллагали белән Зөфәр монда калачак, алар инде үзләре дә тимерчелектә бик әйбәт эшлиләр, иншалла, ат дагалап булса да тамакларына таба алырлар. Ә менә бу бер табын бәләкәйләрне коткарырга кирәк. Шуңа күрә ул хәзергә әле карчыгы белән шушы балаларын гына алып китәчәк. Анда, әйтик, шул ук Петропавловскида, аның һөнәре белән тамаклары ач булмаячак. Калганы исә алла кулындагы эш. Бу афәтле елны исән-имин үткәреп җибәрә алсалар, я үзләре кайтырлар, я барысы да яңа урында тупланып, шунда калырлар.

Әнә шундый мәсьәләне хәл иткәннән соң, алар ашык-пошык җыенып, балаларны ни бары белән җылы киендереп, төеннәрен һәм капчыкларын күтәреп, ноябрьның җепшек кар явып торган болганчык бер иртәсендә Дәүләкән вокзалына чыгалар. Күрше-тирәдән озата төшүчеләр дә шактый гына — тимерче картның бөтен оясы белән диярлек ерак сәфәргә күтәрелеп чыгуы үзенә күрә бер вакыйга!.. Ул чакта поездларның кайчан киләсе билгеле түгел (расписание дигән нәрсә дә юк иде шикелле), нинди поездга ничек эләгеп китәсен берәү дә белми, шуңа күрә көн озын сагаларга кирәк. Озата төшүчеләр саубуллашып һәм бәхилләшеп берәм-берәм китеп бетәләр. Болар сабыр гына көтәләр, көн уза, кич җитә, вокзал эче төенле-капчыклы халык белән шыгрым тулы — энә төшәр урын да юк. Арган-талчыккан балаларын йоклатып чыгар өчен кире өйләренә кайталар. Икенче көнне дә, өченче көнне дә шул ук хәл кабатлана — ничә тапкыр чыгып, ничә тапкыр кайтырга мәҗбүр булалар. Ахырда карт күрә: әйе, китеп булырлык түгел икән, соңгарак калган икән шул!.. Халык купкан, халык ачлыктан кача! Шушы бәләкәй генә Дәүләкән станциясенә дә тирә-як авыллардан ничәмә йөз халык килеп тыгылган. Кайсылары Себергә, кайсылары Ташкент ягына (болары күпчелек). Ә юлларда мәхшәр!.. Сирәк кенә узгалый торган пассажир поездлары тамбурларына хәтле тулып килә, шуңа карамастан халык ташлана, андагы талаш-тартыш, җылау-чинау — якын барырлык та түгел! Күпләр товар поездына эләгеп, аның да вагон түбәләренә менеп, ә кайбер ялгыз-кыюлар ике вагон арасына да утырып китәләр. Менә шушы мәхшәрне берничә көн рәттән күзәткәч, Миңнегали карт, ниһаять, кулын селтн: юк, булмый, ходай җылы өебездән аермасын, ди дә, бала-чагасын ияртеп вокзалдан бөтенләй кайта да китә.

Бәлки, бу хәерлегә дә булгандыр. Юллар бик начар, бик куркыныч. Коточкыч тыгызлык, пычрак-шакшы, тифнең беткәне юк. Кешеләр вокзал идәннәрендә, вагоннарда үләләр. Талау, урлау, бер-берсен югалтулар булып кына тора. Әле шушы кечкенә Дәүләкән станциясендә дә вак караклар башы-күзе тонган халыкның әйберләрен күз алдарында урлап китәләр. Бездән түбән яр астында торучы Сөбханкул исемле бер кара малай көн саен диярлек вокзалдан караңгы төшкәндә генә берәр капчык яки кәрзин күтәреп кайта торган иде. Урлаганын

яшереп тә тормый, киресенчә, мактанып сөйли генә... Әнә шулай Дәүләкән вокзалында күпме тәүлекләр аунап ятып-ятып та поездларга эләгә алмыйча, әйберләрен урлатып, кире өйләренә яки авылларына кайтып китүчеләр дә аз булмады. Миңнегали карт, ичмасам, андый казага дучар булмыйча гына бу «һиҗрәт»тән торып калды.

Без хәзер егерме беренче ел ачлыгы, дип сөйлибез һәм язабыз. Әйе, бу дөрес, әмма чын ачлык үзе егерме икенче елның кышына һәм язына туры килде. Бөтен нәрсәне яндырган-көйдергән коры җәйнең көзе ачлы-туклы булса да ничектер үтте, ә менә кышка кергәч, ачлыкның шәрә-сөяк куллары халыкны чынлап торып бугазыннан буып алды дияргә ярый. Хәер, ачлыкны күрмәгән яки күрсә дә җиңел үткәргән кешеләр дә, билгеле, булды. Болар элекке елның икмәген ашап бетермәгәннәр (мәсәлән, безнең күрше Арыслангәрәй агай кебекләр), шулай ук хәле җитеп, алдан запас хәстәрләгәннәр... (Ул көзне курма юклыктан мал бик күп суелды. Шул чакта һәркем ничек тә булса күбрәк ит алып калырга тырышты. Безнең атакай да бер чибәр генә тана түшкәсе алып куйган иде.) Әмма иң кирәге, иң заруры, иң кадерлесе шулай да икмәк икән!.. Икмәк белән генә кеше тук, икмәк кенә кешене ач үлемнән саклап кала икән! Ә икмәк юк, ашарга түгел, иснәп карарга да юк... Әгәр кайдадыр, кемдер кулында бодай яки арыш булса, ул инде дөньяның иң бай кешесе... Һәм андый байлар да бар иде бугай, чөнки бер пот арыш онына ачтан интегүченең таза келәтен яки ярты ызбасын сатып алучылар да булды. Аннары Дәүләкән базарына да чыккалый иде он дигән нәрсә, ләкин дә инде ул онны кесәсе тулы алтыны булган кеше генә алса алалгандыр. Кыскасы, икмәк юк. Шуңа күрә икмәксез елны «ачлык елы» диләр дә.

Ул елны икмәк урынына йөри торган бердәнбер ризык, әйткәнемчә, алабута булды. Алабутаны бөтен халык ашады. Без дә аны кыш буена ашадык. Әмма ләкин алабутаның бары үзеннән генә пешерелгән кап-кара «икмәк» ашар өчен бик әче, бик тәмсез һәм туклыклыгы да аның юк дәрәҗәсендә аз. Өстәвенә үзәкне көйдерә, саруны кайната, эчне дә бозып бетерә. Аңа ни дә булса, мәсәлән, бәрәңге яки тары оны кушарга кирәк — шул чакта гына аны икмәк итеп ашап була. Тик кайдан алырга бәрәңге белән тарыны?

Безгә алабутаның үзен дә, аңа кушарлык тары онында Ташлыкүлдән Кашшаф җизни китерә торган иде. Ташлыкүл тип-тигез далада утырган бер генә мәчетле кечкенә авыл. Бу авылның җирләре кап-кара туфрак, иген анда һәр елны диярлек уңа, күп кенә ындырларда сугарылмыйча кышлаган эскертләр дә тора иде әлек... Быелгы корылыкта да алар бөтенләй ашлыксыз калмаганнардыр, ахрысы.

Кашшаф җизни белән минем атакай, якын баҗалар булу өстенә, бер-берсен бик яраталар, бик хөрмәт итәләр иде. Бигрәк тә Кашшаф җизнинең атакайга хөрмәте зур иде. Һәм шушы гаять авыр чакта ул безне онытмады, хәленнән килгәнчә ярдәм итеп торды — билгеле инде атакай да аның алдында бурычлы булып калмагандыр (ул заман кешеләре үзара исәп-хисапны бик гадел йөртергә яраталар иде). Кыскасы, без алабута ашарга мәҗбүр булсак та, хәтәр кышны ачыкмыйча гына уздырып җибәрдек.

Ачлыктан тормыш сүнә, кешеләр сүнә. Мин бик яхшы хәтерлим, мәсәлән, малайлар арасында бергә уйнаулар бетте. Җәй көннәрендә элеккечә көтүебез белән тугайларга чыгып, сулар кереп йөрсәк тә, көзен инде, бигрәк тә кышка кергәч, җыелышып шар сугулар, шаулап чана шуулар тынды, тукталды. Якын-тирәдәге дусларым юньләп урамга да чыкмый башладылар. Аларның инде кайберләрен ачлык әкрен генә буа да башлаган иде. Туграк яшәүчеләр дә өйләреннән чыкмыйлар — куркалармы, ачларны күрәселәре килмиме — аңламассың...

Мин үзем урам аша каршыда гына торган Габдрахманнарга аратирә кергәли идем. Алар ишле семья, әниләре Бибикамал апа белән җиде җан, ә әтиләре Хәсән абзый холера вакытында үлеп киткән иде. Хәсән абзый — вак сәүдәгәр, кайчандыр җиләк-җимеш белән сату иткән, ишле булсалар да әйбәт, тук торганнар. Хәзер йорт башы үлеп киткәч, алар бик тиз бөлгенлеккә төштеләр һәм бик иртә ачыга да башладылар. Зур уллары, бик көязләнеп йөрергә яратучы Ибраһим абый ул чагында кайда булгандыр — хәтерләмим. Аңардан кечерәк Таифә апа китапханәдә эшли иде. Калганнары ике кыз, бер малай — ваклар, тик Габдрахман гына минем чамада. Менә шул ваклар барысы да ачтан шешенделәр. Эчләре күпкән, битләре өрелгән, әллә нинди ямьсез күксел төскә кергәннәр. Әкрен генә кыймылдыйлар, үзара әкрен генә сөйләшәләр, күбрәк ятып кына торалар. Ләкин арада иң ачыкканы Габдрахман булды шикелле, чөнки ул, унике яшьлек малай, элек тә ашарга комсыз иде, йөргәндә гел ни дә булса чәйни иде, аннары бөтен нәрсәне, мәсәлән, төрле үләннәрне тәмләп карарга ярата — ярасa ашый, ярамаса төкереп ташлый иде. Ә хәзер көннәр буе ач, тәрәзә каршына баскан, урамга тик карап тора. Ул шешенү генә түгел, әллә ничек картлар сыман булып киткән, авыз тирәсе җыерчыкланган, битенә бала төкләре бәреп чыккан иде. Мин җиң эченә яшереп кенә аңа чуенда пешкән берәр бәрәңге яки он кушылган алабута икмәге кертәләдем. Ул шуны, мине озатырга чыккан булып, өй алдында гына ашый иде. «Әни биргән генә миңа җитми шул»,— дип һаман зарлана иде... Шулай да Бибикамал апа балалары ачлыкны ничектер кичерделәр, берсе дә үлмәде, барысы да исән калды.

...Себергә ычкына алмыйча калган Миңнегали карт семьясы да ачлыктан бик интекте. Якын торгач, Зөфәрне күргәли идем, беткән егет, сөяккә генә калган, йөзе дә күм-күк — бала төге басып бетергән. Аңа бит инде 17 яшь, туярлык ашар өчен бер үзенә генә күпме кирәк?! Ничек әле чыдый диген!.. Ә кечеләре Саниялар, Әхтәмнәр?.. Хәер, ни хәлдә ятканнарын әйтә дә алмыйм — яннарына керергә уңайсызлана идем. Миңнегали карт үзе дә бик бетеренде, әмма чүкечен кулыннан төшермәде. Алачыкларыннан тимер чүкегән тавыш гел ишетелеп тора иде. Ул бит татарлардан бердәнбер тимерче — ачлык вакытында да аңа эш бетеп тормаган, күрәсең... Һәм шушы аларны ач үлемнән коткарды да булса кирәк.

ӘйтКәнемчә, ачлыкның иң рәхимсез чагы егерме икенче елның кышына һәм яз айларына туры килде. Дәүләкән урамнарында өйдән-өйгә кереп, хәер сорашып йөрүчеләр бик күбәйде. Болар барысы да диярлек тирә-як авыллардан килгән ачлар. Һәм иң гаҗәбе — нәкъ менә авылларда ачлык отыры каты булды. Ә Дәүләкән тимер юлы буенда бөтен әтрафның ашлыгы бирегә агылып килә иде, байлары да күп иде заманында, ат аунаган җирдә төк кала дигәннәр — менә шушы өмит ул бичараларны куып китергән дә булса кирәк. Әмма ләкин Дәүләкән үзе ач, үзе бер кабым сыныкка тилмереп утыра, инде азыклырак кешеләр бар икән, аларның капкалары көне-төне бикле. Һәм шул капкаларга сугылып, көчкә генә сөйрәлеп йөргән хәер өстәүчеләр ахырда урамда ук егылып үлә торганнар иде. Әгәр дә берәрсенең ишегалдында егылып үлә калса, аның гәүдәсен дә урамга чыгарып ташлыйлар иде. Моны гаеп итүче дә юк иде шикелле, чөнки урамда яткан үлекләрне махсус тәгаенләнгән кешеләр җыеп алып, каядыр илтеп күмәләр иде.

Бу ачлыкның бөтен хикмәтләрен сөйләп бетерерлек түгел. Мин әле бер Дәүләкән хәлләре турында, аның да үзем күргән һәм истә калганнарын гына сөйлим. Ә бит коточкыч ачлык бөтен Рәсәйне Уралга чаклы «биләп» алган иде. Мондый зур территориядәге ачлык төрле җирдә төрлечәрәк булгандыр, билгеле, әмма иң авыры-катысы Идел белән Урал арасына туры килгән иде бугай... Һәм шушы регион эчендә дә

төрлечәрәк үткәндер инде ул фаҗига... Безнең Дәүләкәнгә килгәндә исә, әйтергә кирәк, аның үзендә дә һәм әйләнә-тирәсендә дә ачлык бик көчле булды. Бик күп халык читкә качты, йортында калганнар исә ач-тан кипте, корыды, бик күбесе бер сыныкка тилмереп үлде дә... Адәм баласы ниләр генә ашамады ул кышны!.. Урамнарда этләр, мәчеләр калмады, хәтта балалар югалу турында да сүзләр чыккалады. Моны-сына никтер ышанасы килмәде, ахрысы, күңел кабул итмәгәндер, ан-нары каяндыр читтән, еррактан килгән сүзләр иде алар... Әмма Дәүлә-кәннең үзендә булган икенче бер нәрсәне мин һич тә оныта алмыйм — бик нык уелып, утырып калды ул минем хәтердә!.. Бу «самосуд» дигән нәрсә. Мин моны үз күзләрем белән күрдем. Ул елны, билгеле инде, ур-лаулар күбәйде, кеше келәтенә төшү, абзардан сарыгын яки кәҗәсен урлап сую, ә базар көннәрендә агайларның йөкләреннән берәр нәрсә чәлдереп китү гадәти бер эшкә әйләнде. Менә шуның өчен урлаучыга бер генә хөкем — самосуд! Эләккән каракны милициягә биреп тору юк, базар халкы тоталар да гөр килеп вата башлыйлар. (Милиция ул чак-та бик аз булды микән — нишләптер күренми дә иде.) Бу бик кансыз кыйнау, ерткычларча кыйнау... Ничек башлана ул?.. Әкрен генә чай-калган базар мәйданында менә бер заман, кинәт көчле өермә купкан-дай, халык шау-гөр килеп бөтерелә башлый. Кемнедер тотканнар!.. Ба-рысы да шунда таба йөгерә, урлаганын күрсә-күрмәсә дә «карак»ка ташлана, кулына ни эләксә шуның белән ватарга тотына. Эләккән ке-ше уртада бөтерелә, әйләнә-тулгана, башын-битен сакларга тырыша, баштарак: «Ай-ай, нишлисез, агайлар? Туктагызчы, агайлар!»— дип кычкырып та карый, аннары бераздан тавышы өзелә-тына, бары дөп тә дөп суккан тавышлар гына ишетелеп тора.

Бер вакытны минем алдымда Иске Кәрмәнкәйнең Хәйдәр исемле егетен шулай эләктереп алып, кыйный башладылар. Ул озын, таза егет иде, кемнәрнедер селтәп тә ыргытты, ләкин базар уртасында, котырган халыктан ычкынып буламы соң?! Урлаганмы, нәрсә урлаган — күргән-белгән кеше юк, ә кыйнаучылар инде Хәйдәрне этләр өере шикелле урап та алдылар. Менә, мәсәлән, чабата-чыпталар сатып торучы яшел Иб-рай дигән кеше тавыш купканны ишетү белән, чанасыннан озын күсәк суырып алды да, изге бер эшкә ашыккандай, тизрәк шунда таба чап-ты. Ул инде шул күсәге белән «карак»ны бер-ике тапкыр тондырмыйча әйләнеп килмәячәк.

Мондый кыйналудан бик сирәк кеше исән кала, күп вакытта үлек гәүдәсен ташлыйлар да китәләр. Җавап бирүче юк, җавап бирүчене табып та булмый, чөнки бу самосуд — бөтен базар аңа катнашкан. Лә-кин Хәйдәр ниндидер могҗиза аркасында исән калган иде. Соңыннан әле ул Кәрмәнкәйдән безнең спектакльләргә дә килеп йөрде. Ярата иде егет «уен» карарга. Ә менә Дәүләкәннең үз егете Нәгыйм белән «эшне» тиз бетерделәр. Аны, бичараны, базар мәйданына якын гына бер йорт-ның ишегалдыннан котырган халык вата-вата алып чыктылар. Имеш, шул ишегалдында урлап суелган кәҗәнең тиресе табылган... Нәгыйм утлы табада биегәндәй зыр-зыр бөтерелә, үзе ачы тавыш белән: «Юк, минем гаебем юк, агайлар!»— дип үкерә... Шул чакта кемдер артын-нан йөгереп килде дә моның башына таза күсәк белән берне кундыр-ды... Егетнең өстенә, әйтерсең, бер чиләк канны коеп җибәрделәр — бөтен алды-арты буйлап, шабырдап акты да китте. «Аһ!» — дип кенә өлгерде Нәгыйм, һәм шунда ук башын учлап җиргә дә чүкте...

Мондый самосуд күренешләре минем әллә ничек миңгерәүләтә, өн-сез итә иде. Ә хәзер адәм баласының ерткычлыгына алай ук исем китми. Ерткычлыкның җир йөзендә ходай бирмеш бер генә көн дә бе-теп торганы юк. Менә алтмыш ел буена җир шарында аның мисалла-рын мин күреп, күрмәсәм — ишетеп киләм. Әмма ләкин дә кешенең үзе кебек кешегә, бигрәк тә химаясыз җан ияләренә күрсәткән ерткычлы-

гына мин бер вакытта да иялэшэ алмадым, алмыйм һәм алмаячакмын!.. Табигатем башка минем...

Хуш, тагынниләр минем хәтердә саклана? Алтмыш елдан соң искә төшерүләре бик читен, бик күбесе, әлбәттә, онытылган. Бары тирән эз калдырганы гына сакланган. Һәм әнә шундый тирән, әмма яхшы эз калдырган тагын бер вакыйганы беләм мин. Ул да булса Совет дәүләтенең ачларга ярдәме! Әгәр бу ярдәм килеп җитмәсә, ачлыкның корбаннары, һичшиксез, тагы да күбрәк булачак иде.

Иң элек шуны әйтергә кирәк, бик авыр — фаҗигале ел булуга карамастан, мәктәпләрдә укулар бетеп тормады — ач балаларның килә алган кадәресен ач укытучылар һаман әкрен генә укыта бирделәр. Егерме беренче елның көзендә безне тагын икенче урынга — русларның элеккеге «городское начальное училище» дигән асты таш, өсте агач зур бинасына күчерделәр. Укуларыбыз хәзер иркен, якты классларда бара, укытучыларыбыз да берәү генә түгел — төрле фәннәрдән берничә. Хәзер инде бик куанып, рәхәтләнеп укыйсы да бит, тик менә каһәр суккан ачлык... Белмим, укуларны без язга чаклы суза алган булыр идек микән, әмма мең шөкер! — кыш уртасыннан безне мәктәптә бер тапкыр ашату башланды. Кайдан килде бу изге ярдәм? Дәүләкәндә 1918 елда ук оештырылган потребкооперация җәмгыяте бар иде. Менә шул кооперациянең зур таш магазинында ниндидер «Ар» дигән оешма исеменнән ачларга азык бирә башладылар. Кемнәргә нинди азык һәм күпме биргәннәрен хәзер инде әйтә алмыйм, ләкин мәктәп балалары өчен шуның кухнясында пешерелгән ап-ак икмәк, дөге боткасы һәм бик тәмле какао биреп җибәрәләр иде. Көн саен берәр укытучыбыз өч-дүрт малайны иртәп әлеге таш магазинга бара иде дә безгә дигән икмәкне чиста капчыкка, ә ботка белән какаоны капкачлы савытларга салып, чана белән тартып алың кайта иде. Шуннан соң түземсезлек белән көтеп торган шул гаять тансык ризыкларны безгә бик тигез генә итеп бүлеп бирәләр. Безнең хәзер букчаларыбызда кашык-савытларыбыз бар — менә шуңа салдырып алабыз да, бер бөртеген дә әрәм итмичә ашап, ялап куябыз.

Бу көненә бер ашау... Бәлки, ул ашау безнең кече тәнебезгә дә йогар-йокмас кына булгандыр, әмма ашау аркасында бик күпләр ач үлемнән котылып калды.

Ике елдан соң Ленин вафат булгач, балалар теленә ничектер үзеннән-үзе «Ленин бабай» дигән сүз кереп китте. «Ленин бабайга» багышлап шул чакта күпме шигырь язылмады, күпме җыр чыгарылмады?! Ачлык фаҗигасе әле онытылып бетмәгән иде, аны кичергән балалар да һаман әле шул ук балалар иде. Миңа калса, «Ленин бабай» дип бик якын, үз итеп дәшүдә әнә шул балаларның да бөек юлбашчыга әчкерсез тирән рәхмәтләре, һичшиксез, ишетелә иде.

Егерме беренче ел ачлыгы, табигый буларак, безнең әдәбиятта да чагылмыйча калмады. Әмма аның иң фаҗигале, иң ачык-шәрә күренешләре Галимҗан Ибраһимовның «Адәмнәр» исемле әсәрендә тасвир ителгән иде. Әнә шул артык «натуральный», артык берьяклы булуы өчен ул әсәр үз вакытында каты гына тәнкыйтькә дә юлыкты.

Ахыры бар.

# Шәүкәт Галиев

## Мәкерле миналар

*Саперлар Бөек Ватан сугышы чорыннан калган дошман миналарын табып, шәһәр читенә чыгарып шартлаттылар.*

(Газета хәбәреннән.)

...Сугыш ул, бетсә дә,
Калдырган миналар,
Юлыгыр дип көтә
Син аңар, мин аңар...

Фронтовик тәнендә
Яшәгән ярчыктай,
Ята ул җиремдә —
Туфракта, балчыкта.

Тутыкса, черсә дә
Әкерен-әкерен,
Әзер ул һәрвакыт
Чәчәргә мәкерен.

Йөрисең, белмисең
Кай төшкә посканын,
Бездәге тормышка,
Бәхеткә дошман ул.

Бабамны өзгәләп
Ташларга чамалап,
Кырык ел буена
Яткан ул сагалап.

Аннары әткәйнең
Килгәнен көткән ул,
Зәһәре эчендә
Кугәреп беткән ул.

Ниһаять, тиеш дип
Оныгы атларга —
Ята ул бүртенеп,
Ачудан шартларга!

Җиңүгә салютлар
Ничә ел яңгырый,
Сугышның үткәне
Һаман да җан сорый...

Әле дә гөрселдәп,
Тетрәнә һавалар —
Саперлар җиремнән
Үлемне алалар...

Сугыш ул илемнән
Бөтенләй китмәгән,
Кемнәрдер өчен ул
Тынмаган, бетмәгән.

Ә инде яңасы
Сәгатьле минадай,
Яный һәр минутта
Сиңа да, миңа да...

## Шугалакта

Уңга-сулга,
Алпан-тилпән,
Чайкалам да
Авып китәм —
Өйрәнүләр
Авыр икән...

Кызлар да бит
Үртәп китә,
Чәнечке сүз
Төртеп китә:
— Фигуралы
Шуа бик тә!

## Җил сурәте

Мин ясыймын,
Син күрәсең,
Менә нинди
Җил сурәте:

Ак каеннар
Бөгелүе,
Сары яфрак
Сибелүе.

Ал алмалар
Коелуы,

Күк болытлар
Куеруы.

Башын игән
Җикәннәр ул,
Киерелгән
Җилкәннәр ул.

Җилдән җитез
Очкан җайдак —
Кулындагы
Кызыл байрак!

## Сабантуйда җиңелгән малай

Җилкенеп чыкты уртага,
Үзе дә белми нидән —
Ахры, мәйданга ашкыну
Җитмеш бабадан килгән.

Карыйлар җиде яшьлеккә
Көрәшче итеп зурлап,
Алды ул иплəп сөлгене,
Бик оста гына урап.

Уйламый кем алдында да
Һич артка чигәрмен дип,
Ышанып, көч тоеп чыккан,
Әлбәттә җиңәрмен дип.

Аңа каршы баскан малай
Озынрак шул бер башка,
Үзең ега алмасаң да,
Тырыш син егылмаска.

Җиңү телиләр дус-ишләр,
Тирә-күршегә чаклы;
Дәрт биреп тора тавышлар —
Танышлар аның яклы.

Әмма көрәш-көрәш инде,
Җиңгәннәр өскә чыга,
Көчленеке замана дип
Әйткән дөрескә чыга.

...Мәйданга беренче керде,
Беренче бирешүе,
Горур атлап чыгып килә,
Сизелми килешүе.

Җиңелү гарьлеген бүген
Егетләрчә җиңәчәк.
Аһ итәр әле сабантуй,
Котлар аны киләчәк!

## Тырнаклы белән канатлы

Песи күбәләк куа,
Бераз уйнамак була,
Аннары тотмак була,
Кабып ук йотмак була....

Күбәләк тә ичмаса,
Уйный инде, уйнаса —
Тотам, дигәндә оча,
Йотам, дигәндә кача!

Ярсып-ярсып сикерә —
Усаллана тырнаклы.
Тырнаклыдан көлгән күк
Очып китә канатлы.

«Булыш миңа!» — дигәндәй,
Песи йөри янымда.
Юк инде, дим, ялынма,
Мин — канатлы ягында!

## Кыш чәчәкләре

— Бигрәк бай икән
Кышның хыялы,
Күр тәрәзләргә
Ясап куйганны:
Үләннәр анда
Төрледән-төрле,
Чәчәкләр анда
Серледән-серле!

— Ел да күрәм мин
Кыш чәчәкләрен,
Беләм исенә
Төшәчәкләрен:
Үзе өшеткән
Чәчәкләр җаны —
Үкенеп искә
Ала шуларны...

## Күлгә форточка ачам...

Бозның калын катламы
Кышкы күлне каплады.
Салкыннардан томалап,
Балыкларны саклады.

Балык сулый су белән,
Аңа һава — су, беләм.
Кысыладыр тыннары,
Өстән боз кысу белән...

Балта-көрәк алам да
Бер көнне чыгып басам,

Суласынчы ичмасам —
Күлгә «форточка» ачам.

Бер малай күреп тора,
«Тиле!» — дип көлеп тора:
— Син тырышканны инде
Балык бик белеп тора!

Малай үзе сизенә:
Исем китми сүзенә,
Күлем иркен сулагач,
Рәхәт минем үземә!

## Югыйсә...

Урман кисүчеләр —
Урлап кисүчеләр
Урман кисә,
Урман гына кисә
Югыйсә —
Урман белән бергә
Күләгәне кисә,
Күләгәләр төшкән
Күлләрне кисә.
Шул күлләр киңәйткән

Сулышны кисә,
Сулыш терелткән
Гөлләрне кисә,
Гөлләр туасы
Көннәрне кисә.
Урман кисүчеләр
Урман кисә,
Урман гына кисә
Югыйсә!..

## Карандаш төпчегенең ак кәгазь белән хушлашуы

Күңелләрне
Тоташтырып
Сүзләр суздым —
Ак кәгазем,
Якты җирем —
Һай, тиз уздым.

Юлларымны
Мин йөрәгем
Белән сыздым,
Авыр чакта
Сер бирмәдем —
Эчтән сыздым.

Кай арада
Йөгерде дә
Гомер үтте,
Үзәгемдә
Язар өчен
Күмер бетте...

Үкенечем
Кала минем
Бу дөньяда —
Ак кәгазьләр
Нинди серле,
Нинди яңа!

## Үпкәләдем...

Әти орышканда
Әни якламады,
Чәчтән сыйпамады,
Кочакламады...
Үпкәләдем!

Дәү әни дә күрми,
Читкә карый, имеш.
Минем күзләр юеш,
Торам шул килеш...
Үпкәләдем!

Дәү әти дә инде
Шул малаен тыйса,
Каты гына юкса
Бер әйтеп куйса...
Үпкәләдем!

Әтигә дә кыен
Булыр иде алай...
Үзем дә бит шулай
Мин кире малай...
Үпкәләдем!

## Арган таяк

«Хәлем юк»,— дисә дә бабай
Авыр таяк күтәргән!
«Күтәрешеп барыйммы?» дим,
Телим ярдәм итәргә:

«Кул таягың биреп торсаң,
Мин җаен табар идем,
Сине дә утыртып, бабай,
Атланып чабар идем!»

Килешмәде:
«Аргандыр ул —
Шактый җирләр үттек, ди,
Өчебезгә дә җай булыр,
Автобусны көтик»,— ди.

Әсрар Галиев

# АСЫЛ КОШЫМ МИНЕМ...

ПОВЕСТЬ

Сәгадәт апама багышлыйм

## 1



Сине тапкан көнне искә төшереп яттым әле, кызым! Чалт аяз иде. Ник шунда бер энә очы кадәр болыт кисәге күренсен. Анда-санда гына, тәрәзә каршындагы куе тополь яфракларын кыштырдатып, йомшак җил исеп куйгалый. Кояш бар нурын безнең алма бакчасына түгә диярсең, агач төпләренә авызларын ачып тавыклар чүмәшкән, кое янына җыелган суда үрдәкләр дә чупырдамый. Куләгәдә кымшанмый гына утыралар. Тәрәзәгә шәүлә салып, күрше Наилә апаң иелде:

— Бәбекәчең нишләп ята, Гөлфания, әтисен көтәсезме?

— Көтәбез инде, Наилә, кайтып төшәр кебек....

— Юлы унса ярый ла инде?!

— Нишләгәндер инде, кайтам дигән телеграммасы бар да бит...

Оныткан күрәмсең, Наилә. Телеграмманы бармак очларына гына эләктереп кичә үзе күтәреп керде ләбаса. «Әтиегездән, Гөлфания яшьтәш, кызың белән икегезне котлаган, иртәгә самолетта очам дигән» сүзләренә кадәр үз теле белән әйтте ич.

Шахтерлар баракта бер гаилә сыман яши, кызым. Берең шатлыгы барыңа да күчә. Наилә апаң шикелле чибәр, ягымлы хатыннар көненә бер түгел, биш керәләр. Керәләр, барысы да сиңа карап сөенәләр. Минем хәлемне сорашалар. Кулыма бер эш калмый. Ашарга пешкән, чәй кайнаган. Өйне юып чыктылар. Җибет-мазардан күчтәнәч-фәләннең агылып торган чагы. Төштән соң әтиең кайтып төшсә, шахтерлар мәш киләчәкләр инде. Әйдә, кинәнсеннәр бер. Алма бакчасына җыйналып утырырлар.

Бер дә авыр тапмадым, кызым, мин сине. Авырсынып та йөрмәдем. Шуңа күрә больниска барырга да өлгәрмәдем. Өйдә таптым. Кендек әбиең дә шул яшь-яшь Наилә апаң булды.

Дөресен әйтим, кызым, баладан болай җиңел котылу һәммә яшь анага да тәтеми. Әтиең киң күңелле булып, җан кыйнамагангамы, әллә үземнең соңгы атнага тикле эшләвемме сәбәпче булды — гел куанып кына йөрдем.

Шул куанычымны аклагандай, якты дөньяга иртә таңда бик матур йөз белән килдең. Яңа туган сабый димәссең — яңа туган ай диярсең: бит очларың туа-туышка алмаланып тора, имчәк очын гына имәрлек иреннәрең кыймылдавы рәхәт кытыклый, чәчләрең нечкә-нечкә сызык булып маңгаеңа ук төшкән. Тач әтиең чәчләре инде — кап-кара. Иягең чокырчыгы мәк чәчәгемени — күңелне тарта. Бөтен нур-йөзең бу кадәр әтиең булыр икән. Кайтып төшсә исләре китәр инде...

Наилә исә бәләкәчемне, бердәнберемне гел үземә охшатып маташа. Ияк чокыры да, кашлар сызымы да, Гөлфания яшьтәш, нәкъ үзең, дип төкеренә. Кендек әбисе булгач, минем күзем тимәс инде, дигән була үзе, шулай да томырып карарга базмый. Әтисе кайтканчы күз тидермик тагын, ди.

Мин үзем ырым-шырымга ышанучы заттан түгел, кызым. Күз тию диюләренә исем дә китми. Ник дисәң, җир өстендә генә түгел, җир астында да бернинди фәрештә, җен-пәри дә күргәнем юк минем. Безнең ише кызлар, шахтада маркшейдер[1] булып эшләүчеләр, җиде кат җир астына төшә. Анда тау токымнары гына: балчык, ташкүмер, таш, су, газлар һәм этиең кебек күмер чыгаручы забойщиклар, шартлатучылар, электровозлар бар. Ташкүмер дә — күмер, күмер чабучылар да ташкүмердәй чем-кара, тик күңелләре генә кояш нуры кебек балкый. Әчкерсез халык шахтерлар. Хыялыйлар.

Әтиең дә шундый. Университет дипломы алгач, әллә ниләр кырырга җыена. Кузбасс шахталарында бер грамм ташкүмер дә әрәмгә калырга тиеш түгел, ди. Хәзер бит әле алтмыш-җитмеш сантиметр калынлыгындагы ташкүмер катламын бөтенләй ташлап китәләр. Аңа тотынган кеше дә юк. Калынлыгы кырык — кырык дүрт метрга җиткән забойлардан алыначак күмернең бихисап өлеше җир астында мәңгегә ятып кала. Башында шундый уйлар кайнаганга күрә университетның геология бүлегенә китте ул.

Без синең турыңда, кызым, мең төрле хыял корып яшәдек. Без бик күп исемнәр юрадык, малай булса — этиеңә, кыз булса — миңа ятышлы исем эзләдек. Безнең халык борын-борыннан шундый исемнәр кушкан лабаса. Тимерханның малае туса Тимерҗан, Гайникамалның кызы туса Гайниҗамал.

Минем исемемне авыр диләр. Шулай да беркемнең дә бозып әйткәне юк. Авыз тутырып Гөлфания, дип эндәшәләр. Кыз булса ничек кушабыз? Гөл белән башланган исемнәр хәтсез: Гөлнур, Гөлия, Гөлзәминә, Гөлфия... — саный китсәң бармаклар җитмәс.

Әтиең хыялга баерак: әйдә, Гөләрия кушабыз, ди. Ул бу исемне гөлләр иле белән тиңли. Гөлләр иленә ия булырлык кыз — Гөлфаниягә тиң булыр, әлбәттә, ди.

Гөлфания исемле кыз булып мин аңа ничек туры килгәнмен, бусын капыл гына сөйләп бетереп булмый, сиңа, кызым, этиең мондый исем тапкач, мин кинәнеп киттем.

Гөлфания — Гөләрия!

Килештек. Кыз туса, шулай кушабыз.

Малай булса этиең исеме — Габбани ишлесен каян табарбыз?

Әтиең шул исемне беренче танышканда әйткәч, үзем дә сизмәстән артка чигенеп куйдым. Гомердә ишеткәнем юк иде. Андый исем бар дип тә уйламый идем. Шаярта, мин әйтәм. Китаплардан укып беләм. Әллә нинди сәер исемнәр истә калган. Курсави, Утыз-Имәни, Кандалыйларны беләм, ә менә бу, гап-гади шахтер егетнең Габбани булуына һич тә ышанасы килми.

Аптырабрак калуым йөземә чыккан иде, күрәсең, егет сизенде моны. Кушылып үскән калын кашлары маңгаена чөелде, кара бөдрәләре колмак кебек җилдә җилферди, матур булып уелып, китекләнеп торган борын канатлары кыймылдап китә. Сүз табалмый. Забойчы дусты Әнәс абыең Зимагулов коткарды үзен:

— Габбани теләсә кемгә түгел, матур кызларга карый,— диде Әнәс.

Мин тагын аптырап калдым. «Ни дип әйтте Әнәс бу сүзне?» Габбаниның мине, минем аны беренче күрүем ич әле.

Безнең танышу-сөйләшү шулай башланды.

Инде малай туса, Габбани ишлесен ничек табарбыз?

[1] Маркшейдер — тау токымнары чыгарыла торган урыннарның геодезик картасын алучы белгеч.

Ясәви дип карадым, Мәснәви дип — берсе дә ошамый. Әтиең әйтә, яңгырап торсын, яндырып торсын исеме, ди. Анысын да үзе тапты:

— Раббани кушабыз! — ди.

Мин шуларны искә төшереп, сиңа карап туя алмыйча яттым-яттым да, кызым, йоклап киткәнмен. Йокымнан манма тиргә батып, куркыныч төш күреп уяндым. Имеш, урамда, яшен яшьнәп, чиләкләп яңгыр коя. Ул да түгел, йодрык-йодрык боз ява башлады. Күрәм, шушы афәт эчендә, әтиең белән син кайтып киләсез. Әтиең сине күкрәгенә кысып, алга иелгән, имеш, боздан сине саклап, чаба-чаба кайта. Ышыкланыр урын юк. Баракка җитәргә унбиш-егерме адым калгач кына, әтиең, кинәт таеп егылды. Күрәм, өстенә бозлар ява. Тора алмый, бәгырькәем. Ә син, кызым, ачыргаланып-ачыргаланып елыйсың, имеш, кочаклап-кочаклап әтиеңне тартасың.

«Кызымны да боз сугып үтерә бит», — дип тәрәзәдән ташландым. Әллә ничек аягымны, билемме авыртып киткәндәй булды. Түшем белән шуышып барып, кызым, сиңа сарылдым.

Шул чак, бәгырьләрем өзгәләнеп уянып китсәм, ачык тәрәзә аша, көлемсереп, Наилә апаң карап тора.

— Нәрсә сулык-сулык киләсең, Гөлфания яшьтәш, кызың иммиме әллә? — ди. — Әкрен генә тор, яулыгыңны бәйлә! Йөгерә-чаба Габбаниең кайтып килә...

Ул да түгел, әтиебез кайтып керде. Бөтен өй эче җылы нурга чумды. Минем битләрем ут кебек кызышып чыгуны үзем дә тоям. Әтиең исә, алтын кош тоткан экият батырыдай, мәһабәт мускуллы беләкләре белән мине сак кына кочып алды. Сорап та тормады, кая, ничек тотыйм кызымны, дип уйлап та бирмәде, биләүдә ике көнлек кызын күтәреп алды да идән буйлап биеп тә китте.

Аллар ияләренә, гөлләр ияләренә,
Бәхетләре белән генә булсын ияләренә!

— дип җырлап та җибәрде.

Әй, бу ир-ат халкы, җиренә җиткереп шатлана белә дә инде!

— Гөләрия булгач, кызым тугач, дөнья киң хәзер! Әйеме, аккошым! — дип миңа әле генә күргәндәй эндәште.

## 2

Казанда әтиеңнең юллары уңмаган булып чыкты, кызым. Укырга керә алмыйча кайткан ул. «Кызың бар» дигән телеграмманы алу белән, иң соңгы имтиханга — инша язарга кереп тә тормаган. Син туган шатлыктан имтихан кайгысын да онытып, самолетка утыра да Новосибирскига, аннан Прокопьевскига оча. Ярый әле язуларын онытып калдырмаган!

Әтиеңнең имтихан кәгазендә «өчле»ләре юк иде, иншасын гына яздырдылар да Прокопьевск тау эшләре техникумына укырга алдылар. Кичке бүлектә укып йөри башлады. Мин дә, кичке бүлектә укып, тау эшләре институтын тәмамлаган идем. Габбанига уңай булды бу. Лекция дәфтәрләрем барысы да үземдә. Ә аның өчен дәрес әзерләшү кунакка барган шикелле генә тоелды миңа. Бу, гади бер уку гына түгел, ә көн саен шахтаның астын-өскә айкап йөрү белән бер иде. Ник дисәң, шахта эшен икебез дә беләбез. Хәтта, китапта язылганнар белән килешмичә, галимнәр белән бәхәскә керешеп киткән чакларыбыз да була.

Ни әйтсәң дә, күмер чабу — кухняда кәбестә турау түгел инде ул. Забой күкрәге — борт ишелә башлап, өстәге тау токымнары бер кузгалып китсә, лаваны шыплап яба да куя. Забойсыз каласың! Бурмашина урнаштырып, астан өскә таба скважина бораулаганчы, аннары забойчылар шул скважина буйлап лава тишеп үткәнче атна-ун көн вакыт уза. Ярый әле бу эшләр барысы да авариясез генә барса. Аның бит әле

төрткән саен дигәндәй газы чыга, суы ага. Җир астыннан вентилятор торбасын да суза кил. Беркетү өчен агач, такта, багана, өрлек әзерлә. Клетка[1] салып барганда, күпме көч сарыф итеһә, күпме вакыт әрәм китә. Ә забойщикның эш дәвамы нибары алты сәгать. Шул арада шартлаг та, күмерне дә бушат, забойны беркетеп тә өлгер. Болары — һәр сменаның төп эше! Шуңа баягы вак-төякне, забойны беркетү өчен баганалар, такталар әзерләүне дә өстәсәң — забойщикның мышнарга да вакыты юк.

Забойны куганда көн саен клетка салып яту каһәреннән котылу чарасы юкмы? Меңнәрчә тонна тау токымы басымына клетка барыбер ышанычлы тотнак түгел. Күңел өчен ярый ул, клетка салынган, борт китмәс, дисең, үз-үзеңне тынычландырасың. Белеп торасың бит: тау-таш бер кузгалса, өелгән бүрәнәләр тарала да китә. Әгәр бортта өч-дүрт багана беркетерлек кенә күмерне бөтенләй алмый калдырсаң? Күмер катламы акренләп шуышмасын, кителмәсен өчен борт астын юан баганалар белән беркетсәң һәм аны такта белән текмәп, тегеп куйсаң? Һәр өч-дүрт метр саен борт астыннан штрекка авыш мичләр тишсәң? Моннан йөреп тә була, агач та бирә аласың, җил дә әйбәт үтә. Әйбәт кенәме соң, хәтта сызгыртып торачак. Барыннан да битәр, бортта калдырылган күмер катламын — миллион ел буе шунда кысылып торган катламны — агач түгел, тимер клетка да алыштыра алмый. Без, әтиең белән шундый фикергә килдек, кызым!

Юк, мин моны турыдан-туры безнең генә ачыш дип әйтергә җыенмыйм. Бәлки, һәр забойщикның бу турыда уйлап караганы бардыр. Ләкин аның безнең шахтада кулланылганы юк. Тиктомалдан гына болай күмер калдырып китәргә беркем дә рөхсәт итмәячәк. Мәсәлән, без, маркшейдерлар, үзебез үк каршы моңа. Шулай да сынап карарга булдык. Өченче-дүртенче сменаларда эшләргә кирәк моны. Зуррак начальство килеп чыкмасын. Алдан ук лавачылар бригадиры Әнәс Зимагулов белән Габбани сөйләшергә тиеш. Икәү бергәләп участок начальнигы Владимир Боголюбовка әйтерләр. Боголюбов — тәвәккәл инженер. Производствога яңалык кертергә җаны фида. Әтиеңнең кулдашы Мишка Роговцовтан эш тормас! Котырган үгез кебек, ди әтиең аның турында, иң куркыныч урынга күзен дә йоммый керә дә китә, ди. Аңлашып эшлиләр. Үзем дә белеп торам.

Һөҗүмне шулай башларга булдык.

Билгеле, кызым, мин сиңа боларны тәфсилләп сөйләп тә тормас идем. Син, бәлки, гүзәл бер җырчы, яки рәссам булырсың. Кем белә, бәлкем, әниең шикелле үк тау эшләре инженеры булып китәрсең. Алма агачыннан ерак төшми, диләр бит. Минем әтием дә, әнием дә шахтер булганнар, үзем дә шахтер. Нәселдән килә торган профессия дияргә җыенмыйм мин. Теләсә кем төшеп эшли ала шахтада. Ләкин... бигрәк тә хәзерге заманда, теләсә кем, теләсә каян килеп шахтага төшми. Бусы — бер. Икенчедән, шахтадагы авыр эшкә хәзер хатын-кызны бөтенләй алмыйлар. Вентиляция участогы десятниклары, маркшейдер, нормировщик сыйфатында гына хатын-кыз җир астына төшә ала. Башка һәр урында ир-ат.

Шахта ачылган һәр урында борын-борыннан татарлар эшләгән. Алар җәен үз авылларына кайтып иген иккәннәр, кышын янә шахтага килгәннәр. Шуңа да аларны зимагур дип йөрткәннәр. Ягъни кышлык эшчеләре. Алар турында күпме җырлар бар, белеп бетерешле түгел. Сүз уңаеннан гына әйтүем, Әнәс абыеңның фамилиясе дә шуннан калган түгелме икән?! Бабасы, бәлки, бабасының бабасы заманында шахтер булгандыр, зимагурлыкта йөргәндер. Кушаматы — зимагур булгандыр, аннары шул кушамат нәселенә ябышып калгандыр. Зимагулов! Мөмкин, бик мөмкин. Кан тартмаса — җан тарта, ди бит. Нәсел-ыруында бер-бер шахтер булмаса, Әнвәр абыең шахтага килеп кермәс иде кебек. Ул бит җир-суны, авылны җаны-тәне белән ярата. Флера апаң шулай сөйли. Трактор, комбайн

[1] Клетка — өй бурасы рәвешендәге агачтан салынган ныгытма. Күләме күмер катламының калынлыгына карап төрлечә эшләнә.

жене сугылган кеше иде, ди, тиктомалдан китте дә барды, ди. Кандамы-жандамы,— шахтерлык жене бар Зимагулда.

Кызым, безнекеләр сугыш чорында килеп калганнар шахта жиренә. Авылдан ФЗӨгә килгәннәр, Прокопка. Төрле төбәктән, төрле авылдан күп яшүсмерләр килгән. Алар барысы да шахтерлыкка өйрәнгән! Шул егетләр авылга кайтып өйләнгән. Күмер жиренә алып киткәннәр кызларны. Бәхеткә кызыктырганнар. Кемерово шәһәренең исеме дә күмер сүзеннән алынуын сөйләп, авылны шаккатырганнар. Шул Кемерово якларының ташкүмер үзәге дә Прокопьевск шәһәре, имеш. Һәм шунда мин дөньяга килгәнмен.

Мине охшатып-чагыштырып түгел, үзләре яраткан исем белән Гөлфәния дип кушканнар. Мин чыннан да, гөлләрне, жирне-күкне, кешеләрне яраттым.

Әниемнең бар шатлыгы эти дә мин идем кебек күңелгә. Мин аларга гомергә бер булып калдым. Минем энем дә, сеңелем дә булмады. Тагын... тагын әниемнең көн саен сагынып сөйләгәне — туган Идел ярлары, Актай әрәмәләре...

Мин ул әкияти газиз илгә гашыйк булдым. Әмма бөтенләйгә кайта алмадым. Эти-әни һөнәре, туган жирем тартты мине. Шахтер шахтер урынын алыштыра, ә шахта бары тик әзерлекле кешеләргә генә буйсына. Әзерлек яшьләй килә. Вак-вак кына тамчы булып зиһенеңә өстәлә килә. Атаң-анаң сүзе булып зиһенеңә сеңеп үсә. Үз хыялыңда баетыла. Аннары аны берни белән дә кысрыклап чыгара алмыйсың.

### 3

Син уймак-уймак иреннәреңне әвәләндереп: «Әт-тәт-тә!»— дия башлагач, мин шахтага эшкә киттем, кызым. Телең синең «эти» сүзе белән ачылды. «Ән-нән-нә»не шактый соң әйттең. Һәм шул сүзләрдән соң әбибабайны тезеп китә башладың. Минем әнигә бу житә калды. Хәзер синең яннан китми дә. Югыйсә, Шахта бабаң хатыны Мәхтүмә әбиең карап торырга бик риза иде сине, кая ул, әни туздырып ташлады үземне.

— Бердәнберемнең бердәнберен кеше кулына калдыраммы соң,— диди ачулана.— Кызымны, ак күгәрченемне, үзебезгә үк алып китәм. Бабасы да гел сагынып кына сөйли.

— Нишләп, әни, бердәнберем дисең син? Мин дә бар ич...

— Баланың һәркайсы бердәнбер була, кызым. Ана өчен бердәнбер.

— Ата өчен?..

— Ата өчен дә! Менә сиңа этиең дә, мин дә бердәнберебез, дибез.

— Анысы шулай... Сезнең башка юк, без бит әле яшьләр...

— Анысы да бердәнбер малай булыр...

— Абау, әни, көлдереп үтерәсең инде...

Шахтада маркшейдерлар эше — авыр булмаса да, катлаулы хезмәт, кызым. Күмер катламының төрле урыннан калынлыгын, лаваның озынлыгын үлчисең һәм, күпме ташкүмер чыгасын исәпләп, һәр бригадага айлык план билгелисең. Лавачыларның план үтәлүен белеп торулары бик мөһим. План — акча. Арттырып үтәү — премия. Жир астында тузан-газ йотып беркемнең дә буш кесә белән йөрисе килми. Ипи-бәрәңге ашап кына шахтада эшли дә алмыйсың. Анда һәр эш күтәреп, төшереп, сугып эшләнә. Нәзек челтәрләр бик тиз бөгелә. Бөгә шахта эше.

Мин забойга килеп кергәндә лавачылар мәш килә иде. Авышлыгы житмеш-сиксән градуслы лаваларда эшләү үзе бер осталык сорый. Монда ялгыш басуың, абынуың, борылуың да куркыныч. Ә забой күмерме, породамы гел ыргыта тора. Борт өч рәт күмер катламы калдырып беркетелгән. Баганалар такта белән текмәлгәч, борт асты яктырып калган. Аннан бер бөртек күмер коелмый. Тау басымы да сизелми. Габбани белән Әнәс алмаш-тилмәш шпурлар бораулыйлар. Шпурда күпме тузан

булса, бөтенесе өсләренә коела. Берни эшләр хәл юк. Чөнки лава текә. Шпурлар астан өскә бораулана. Штрекка мич тишеп чыгу шулай башланды.

Әнәснең матрос тельняшкасы манма су. Габбани майкачан. Пөзенә карап танып булмый — күмер дә күмер, Габбани да күмер.

Боголюбов та үзенә урын таба алмый. Әнә штрекка менә, ул да түгел забойщиклар янына төшеп китә. Уйланылмаган нәрсә калмадымы, ныгытылмаган урын юкмы, янәсе. Мишка Роговцов кына гадәти кылана. «Бөтен әйберем әзер, әйтегез генә, үтим!» — дип тора.

Шахта бабай да дулкынлана. Ул хәзер, өченче-дүртенче лаваларны да Әнәс Зимагулов бригадасына тапшыргач, үзе забойчылар өчен кирәк, кәйлә, кувалда саплап, балталар үткәреп, тәртип саклап кына йөри иде. Кырык ел эшләп җир астыннан туймаган Шахта бабай бүген тагын яшәрә төшкән. Забой күкрәген ныгыту өчен күмер калдырып эшләү хәбәрен Габбанидан ишеткәч, аска ук төшеп утырган. «Күп тутырмагыз шартлаткычны, серияләп шартлатыгыз, серияләп», — дип тукый забойчыларга.

Аның сүзенә колак салалар. Боголюбов та шуны куәтли: «Карагыз, егетләр, әйбәт ныгыттыгызмы? Шартлатканда баганалар очса, бетте баш...»

Шартлату көткәннән дә әйбәт булды. Күмер гел аска очты. Баганалар, өрлекләр селкенмәде дә. Бүрек кадәр күмер тузаны гына күтәрелеп алды бер мәл. Аннары ул да аска китте. Шул тишектән куе булып бөтерелеп, ак-күксел шартлау газы ыргып чыкты.

Мондый чакта газ чыгып беткәнне көтеп торамы соң забойчылар. Дәррәү аска төшеп киттеләр. Бераздан, кәйлә белән мичне, забойны күмердән чистарта-арындыра, Габбани да штрекка килеп чыкты.

Ул күрсәң иде Мишка Роговцовның шатланганын, үзе бер кәмит, чын әгәр. Егыла-нитә калса — кеше, кулдан ычкынса — инструмент тотылып калсын өчен сузылган сәндерәләргә баскан да тетә генә матрослар биюен.

— Миша, частушка! — дип кычкырды Габбани.

Ялындырамы соң Миша, үзе бии, үзе җырлый:

**В шахте «Красном Углекопе»**
**Есть трое молодцов;**
**Г-габбани, Зимагулов,**
**Третий Мишка Роговцов.**

— Молодец, Миша! — диде Боголюбов көлемсерәп. — Шулай, үзеңне калдырма...

— Кыланчык, — диде Шахта бабай да мыегын сыпырып, — минем лаваларда бии-бии дә такталарны сындырып бетерә иде, кара, ничек җырлый...

Инде мичне беркетеп, кайтып китәсе генә иде, Роговцов тагын эшне бүлде. Бортка меңүе белән кычкырып җибәрде:

— Егетләр, мич түгел — дудка бу!

Чыннан да, астан, забой буйлап күтәрелгән һава агымы мичтән шундый бәрә ки, хәтта давыллы көнне морҗада улаган җилне хәтерләтеп, сызгырып тора иде.

Забойчылар «дудка» дигән сүзне бердәм күтәреп алдылар. Бу — шахта терминына әйләнде.

4

Шахтадан юынып өйгә кайтканда, әтиең белән бәсле урамнан бергә атладык. Себер иртәсе. Тып-тын. Ун-егерме метрдан кешене танып булмый — куе томан. Җил юк. Ә салкынлык ким дигәндә кырык градус. Әгәренки җил дә булса, иреннәреңне куырып алыр иде. Болай тын торгач, салкынлык сизелми. Үзенчә бер рәхәтлек бирә бу салкынлык. Сулышка иркен. Аяк атлавы җиңел. Күңел күтәренке. Әй, дөньяның һәр җире дә Себер киңлекләредәй ямьле булсын иде! Бу ямьне бозарга бер генә кеше дә җөрьәт итмәс иде. Сугышларсыз, окопларсыз матур бит Җир шары.

Кемгә җитми бу һава, бу җир, бу дөнья, бу тормыш! Өемдә балам, Гөләриям сагынып көтеп тора, мин кибеткә чыксам да аның янына ашкынып кайтам. Янәшәмдә нык, батыр адымнар белән ирем Габбани атлый. Ул минем өчен корыч стена, мәңгелек таянычым.

Габбани озын тунын төймәләмәгән дә, изүләре ачык; үзе якасын күтәргән, бүрек колагын төшермәгән. Ялан кул! Бияләе тун кесәсендә. Шарфын урамаган, муенына гына салган. Тоташкан кашлары астыннан каен дегетедәй соргылт-карасу күзләре нур сибә. Бит алмалары кызарып, янып тора. Тыгыз, нечкә, чем-кара сызылган мыегына ап-ак бәс сарган. Атлаган уңайга борын яфраклары киерелеп-тартылып куйгалый. Күренеп тора, ул бүгенге эшеннән канәгать. Үзе өчен түгел, Әнәс, Миша, Габдрахман ага, Боголюбов өчен шатланып кайтуыдыр әле. Кинәт ул мине култыклап алды. Дәшми-нитми генә, капыл гына. Бу аның онытылган гадәте иде. Кыз вакытта да еш култыкламады ул мине. Салмак кына атлаган көйгә, кулларын бутый-бутый сөйләргә ярата иде. Бик аерым очракта, кинога, концертка билет алса гына, яшерен сер әйткән кешедәй, култыклап алыр иде дә иелеп колакка пышылдар иде: «Гөлфәния, бик әйбәт картина ди бүген». «Гөлфәния, Илһам Шакиров килгән, барабызмы?» Тиле кеше әйтмешли, әллә ун тапкыр бардык инде Илһам Шакиров концертына. Ун түгел, йөз тыңласаң да туйдырмый үзе. Җырга, моңга якыная гына барасың. Бер-береңә якыная барасың. Хисләнәсең. Сафланасың. «Маганак» шахтасындамы, «Черная гора»дамы, «Зенково»дамы, «Березовая Роща» шахтасы клубындамы — берсен дә калдырмадык. Шәһәрдә шахталар күп, клублар күп. Егерме көн барды концертлар. Кая барма, клуб тулы халык. Габбани гына билетны ничек юллап өлгергәндер...

Әле янәшә атлап кайтканда култыклап алгач та, нидер әйтәсен сизеп алдым Габбаниның. Сорамадым. Үзеннән көттем. Озак көттермәде.

— Гөлфәния,— ди Габбани, белегемне кыса төшеп.— Рәхмәт, сиңа! Бәладән коткарасың безне...

— Нинди бәла, Габбани?— дим мин аңламыйча.

— Нинди, нинди? Җан кисәгем, шуны да аңламаска. Бүген үзең карап тордың бит. Ничек килеп чыкты. Менә дигән!

— Минем ни катнашым бар инде, Габбани. Сез эшләдегез ич.

— Сызып, язып син аңлатмасаң, мин аңа чынлап торып керешә идемме? Боголюбовка, Әнәскә, Габдрахман агага аңлатканда да синең исәпләүләр, сызымнар күз алдымда торды. Бортта күмер калдырып эшләүгә күчү — үзенә бер яңалык бит. Зур түгел, әмма яңалык, җаным!

— Бәлки, шулайдыр...— дидем мин. Без инде баракка кайтып җиткән идек.

Ишектән килеп керүебезгә син безне каршы алдың, кызым! Сиртмәле бишегеңне әни күтәреп алды да үзеңне ишек янына алып килде.

— Куыгыз салкынны, өйгә кертмәгез! Чишенегез. Кызыгыз сагынып бетте, кызыгыз... Әнә, ән-нәсе дә кайтты, әт-тәсе дә...

Мин сиңа туйганчы күкрәк сөте имездем, кызым! Йөрәк сөле, яшәү сөле эчтең син. Иреннәреңне мүлтәйтеп-мүлтәйтеп, ашыга-ашыга сөт суырганда, мин сиңа сокланып утырдым. Аның саен сине иркәләдем, рәхәтләнеп имсен дип, үзеңне төргән нәзек одеалны рәтләп, аның саен иркәләп аякларыңны, аркаңны сөйдем, башыңнан сыйпап тордым. Ә син йотлыга-йотлыга имдең дә имдең, һәр суырган саен диярлек зур күзләреңне тутырып, миңа карап-карап алдың. Бу синең: әнием бит бу, дип танып каравың иде. Имеп туйгач та, ы-ых! итеп тирән бер суладың да, әтиеңә карап көлеп куйдың. Ике тешең күренгән авызыңнан әллә нинди кызык авазлар чыгара-чыгара көлдең. Синең бу әчкерсез көлүеңнән өй яктырып китте сыман, туң тәрәзә эреде кебек. Мин әчке бер шатлык белән аш-су әзерләргә керештем, әтиең сине итәгенә утыртып, нидер сыза башлады. Тагын лава белән җенләнүедер инде...

Әтиең белән юлда кайтканда да сиземләү турында бер искә алган идем, кызым! Кыз бала өчен, хатын-кыз өчен җан белән кан шикелле үк кирәкле нәрсә ул. Сиземли, тоя, хыяллана белгән кеше генә кеше! Ир белән хатын булуның сере дә шуннан киләдер, бәлки. Икең бер тирәдәрәк укый-сиземли белсәң — бу яхшы! Әгәр ирең тирәнрәк, нечкәрәк хисле кеше булып, син дә шул дәрәҗәгә күтәрелергә тырышмасаң — бу начар! Ә инде үз сиземләвең, хыялың биегрәк булып, шуңа иреңне иярта белмәсәң — монысы бөтенләй начар. Хиссез, ташкүмердән дә каты бәгырьле, тау токымыдай утырып калган мәнсез кеше генә ире йөрәгенә салкын бармаклары белән ябышыр. Ә бит сүз белән дә кагылырга ярамый торган йөрәкләр бар. Онытма, кызым! Ир-ат кичерә ул, әмма аның йөрәгe сиңа бал да май түгел инде. Кичәге — мәхәббәте, бүгенге — балалары хакына да яши кайбер ирләр. Ләкин сынык күңел белән... Аларга җылы өрүче без — хатын-кызлар — ирләр йөрәген зәрәгә яраламыйк. Алар — гаилә тоткасы, алар — ил терәге. Алар өйдә Верховный Совет Председателе! Бүген дошман бер пуля атты икән, ул пуля алар күкрәгенә барып тия...

Уйларыма чумып, бәрәңге әрчеп утырганда тек-тек ишек шакуга борылып карасам, әйе, кер, диярга дә өлгермәдем, ай-кояштай балкып, Наилә апаң керeп килә.

— Гөлфәния япьтәш,— ди бу, кергә-керешкә үк минем янга чүмәшеп,— син әллә эштән яңа кайттыңмы?

— Әйе,— димен. Үзем күршемнең өс-башын күзәтәм, төсен-буен, килеш-килбәтен күздән кичерәм. Хатын-кыз шулай бит ул, бер-береңне тикшереп кенә торасың. Зәп-зәңгәр күзләре томырып карый. Аскы иренe бераз түгәрәкләнеп килгән кечкенә авызыннан күзләрне камаштырып ап-ак тешләре җемелди. Коңгырт чәч толымнары алдына төшеп, идәнгә үк тиеп тора. Наилә апаң чәчен аерма ясап үрә. Бу аның матур тулы гәүдәсенә бик килешә. Көнбагыш башыдай зур чәчәкле алъяпкычын да биленә бәйләп куйса — күзеңне ала алмыйсың, менә дигән татар кызы инде. Мишка Роговцов та бер күрүдән аерыла алмады. Бер ел йөрде артыннан; тәки үз дигәненә ирешто, парин (үз әйтмешли), бер ел дигәндә туй ясадылар. Синнән, кызым, бер генә яшькә олы уллары Руслан үсеп килә.

Минем уйларымны әллә сизде, әллә сизеп тә белмәмешкә салышты Наилә, аның үз туксаны — туксан иде.

— Шахтада бер-бер бәйрәмме әллә бүген? Безнеке кайтып керде, авызы колагына җиткән. Үзе көлә, үзе җырлап куя: есть трое молодцов, дигән була. Шуларның берсе Мишка Роговцов дип тә җибәрә,җүләрем. Әллә эчкән-ниткәнме бу иртә таңнан дип аптырагач янына килеп иснәп тә карадым. Юк, берни юк! Малайлар кебек, һаман уйнап йөри идәндә Руслан белән. Күңелем сизә: нәрсәдер бар барын. Әллә зуррак премия бирәселәрме?!

Әйтәм бит, сизенә хатын-кыз күңеле, килеш-килбәтеннән күреп торам. Үзе сорарга базмаган. Мишкасы — ачылмаган. Нәрсәдер бар, белә ул аны! Ләкин нәрсә?! Менә сорашырга кергән.

Төнге сменада Мишаның «дудка» уйлап табуын әйткәч, ышанмый торды Наилә:

— Китче, кит булмаганны,— ди.— Эшкә барганда, кулына тоттырмасаң, бүреген киярга дә онытып чыгып китә торган кеше, уйлап табамы соң? Әле минем исемне ничек онытмый дигән...

— Наилә, укымадыңмыни, күптән түгел генә газетага язганнар иде бит: Нобель премиясе лауреаты, немец галиме Пауль Эрлихның бер сәер гадәте булган. Ул иртәгә башкарасы эшләренең барысын да язып почта аша үзенә хат итеп китерттергән, имеш. Шундый таркау булган.

— Бусы инде бигрәк тә...— ди Наилә көлә-көлә.— Үзе лауреат, үзе эшен оныта. Хәер, Архимеды да мунчада ачыш ясаган ди түгелме соң? Миша да шул, баштa үзе сызгырып куйгандыр да, аннары «дудка!» дип кычкыргандыр...

— Нәкъ шулай, Наиләкәем. Ул моны белми дә калды. Забойщиклар ишетеп алды да, тагып та куйды.

Наилә терриконда эшли. Җир астыннан чыгарылган ташкүмерне чистартып, ят токымнардан арындырып тора алар. Җир асты эшләрен дә белә. Төшеп-төшеп караганы бар.

Наилә апаң, бәлки, безнең шәһәрдә төпләнеп калмаган да булыр иде, кызым! Аны да шул, әни әйтмешли, әлеге дә баягы, шахта җире шаукымы тартты.

Ник дисәң, ярты миллионлы шәһәр булса да, татар кызлары алай күп түгел. Ә егетләр ел саен армиядән шахтага кайта. Бик бәхетлеләренә генә якташ кызлар эләгә.

Бездә кичләрен татар-башкорт җыелып уйный торган урын бар. Монда җырлап, түгәрәк уеннар уйныйлар, егетләр-кызлар таныша торган урын бу.

Гөрләвекләр агып, шәһәргә язгы җил истеме, шунда җыела башлый инде халык. Узган елгы кызлардан икәү-өчәве генә күренә. Кияүгә чыгып беткәннәр. Һәр ел шулай бу! Уенда гел кунак кызлары гына диярсең, күз ияләшмәгән чибәр-чибәр, япь-яшь кызлар. Авыл кызлары, унынчыны бетергәч тә, укырга керә алмасалар яисә юньле эш тапмасалар — безнең шахта җиренә туганнары янына киләләр. Күздә үк һәр гаиләгә диярлек берәр кунак кызы килеп кала. Кышын күрмисең дә, белмисең дә син аларны. Ә язын, җир өстенә төрткән ямь-яшел бәбкә үләне күк, күз нурыңны алырдай чибәр-чибәр кызлар. Егетләрнең күзе уйный. Йөрәкләре дөрләп яна. Ул китә бүлеш, ул китә танышу, ул башлана туйлар. Наилә апаң да менә шул дулкынга эләкте, кызым! Ләкин алай тиз генә түгел...

Без җыенга Наилә апаң белән бергә чыктык ул көнне.

«Талы, талы» дигән уен уйныйлар. Кызлар, егетләр зур түгәрәккә тотынып, җырлый-җырлый бииләр.

Үзәкләр өзелеп, йөрәк җилкенеп тора. Бигрәк тә, уртадагы гармунчының бөгелә-сыгыла тальян тартуы бәгырьләрне кисә. Кая туган да, кая үскән бу егет. Гармуны да гармун, үзе дә гармун бу.

Гармунын икенче егеткә биргәч, ничектер, безнең янга килде бу.

— Мидхәт!— дип кулын бирде танышканда.

Без дә үз исемнәребезне әйттек. Әмма, ни өчендер, Наиләнең кулын озаграк тотып торган шикелле тоелды бу миңа.

Күрер күзгә әллә ни матур түгел иде Мидхәт. Какча яңаклы ачык йөзендә җәлпәгрәк борын, ләкин ихлас күңел белән, яктырып сөйләшүе бар нәрсәне оныттыра. Гармунчы булуы белән кыз күңелен бер урап алгач, аны читкә этәрүе авыр иде, ахры, кызларга. Әйе, гармунчыны гармуны яктырта! Гармунчы — кызлар күңелендә һәрчак бер башка өстен. Уздырса, сабантуй батыры гына аннан уздыра. Башкага чут юк. Сабантуй батыры исә меңгә бер авылда гына үсә.

Шул кичне Наиләне озата кайтты Мидхәт.

Ләкин Наиләнең йөрәген башка берәү били иде. Кичке җыенда Мидхәттән читләшеп, аның тирәсендәрәк чуалып кайнашты Наилә. Әллә Наиләне аңламады, әллә белеп тә белмәмешкә салышуы булды — ул егет Наилә белән сөйләшеп китә алмады. Ә Мидхәт аның саен килә. Эшенә килеп йөри башлады Наиләнең. Ун чакрым ара лабаса. Гел-гел килеп-китеп йөрешле дә түгел. Автобус көтә-көтә соңгарып, ике тапкыр эшенә прогул ясады ул. Зимагулов пешекләгән үзен. Шахта бабай белән икәүләп игәүләгәннәр моны. Габбани да катнашкан бугай. Минем моны ул чакта да, соңыннан да сораганым булмады. Ничектер онытыла. Искә төшми иде.

Шул, сәбәбен сораганнар үзеннән. Мидхәт, ачык авыз, түкми-чәчми сөйләгән дә биргән. Яратам, дигән, игә килми йөри, ниндидер башка берәүне ярата, ахры, дигән. Тик бер нәрсәне һаман әйтмәгән...

Орышканнар, кызганганнар, көлгәннәр үзеннән. Өйрәткәннәр дә үзен. Әнәс бер жыр әйтеп күрсәткән, бүген кичен шул жырны жырла син ул кире беткән кызга, дигән.

Мидхәт бу кичне дә гармун тартып кына утырды. Наилә тагын теге егетне уртага алды. Мидхәт бу егетне биетеп чыгарды да, үзе уртага кереп басты. Үзе уйный, үзе жырлый, үзе Наилә каршысына ук килеп, бармаклары белән үзенең күкрәгенә күрсәтеп, төртеп-төртеп ала.

Дулкыннары бәреп керә
Корабль идәненә.
Сознательный булсаң гына
Ярарсың сөйгәнеңә.

Я инде, аңла инде Наилә, янәсе. Сөйгәнең — Мидхәт бит ул. Ул аны беркемнән дә яшерми әйтә. Әллә кемнәргә баш игәнче, үзеңне сөючегә тугры бул да, котыл мәшәкатьләреңнән, фәлән-фәсмәтән, янәсе.

Шул кичәдән соң йөрергә килешәләр бугай алар. Хәтеремдә шулай калган.

Ә Мидхәтнең — Михаил Роговцов исемле рус егете булуын язылышырга барганда гына белдек. Татар авылында бердәнбер гаилә белән яшәгәннәр алар. Үз телен — әти-әнисеннән, татар телен — халыктан өйрәнгән Миша абыең. Ләкин аның кебек ике телдә дә өздереп жырлаучыны димим, хәтта иркен итеп сөйләшә белүчене дә күргәнем, очратканым юк әле минем. Татарча жырласа — син аны татар бу дисең! Русча сөйләсә — чын рус бу дисең! Дөнья бай бит ул. Халык бай. Роговцовлар, Наиләләр, Габбанилар белән бай бу дөнья.

## 5

Шахта жирендә вакытның үткәне сизелми, кызым. Габбани сөйли, егет вакытта туган көнемне онытып эшләгән еллар булды, әле дә ярый искә төшереп торырга син бар, Гөлфания, ди. Мин ышанам моңа, кызым. Шахтер төнге сменадан чыгып, юынып, киемнәрен алыштырып, өенә кайтып кергәнче көндезге сәгать уннар чамасы була. Ә эшкә төнге сәгать уникедә чыгып киткән кеше бит ул. Төнге бердә участокта нәрәт алалар, сәгать икедә забойда смена алышына. Шуннан, иртәнге сигезгә тикле күз какмый эшли ул. Шурфка чыгып, кайчакта жәяү, кайчан машина белән комбинатка кайтасың. Аннан аккумуляторыңны ламповойга тапшырып, табель номерыңны аласың. Мондагы чират, кибет каршына хатыннар тезелеп баскан кыше генә түгел. Биш-алты тимер тәрәзә тишегендә мең ярым — ике мең шахтер. Аннары, мәш килеп, ашык-пошык юыналар шахтерлар. Бала-чага авыл буасында коена дип белерсең. Юынырга керделәрме, шахтерлар тавышына өч катлы кирпеч комбинат һавага күтәреләме әллә дип торасың. Гүя забойда булмаганнар да кебек. Төн буена балта керми торган биш-алты метрлы туң бүрәнәләрне сөйрәмәгәннәр дә, егерме килограммлы балта белән суга-суга шул баганалар белән лаваны беркетмәгәннәр дә сыман. Йөзләрендә ап-ак тешләре генә елтырап күренгән бу кешеләр бары да елмая. Бары да шат.

Өйгә кайткач та, ашадылар исә, изрәп йокыга тала шахтерлар. Хет каравыл кычкыр, хет барагыңның яртысы янып бетсен — уянмыйлар.

Габбани шулай йоклаганда, аш-су әзерләп йөрү бигрәк рәхәт була, кызым! Аш пешерүне мин һәрдаим изге бер эшкә тиңлим. Чаштыр-чоштыр бәрәңге әрчеп, дөбер-дөбер кәстрүлдә кайнату гына түгел ул аш пешерү. Жаның-тәнең белән шуңа бирелеп, ул ашның тәмен күңелең белән тоеп, авыз суларын китерә-китерә аш пешерүгә ни житә! Мин аны ирем яратып ашасын өчен, шул ризыктан ул көч-куәт, гайрәт алсын өчен яратып, ләззәт табып пешерәм. Мин аны кызым Гөләрия ут чәчәгедәй янып, күбәләктәй очынып-очынып, нурлы йөзкәйләре гел-гел алсуланып торсын өчен күңелемне биреп пешерәм. Мин аны иремнең, кызымның дуслары алдында, үз дусларым алдында оятка калмас өчен бар булган осталыгымны жыеп пешерәм. Шуңа да, авыз тутырып, Габбани аш ашаганда, әни мәмәй, тагы, тагын, дип кызым аш сорап алганда, минем

түбәм күккә тия. Шатлыгым, яшен ташыдай, күкрәгемдә уйнап тора. Мин аны яшерергә тырышам. Битләрем янып чыга, маңгаема бөрчек-бөрчек тир бәрә — сиздермәскә тырышам. Үзем оялам, үзем әле әтиеңә, әле, кызым, сиңа карап-карап алам да, самавырга чәй ясарга үреләм.

Көнена ничә мәртәбә табынга җыйналсак, шул чаклы шатланам мин. Әтиең өчен, кызым Гөләрия өчен, бөтен бер гаиләбез өчен шатланам. Илләр иминлеге, туган җирем өчен шатланам.

Шахтерлар йокысыннан уянгач, кайсы спортзалга, кайберләре кичке укуга йөри. Эш сәгате тагын килеп җитә. Төнге сменада эшләүчеләр көннәрне түгел, числоны бутап бетерә. Туган көнне әйтәсе дә юк.

Без, Габбани белән кушылгач та, менә бишенче ел инде, аның туган көнен үткәрми калганыбыз юк, кызым. Кирәк хәстәрен алдан күреп куям. Аннары, бер көн алдан, Габбанинең үзенә әйтәм: кемнәрне чакырыйк, дим. Кемнәрне үз итеп чакырганын белеп тә торам, шулай да киңәшәм. Киңәшле эш таркалмый, диләрме әле, бу да шуның эше инде. Ир белән киңәшмичә бер эштә дә баш булып йөрергә ярамый, кызым. Ир — гаиләнең мәркәзе. Аның сүзе бер! Икең ике төрле уйлап яшәсәң, ул нинди гаилә, ди. Бала кемнән гыйбрәт алсын, ди. Буе-сыны төз булган тере гарип үсәчәк бит җәмгыятькә. Ә ул кемгә кирәк?

— Кемнәрне чакырыйк?— дип сорагач, Габбани тигез тешләрен елтыратып көлеп җибәрә дә:

— Габдрахман агайларны, Әнәсләрне, Мишкаларны, Владимир Боголюбовны, әнкәй белән әткәйне, ну, калганын тагын кемнәрне үзең телисең,— дип куя.

Һәм, ел саен уналтынчы октябрь көнне, билгеләнгән сәгатьтә без бу мәҗлесне башлыйбыз. Ләкин быелгы кебеген хәтерләмим.

Әле өйләнешкәнче үк, Габбани: «Мин туган көн һәр елны кояшлы булыр, Гөлфания!»— дигән иде. Әни әйтмешли, фал китабы ачучы диярсең, чыннан да, кояшлы була уналтынчы октябрь көне. Без ул көнне, иртәнге якта бакчаны җыештырып куябыз. Күршеләр дә чыга бакчаларына. Кеше килгәнче барак тирәсе ялт итә. Хәтта үтеп-сүтеп йөрүчеләр дә, бәйрәмме соң әллә монда, дип сөйләнеп узалар.

Иң башлап, төенчек кадәр карчыгын ияртеп, Шахта бабаң килеп керде.

— Исән-саулыкмы, Габбани! И-и-и, Гөлфания кызым! Бәрәкәт, әбисе, кечкенә кызыма, теге, алтын йөгертелгән алманы алып бир әле,— дип, өйне шаулатып сөйләнде Габдрахман абзый, берәмләп күрешеп чыкты. Сине, кызым, түбә тактасына кадәр очыртып, үчтеки-үчтеки иттерде. Карт димә, егәре үзендә.

— Бабай үтеләсең, у-уф!—диден син.

Барыбыз да көлештек. Алтын шардай сап-сары алмаларны учларында йомарлап, син диванга менеп утырдың, әтиең белән Шахта бабаң өстәл янына урнашты. Мәхтүмә әбиең, почмак якка кереп, миңа булышырга тотынды.

Без почмакта эшне бетергәндә, кунакларыбыз җыелып та житте.

Мәҗлесне әти ачты. Түм-түгәрәк башын такыр итеп пәке белән кырдырган. Калын, таза муенлы булганга житү сакаллы, чолгыйланып торган кырпак мыегы бик килешеп тора үзенә. Әти һәрвакыт чиста-пөхтә, йөри. Тавышы саф, шахтерларча яңгыратып сөйләшә ул.

— Бу гаиләдә иң олы кеше булганга, Габдрахман кордаш, син мине кичерерсең инде,— диде әти, бераз шаярта төшеп.— Рөхсәтсез-нисез генә сүзгә керешим әле. Габбани улым, таза-саулыгың белән йөзгә кадәр яшәргә булсын! Җырлый-җырлый, гөрли-гөрли, шахталарда күмер чабабыз, ди торган идек без заманында. Шулай булсын!

Мәҗлес шулай шома башланып китте. Озак көттерәмени шахтер халкы, Мишаның гармун тартып җибәрүе булды, Әнәс белән Флера җыр башладылар.

Аннары Шахта бабай үзенә каратты. Башын бераз гына кыңгыр салып, иреннәрен сизелер-сизелмәс кенә кыймылдатып, озын көйләр сузарга ярата ул. Әнә бит ничек җырлый:

Ефәк кенә баулы күк карчыга
Талпына микән кош күреп?
Әй-й... киң түшәккәен тарлар җәеп,
Көтә микән Мәхтүмәм, төш күреп,

— дип җырлый торган идек без яшь чакларда, әйеме, Мөҗип!

Ул минем этигә каш сикертеп куйды. Әти җавапсыз каламы соң, әле сугыш чорында җырлаган җырың да исемдә, Габдрахман, дип, без белмәгән җырны җырлады.

Күмер катламнары кебек тирәндә калган истәлекләр, онытыла башлаган җыр-биюләр яктыга чыкты. Менә шундый хатирәләр, түгәрәк табын җылысы, туганлык-якынлык тойгысы белән кешенең гомере озая шул.



## 6

Бу көнне Боголюбов участогыннан күмер ташкын булып агып торды. Дүрт лаваны да шартлаттылар. Күмер белән мичләр тулы. Диспетчер буш вагоннар бирер өлгертә алмый.

Өске, уала торган катлам астында күмер ныгытма калдырып лаваны куу үзен сиздерә. Айлык план утыз биш метр иде, бүген үлчәдем, әтиеңнәр кырык метр узган. Ай бетәргә тагын өч көн бар.

Бер бригадада — дүрт лава бит, кызым! Әле өченче ел гына бер бригадага бер лава иде. Дүрт план бит бу. Ә кешеләр шул ук: Габдрахман агаң белән Әнәс абыең бригадасы забойчылары.

Бригаданың эше бердәм, сүзе бердәм. Алар участокта бирелгән наряд буенча гына түгел, үзләре белеп эшлиләр. Кайдан башларга дип, вакыт үткәрәсе юк. Килдең — башладың.

Төрле сылтау, сәбәп табып, сменада забойга төшмәүчеләр белән дә сүзне кыска тоттылар. Шахтер халкы болай бик гади күренсә дә, эшкә бик коры ул. Монда сүз юк, эш кенә бар. Забой бик тынычсызлана икән, кермә забойга, әмма лавада әзерлек эшләре күр, тәртипкә сал. Эш күп шахтада. Иренмә генә. Теләмисең икән, рәхим ит — сине тотып торучы юк.

Мин лавалар буенча үткәндә шуларны уйладым. Комбинатка кайтканда төп штректан җәяүләп атладым.

Төп штрек — бусы, кызым, шахтаның төбе. Җир-туфрак, балчык катламнарын узып күмергә кагылсаң, бу — беренче горизонтның төбе була. Ә кырык-илле, бәлки, йөз елдан соң, беренче горизонт эшләнеп беткәч, әлеге төп штрек — икенче горизонтның өсте булып кала. Аннан, өченче, дүртенче горизонтлар да бар әле. Соңгысы инде меңмең ике йөз метр тирәнлектә була. Без — беренче горизонтта. Дүрт йөз метр тирәнлектә безнең шахта. Менә шул тирән..екне дүрт лава били. Бераз авышлык барын да онытмасаң, шактый озын килеп чыга лавалар.

Бер участокта лавалар да, забойщиклар гына түгел бит, кызым, монда люкогрузчиклар, лесогоннар, крепильщиклар, проходчиклар, забойчылар, тау эшләре мастерлары, шартлату эшләре мастерлары, вентиляция десятниклары, тагын бик күп профессия кешеләре эшли. Ләкин участок буйлап җир астында йөргәндә эш урынына килеп чыкмасаң, син аларның берсен дә күрмисең. Шахтада беркем юк кебек. Ә һәр кешенең үз эш урыны бар. Эш урыны гел артып кала монда, кешеләр гел җитми. Берне бишкә ярыр чаклар була, бер нишләп булмый. Лаваларны авариялән коткарганда участок начальнигы, аның урынбасары, смена мастерлары булыша. Их, булсын иде участокта биш-ун гына артык кеше. Юк, гомердә булганы юк!

Мин бер ялгызым кайтам. Каршыдан, җир өстенә күтәреләсе яктан, бәреп егарлык көчле җил исә. Алга иелеп, башым белән һава агымын сөзеп барам. Яңгыр яугандагы кебек бит-күз чыланган. Пластмасс каска түбәсенә тып-тып тамчылар тама. Минем лампочка яктысын йотып, түбәдә бүрек-бүрек электр лампалары яна. Тышлары бармак юанлыгы пыяладан. Борылышлардан ажгырып электровозлар килеп чыга. Электр фаралары, куркынган киек күзләре кебек, кызарып яна.

Сөйләшә-сөйләшә каршыга кешеләр якынлаша. Лампочкаларын кулларына тотып киләләр. Аяк атлаганда яктылык нуры чайкала, шуннан сизелә бу. Бер-бер нәчәлниктер. Алар шулай йөри. Шахтерларның лампочкасы каскасына батырып, урап-чолгап куелган була. Каскасы очып төшмәсә, лампочка селкенми дә, ябыштырып куйган кебек тик тора.

Менә без, кара каршы бәрелешә язып, иң алдагысы белән күзгә-күз очраштык.

— Семен Прокопьевич! Исәнмесез!— Шулай кычкырып исәнләшүемне сизми дә калдым. Әллә ничек, уңайсыз булып китте үземә дә. Шахта начальнигы кебек дәрәҗәле кеше белән җиде кат җир астында япа-ялгызың очраш әле менә. Аңа бит урамда очраса да, урталай сынып, бил бөгеп узалар.

— Ә-ә-ә, Гөлфәния Мөҗиповна!— Семен Прокопьевич елмая төшеп, кожанка кигән җилкәмнән какты.— Нихәл! Ничек болай, курыкмыйча, бер ялгызың җир астында йөрисең. Күр әле, мин әнә ни кадәр кеше ияртеп төштем,— диде ул, шаярта биреп, аннан үзе артыннан килүче иптәшләренә күрсәтте.

Алар да:«Исәнмесез!»— дип беравыздан исәнләштеләр.

Мин сәламга сәлам белән җавап кайтардым да, шахта начальнигына текәлеп:

— Төп штректа курку түгел, Семен Прокопьевич, шахтаның бөтен забойларында да ничә ел инде пәри кебек ялгызым йөрим,— дидем. Тагын да ачыла төшеп көлде генә. Шахта начальнигы белмимени соң безнең эше маркшейдерлар эшен. Юри соравы бу. Юатуы. Шахтада эшләп йөрүче санаулы гына булган хатын-кызның күңелен күрүе. Үзенең мәрхәмәтен күрсәтүе. Ә, чыннан да, шул җитә кала кешегә. Сөенеп куясың. Биш-алты мең кеше эшләгән шахта начальнигы, үзеңне танып, исемеңне, әтиең исемен танып исәнләшсен әле синең белән, әйләнмәс җирдән башың әйләнер. Озын буйлы, чандыр, какча яңаклы бу ягымлы начальникны шахтада бөтенесе хөрмәт итә. Габбани әйтә, забойга килгәч, безнең белән бергә утырып, ипи-колбаса ашый, ди. Капкара күмерле кул белән суган, сарымсакны бүләбез, карап та тормый, ди, без бер кисәген алсак, ул икенчесен алып каба, ди. Колхозга бәрәңге алырга баргач, үзе бәрәңге казый, үзе Габбанилар белән бәрәңге бәрешеп уйный икән. Өмә көнен сабан туена әйләндереп бетерә, ди. Учакларда бәрәңге пешерә, ди, йөгереп узыштыра, көрәштерә, ди. Забойчы Әнәсне аркасыннан сөеп кенә тора икән. Ничә ел инде сабан-туенда да, шахтада да батырлыкны һичкемгә бирми Әнәс. Быел үзем булмадым, Габбани белән сәгатькә якын җәфаланды, диделәр. Егыша алмаганнар. Шуннан, Семен Прокопьевич, әтиеңне дә тәбрикләп, аркасыннан сөйгән бугай. Икесенең бер бригада забойчылары булуын белгәч, икесен берьюлы кочагына алган.

Монысын Мишка Роговцов сөйләгән иде.

Семен Прокопьевич, көлемсерәп, янындагыларга Әнәс, Боголюбов, участогы, Габбани белән минем турыда сөйләп алган арада, мин аның әнә шул мәзәк якларын уйларга өлгердем. Аннары ул җитдиләнә төште, сүзне икенчегә борып:

— Ничек анда, Боголюбов участогында эшлиләрме?— диде.

— Күмер агымсу урынына ага, диспетчер вагоннар гына җиткерсен! Дүрт лаваны да шартлаттылар, мичләр тулы,— дидем.

— Сменада кемнәр?

— Әнәс, Габбани, Миша, Габдрахман абзый, Боголюбов үзе дә анда калды...

— Рәхмәт, Гуля, барысын да беләсең,— диде Семен Прокопьевич, лампочкасын өскә күтәреп, саубуллашу билгесе ясагач, аннары, лампочкалы кулын алга таба борып, янындагыларга:

— Тизрәк, забойга китик!— диде.

Кузгалып киткәндә генә, килешле итеп тагын бер елмайды да, шатлыклы хәбәр әйткәндәй, алга иелә төшеп: «Тиздән күмер комбайны эшләр анда. Шуны юллар өчен барабыз!»— диде.

Чыннан да, бу яңа хәбәр иде. Шатлыклы хәбәр иде. Габбани беренче-икенче курсларда укып йөргән чакларында ук саташып йөрде шул хакта. Әнәс, Боголюбов, әтиең, шахтаның комсомол комитеты секретаре Геннадий Зиновьев — Семен Прокопьевичның бусагасын таптап бетерделәр. Габбани диплом эшен дә шушы темага язып ята. Текә лаваларда күмер комбайны куллану бу сиңа Донбасс шахталарындагы горизонталь забойлардан күмер алу түгел. Анда шахталар тирәндә. Өскә катлам ишелми. Лавалар горизонталь. Урыны-урыны белән авышлык сизелми дә. Лаваларда комбайн күптән эшли анда. Мин практика үткәндә Шахта шәһәренең үзәгендә булдым. Калдырырга бик теләделәр. Кузбасс тартты күңелне, туган җир тартты! Комбайн кертергә булдык, ди шахта начальнигы. Ничек булып бетәр инде?!

Клетка утырып өскә чыктым. Күк зәп-зәңгәр. Болында үскән күгәрчен күзе чәчәге сыман зәп-зәңгәр. Карыйсың, карап туя алмыйсың, күзләр чагыла. Күкрәккә, җанга-тәнгә ниндидер бер рәхәтлек тула. Күкрәк тутырып, еш-еш саф һава сулыйм.

Сокланып, озак карап тордым мин зәңгәр күккә. Аннары гына, терриконга, Наилә апаң янына кереп киттем.

Наилә апаңның матурлыгын шахта киеме дә кимется алмый. Кызлар кебек, чәчрәп тора. Порода чүпләгәндә кулы кулга йокмый, йон тетү фабрикасында станок эшли диярсең, ялт-йолт итеп кенә күзгә чалына. Берүзе эшли.

Аннары Наилә белән ламповойга кердек. Монда шахтерлар сафы тезелгән иде.

—777!

—1021!

—887!— дип кычкырган номерны ишеткәч, йөгереп бардым. Бу — Габбани номеры иде.

# 7

Кызым, Гөлрия, мин хәзер сине балалар бакчасына өйдән генә озатып калам. Бакча ерак түгел, бер-ике талпынуда барып житәсең. Карасу елгасы буенда гына. Шунда стадион, шунда парк. Сезнең бакча Казандагы Ботаника бакчасы кебек. Шау чәчәктә утыра. Ә син, кызым, шул гөлләргә куна-куна очучы күбәләк сыман. Сап-сары бантикларың да күбәләк канатына охшаш. Чыннан да, чокырлы иягең, чигәңә кадәр сузылып киткән кашларың — минеке төсле үк. Наилә апаң син тугач та дөрес чалымлаган моны. Мин дә күрә белгәнмен: чәчең бөдрәләре, борын яфрагының матур булып уелып китекләнеп торуы — Габбаниныкы. Һавага чөелгән туп та туп, кулга тотып алган син дә туп. Гел биеп кенә йөрисең. Бар яраткан эшең рәсем ясау. Буяу карандашларын әтиең белән икәүләп ташыйбыз үзеңә. Кайсын буяп, кайсын чәйнәп, бер ишесен сындырып бетерәсең. Киләсе елга укырга керәсең бит. Укытучың ничек түзәр инде. Әти-

еӊ әйтә, энисе, ди, алмаш-тилмәш дәрескә йөрмәсәк, моны укытучы тыеп өлгерә алмас, ди.

Балалар бакчасында Флера апаң тәрбияче булып эшләгәч рәхәт миңа. Бер кулдан чыгасың, икенчесенә барып керәсең. Ул — сезгә, сез — аңа иялэшеп беттегез. Ничә елдан бирле: бер ана балалары кебек инде хәзер. «Татарстанга бөтенләй кайтып китсәк, бу балалардан ничек аерылырмын, Гөлфәния!»— дип былтыр җәй уфтанып йөргән иде дә, Энәс абыең аспирантурага читтән торып укырга кереп кайтты. И сөенде инде Флера, и шатланды.

Габбани техникумны ерып чыкты. Тау эшләре мастеры итәргә теләделәр, бармады. Забойда калды. Хәзер комбайн белән күмер җимерәләр шахтада. Безнекенең шахтадан киту турында уйлаганы да юк. Энәс вәгъдәсендә торырга тырыша, ди. Аспирантураны бетергәч тә, машина-трактор тирәсенә, туган җиргә кайтам, дип әйтә, ди.

Флера апаң белән очрашмаган көнебез юк. Сөйләшмәгән сүзебез юк дисәм дә була. Үзеңне мактап сөйли, кызым Гөләрия! Бик аралашучан, ди, иптәшләрен ярата, ди. Тик рәсем ясап стенаны буйыйсың икән, бармагын кисикме әллә, ди.

Ярар, дидем, үзенә әйтеп карарбыз, бәлки буямас, дидем. Буяса, кисми булмас шул, дидем.

Кичен үзеңә сөйләдем моны.

— Эни, бүтән буямыйм, бармакны кисмә!— дидең. Әз генә балавыз сыгып та алдың бугай әле. Әтиең:

— Я, я, кызым, сүз тыңлагач тимибез инде,— дигәч кенә көлеп җибәрдең. Аннары, чабып барып, әтиеңне кочаклап алдың.

Бүген Флера апаң үзе балавыз сыга. Аны инде, бармагың кисәм дип кенә туктатып булмый, түзә алмыйм, үзем дә елыйм.

Теге синең группадагы энисе ташлап калдырган Романы больницадан алып кайтканнар бүген. Бәбекәемнең бер күз алмасын операция ясап алганнар иде. Флера апаң үзен алырга баргач, күз бәйләвен чишкәннәр дә, кая әле, улым, тәрәзәгә таба кара әле, яктылык күрәсеңме ди икән врач. Башта теге, сукыр күзен (Рома күз алмасы юклыгын белми бит, операция ясадылар дип кенә уйлый ул!) учы белән каплаган да шатланып кычкырып куйган: күрәм, дигән. Аннары икенчесен каплап, озак итеп берни дәшми торган-торган да, тәрәзә пыялаларын бармагы белән капшагач кына, әкрен пышылдап: әзрәк күрә, дигән, балакаем! Иреннәрендә юри генә дә елмаю әсәре юк икән.

Палатадагы авырулар үксеп елыйлар, ди Флера апаң, үзе сөйли, үзе елый. Аңа кушылып мин елыйм. Ятим балакай, ниндидер өмет белән яши диген, дөм сукыр күзен дә әзрәк күрә дип ышана. Ул энисе барлыгына да, әтисе барлыгына да ышана! Тик белми. Берсен дә белми бәләкәй Рома. Ул, кызым, сезне үзенең туганнарына тиңли. Тәрбиячеләрне — энисе, әтисе итеп тоя. Тик кичләрен сез өйләргә таралгач кына, Рома боегып кала. Нигә болай? Ник беркем дә аны алырга килми? Рома, белми, бәбекәчем!

Сез, кызым, эниләрегез, әтиләрегез бакчага килгәч тә кечкенә кәҗә бәтиләре шикелле безнең янда сикерешәсез, әтиләрегезнең муенына ук менеп атланасыз. Тиз-тиз киенә башлыйсыз. Өйгә ашыгасыз. Ул йөзләр якты: көлү дә шаяру, иркә сүзләр әйтү, ашыга-ашыга сөйләшү. Аннары җитәкләшеп, Рома белән саубуллашып, кайтып китәбез. Ә ул бу бәхетне, бу сөенечне көн саен карап кала. Кешеләр бәхетенә карап кала. Әллә ниләр уйлана ул балакай, ләкин ни өчен икәнен үзе генә белми.

Ә кайда соң аның газиз энкәсе? Ул аны, үз карынында чакта ук, балам, бәгърем, җанкисәгем дип, сыйпап-сыйпап үстермәде микән?

Ул кыймылдаган, ул талпынган саен, балам, йөрәгем пәрәсе дип, эчке бер якты моң белән шатланмадымы икән? Этләр, хәтта бүреләр дә үз баласын ташламый. Ерткыч булып ерткыч, үз баласы өчен өзгәләнеп сугыша, егыла, үлә, әмма тәнендә җаны барында — баласын бирми.

Үз баласын, күз карасын сөймәгән ана — ул тере мәет. Аның ватаны да, туган Җире дә юк, сөйгән яры да булмый, мәхәббәте дә юк. Дөньялыктан коры калган усак череге ул. Аның йөрәген, корт ашыйашый, тузанга әйләндергән: анда гөл түгел, билчән дә үсми.

Әниләр... Ана назына эреп, бишек җырын җырлап үскән әниләр, кайда соң сез? Мин монда Романы тапкан әни кешегә кычкырам. Әллә син бишек җырын гомердә бер ишетмәдеңме? Әллә синең үзеңә аны чын күңелдән түгел, аптыраганнан гына, авыз эченнән генә мыгырдадылармы? Йөргән кешең алмаса да — баладан үч ал, иреңнән аерылсаң да — сабыйдан үч ал, икенче бер кияүгә китәргә булсаң да — нарасыйдан үч ал, имеш! Кая китә бу? Кая ирләре сугыш кырында ятып калган сигез-ун бала үстергән әниләр горурлыгы! Фашист палачы автомат төбәгәндә дә, балам, бәгърем, дип пуляны үз күкрәгенә алган аналар батырлыгы кайда? Безнең буын аналар бәхете кайда? Ана бәхете — баласында, кызым. Ана күңеле балада...

Чәй әзерләп, өстәл янына утырышкан гына идек, өйне яңгыратып Әнәс абыең килеп керде. Матрос тельняшкасының җиңнәрен терсәгенә тикле сызганган, нинди дер бер шатлыктан йөзе балкып тора. Флераның да монда икәнен күреп, исе киткәндәй итенде дә, карлы чүәкләрен салып, безнең янга узды.

— Кызлар, исәннәрмесез? — диде, башта безгә карап, аннары Габбани кырыена барып утырды. Алар күзгә-күз карашып сүзсез калдылар. Шуннан соң гына Әнәс телгә килде.

— Нәрсә, уйлап бетердеңме?

— Лавадан китәсе килми, Әнәс!

— Минем килә дисеңме?

— «Алдан»да алданмасак ярый ла, Әнәс дус,— ди әтиең,— анда бит әле эшләп караган кеше юк. Беловода күреп кайттык анысы. Күз алдында...

— Күз алдында... Биш катлы йорт сыярлык бушлык, менә-менә ишелергә, шуып төшәргә торган мунча хәтле күмер кливажлары дигән,— диде Әнәс тә, көлә-көлә.

«Алдан» ысулы белән забойда эшләү кыен түгел, кызым. Ләкин бик куркыныч.

Менә шундый забойга кертергә телиләр икән әтиеңнәрне. Әнәс абыең үзе көлә үзе Габбанига карый. Әтиең аның сынаулы карашына түзә алмый.

— Тотынсак, өйрәнәбез инде, башлап җибәрүе генә... — ди.

— Димәк, син риза! Болай булгач, алданмыйбыз, Габбани!

8

Җәй уртасында Биктимергә кунакка кайтып киттек. Җыену озак булмады. Алдан хәзерләнгән идек. Әйберләребез күп, дүрт чемодан шыплап тулган. Барлык туган-тумачаларга бирәр кат бүләк киемнәр алдык. Ситса-мазарның чуты юк. Габбани көлә, мине билсез калдырырга телеңме соң бу, Гөлфәния, ди. Әллә син Татарстанда чүпрәк-чапрак юк дип беләсеңме, ди, бу кадәр тутырырга! Чүпрәк-ситсаның хәзер кайда да тулып ятканын беләм мин, кызым! Хатын-кыз күңеле бит, буш кул белән кайтып керәсе килми. Килен булгач та әтиең авылына нибары өченче кайтуым. Син туганчы ике ел рәттән кайттык. Синең белән бергә — өчәүләп беренче кайтуыбыз. Җиде ел вакыт үткәне сизелми дә. Зур кыз булдың! Йоклаганда күргән төш кебек тиз уза гомер. Әле кызымны яратып туя алганым юк. Еллар узган да киткән.

Әбигә-бабайга кунакка кайтырга булгач, и сөенден инде, кызым! Кичен — ятсаң, иртән — торсаң — телеңдә гел бер сүз: дәү әти, дәү әни, Биктимер булды.

Поездлар иркен йөри хәзер. Буфеты, рестораны эшли. Ашарга-эчәргә сатып йөриләр. Проводниклар, нәрсә кирәк, дип сорап кына торалар. Урыннар иркен: өчебезгә бер купе. Новосибирскида Мәскәү поездына (ул Казан аша уза!) күчеп утыргач, уйламаган җирдән күзсез кала яздың, кызым. Йөрәгем «жу» итте. Әле дә әтиең бар, нишләргә белми калтырап төштем.

Поезд тегәрҗеп тарткан кебек туп-туры юлдан алга чаба. Тимер юл буендагы куаклар үзләре безгә каршы йөгереп киләләр сыман. Син, кызым, тәрәзәгә авызыңны куярлык булып, карап барасың. Юл кырыендагы сыртлыкта малай-шалай уйнап утыра. Кай ерләре саубуллашу билгесе ясап поездга кул болгый. Син аларга төртеп күрсәтүең булды, мин үрелеп кararта да өлгерә алмадым — чылтыр! тәрәзә пыяласы. Купе ишегенә йодрык кадәрле таш килеп бәрелде, ике кат тәрәзә пыяласы аркылы бит.

— Бетте!..— дип кенә кычкыра алдым мин. Кызым, диярргә, Гөләрия, диярргә өлгерә алмадым. Әтиең сине күтәреп алган иде инде.

— Юк, юк, Гөлфәния, зарар юк,— ди әтиең. Шунда гына хушыма килгәндәй булдым.

Кызым, син еламадың да, көлмәдең дә. Әтиең иягендәге, кулыңдагы канны сөрткәндә дә исең китмәде шикелле. Син бары тик идәндә аунап яткан ташка гына сәерсенеп карап тордың...

Тәрәзә ватылып кына, Урал тауларының бирге як табигатенә тәрәзә аша карап сокланудан барыбер туктамадык без. Урал тауларыннан көнчыгышка таба Себер җире җәелә, кызым! Мин туган, кызым, син туган Кузбасс җире — Урта Себер җире. Себернең үзәге. Себер бөтен җирдә дә матур. Чакрымнарга сузылган тигезлекләр, иксез-чиксез ямь-яшел болыннар — Себер җирендәгедәй бер кая да хәтергә кереп калмый. Свердловскига якынлашканда күңелдәге шушы ямьне бозардай кеше дә табылды.

Янәшәдәге купеда игезәк бала белән ирле-хатынлы берәүләр кайта иде. Балалары шук, ике малай, бер дә тик тормыйлар. Әтиләре тынычландырырга тели:

— Малайлар, монда без генә түгел, шауламагыз!

Хатыны:

— Нәрсә, әллә балаларга сөйләшергә дә ярамыймы?..

Ире:

— Малайлар, чапмагыз, кешеләр ял итә!

Хатыны:

— Алар аяксыз түгел лә, чапсыннар!..

Гел шулай. Ире уңайга әйтсә, хатыны киресен сукалый тора. Габбани әйтә: бу хатын белән кире сөйләшергә өйрәнергә, ди. Балалары да ни әтиләрен, ни әниләрен тыңларга белмиләр, аннары үзләре теләгәнчә эшлиләр. Кызым, син дә аптырап калдың. Үзебез сүз көрәштермәгәч, синең мондый хәлне күргәнең юк.

Инде шул гына җитмәгән иде, бу хатын кара еланлыгын тагын күрсәтергә өлгерде.

Ниндидер бер станциядә поезд кузгалып киткәч тә, ире килми тора моның. Чыга, карый, җикеренә бу, чыга, карый, дулый бу!

— Поезд астына кергере, ресторандадыр әле...

Малайлары аптырап әниләренә карый. Дәшмиләр. Әтиләре яннарында булмагач, үзләрен яклаучы юк икәнен беләләр, бичаралар.

Габбани тынычландырып карый:

— Бала түгел бит, керер, борчылма, ди. Забойларда эшләгән ир, поездда гына сынатмас, ди.

Мин дә кушылам:

— Гел бер җирдә утыру туйдыра бит, берәр җирдә домино уйныйдыр,— дим. Ул ара бу ир килеп тә житте.

Ирен күрүе булды бу хатынның, башы-күзе акайды: мин монда, муенына ике малай асып, ут йотып утырам, ди. Синең уеңа да керми, ди. Шахтада булып шахтадан кайтып кермисең, инде юлда да бездән качасың, ди. Адәм актыгы син, ди.

Бу рәвештә телгә килмәгән сүзләр белән бер урынсызга ирен мыскыллауга да түзгән булыр идем әле, аягындагы туфлиен салды да, чалт иттереп иренең яңагына ялтыратты бу.

— Син хатын түгел, оятсыз ерткыч!— дидем үзенә.

Күзе маңгаена менде. Күгәргән йөзе каралып китте. Бер сүз әйтә алмады.

Мин үзебезнең купега кереп, ишекне бикләдем. Габбани белән ни әйтергә белми утырабыз. Минем үз иренә кул күтәрүче хатыннар турында ишеткәнем бар иде, әмма үз күзләрем белән күргәнем булмады. Башка күрергә түгел, ишетергә язмасын.

Әни әйтмешли: ир бит — җан бит, ир бирмәк — җан бирмәк, дигән борынгылар. Ә җанны беркайчан да кара җиргә салып таптамыйлар, кызым!

Свердловск белән Казан арасын тиз уздык. Иртәнге якта Казан тимер юл вокзалында идек. Теге хатын купесы ягына карамыйча гына вагоннан чыктым. Изге Казан урамнарына кара шәүлә ияртеп төшүеннән шикләндем мин. Карасам иярер кебек тоелды.

Һәр съездны Ленин үзе ача,
Үзе алып бара шикелле...
Әйтеп тора кебек үзе безгә
Кирәк чакта кирәк фикерне.
Ленин исән! Гүя бүген дә ул
Түргә уза якты зал аша...

Казаннан самолетта очтык. Аэродром Биктимер кырында. Ат җигеп, эти каршы алырга килгән. Чигәсеннән үк үремләнеп ияк очына килеп тоташкан элеккеге кара сакалына бәс кунган. Габбанинекы кебек калын кашлары астыннан тыныч кына карый торган соргылт-яшькелт күзләре һаман шул көе: ягымлы, үз итеп, сөенеп карыйлар.

— Ах, аны, кызымны, буй җиткәнче алып кайтмадылар, кызымны! — дип дәү әтиең үзеңне Шоңкар таулары күренгәнче күкләргә күтәреп сөйде дә, кызым, аннары гына ике куллап безнең белән күреште.

— Саумысыз, балакайлар!

Габбани әтисен кочаклап үпте. Шунда гына күзем төште: үлчәп кискән бау кебек — икесе бертигез икән буйга! Ике метрлылар, билләһи. Чәчеп үстерсәң дә болай булмас. Аэродромдагылар исләре китеп аталы-уллы шул пәһлеваннарга карап тора. Аерым-аерым булсалар, карар идең дә үтеп китәр идең, телеграмм баганасы тикле ике ир ягыннан алай шома гына уза алмыйсың шул.

Әти — атаклы сабантуйлар батыры. Талибулла Яруллин дисәң — бөтен тирә-як белә. Яшь чагында аның гәүдәсе сигез пот тарткан. Кыргыз даласындагы тирмәләр аша ике потлы гер ыргытып уйнаган. Салам төясә — сәнәк сабы, печән чапса — чалгы сабы сынып чыккан. Шуңа да аны авыр эшләргә генә тотканнар. Әткәй зур-зур тракторларда эшләгән. Урта Азия шахталарында руда чыгарган. Әле мин беренче күргән елларда да муены нәсел үгезенеке шикелле кабарып тора иде.

Буйлары бер булса да, карап торышка Габбанидан кайтыш хәзер. Җилкәләре кайтыш, гәүдәсе сула төшкәнме шунда.

— Ярар, олайнар, кузгалыйк! — диде әти, яшел печән чабып салынган арбаның өстенә көлсу кожанын җәеп. — Әнигез көтә-көтә көтек булгандыр. Әйдә, малкай!

Тимеркүк айгыр атлаган көйгә тирә-як кырларын карап кайтуга ни житә, кызым, әйеме? Мин сине әтиең сөйләгән урыннар белән таныштырып кайтам. Әти белән Габбанинның үз сүзләре.

Менә бусы, кызым, үр астында җәйрәп калган авыл — район үзәге. Күренеп торган куаклык — зират! Ә-ә-нә тегендә, еракта, күрәсеңме, Чаллы басулары. Урман кебек куе, биек агачлы зираты ун чакрымнан күренеп тора. Көнчыгышта да шундый ук шаулап торучы урман, өскә авам дип тора. Ә без анда җитмибез, кызым, бу туры юл хәзер Сәлим күленә килеп чыга. Анда инде Биктимер авылы малайларының чыр-чу килеп, су коенып яткан чагы. Сәлим күленнән бер атлыйсың — Зират тау башы, икенче атлыйсың — Актай елгасы, өченче атлыйсың —әтиеңнәр өе, кызым! Типтигез яшел хәтфә уртасында күзгә кебек ялтырап яткан Сәлим күле суын карап туеп өлгермисең — Зират тау башында идек; аннан тимеркүк элдереп төшеп китте дә, Актай суларын болгатып кичеп тауга күтәрелүгә, без инде коймалары челтәрләп эшләнгән алты почмаклы өй янына килеп туктадык. Капканы тутырып ачып, каршыга әни килеп чыкты.

Үзе шатлыгыннан күләргә итенә, үзе күз яшьләрен сөртә, бәгырькәем! Битләре җыерчыкланган, кашлары сирәгәйгән, агарган. Гәүдәсе бөрешә төшкән. Гомер уза! Мин әле әнкәйне кызлар кебек җил-җил йөри дип күзаллый идем. Адымы сүлпәнәйгән. Тормыш үзенекен итә...

— Гөләрия кызым! Синме соң бу? Чү-чү, күз тимәсен, сөбханалла, әнисе кадәр үскән! Минем хәтле, әтисе хәтле! — дия-дия әнкәй үзеңне коча, үбә, чәбәкли, ана каз үз күтүеннән аерылып калган сары бәбкәсен тапканмыни!

— Әнкәй, күрешик әле... — дидем мин.

Шунда гына әнкәй үз халәтенә кайтты, сине ычкындырмый гына минем яныма ашыкты.

— Гөлфәния кызым, исән-сау гынамы?— диде, кытыршы, җылы кулларын сузды.— Кодалар исән калдымы?

— Исәннәр, әнкәй, күп-күп сәламнәр әйтергә куштылар...

Әни Габбаниның киң күкрәгенә кысылып, эреп юкка чыкты сыман тоелды миңа бу минутларда. Бер сүзен әйтә алмый әнкәй, учы, бармаклары гына улының аркасында кыймылдый, әледән-әле шулай чәбәкләп тора, үзе тавыш-тын чыгармыйча гына елый. Габбани әнкәйне юата, елама әни, менә кайттык, күрештек бит, ди, бер ай торабыз, туйдырып бетербез әле, ди, үзе әнинең башын сыйпый.

Ир-ат йортта ат туара калды, без, кызым, өйгә кердек. Өстәлдә ак самовар чыжлап утыра, ашъяулык җәелгән иде. Шунда, кызым, син минем колагыма үрелеп сорап куйдың:

— Әни, Прокопьевскида зур әтигә — әти, зур әнигә — әни, дисең, монда да дәү әтигә — әти, дәү әнигә — әни, дип әйтәсең. Нишләп минем әнием дә, әтием дә берәү генә, сезнеке икешәр? — дисең.

Минем ул турыда сөйләгәнем бар иде дә, кызым, хәтереңә алып кала алмагансың, ахры. Яшьләй буталчыграк та шул әле ул. Борынгыдан калган йола буенча, бездә килен кеше иренең әти-әнисенә, ире шикелле үк, әти, әни дип әйтә, ирләр кызның әти-әнисен әби-бабай дип йөриләр. Без әтиең белән кыз-егет чакта ук килештек: ике якка да әти-әни! диячәкбез. Син дә безнең әти-әнигә: дәү әти, дәү әни, дип эндәшәсең. Башка бик күпләр кебек, без синнән картларга әби-бабай дип әйттермәдек, кызым. Югыйсә, синең дә ике әбиең, ике бабаң булыр иде.

Аннары чор да үзгәрә, гадәтләр дә үзгәрә бит. Хәзерге яшь буын тиз өлгерә, унтугыз-егермедә өйләнешеп, кияүгә чыгып бетәләр. Яшь-яшь әтиәниләрен әби-бабай итәләр. Нигә аларга килен булып төшкән кыз шикелле үк «әти!», «әни!» дип хөрмәтләп әйтмәскә?..

Йортта ир-ат тавышы көчәйгәннән-көчәя бара. Авыл кечкенә. Кырыкилле йорт. Капка төбенә чыгып кулыңны бер изәсәң, бөтен кеше киләчәк. Безнең аэродромнан кайтканны да әллә кайчан белеп, күреп торганнар. Менә хәзер бөтен авыл купты. Барысы да безгә агыла. Монда шулай: кайсы йортка, кем кайтса да, бөтен авыл җыела.

Ул ара баскыч төбендә итек, галош салып өйгә тула башладылар. Синеңише балалар, кызым, тирә-юнеңне сырып алды. Әтиең дус-ишләре,

эти-әни кордашлары, бабайлар, әбиләр килеп тулды. Монда шулай, кызым, бер авыл — бер гаилә! Бай авыл, бай өйләр. Өчәр баш сыер үзләрендә. Егермешәр сарык асрыйлар. Каз-үрдәк белән дә дөнья тулган — алары су буеннан кайтып та керми, күзгә тикле шунда йөзә. Төшеп, төшереп кенә ашаталар икән. Салам, печән, силос, сенаж да бүленеште түгел. Совхоз маллары ни ашаса, халыкныкы шуны ашый. Бүлеш юк. Бары уртак. Иген игәләр, фермада эшлиләр, совхоз малларын да, үз малларын да бертигез күреп карыйлар. Утынны һәр йорт башына икешәр трактор арбасы итеп совхоз китереп бирә. Дөньяның рәхәтен күреп яши халык. Карты-яше: без хөрлектә яшибез, диләр. Эшкә беркем кушмый монда, эшкә һәркем үзе бара.

Дәү этиең белән дәү әниең әзерләнеп, көтеп торганнар шул, кызым. Табын әзерләүгә дәү этиең янгын чаны кадәр кисмәк күтәреп кереп идән уртасына бастырды.

— Габбани, капкачын ач, улым, кунаклар өчен! — диде.

Габбани кисмәкне ачты.

Ачы бал телләрен тиз эретте кунакларның, бер яшь егет җыр башлады.

Сезнең белән безнең ара
Суырылып үскән чуклы тал;
Чуклы талның чугын әзмиек,
Бер-беребездән, дуслар, бизмиек.

Шәп җырлый бу яшь егет. Борынгы көйне тарта. Шахта бабаң монда булса, әй, сөенер иде, дип уйлап куйдым, кызым. Ул да түгел, түр башында, әбиләр янында утырган кара тут йөзле, чибәр кыз шул ук көйне сузды:

Өстәл өсләрендә чынаяк,
Чынаяк эчендә чын җимеш.
Ул чын җимешләр гел бетмәсен,
Башыгыздан дәүләт китмәсен.

— Рәхмәт, Зөлхиҗә сеңелкәш, матур әйттең. Гомерең баллы-майлы табыннарда, кияү рәхәте күреп узсын! — диделәр ана, бу яктан ирләр, теге баштан хатын-кызлар да шул ук сүзне кабатлады. Бу җырны, зур мәҗлесләрдә гел шулай, быел кушылачак яңа парлар башлап җырлый икән. Аннары лава ташкынындай шаулап торган көр тавыш белән эти шул көйне алып китте. Аңа бөтен мәҗлес кушылды.

Җыр бетәр-бетмәс үк мәҗлес кул чабарга, «Габбани, Габбани! Синең чират» дип кабатларга кереште. Йомрыдагы ачы балны бер генә йотып куйдылар да, айныган балыгыз, дип янә кул чабарга, Габбанинең җырлавын сорарга тотындылар. Мин үз-үземә куркып утырам, кызым! Этиең өчен куркып, оялып утырам. Каян белсен ди ул бу җырны. Тугыз ел буе забой чүкеп, аның башында нинди җыр калсын. Русча булса әле бер хәл иде, мондый матур җырны пластинкадан да тыңлаган юк безнең. Ә этиеңнең гамендә дә юк. Ап-ак тешләрен күрсәтеп, елмаеп тик утыра. Ничек башларга соң, туганнар, онытылгандыр инде ул, ди.

— Егет чагындагыча җырла, Габбани! Урамнан кичен җырлап кайткан чагындагыча...

— Батыр калган көннәрдәгечә җырла, Габбани! Әтиең белән сабантуйларын тоткандагыча...

Башлады Габбани. Иркен, көр тавыш белән башлады.

Бохарадан яулык алдырдым,
Алган яулыкларым шәл түгел.
Сез дускайларның хәтере өчен
Җырым түгел, җаным жәл түгел...

Шатлыгымнан сикереп торып, этиеңне кочып үпмәкче идем, эти-әниdән тартындым. Киленнәре тыйнаксыз, дип әйтмәсеннәр өчен авылдашлардан яхшысынмадым. Себердә булсак, коча да идем, үбә дә идем.

Беркемнән дә тартынып тормас идем. Булдырдың, Габбани, рәхмәт! Коткардың! Минем әүхәтем кире кайтты. Миңа рәхәт хәзер. Кызым, сиңа да рәхәт. Әнә син ничек боргаланып әтиең янында иркәләнәсең. Югыйсә, котларым очты бит, җавап бирә алмас, дип курыктым. Ни гомергә бу җырны бер җырлаганын хәтерләмим.

Көтү керер алдыннан кунаклар таралышты. Без, кызым, өчәүләп Киләккә кереп киттек. Монда — чәчәкләр дәрьясы.

Умарта аланында алмагач күләгәләренә сыенып нинди генә чәчәкләр елмаеп утырмый: кып-кызыл дегет чәчәге, шәмәхә күке күзе, зәп-зәңгәр чыпчык күзе дисеңме, ак керфекләрен киң ачып, ромашкалар тирбәлүен әйтәсеңме, бөрлегән, җир җиләгенә үреләсеңме — барысы да аяк астында, җирдә үсә. Кызым, Гөләрия, әтиең синең асыл исемеңне менә шушы чәчәкләр иленнән эзләп тапкан. Хәзер син үзең шушында, май аеның зәңгәр күбәләге кебек очынып, чәчәккә кунып йөрисең.

Чәчәк бәйләмнәре җыя-җыя ямьле Киләкнең көньяк кырыена килеп чыктык. Монда ап-ак чәчәккә күмелеп карабодай басуы җәйрәп ята. Иксез-чиксез диңгезмени?! Тирә-якта бал исе, яңа суыртылган бал исе аңкый. Умарталар көтүләре белән бал җыя. Умарта иле очкан диярсең, әле анда, әле монда, безелдәп очып кына торган чаклары. Шул «ак диңгез» уртасында, кул сузымы җитәр җирдә генә, ак кургашын кебек күлләр ялтырый. Бер үк зурлыкта янәшә ике күл! Камыш сабаклары кыштырдаган тавыш колакка ишетелә сыман. Тәңкә балыкларның алкаланып сикерүе күзне чагылдыра төсле. Саз күлләре кырыеннан ук мәһабәт урманнар башлана: Авыл урманы, Мишәр урманы, Арттагы урман!

Анда барып тормадык бүген. Соң. Көтү кайткан тавыш ишетелә. Сарык бәрәннәре кычкыра. Анда-санда казлар кыйгаклап куя. Аналарыннан аерылып калган сарык бәрәннәре чабып килгән уңайга куркыта, ахры, ул казларны. Му-му! дип сөтле сыерлар сөрән сала. Хатын-кызлар, бала-чага тавышы. Башта тыңлап тордык. Кызык булып китте. Аннары шул якка борылдык, кайту ягына...

Әтиең миңа, кызым, сөзгәк сыерлары турында еш сөйли иде. Мин аны үзем күреп тә беләм. Маңгаенда йолдыз кадәр агы бар иде. Исеме дә «Йолдыз» иде. Сугымга симертелгән үгез кебек таза, сырты, янбашлары кояшта елык-елык килеп торыр иде. Муен асты салынып төшкән, калын гәүдәле, түм-түгәрәк сыер иде ул. Сауганда, әнидән башка һичкемне якын китермәгән. Миннән саудыргач, әнинең исе киткән иде. Килен кайнана туфрагыннан ярала, сине яратты, диде. Кышларын бәке кырыена тезләнеп Актайдан су эчә икән шул сыер. Аны көтүдән каршы аласы, көтүгә куасы юк: үзе кайта, үзе китә. Көтүдән бер тапкыр да качмаган үзе. Атнасына сигез-тугыз кадак май атлаганнар. Сөте май гына иде, үзем дә беләм. Кибеттәге каймакка алыштыргысыз куе сөтле иде, чын әгәр. Без кайтырга унегерме көн кала гына югалган ул малкай. Эзсез, иссез югалган. Авыл урамыннан кереп, алып киткәннәр, ди. Кыркапка ачык калган. Әти дә, авыл халкы да эзләмәгән җирне калдырмаганнар. Юк, сөяген дә тапмаганнар малкайның. Габбани бик сагынып кайткан иде үзен. Кызыма күрсәтергә дә булмады, ди.

Икенче көнне дә «Йолдыз»ны сагынып искә алды әтиең. Бу юлы, кызым, син генә белеп кал дигән сымак, сиңа сөйләп утырды, Габбани.

— Ул чакта, кызым, мондый биек такта койма, кәрнизле урыс капка түгел иде безнең,— ди Габбани, йорт-тирәсенә төртеп күрсәтеп. — Киләк чыбыгыннан үргән читән иде. Күрсәтер идем дә үзеңә, хәзер авылда читән юк шул! Көтү куалар. Әни кушты микән сыерны сакларга, әтиме, хәтерләмим, кулыма озын чыбык тотып читән башына менеп утырдым да, тик селтәнәм сыерны котыртып. Бер сөзәргә чамалап читәнгә кадәр чабып килә бу, читән биек, таза, бер эшем дә кыра алмагач, янә китә. Мин тагын селтим чыбыкны, тагын котырына бу. Малай чак, кызык бит, һәр нәрсәдән кызык таба торган чак. Шул сөзгәк сыерның курыкмыйча, мөгезен тотып караган чак булды. Пыяладай шоп-шома, калын, очлы мөгезен тотып

карарга гел кызыгып йөри идем. Бу теләкне әти-әнигә әйтәсе дә юк, якын да җибәрмиләр, болай да тукып кына торган көннәре: сыер янына якын барасы булма! Вәссәлам. Кышкы көннәрнең берендә чамаладым мин моны. Безнең өйалды баскычы текә, күршеләр кебек сыерны өйгә кертеп саумыйбыз, күнекмәгән ул баскычка. Күпме котыртсаң да дөбер-шатыр баскычтан менеп китмәячәк. Менәргә — Донбасс Мирзасы шикелле исерек түгел бит ул. Ал аяклары белән генә, анда да куркынып кына, бер-ике баскыч атлый да туктый. Бердән — текә, икенчедән — урын тар, өченчедән — такталар сыгыла, чатыр-чотыр итә. Сиздем моны. Котыртып баскычка китердем дә, сузылып мөгезеннән тоттым «Йолдыз»ның. Исең китәр, шундый сизгәк сыер, башын ник бер чайкасын, ичмасам! Әллә минем кул җылысын тойды, әллә эчкерсез бала күңелен сизенде, башын иде дә, тик басып тора. Мөгез төбе әни кулы кебек кытыршы икән, җылы икән. Андагы йон аралары әни иләктән он иләгәч җыелып калган көрпә кебек тузанлы икән. Кечкенә бармакларым белән шул көрпәне кагам, мөгез төбен кашыйм, мәрткә киткәнмени җаныкаем, мышнаганы да ишетелми, тып-тын тора.

Мөгезен җибәргәч кенә фы-ы-ш-шш! итеп авыр сулап куйды.

Юк, моннан соң да дуслашып китә алмадык «Йолдыз» белән. Дөрес, мөгез төбен кашытты кашытуын. Башкасына ирек куймады. Җирдә янына китермәде, сыйпатмады.

Менә шулай яхшылыкны аңлый торган изге мал иде ул, бичара. Начарлыкны, нахакны өнәмәде. Кирәкмәгәнгә чыбыркы белән сукса, көтүченең дә өстенә ыргыла иде.

— Мин кайтканны көтмәгән, югалган, былбылым! — диде Габбани. «Йолдыз»ны ихлас күңелдән юксынып. Синең күзләреңдә, кызым, яшь иде. Мин хәлне җиңеләйтердәй сүз тапмадым.

Авыл җирендә сыерсыз йорт — сөйкемсез йорт, кызым. Һәр иртә-кич чиләк тутырып чаж да чыж сөт саумагач, нәрсәдер җитми төсле. Бүген иртән әни йөзендә, әтидә, Габбанида сиздем мин моны. Тик әйтмәдем генә. Ә хәзер, Габбани тагын бер сөйләп юангач, сүз кузгаттым.

— Әтисе, димен, әллә кызыбыз саварга өйрәнеп кайтсын өчен бер сыер алып калдырыйкмы әтиләргә?! Кайткан саен сыер савар, дәү әнисенә булышыр, әйеме, кызым!

—Әйе, әйе,— дисең син, кызым, үзең черк-черк көләсең. Күзләрең очкынланып китте, битеңә алсу нур кунды.

Әтиең кистереп әйтергә ашыкмады.

— Гөлфания, авылда кем сыер сатсын сиңа?! Әти бозавын үстерербез, ди бит.

Бозауның сыер булганын көтеп ятканчы ике-өч ел гомер уза. Без кайтырбыз да китәрбез, картлар сөт-катыксыз ничек яшәр? Авыл кибетенә мае түгел, сөт-катыгы да чыкмый ич аның. Акчабыз җитәрлек. Юлдамазар яки Казанда яхшы әйберләр очраса кирәк булыр дип алган акча кенәгәсе дә үз янибызда. Яхшылап әйтергә кирәк Габбанига. Әти белән сөйләшсен.

Икенче көнне кичкә таба бура кадәр сыер җитәклән кайтты болар.

— Кәчи авылыннан, чуваштан алдык,— ди әти. — Бик мактады үзен, сауган саен бер чиләк, дигән булды. Кыйммәтен кыйммәт тә, итнең бер килограммы биш сум торганда, кем сиңа биш-алты йөзгә савым сыеры тоттырсын... Мең дә бер йөзне түләде Габбани!.. Рәхмәт инде, улым, рәхмәт, кызым Гөлфания!

— Әнекәем, өй бәясе,— диде әни дә, ни әйтергә белмичә. — Үзебезгә язган мал булып, бәхете белән килсен, илаһи!

Аклы-кызыллы чуар бу сыер бизәклән эшләнгән матур бу йортка килешеп тора. Әллә кайчан шундый мал җитенкерәми торган кебек. Исеме дә матур: «Малина». Кура җиләге, дип төшендергәч, әни дә ошатты. Ярар, ярар, бозык исем түгел икән, диде.

Әти әйтмешли, чуваш алдамаган икән, сыер гына түгел, сөт чишмәсе

бу «Малина». Киң авызлы зур чиләк тулды. Кечкенә чүлмәккә, аннан да калганын каҗә сава торган кара чуенга сауды әни. Җып-җылы сөт тулган кара чуенны Габбанига китерде.

— «Йолдыз»ның җилен төбен шул чуенга савып сиңа эчерә идем, улым! Әнә нинди бахатир булдың. Бусыныкын да син башла. Аннары, кызларым эчәр,— диде сөенә-сөенә. — Болай булгач, күз генә тимәсен, уңдык, оланнар, уңдык сыердан...

Кунак көннәре дә үтә тора. Әти, тракторына утырып, бүген дә кырга китте. Габбани бәрәңге бакчасы артына рәшәткә тота. Ул башта багана төпләре казып, баганалар утыртып чыкты, аннары агач киртәләрдән җепсә какты. Без дә шунда булышып йөрдек, кызым. Рәшәткә кагарга гына калгач, эш җиңеләйде, әтиең үзе малай чакта күргәннәрне сөйләп кенә тора, кызым.

Әтиеңнәр бакчасы тау итәгенә таба сузыла. Моннан аэродром, Зират таулары, Кое каты, Мәндеки, Чагыш таулары уч төбендә кебек күренә. Аста, иң түбәндә, көмеш тасма сыман борылып-сырылып Актай елгасы сузыла. Безнең бакча артында гына буып куйганнар үзен. Буа янәшәсендә генә ике каен үсеп утыра. Мәчет каеннары икән. Элек, әле әтиең дә дөньяда юк чагында, монда мәчет торган икән. Авыл шунда кадәр җәелеп утырган булган.

Әтиең миңа бу таулар, тугайлар, әрәмәләр турында күп сөйләде. Без анда бергә-бергә йөргәнебез бар. Сиңа сөйлисе сүзләре дә калган икән әле. Мин белмәгәннәре дә.

— Бервакыт, Закуан абый белән бакча казып кайнашабыз,— дип, сиңа сөйли әтиең, Гөләрия кызым, мин янығызда тыңлап кына утырам.

— Яз көне иде бу. Май ае. Үзе кояшлы, үзе җилле шунда. Көрәкне ташлап,уйнарга чыгып чабасы килеп кенә тора. Шул мәлне, читән буеннан лаплоп атлап, бер айгыр чабып узмасынмы! Яшь тайларны,бияләр көтүен күреп алуы булды моның, тауга түбән очты гына. Көчкә танып алдым — «Тамук». Колхозның бердәнбер айгыры. Кыска йоны бал кәрәзе кебек сыек сары, ялт-йолт итә; муенындагы яллары киндер орлыгы сымак соры, дулкын-дулкын җилдә бөтерелә. Ул муен бөгеп чабуын әйтәсе дә юк, ата күркәдәй боргалана. Очар кош та кош, «Тамук» та кош. Түгәрәк тояклары җиргә тими. Яшел чирәм өстендә аш тәлинкәсе чаклы эз генә кала. Әкияттәге матур кызга әверелә ала торган акбүз айгыр сыман, «Тамук»ның пошкырып-пошкырып кешнәвенә түзәр чама юк, Актай буйлары гөр килә. Тайлы бияләр дә куркышып куйды, ахры, бер тирәгәрәк җыела төште. Җирән туры алаша — «Җак» кына урынында калды. Ул да аптырап карап тора шикелле. Аптырарсың! Гомердә бәйдә торган усал эт бер ычкынып урамга чыкса, бөтен авыл хәйран кала. Урамга чыгарга куркып, тәрәзә ярыгыннан гына күзлиләр. Шуның шикелле бу да ычкынып качкандыр. Бер ялгызын җәйләүгә кем чыгарсын, ди аны. Исерек дисәң дә, Донбасс Мирзасы ул кадәр үк юләр түгел бит. Әти күрсә кирәген бирер...

«Тамук» шул җан-фәрманга чабып килгән хутка елгага сикерде. Чүт сөрлегеп егылмады, бетә иде. Бер-ике сикерүгә ярга чыкты да, «Җак» өстенә бөркет булып атылды.

Килгән хутка күкрәк белән бәреп егарга теләгән иде, ничек борылып өлгерде диген «Җак», ямады кушаяклап «Тамук»ның сакалдырыгы астына, һавага ут көлтәсе очтымыни, сары йоннары гына ялтырап китте, җирдә әйләнеп-әйләнеп бара. Инде тора алмас, үләр диген идем мин, Закуан абый тамаша карарга җыена гына икән әле: «Малай, Габбани, айгырлар сугышын карап тор хәзер», ди.

Малайлар егышып уйнаган кебек кенә сикереп торды да бу сары ут көлтәсе, «Җак»ка таба сузылды. Гүя, алашаны көйдерә, яндыра инде. «Җак» бу гайрәткә түзә алмады, бар көченә якын талларга таба чабып китте. «Тамук» аның җилкәсенә ыржайган тешләрен куеп бара. Тибешергә вакыт юк. Алаша кинәт сөрлегеп егылды, «Тамуг» аның аркылы очып барып төште. Тиз генә торып «Җак»ка ташланды. Әйе, авызы белән тешли, ал аяклары белән суга иде. Алаша ниндидер җай табып сикереп торды да

«Тамук»ның янтыгына китереп типте. «Гөп!» иткән тавышка мәчет каены башындагы каргалар көтүләре белән күтәрелде. Ул да түгел, айгырлар артка-арт торып тибешә башладылар. «Тамук» еш тибә, «Жак» сирәгрәк, әмма саллы суга. Ниндидер бер мизгелдә айгыр аякларын күтәрергә өлгерми калды, «Жак»ның тибүе булды, айгыр көрән ефәк ялын ялтыратып, яны белән чокырга барып ауды. «Жак» мәчет каеннары ягына чапты. «Тамук» жил тизлегендә аны тагын куып житте. Шунда гомердә күрмәгән тамашаның шаһиты булдым. Айгыр да, «Жак» та арт аякларына каракаршы торып бастылар. Һич ялган түгел, икесе ике каен биеклеге. Яллары арт саннарына кадәр тузгып төшкән. Авызлар ачык — бүрек сыярлык. Телләре — кызыл ялкын кебек. Баш бармак тикле тешләре үткен ханжәр сыман. Шул кылыч белән «Тамук» та, «Жак» та бер-берсенә чабыпмы чабалар. Бер боксерда да мондый тизлек, мондый реакция юк. Гел башка, янакка, күкрәккә сугарга тырышалар. Дөп-дөп иткән тавыш колакны яра. Ул тоякка-тояк туры килгәч, тәннәр чемердәп китә, ташка-таш чәкешәмени. Ут чыга!

Бу хәлләр санаулы минутлар эчендә үтте. Ниндидер бер жай белән «Жак»ның колак төбенә «Тамук»ның сугуы булды, алаша әйләнеп китеп сөрлекте, ләкин егылмады, шул борылган уңайга айгырның корсак астына кушаяклап китереп типте дә, үзе якын талларга таба томырылды. Монда елганың борылган төше иде.

Шул чак кулларына дилбегә, уникеләп үргән каеш чыбыркылар тотып, су буена ирләр килеп житте. «Жак», жанкисәгем, аларга таба ашыга. Гүя, ярдәм сорый сыман. Адымы сүлпәнәя бара. Менә ул суга керде, икенче якка тизли. Ә «Тамук» менә өстенә басам, менә бетерәм дигән сыман дулап килә. Әтинең селтәнүе булды, беләк калынлыгы чыбыркы, кара елан сыман, айгырның муенына уралды. Әти, шул галәмәт авыр гәүдәсе белән, өс киемнәре манма су килеш, «ах!» дигәнче ярга сикерде, чыбыркыны үзенә тартты. «Тамук», язын беренче тапкыр өйдән чыккач та чәчәкле-чуклы муенчагын жилфердәтеп урамда уйнаклап йөрүче бозау кебек, кинәт жиргә сөрлекте. Әти аның башыннан тотып алды. Ул да түгел, бөтен су буен яңгыратып «Тпру-у-у!» — дип кычкырды. Үтәдән-үтә жил сызгырып узды да, күк дөбердәдемени! Әти тавышы астында айгырның ми-һа-һа! дип кешнәве көтүче малайның чыбыркы шартлатуы төсле генә ишетелде. Ул ара «Тамук»ны ирләр дилбегә белән уратып алганнар иде инде. Кайсы йөгән кигерә, кайсы сакалдырыгын бәйли...

Закуан абый белән без дә тау астына йөгереп төштек. «Тамук» дер-дер килә, калтырый. Үзе чирәмгә үрелгән була, иреннәрен бөрештерепбөрештереп карый, чирәм эләкми, алай да, башын күтәреп, «Жак» ягына карап ярсулы кешнәп-кешнәп куя. Янәсе, бәхетең, кешеләр булды. Сакалдырык асты уч тикле кадәр шешеп чыккан, күкрәгендә, муенында тояк эзләре ярылып ята. Күкрәге мендәр кебек кабарып шешенгән.

— Бетерә язган айгырны! — диде ирләр.

Аннары әти тезгенне берсенә тоттырды да, елганы чыгып, «Жак» янына килде.

Безнең килгәнне сизмәде дә, жанкисәгем. Бөтен гәүдәсе белән калтыранып тора. Күзләре йомык. Поклаган, малкай! Әллә бик арыганмы?

— Бөтен көтүнең фажигасен үз өстенә алды, мескен! — диде әти. Әти тавышына «Жак» дер итеп сискәнеп куйды, күзләрен ачты. Күзләре мөлдерәмә тулы яшь иде. «Жак»ны жәлләп мин дә, абый да еладык. Малкай чак кына башын борып, көтүдәге тайларга, бияләргә карады, аннары иренеп кенә Мендеки тау битендә сары ут көлтәсе булып янган «Тамук»ка күз салды. Безне күргәч тынычланды, кабат күзләрен йомды. Без аның яраларын карадык, әле генә булган хәлләрне сөйләшеп утырдык.

— Туйганчы йокласын! — диде әти, урыныннан торгач. — Жен шикелле айгыр белән сугышып арыган малкай. Ул бит тегенең шикелле аранлыкта солы да печән генә ашап ятмый, көне-төне жигелә, эшли. Төнен урманнан кайтып керде генә...

Эти шулай, ди. Ә минем йөрәгем кысыла: айгыр тагын килеп алашаны җәберләмәсме? Бер этигә карыйм, бер айгырга. Эти сиздә моны.

— Аны хәзер абзарына алып китәләр! — диде, лычма су өс киемнәрен сыпыргалап. — Донбасс Мирзасы лаякыл исерек, җүнсез. Шул килеш тотып чыккан... Тотарсың айгырны! Яз көне түгел, мәлҗерәгәнне кыш көне дә каплап кына калдыра ул. Ат токымы каты куллы кешегә генә буйсына... Баргач иманын укытам әле Мирзаның...

Минем күңел һаман тынычланмый. Тик торганнан ник алашага ябырылды «Тамук?» Матур гына йөрсә ни булган?

— Эти! Ник сугыштылар соң алар? — дип сорап куйдым.

— Нәсел айгыры карап торышка бик матур, авыл күрке булса да, көтүдә яман нәрсә ул. Бер биягә тынгы юк, ни ашый алмыйлар, ни аерылып китә алмыйлар. Ни үзе ашамый. Котырынып тик йөри. Шул, үзен-үзе белештерми котырынган чагында яшь тайларны таптап китә, я тибеп очыра, имгәтә. Ул айгырга айгыр очрашса... бетте. Үзең күрдең! Айгыр айгырны сөйми. Көтүдә берүзе патша булып калырга тиеш. Шуңа да ни кыланганын белми. Шул тилегә каршы чыкты «Җак» бүген...

Габбани бераз җилләнергә уйлады. Бер көн иртән торгач, йортта физзарядка ясап йөрде-йөрде дә, койма-киртә буйларын карап әйләнгәч:

— Әни, сыерың сөтле, бер кар базы ясап калдырыйммы үзеңә, диде. — Нәрсә тора ул шахтер кешегә...

— Кирәкмәс улым, ял ит! Искесе дә безнең гомергә җитәрлек! — дип, әнинең кул-аягы белән каршы килүенә дә карамастан, Габбани, иртәнге чәйдән соң ук, баз казырга кереште. Ул, этинең калын табанлы авыр итеге белән көрәккә бер генә баса да, кызыл балчыкны лас та лыс ыргытып кына тора. Син, кызым, дәү әниең белән тау астына казлар ашатырга киттең, мин өй эшләре белән кайнаша калдым. Өйне җыештыргач, янә Габбани янына чыктым. Чыгуымны көтеп кенә торган диярсең, Гөлфания, ломны алып бирсәнә, балчыгы үзле, көрәк керми, ди бу миңа.

Ул тотынды үзле балчыкны лом белән кисәргә, каты итеп бәргән саен, лом луф итеп җиргә кереп китте. Берсендә мин ломны тартып чыгарган итенеп, тартып караган идем дә, кая ул — селкенми дә! Габбани ничек шулай эшли диген! Ала да бәрә, ала да бәрә. Үзе алай, көчәнми дә шикелле, йөзенә чыкмый. Тик беләк мускуллары гына чүлмәк-чүлмәк күпереп ала, чәченең бөдрә чолгыйлары дерелдәп-дерелдәп куйгалый. Төшке ашны да базда гына утырып ашады Габбани, эти кайтканчы казып бетерергә кирәк, ди.

Кояш баегач эти кайтты. Тракторын өй каршына куеп сүндерде дә, йортка керә-керешкә үк, балчык өеменә таба кулы белән төртеп:

— Бу ни тамаша? — диде.

— Габбани анда, эти, Габбани баз казый! — дидем мин.

Ул төтен, май исе сеңгән казакие белән баз кырыена килеп иелде дә:

— Улым, Габбани, әллә бер кечтә шахтаңа барып чыгарга уйлыйсыңмы? Чык, әйдә!— диде.

— Эти, ике көрәк тирәнлеге генә алам да, бетә,— диде Габбани этигә карап елмаеп. Чыннан да елмаерлык иде шул. Баз Габбани биеклегендә казылган иде. Эти дә түзмәде, майлы казакиен салып атты да, базга сикереп төште. Эти лом белән кызыл балчык чаба, Габбани көрәк белән өскә чөя. «Карагыз аны, якын йөрмәгез!» — дип безгә кычкыра үзе. Алар шулай караңгы төшкәндә базны казып бетерделәр. Үзләрен чыгарырга баскыч кирәк булды. Әни әйтә, әвен хәтле ирләрне күмәрлек нинди баз булсын инде, ди.

Эти исә:

— Баз ди синә, подвал бу, подвал,— ди, өсләрен каккалап. — Бөтен әйберең сыеп бетә монда. Бомбоубежище...

Аталы-уллы ха-ха-хайлап көлделәр. Йорт тирәсендәге коймалар, тәрәзә пыялалары калтырап куйгандай булды. Тагарактан тәмләп бәрәңге кабыгы ашап торучы «Малина» да башын күтәреп, беразга тын калды.

Дуслар шаяруы икәнен белгәч кенә, яңадан башын батырды.

Икенче көнне Габбани базның дүрт як стенасын да имән баганалары белән текмәп беркетте. Нәкъ шахта штрегын беркеткәнчә: баганаларның өске өлешен киртләп, ул төшләргә өрлек башларын да киртләп куеп беркетте. Бер кадак какмады. Багана киртенә өрлек кирте кереп яткач, як-якка селкенми дә. Өстенә туфрак та салсаң, гел шунда торган кебек, ташка әйләнәчәк.

Әти бүген күрше-күләнне ияртеп керде. Менә, күрегез, ди, мин сөйлидер идем сезгә, шахтада фәләнне фәләнчә беркетәләр, дип. Карагыз, бер кадак кагылганмы?

Барысы да ах-вах килә, нинди гади, нишләп без моны белми яшәгәнбез, янәсе.

Аннары бергәләшеп базның авызын бурадылар. Тик күләме генә кечкенә, үзе нәкъ шахтада мич беркеткән шикелле булды. Бу эш тә, әни әйтмешли, ай күрде — кояш алды, дигән сыманрак бик тиз бетте. Кайсысы тигезләп кисте, кайсысы балта чапты, хуҗалар — әти белән Габбани, бер ярыгын да калдырмыйча, баз авызы бурасын өеп бардылар.

Шуннан соң баз өстендәге имән өрлекләр өстенә тигезләп сумалалы толь җәйделәр дә, биш кулга биш көрәк тотып, соңгы бурага тикле җиңел торф өйделәр. Кызыл балчыгын читәнләп кырыена өярбез, диде әти.

Кар базының эше моның белән генә бетмәде әле. Өченче, дүртенче көнне дә шунда кайнашты Габбани.

...Иртәгә китәсе көнебездә әни гел боегып йөрде. Төпчек малаен үз яныннан бер дә җибәрәсе килми иде аның.

Ә иртәгесен әти безне озатырга тимеркүк айгырны җигеп кайтты. Нәкъ кайткан көнебезчә: арбада яшел печән, күл сыман күксел кожан җәелгән.

Әни белән жылы гына саубуллашып аерылыштык. Ул албакча почмагы янына басып, елап калды. Безгә таудан төшеп күмелгәнче кул болгап калды. Кызым, син ак кулъяулыгыңны дәү әниеңә селкеп бардың.

Бакча артындагы әтиең кадаклап торткан рәшәткәләр дә ерагайды. Буаны чыккач, зират тавы култыгында көтү күренде. «Малина!» — дип кычкыруыбызны сизми дә калдык. Малкай иялэшеп беткән, абынасөртенә яныбызга чабып килде. Без дә арбадан сикереп төштек. Сыйпап саубуллаштык «Малина» белән. Артыбыздан мөгрәп, кычкырып калды. Әти әйтә, сизенә, малкай, ди. Китүегезне сизенә, ди.

Зират тавы, Сәлим күле буйларыннан узып, аэродромга килеп життек. Кырык-илле йортлы Биктимер авылы, шаулы Киләк, әтиең кар базы казыган безнең йорт — кырык адымда гына шикелле җәйрәп ята, кызым. Албакча рәшәткәсенә тотынып, яшьле күзләре белән әни басып тора сыман. Хуш, әнкәй! Бәхил бул!

Без, кызым, әти белән саубуллашып, самолетка кереп утырдык. Габбани әтине кочаклап, аерылыша алмый торды. Самолетка кергәндә әтиеңнең күзләре яшьле иде. Мин аның күз яшен беренче күрдем.

Әти ике кулын да югары күтәреп, самолет үкереп улаганда якында гына торды. Без алып кайткан бүләк костюмының төймәләрен чишеп җибәргән, сакал-мыегына килешеп торган күксел эшләпәсен уң кулына тоткан килеш аякларын аерып баскан да, иләп-иләп саубуллаша. Кыр пәһлеванымыни!

## 9

Прокопьевскига кайтып төшүебез Шахтерлар көненә туры килде. Авылда чакта бу турыда уйлап та карамаганбыз. Күрәсең, жирлеге шул булмагач, онытыла! Шахтерлар бу көнгә Яңа ел кичәсенә караганда да болайрак әзерләнә бит. Бөтен-бөтен шәһәрләр, бөтен бер Кузнецк бассейны бәйрәм итә. Бәйрәм иртә таңнан башлана, шахтерлар поселогы көн буена гөрли. Тәрәзәләр ачык, кая карама — җыр! Ачык тәрәзәләрдән җыр урамга агыла, бәйрәмчә бизәлгән урамнар буенча җырны яшьләр күчереп йөртә. Сабантуе да сагынылган бәйрәм, Шахтерлар көне дә сөенечле бәйрәм. Шахта җирендә икесе бердәй кадерле...

Карасу елгасы буена якынлашуыбыз булды, безнең бараклан гармун тавышы ишетелә. Миша уйный. Аның кебек тальян моңы таратучы юк бу тирәдә. Габбани елмаеп куйды: егетләр өйдә, янәсе.

Син, кызым, бер аякта сикерә-сикерә кайтасың. Ак нәзек оекларыңа тузан кунган. Зәңгәр фирүзә күлмәгең талгын җилдә җилферди. Сары бантигыңа тополь мамыгы кунган. Йөзең шат, янып тора. Шул галәмәт юл узып та арымагансың, мәнә яшьлекнең яшерен бер сере шушы инде. Ару-талуны белми яшьлек. Ул гел ашкына, тизләгән саен — чабасы килә, йөгергән саен — очасы килә. Очар да иде, канатлар юк. Яшьлекнең очар канаты — матур хыял, кызым! Өметле хыял! Җилдән житез, очар коштан өлгер — мең төрле бизәкле хыял. Ләззәтле хыял!

Шахтага төшкәнче ике-өч көн вакытыбыз бар иде әле. Өйләрне җыештырырмын, кызымның мәктәбенә барып китап-дәфтәрләр алып кайтырбыз, дип уйланып кайткан идем. Өйне җыештырасы юк, курчак өе кебек ялт итеп тора. Тәрәзә төбендә яран, тамчылы, исле гөл чәчәк атып утыралар. Наилә апаң үз өе кебек караган.

Тәрәзәләрне ачсам, күренеп тора, бакчада эшләр арткан... Каршыдагы өченче ел утырткан колмак тупыл кәүсәсенә чолганып, сыерчык оясына тиклем үрмәләгән. Колмаклары өлгергән. Кара шомырт тәлгәш-тәлгәш эленеп калган, чүт селкенсә коелып төшәр кебек, җыеп аласы булыр. Ул җәелеп утырган алмагачларда йодрык-йодрык алмалар кызарып пешкән. Кешеләр килер, чәйгә салырбыз, өзеп керергә кирәк.

Минем әти-әни белән барак коридорында очрашып кочаклаштык. Әнәсләргә кереп баруым иде. Урта ишекне кем ача икән дип карасам: алда — әни, ишек бавын тотып, артта — әти баскан. Чемоданнарны бушата торыгыз, дип аларны өйгә кертеп җибәрдек.

Мишка Роговцов барак алдында гармун уйнап утыра.

— Сагынмадыңмы әллә, Миша, кермисең? — диде Габбани.

— У-у-у, сагындым, Габбани!— диде Миша, гармунын идәнгә куеп, сикереп торып күреште. Габбанины күтәрергә итенгәләп маташты, уфылдады да: «Билләһи, ун пот бар!»— диде.

Барысы да көлештеләр.

— Миша, Наиләң кая?— дидем мин.

— Сез кайтасыз диеп, кибеткә киткәние...

Тирләп-пешеп, тынына кабып Наилә кайтып керде.

— Кайттылар, дигәч, нәрсә алганымны, кая аяк басканымны белми чабып кайттым, уф!— дип минем кочагыма килеп ауды...

Габбани ирләргә авыл, юл, отпуска хәлләрен сөйләп утырган арада, без, хатын-кызлар, табын әзерләдек. Табада ит кыздырырга җыенгач, бердән туктап калдык. Наилә чыннан да нәрсә алганын белмәгән, ахры. Тәүмәле белән дуңгыз ите күтәреп кайткан. Шытырдап торган саргылт кәгазен ачсак: ап-ак май гына!

— Әй алла, майсыз ит сораган идем бит,— ди-ди Наилә миңа угалана.

— Кем ашар моны,— дип, без як-якка каранабыз. Иң башлап Әнәс төшенде.

— Ашаса, Мишка ашый инде аны, кызлар! Күбрәк пешерегез, иртәнгә дә калсын!— диде.

— Юк, Әнәс дус, гөнаһысына кермик, ашамыйм,— диде Миша да.— Артык майлы. Күңелгә ятмый. Аннан минем дуңгыз ите ашаганым булмады да. Үз гомеремдә бер тапкыр дуңгыз суярга катнаштым, анысында да уңмадым, шуннан биздем.

— Тәки суйдыңмы дуңгызны?— диде Габбани. Ул, бу хәлне белә иде, ахры, көлә-көлә Мишка Роговцовка карады. Янәсе, сөйләп бир әле үзләренә.

— Суйдым дип... суймадым шул,— диде Миша. — Дуңгыз үземне ашый язды. Күрше Женя түтәй керде дә, малайга дуңгыз суярга булыш әле, Миша, ди. Каны акканда табак кына тотып торырсың, калганын малай үзе башкарыр, ди.

— Ярар, димен, күрше хакына барам, димен. Женя түтәйгә. — Түлке минем тавык та суйганым юк...

— Табак кына тотарсың, табак кына,— ди бу һаман.

Киенеп чыктым. Сарайлары янында верзила кебек озын буйлы, битен сары сакал-мыек баскан бер ир-ат йөренә. Кулында ботаклы бүкән яра торган калун, мин сиңа әйтим. Юкә кайрысыдай аксыл-саргылт чәчләре маңгаена төшкән, тик яшел күзләре генә тере елтырый. Нәрсә уйлый ул, күзләреннән белеп булмый. Ул арада кулына табак тотып Женя түтәй килеп житте. Шул, малае икән, мин әйтәм.

Кереп киттек без сарай эченә. Женя түти бармак очы белән төртенә калды, хәерле сәгатьтә! дип теләкләр тели. Ул да түгел, келт иттереп тышкы яктан ишек келәсен дә төшереп куйды түтәй. Сарай эчендә теге ир дә мин, ике адымда гына, беләк калынлык куралар артында, тай кадәрле дуңгыз. Ишек тыштан бикле. Ул-бу була калса, дип, як-якка карыйм, тотынып урын да юк, лава шикелле текә стена гына.

Теге рәхәтләнә тәмәке суырып. Кулыннан калунын төшерми үзе. Малкай, ашарга куйдылар дип белде ахры, ашыгып табак янына килүе булды, теге шалт моның әрекмән колагыннан эләктереп тә алды.

Үзе дуңгызны тынычландыра, үзе сөйләнә, аның белән аңлашып сөйләшкән кебек итеп, миңа сөйли.

— Син әллә кая китмә, аккан канны табакка тотарсың,— ди бу миңа.

Табакны иелеп алдым да, күтәреп торам. Минем эш, билгеле бит инде. Шул заман теге шалт моның ялтырап торган маңгаена кулындагы калун белән. Бичара җан иясе башта югары сикерде, юк, колагын җибәрми теге, урман бете кебек кадалып ябышкан, гөп тә гөп калуны белән маңгаена суга кабанның, чиный-чиный дуңгыз чаба, аның колагына ябышып ул чаба, табак күтәреп мин чабам. Сарай эчендә чабабыз шулай. Ычкынып китсә, яралы ерткыч өзгәли бит безне, дип уйлыйм. Табакны ташладым. Күзем ни күрә дисәм, соңгы өмет итеп, теге кураларны шәйләдем. Чатырдап ябыштым да иң өстәгесенә, аякларны да шунда күтәреп, бер арага тыктым. Ярканат кебек кире аркан асылынып торам мин хәзер. Кыеклап кына карыйм сул күзгә күренә, ирнең үз хәле хәл. Әрекмән колакны һаман җибәрми бу. Минем табакка абынып егылды болар. Баягыдан да яманрак чинап кабан үз аранына ташланды, күзе тонган, күрәмсең, малкайның, килеп бәрелүе булды, теге куралар шылдырт — коелды төште. Ятам дуңгыз аранында, аякларны һич аралап булмый. Янәшәдә генә кабан мырык-мырык килә, фыш-фыш сулый. Йөрәгем ярылып, сикереп торсам, теге ир ишекне тукмый.

— Ач, тизрәк ач, бетерә!— дип, әнисенә кычкыра. Сүгенә дә бугай әле. Кая киткән диген баягы битараф кыяфәте, кая качкан? Арыслан өненә эләккән бичара куян кебек, дер-дер килә.

Бәхеткә, Женя түти ишекне ачып җибәрде. Икебез бердән атылып чыктык. Аяк очына эләгеп теге табак кына шалтырап калды.

Бу вакыт халык кинодан кайтып килә иде. Хәлне тиз-тиз аңлаттым үзебезнең участоктагы Митяга.

— Кая әле,— ди Митя,— кереп карыйк әле.

Теге ирнең пычагын алып, кулын аркасына яшерде дә, буряк! буряк! итенгәләп аранга керде бу. Ишекне дә бикләмәде, табак та тоттырмады...

Шуннан соң дуңгыз суярга беркайчан да йөрмәдем. Итен ашарга да кызгандым.

Әнәс, нәрсәдер исенә төшкәндәй сәгатенә карап алды.

— Кызлар, егетләр! Клубка халык җыелгандыр,— диде.

Барыбыз да дәррәү аякка бастык.

Клубта тантаналы бәйрәм кичәсе башланды. Шахтерлар сүзне озакка сузмый. Шахта начальнигы кайнар котлады да, бүләкләү өлешенә күчтеләр. Бусы кайбер елларны сәгать ярым — ике сәгатькә сузыла. Быел да шулай булыр, ахры. Шахтком председателе Николай Тараканов кулында амбар кенәгәсе калынлыгы кәгазьләр күренә.

— Скударнов!
— Фәхразиев!
— Коломыцев!
— Шәфыйков!
— Мальков!— дип, шахтерларның исем-фамилиясен атавы була, бүләк исемен әйтүе була, музыка уйнап ала. Кул кысып, шахтерларга бүләкне шахта начальнигы Семен Прокопьевич үзе тапшыра.

— Яруллин!— диде бер заман Тараканов. Без инде отпускадан килгән кешеләр, уйламый да утырабыз. Аннан Яруллиннар да бер без генә түгел.

— Яруллин!— Николай тагын кабатлады.

— Габбани Яруллин!— диде Геннадий Зиновьев дөресләп. Шуннан соң гына этиең сәхнәгә менеп китте, кызым. Аның артыннан идән такталары шыгырдап, баскыч басмалары сыгылып калды.

— Вәт, гигант!— дип сокланып утырды залдагылар.

— Шахтер тек шахтер,— диделәр икенчеләре.

Шахта начальнигы белән этиең кул кысышкач, кызым, ул залның алкышлап кул чабуын ишетсәң, мондый алкышларны бары тик сабантуенда мәйдан батырын күккә чөйгәндә генә ишетерсең. Габбани көлә-көлә безнең янга төшеп утырды. Кулында бер бәйләм китап!

Президиумда кемнәр генә юк: Советлар Союзы Герое, Социалистик Хезмәт Геройлары, Шахтер Даны орденының тулы кавалерлары монда. Габдрахман абзый иң алда, иң уртада утыра. Ул иң өлкән шахтер. Күкрәгендә беренче, икенче, өченче дәрәҗә Шахтер Даны орденнары. Аңа Семен Прокопьевич исемле алтын сәгать бүләк итте. Зал тын алмый кул чапты.

Габдрахман абзый урынына утырырга борылган гына иде, шахта начальнигы янәшәсендәге хәрби киемле полковникка ым какты, тегесе, шуны гына көткәндәй урыныннан сикереп торды да:

— Тынычланыйк әле, җәмәгать!— диде, бер кулын югары күтәрде.— Сез әле генә иптәш Рафиковны бик олыладыгыз. Рәхмәт сезгә! Аның фронттагы батырлыгы да олылауга лаеклы. Менә мин хәзер сезгә приказ укыйм: «Хәтәр авыр сугыш көннәрендә Днепрны кичкәндәге батырлыклары өчен өлкән сержант Рафиков Габдрахман Хәлимовичны Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләргә». Ничәмә-ничә еллар узгач, орден үзенең иясен тапты, иптәшләр! Габдрахман Хәлимович, ягез, бире килегез инде!

Шахта бабай ары карады, бире борылды, нишләргә белмәде, әллә соң ялгыш ишеттемме, дип уйлады, ахры, иелеп-иелеп ян-ягына утырган күршеләреннән нәрсәдер сорады. Аннан полковник янына килде. Тегесе, иелеп, иплән кенә Кызыл Йолдыз орденын Габдрахман абзыйның костюмына, йөрәге өстенә такты. Аннары ирләрчә, нык итеп кочты, үпте. Шахта бабай, хуштан язган кеше кебек, башта ни әйтергә белми торды, аннары гына зиһенен җыеп:

— Советлар Союзына хезмәт итәм!— дип залны ярды. Зал аягүрә басып алкышларга тотынды.

Бу юлы Шахта бабай урынына утырырга исәп тә итмәде. Алкышлар астында сәхнәдән төште, беркемгә карамый гына ишектән чыгып китте. Аның күзләрендә яшь иде...

## 10

Йокыдан Әнәс уятты.

— Габбани! Сиңа бүген икенче сменага чыгарга кирәк,— диде.— «Алдан»ны башладык башлавын. Үзебезнең егетләр лавада калды, монда санап кына күчерделәр. Анда да Боголюбов даулагач кына күчерергә ризалаштылар. Ә эшне кыю тотарга кирәк. Күмер агымсу түгел, гел агып кына тормас... Шул сменада төпләнеп калырсың. Мишкаң үзең белән

инде... Тәк-тәк! Мин шахтага киттем. Алайса, забойда очрашырбыз...

— Ярый, әлегә...

Әнисенең чыгып китүенә Габбани эш киемнәрен барларга кереште: брезент тужурка, брезент чалбар, кыска балтырлы резин итекләр, эчтән кия торган киемнәр, каска астыннан кия торган башлык. Һәммәсен әзерләп, бергә бәйләп куйды.

Шуннан гына юынырга чыгып китте.

Ул көнне без, кызым, өчәүләп төшкә кадәр бакчада эшләдек. Син, муеныңа пыяла банка асып, карлыган җыйдың, кара җиләк җыйдың. Икәү җыйгач, чиләк күзгә күренеп тула. Әтиең бакчаны чүп-чардан чистартып йөрде.

— Әни! Әни! Банкам тулды! — дип кычкырдың син.

Габбани да:

— Гөлфания, мин кыяр-помидорларны өйгә ташып куйыйм әле, эшкә җыенырмын,— диде.

Бөрлегән суыдай ап-алсу иреннәрең, кызым, кара җиләк, шомырт, карлыган ашап каралып беткән. Йомшарып пешкән карлыган карасыдай чем-кара күзләреңдә шатлыклы очкыннар уйный. Зур булдың бит инде, кызым! Әти-әниеңә эшкә ярыйсың. Күпме җиләк җыйгансың.

Төштән соң Габбани эшкә китте.

Мин кура җиләге җыеп арыгач, варенье кайнатырга утырдым. Аны сы рәхәт: мичебез бакчада ук. Ташкүмер саласың да көн буена яна. Теләсәң су җылыт, телисеңме — аш пешер. Бер-бер артлы, сәгатьләр буе варенье кайнатканда, өйдә булса, тирләп үләр идең, чын әгәр. Өең мунчага әйләнер иде, кеше керерлек булмас иде. Күмер җылысы бит, кышын морҗаң бер япмаган килеш тә, кырык градуслы суыкта өеңне май итә дә куя. Җәйләрен өйдә мич ягу юк. Һәр гаиләнең бакчасында кечкенә миче бар. Шунда ашыйбыз, шунда эчәбез. Җәй җиттеме, соңгы көзгәчә тормыш бакчага күчә. Кунак-төшем килсә генә өйгә керәбез. Син туган җир, Себер җиренең рәхәте бу, кызым!

Иртәнге кояш безне көлеп уятты. Кояш нурлары тәрәзә пәрдәләрен ачып, өйгә узган. Өстәл өстендә, синең одеалың өстендә нурлар бии. Әтиең торып баскан, көлеп тора.

— Беренче сентябрь, кызым! Чыпчыклар әллә кайчан уянган, очып йөри. Мәктәбеңә соңга каласың, тизрәк тор, ди. Синнән алда барып, партаңа кунарлар. Урынсыз калырсың...

— Мин хәзер, әти...

Укучылар формасы кигәч, син, Гөләрия, зур кыз булып киттең. Шома, яшел төсле сумкаң да килешеп тора үзеңә. Әллә кайчан шул сумканы күтәреп йөргәнсең шикелле.

Чәйдән соң без өчәүләп мәктәпкә киттек.

— Бишлегә укырга, кызым! — диде бусаганы атлап чыкканда Габбани.

— Тәртипле булырга!— дидем мин.

Син артыңа борылып дәү әниеңә кул болгадың.

Берничә көн өйдә, бакчада кайнашып йөргәннән соң, өстәмә отпускамны да бетереп, мин дә эшкә чыктым. Технологик, геологик карталардагы үзгәрешләрне өйрәнгәч, шахтага төштем. Турыдан-туры элек Габбанилар эшләгән лаваларга бардым. Штрекларда цикличность тамгалары куелган калай кисәкләрен барлап, лаваның төрле урыныннан күмер катламының калынлыгын үлчәдем. Һәр үлчәмне блокнотка теркәп бардым. Комбайн артыннан ук беркетеп баргач, җимерелеп төшкән урыннар да, бүселеп калган төш тә юк. Лава бертигез үлчәмдә куыла. Забойда бертуктаусыз комбайн гүли. Әйбәт эшлиләр икән, күңел күтәрелеп китте. Хәзер инде «Алдан»га Габбани янына барсам да була. Алар участогына да маркшейдер буларак мин беркетелгән идем.

«Алдан»да тавыш-тын юк. Күмер комбайны эшләми монда. Балта белән суга-суга авыр баганалар да беркетмиләр. Йомран тишеге кебек, кәрә-чыга шомарып беткән дудка янында Мишка Роговцов сверлоны

электр линиясенә тоташтырып маташа. Капсуллар тутырылган сумкасын муенына асып, аммонит сумкасы өстендә шартлау эшләре мастеры Гололобов йокымсырый.

— Әй, «Гололубов», йоклап утырма, әбиеңә утырмага килмәдең, аммонитыңны кора башла!— диде Миша.

Гололобов ялт итеп күзен ачты. Көлеп куйды. Аның болай да сөйкемле йөзе, тагын да ачыла төште.

— И-и, Гөлфәния килгән, исәнме?— диде миңа карап. Ул, янәсе, Мишканы күрмәде дә, ишетмәде дә.— Габбани анда, забойны ишә... Әйдәле...

Дудкадан үрмәләп «Алдан»га кереп китсәм, күрәм, чыннан да, Габбани югарыда, әллә кая. Тонык булып лампочка яктысы гына күренә. Әнәс, кулына калын җепнең бер очын тотып, сакта калган. Ул-бу булса, сөйрәп алырга әзер, янәсе!

Габбани әнә кая үрмәләгән. Шуып китсә, мичкә генә очасы. Өстенә кливаж ишелеп төшсә, табып та ала алмыйсың.

Мин озак уйладыммы бу уйларны, әллә бер секунд эчендәме, тәгаен әйтә алмыйм, әмма:

— Габбани, төш!— дип бар көчемә кычкырып җибәрүемне сизми дә калдым.

Минем тавышка Мишка да, Гололобов та дудкадан шуышып забойга керделәр. Ялт-йолт караналар, берни аңламыйлар.

Мин каккан казык кебек баскан урынымда өнсез торам. Лампочкам нурлары гына Габбани баскан ташларны ялый.

Габбани төште.

Елмаеп безнең янга килде. Мин аның күкрәгенә капландым. «Дөньяда мин барын да онытма, Габбани! Бу дөньяда кызың Гөлария барын да онытма, Габбани!»— дип үкси-үкси еладым.

Габбани көлде генә:

— Гөлфәния безнең забойга икенче участоктан килеп эшләмәсләр бит инде,— диде.

Әнәс сверлоны сорады.

Бу юлы, Әнәсне саклап, дудка янында Габбани калды. Әнәснең көчле куллары басымы астында бора күмер ятмасына батып керә. Бөтен тирә-юнь пулеметтан аткандай текелдәп, выелдап, зырылдап тора. Ул тузан күтәрелде, янындагы кешене танып булмый. Әнәснең лампочка уты шәүләсе генә чалымлана. Башы, тельняшка кигән гәүдәсе бөтенләй күренми. Бераздан ул кулына сверло, штанга тотып, тузан арасыннан үзе килеп чыкты.

Шартлатканда мичнең тыгылып калмавы бик мөһим иде. Чөнки тыгылган мичне забойчылар астан менеп үзләре ачалар. Бу хәтәр эш! Оста забойчылар, күмерне үзләре аша җибәрә. Теләсә кем булдыра алмый моны. Кулындагы бер такта белән күмер ташкынын тыя-тыя, астагы беренче дудкага кадәр төш әле син, ай-яй!

Кайчакта зур-зур кливажлар мичкә кысылып тыгыла. Аларны кәйлә белән дә ватып булмый, кувалда белән дә,— шартлатырга туры килә.

Бар да тәртиптә булып чыкты бүген.

Забойны шартлаттылар.

Күмер ташкыны кузгалды.

Без тауга менеп киттек. Шунда гына Габбани мине юатырдай сүз тапты. Иңбашыма авыр кулын салып: «Син, Гөлфәния, алай борчылма, бәгърем! Без бу забойны барыбер буйсындырабыз!»— диде.

Аның сүзендә әз генә дә икеләнү әсәре юк иде.

## 11

Көннәр, айлар үткәне сизелми дә кала, кызым. Без — эштә, син — мәктәптә, әни әйтмешли, таң ата да кич була. Габбанилар «Алдан»ның

жаена төште хәзер. Шулай да өйгә әлегә гел соң кайта Габбани. Мин Миша белән Габбаниның аяк атлаган тавышын барак коридорына ничек басуларыннан ук таныйм. Һәм ялгышмыйм, алар булып чыга. Төнге сменадан кайтса да, ишек шакыганын көтмим, сорамыйм-нитмим, ишекне барам да ачам. Габбани көлә: кеше хатыннары йокыдан уянганчы, син, Гөлфәния, ишекне ачкан буласың, ди. Әллә ишек төбендә саклап торасыңмы? Ялгыш берәрсе урлап китмәсен үзеңне, ди.

Әле бүген Мәхтүмә әби, Габдрахман абзый белән сөйләшеп утыра идек, шылт-шылт баскан ботинка тавышы ишеккә таба якынлаша. Кайта, Габбани, мин әйтәм, чабып барып ишекне ачсам — этиең! Көлеп тора.

Совет Армиясе көне иде бу.

Син, кызым, этиеңә үзең ясаган «Маугли» исемле картина бүләк иттең. Яшел тропик фонда кеше хәтле кара эт! Янәшәсендәге яшь кыз аның муенына кулын салган. Кара этнең зур авызы ачык: кызыл теле, тешләре күренеп тора. Шулай да, һич куркыныч түгел бу кара эт. Аның зур, түгәрәк күзләре, үзен яраттырып, дөньяга матур карый.

Габбани озак карап торды. Без дә, кызым, этиеңнән алда бер сүз дәшмәдек. Бала эше, кем ничек аңлый бит! Аннары гына этиең, бер кулына бүләгеңне, бер кулына синең үзеңне күтәргән килеш телгә килде:

— Ай-яй, кызым, үзеңә якын дус сайлагансың!— диде.— Моның белән тайгада да, бүре көтүе арасында да куркыныч булмас. Ә кызны, кызны кара әле син, койган да куйган үзең.

Аннары этиең үзеңне чуп! иттереп битеңнән үбеп алды. Ул әле сине тагын да үбәргә теләгән иде дә, Габдрахман абзыйдан тартынды бугай. «Кеше керми торган забойда эшли үзе, үзе бала янында эри дә төшә» дип уйлавыннан шикләнде, ахры.

— Кызым, мин үзем рәсем ясый белмәдем, сиңа соң кемнән күчкән бу!— диде Габбани.

Әйе, Гөләрия кызым, үзең ясаган кыз сурәте — ул синең тач үзең иде. Син аны, билгеле, нәрсә дә булса уйлап ясамагансың да, кемдер ясаган сурәтне күчереп кенә алгансыңдыр... Бәлки ул, кыз да булмагандыр, малай рәсемедер. Күчергәндә үз күңелеңнән аерым сызыклар өстәгәнсеңдер. Кемгә дә булса охшатырга тырышкансыңдыр. Көзгедән күренгән портретыңны ясагансыңдыр. Бәлки бу сөйкемле кара эт тә — эт түгелдер, эт нәселеннән булган берәр җанвардыр. Бәлкем, кара пантерадыр...

— Гөләрияне быел рәсем мәктәбенә кертерсез инде,— диде Мәхтүмә әби дә.— Безнекеләрнеке өченче елын шунда йөри...

— Әйе!— диде Габдрахман абый, карчыгының сүзен хуплап.— Мин йоклаганда да сакал-мыеклы карт ясап, өскә куеп китә, оялтып бетерә мине...

Син, кызым, олылар сөйләгәндә ашамый-нитми, сәгатьләр буе тыңлап утырырга риза. Ә этиеңнәр сөйләшүенең очы-кырые юк. Сүз «Алдан»-га кереп китсә, аннан тиз генә чыгармын, димә. Ул сүз Шахта бабаң килгән саен кузгалмый калмый. Лаваларны онытты лар диярсең. Телләрендә: «Алдан» да «Алдан». Этиең: «Забойдагы күмер яртылаш әрәмгә кала»,— дип сыкрана. Габдрахман ага: «Нишлисең инде аны?»— дип куя. Эш менә шунда шул: нишләргә?

Беләм: Габбани да, Әнәс тә, Боголюбов та мондый калын катламнарны комбинированный ысул белән эшләп карарга тәкъдим итәләр. Электән килгән лава алымын кулланырга! Әмма турыдан-туры лавада эшләү генә түгел бу...

— Бу гасыр башында гына өстән шурфлар тишеп, бадья белән күмер чыгарып ятканнар,— ди Габбани.— Штольнялар тишеп, тау астына кергәннәр дә шунда күмер чүкеп интекканнәр. Без хәзер нишлибез? Тәүлегенә бер забойдан сигезәр йөз тонна күмер бирәбез! Забойларга кос-

мос тизлеге килә, Габдрахман абзый, хәзер елына миллион тонна ташкүмер бирүче бригадалар Кузбасста гына ничәү! Ә ул заманда моны бер шахта бирә алмый иде. Уйларга, иренмәскә, табарга...

— Автоматлаштырырга...— диде Шахта бабай сузып кына.

Мәхтүмә әби:

— Карт, әйдә, кайтыйк. Соң инде,— диде.

Сүз әле бетмәгән, кызып кына килә иде. Әмма чыгып киттеләр, утны сүндереп, без дә йокларга яттык.

Тышта җилсез суык. Сөрмә күкне якты нурга коендырып тулган ай йөзә. Безгә тыныч йокы теләгәндәй, зәңгәр йолдызлар гына чекерәешеп-чекерәешеп күз кысалар. Уйламаган җирдән бер җыр исемә төште:

Күктә нурлар, җирдә дуслар,
Дус янында кем ятим?!
Күктә нурлар, җирдә шатлык,
Җирдә бәхет гөлгә тиң.
Дөнья матур, дөнья киң!

Әй, кызым, Гөләрия! Дөньяда яшәве нинди рәхәт!

## 12

Җиргә кояш нуры карый башлаган көннәрнең берендә Әнәс абыең больницадан игезәк балалар күтәреп кайтты. Флера апаң игезәк бала тапты: берсе малай, берсе кыз. Бу хәбәр сәгате-минуты белән бөтен шахтага таралды. Әнәс эштән чыкты исә — больница ишеге төбендә, эшкә барырга җыендымы — больницага сугылмый узмый, ди. Габбани сөйли боларны. Олы малайның исемен алыштырам, игезәкләргә Таһир-Зөһрә куштырам дип әйтә, ди. Әни әйтә: булыр, булыр ул шахта зәхмәте кагылган Зимагулдан, дөньяда башыңа килмәгән эшләрне эшләп куяр әле, ди. Флераны алырга, кеше сөйләрлек булсын өчен, «Волга» автомобиле алып барган бит. Хакын түләгән, рәхмәтен әйткән, аннары син безнең арттан әкрен генә кайтырсың, яме, дигән шоферга, ә үзе ике баласын ике кулына күтәреп, бөтен поселок буенча җәяү атлаган. Исе китмәгән кеше калмаган. Сөйлиләр, көләләр. Ата шатлыгын барыбер аңлыйлар. Гомердә булмаганны, безгә, коридорны дөбердәтеп, дулап, чабып килеп керде Әнәс. Ишеккә сыймый, валлаһи, яңы белән кысылып керә.

— Әйдә, Габбани, Таһир-Зөһрәне күрсәтәм!— ди.

Чыгып киттеләр. Артларыннан мин дә иярдем. Сөйләнә-сөйләнә баралар.

— Сабантуйлар батыры гына түгел, болай да батыр икәнсең, малай!— ди Габбани.— Аспирантура бетерәсе елыңда, имтиханга китәсе көннәреңдә, курыкмыйча берьюлы ике бала алып кайт әле син, ә?! Батырлык бу, валлаһи, батырлык!

— Имтиханын тапшырырбыз, анысы үтәр, Габбани!— ди Әнәс. Үзе шатлыктан нишләргә белми, үзе әтиеңнең җилкәсенә кага.— Иң кыйммәте — игезәкләр, кыз әнисенә ярдәмче була бит...

Без кергәндә Флера бәбиләрен биләүләп төрә иде. Ялт итеп тураеп басты. Оялып киткәндәй булды, кызарып чыкты. Хатын-кыз шулай, кешедән генә түгел, үзеннән-үзе дә тартына бит ул. Ир-ат халкы мондый очракта шашына: өч килограммлы малаен биш килограммлы итеп, кем очраса шуңа мактанып йөри. Хатын-кыз шатлыгын тышка чыгармаска тырыша, эчтән генә сөенә.

— Ничек, Флера, имчәк кабалармы?— дидем мин, бәбиләр янына якын килеп.

— Суыралар гына, Гөлфәния!

Үзе сабыйларына яратып карап, көлеп куйды. Қечкелдек күгәрченнәре безне күрмиләр дә, белмиләр дә. Күзләре йомык, рәхәтләнеп йоклыйлар.

Аннары бәбиләр янына Әнәс белән Габбани килде.

— Кайсы кыз, кайсы малай моның?— ди Габбани, Әнәс колагына пышылдап.

— Мин үзем дә аермыйм әле, энә, энисеннән сорыйк!— ди Әнәс тә шулай шыпырт кына. Үзләре аның саен — тын гына көләләр. Янәсе, бәбиләр уянмасын! Аларга кушылып, телевизор карап утырган жиреннән шырык-шырык Таһир көлә.

— Көл әле, көл менә!— ди аңа Габбани, уйнап бармак яный. Әтиең әйтә, Таһирның исемен бәләкәй батырга бирәбез, ди. Таһирга — Мортаза кушабыз, ди.

— Юк, юк, Габбани абый, алдашма!— диде Таһир, сикереп торып.— Аның исеме — Шөһрәт! Кызныкы — Зөһрә! Мин Таһир ни дә, ул Таһир ни?! Зөһрә — икебезгә уртак.

— Һе-е, каян белдең?— диде Габбани һаман ышанмыйча.

— Әти белән ун көн талаштык, ун көн исем эзләдек. Бүген генә Мәхтүмә әби әйтте әле...

Әнәс башын селкеп куйды.

— Болай буласын белсәм, малай Габбани, Таһирга — Шөһрәт кушасы калган. Яшьтәшләр: Таһир-Зөһрә буласы иде. Ярар, кайсы Таһир, кайсы Шөһрәт булуындамыни эш, Зөһрәсе бар әле аның, Зөһрәсе бар! Әнисенә тансык иде...

Икенче көнне, бөтен барак җыелып, бәбәй чәе уздырдык. Шахта бабай монда да гыйбрәтле хәлләр сөйләде.

— Менә балалар, көн дә бәйрәм хәзер, кадерен белеп яшәргә генә,— диде Габдрахман абзый тамагын кырып.— Дөньялар бит алай гына бармады. Хәер, Себер җиренә тимәде тиюен, безнең Идел буен егерме беренче ел ачлыгы кырып салды. Ачлыгы, тифе-ние белән дөнья кырылды. Аннары колхозлашу еллары. Ул сугыш чорын әйтәсе дә юк, сугыштан соң да авыз тутырып бал да май ашамадык. Әлеге табындагы кебек нигъмәтне төшеңдә дә күрә алмый идең. Рәхмәт совет властена! Эшен дә эшләдек, ашын да ашадык. Беркем дә ким-хур булмады. Шул хөрлекне күрә алмаучылар да бар иде бит монда, Себердә...

Без, хатын-кызлар, тыныч кына чәй ясый торабыз, бәбиләр йоклыйлар, ирләр идәнгә төшеп аяк сузып утырышты. Габдрахман ага сөйли дә сөйли.

— Сугыштан соң, рабочий батальонда шахтада эшләгән еллар инде бу. Үтәмешкә кайтып, Мәхтүмә апагызга өйләнеп килгән ел. Карасу күпере янында әле дә утыра бит әле засыпной барак, хәзер беркем тормый анда, шунда квартираны бирделәр. Сөенеп барам инде... Үз квартирам була, дип уйлыйм.

Барак ишеген ачсам, бер хатын идән юа. Авылдагыча әдәп саклап, итекне салам да оекчан гына үз ишегемә узарга ниятлим.

— У-у-у!— ди бу апаң миңа.— Итек белән сукмакчы буласыңмы?

. Берни аңламыйм. Шаярта, мин әйтәм. Үзем көлеп, моңа карап торам.

— Син әле, издеваешьсямы? Килеп кермәс борын, авыз ерып көлә дә башламакчымы?

Күрәм, уйнап сөйләшми бу апаң. Күзләре ачулы, авызыннан зәһәр чәчә. Озаграк торсаң, әллә нәрсәләр ишетерсең. Тизрәк узарга кирәк!

Шул чак ишекләр ачылып, берәм-берәм хатын-кыз җыела башламасынмы. Бер коридорга утыз җиде ишек бит. Әкәмәт, бер базар хатынкыз, тиктомалга чыр-чу киләләр. Араларында бер ир-ат заты юк, ирләре чыкмый, янәсе, алары катнашмый бу эшкә.

— Фронтовик!— дип акаеп карыйлар.

— Бандит!— ди икенчесе.

— Татарин!— дип кычкыруларын колакка да элмәс идем, сугышта да, шахтада да дусларның: «На свете есть два дурака: русский да татарин...» дип зурлап, ихлас күңелдән әйтүләре искә төште. Чыннан да, иң хәтәр, куркыныч чакларда рус белән татарның аерылмас дуслар

булып калуына иманым камил минем, шуңа бер генә кычкырдым болар өстенә:

— Таралыгыз, җеннән яралган бәндәләр!— дидем.

Шул сүз җитә калды.

Кешене хурлау, башка милләт кешесен сөймәү фашизмнан йоккан бер чир ул, кызым!

Шахта бабаң нәрсә ди, кызым, шахтада бөтен милләт бер, бөтен кеше унсигез яшьтә, диме? Дөрес әйтә! Бер үк һаваны сулыйлар, бер үк эш башкаралар. Бу эшне син, монысын ул эшләсен, дип чын шахтер әйтми. Әйтмәс тә...

Габдрахман абзый тынган арада Мишка Роговцов тальянына үрелде.

— Шахта бабай, бер җырлыйбызмы?— диде.

— Әйдә!— диде Габдрахман абзый, гел шуны гына көткән кебек.

«Туган тел»не барыбыз бергә кушылып җырладык.

Кунаклар таралышты. Без дә өйгә чыктык. Габбани бөтен гәүдәсе белән өстәлгә капланып, нәрсәдер сызып, исәпләп утырды. Аннары гына бакчага чыгып китте.

...Яз, җәй җиттеме — бакчада эш бетми, кызым. Тырмалыйсы, чүбен җыясы, казыйсы, түтәлләр ясыйсы, утыртасы, су сибәсе — санап бетергесез эшләр. Син бу эшләрне хәзер үзең башлап йөрисең. Кар астыннан ала сыер төсле җирнең күренүе була, язгы суган яшәреп борынлый. Син, кызым, шул суган түтәлен матурлаудан башлыйсың эшне. Кичен, шул яшел суган кыякларын аерым-аерым да, бер төптә, бер рәттә итеп тә кәгазьгә ясыйсың. Түтәл янында кар әле эреп тә бетмәгән, яз хәбәрчесемени, ямь-яшел суган үсеп утыра. Матур күренеш бу!

Бакчадагы чәчәк түтәлләре барысы да синеке, кызым. Быел Карасу яры буена тикле чәчәкләр утырттың. Әни әйтмешли, кулың җиңел, күрәмсең, чәчкән бер орлыгың икенче көнне үк тишелеп чыга, зифа булып үсеп тә китә. Карасуның ярына тулышып аккан суы көнләшә кебек синең чәчәкләрдән. Мин ел буена агам-агам, ди төсле агымсу, һаман агарып, матурланып бетә алмыйм. Гөлләриянең чәчәкләре язын гына чыгып утырсалар да, янар чәчәк булып, гөлт итә дә куя, ди кебек Карасу.

Карасу буендагы гөлләрне рәсем дәфтәреңдә күреп, этиең хәйран калды. Укытучы зур итеп бишле билгесе куйган да астына «Молодец!» дип бер сүз өстәгән.

— Рәссам була бит кыз, әнисе, рәссам булачак!

Бу елны без сине балалар художество мәктәбенә яздырдык.

## 13

Шахта җиренә аяк басып та, Прокопьевскиның Зенково ял паркын күрмәгән кеше — бу шәһәрне күрмәгән кеше. Ял паркы безнең шахта белән янәшә генә. Тау менеп, тау гына төшәсе. Зур тауга менү үзе бер сәяхәт: бормалы тар сукмактан күтәрелгән саен дөнья яктыра бара, күз күреме киңәя бара. «Красный Углекоп» шахтасы аяк очында гына, түгәрәк бер зур казан эченә төшеп утырган сымак. Күршедәге «Южный» шахтасы поселогы да яшеллеккә чумып утыра, тау башыннан чыбык сындырып ыргытсаң, өй түбәләренә барып кадалыр шикелле. Шахта поселогы ял паркы култыгына ук сыенган. Аны бу урында борылып узган Карасу елгасы гына парктан аерып тора. Тауга күтәрелгән саен шахталар саны артыграк күренә бара, шәһәр әллә кая сузылган. Кайсы якка карама шахта терриконнары тырпаеп тора, кая күз салма хәрәкәттәге вулкан сыман, тау-тау порода сыртлары болытларга ак төтен бөрки. Кечкенә-

кечкенә таулар, тау аралыкларында тар-тар елгалар, тугайлар яшәреп күренә. Алардан ары колхоз-совхозларның басу җирләре. Үзләре бер күз күреме җир. Басулар, стена-стена ешлык булып, күкселләнеп күренгән тайга урманнарына барып тоташа. Тауның икенче ягына төшә башладыңмы, монда нарат-чыршы урманы. Иң аста, Зур тау итәгендә, Байкал күлемени, су җәйрәп ята. Ял итүчеләр өчен махсус корылган сусаклагыч бу. Буе чакрымнарга сузылган. Очы-кырые күренми. Ишкәкле көймәләрдә балык каптырып утыралар. Уртада, су ерып, моторлы көймәләр узыша. Яр тирәли сикерү вышкалары. Яр буе, су кырые чуп-чуар: кешеләр, кешеләр, кешеләр... Әз генә арырак, авыш үр кашында, ап-ак павильоннар тезелеп утыра. Анда җаның теләгән ризык бар.

Алдан сөйләшеп куелган кебек, су буенда җыйнаулашып очраштык без. Габбани, Әнәс, Мишка, Шахта бабай, алар янына Владимир Боголюбов, Геннадий Зиновьев, Николай Тараканов килеп кушылдылар. Барысы да хатыннары белән, бала-чагаларын ияртеп чыкканнар.

Шау-гөр килеп, түгәрәк ясап чирәмгә утырышырга да өлгермәдек, «Караул, коткарыгыз!» дигән аваз тирә-якка таралды.

Безнекеләр дәррәү суга сикереп төштеләр дә, күл уртасындагы бер карачкы көймәгә таба йөзә башладылар. Көймә капланган, ахры. Юк, батып бетмәгән. Кырыена ике кеше ябышкан. Бер-беренә булышкандай итәләр. Алардан бирегә таба, агым уңаена, тагын бер карачкы селкенә. Кечкенә генә, төргәк кадәрле генә.

— Чү, чү, юрганга төргән бала түгелме соң бу, оланнар!— ди ныбыздагы әти. Шул карт күзләре белән ничек абайлаган диген әти, аның шулай әйтүе белән, мин дә ачык чамалап алдым: бала! Йөрәгем ярылдымы әллә дип торам, күкрәгем жу-у-у итте, кызым, сине кочып алуымны сизми дә калдым. Ә күзләрем судагы балада, өс киемнәре белән йөзүче әтиеңнәрдә. Иң алда Әнәс абыең бара. Кулын күтәргән саен сызыклы тельняшкасы күренеп-күренеп кала. Аннан әз генә калышып Габбани йөзә. Боголюбов, Геннадий, Николай да аларның үкчәсенә үк ияреп баралар.

Шахта бабаң: «Хәзер җитәләр, хәзер, әй, Мөҗип, яшь чак булса!»— дип көч биреп тора.

Шул чак күлнең теге ягыннан йөзеп килүче ялгыз нокта күзгә чалынды. Әйе, бер ялгызы бу! Кара нокта булып башы гына күренә. Ике кулының ник берсен бер мәртәбә өскә чыгарсын, ичмасам. Үзе терекөмеш кебек, алай да түгел, су өстендә йөрүче энә карагы кебек тиз шуыша. Дельфинмыни, астан ишеп кенә бара, күрәсең. Менә ул, теге юрганга килеп тә җитте, әйләндердеме, бордымы шунда, юрганны кулына алырга маташканда моңа Әнәс белән Габбани килеп кушылды. Арттарак йөзүче өчесе дә кушылгач, зур бер төркем булып көймәгә киттеләр. Эчем жылынып китте. Котылдың, мескенем.

Көймә янында шактый кайнаштылар әле. Коткару көймәләре дә килеп туктады — дүртесе дүрт яктан. Янгын сүндерүчеләр кебек болар, кызым, өй янып беткәч янгын машиналары сызгырып килгән кебек.

Безнекеләр табынга кайтты. Киемнәреннән шыбырдап су ага. Айгырлар сугышканда эткәй суда коенган кебек...

Ашыктырабыз: «Нәрсә? Ни?» дибез.

Чыннан да, җиңел юрганга төргәне яшь бала булган. Көймәләре ауган, хатыны минем шикелле бөтенләй йөзә белми, ди. Үзе ачы итеп кычкыра, үзе иренә чатырдап ябышкан, ди. Габбани әйтә, бармакларын каерып алышлы түгел, ди. Хатынны да калдырып китә алмый, бала да йөрәк пәрәсе, ир дә аптырап калган. Юрганның тиз генә батмаячагына ышандым мин дип әйтә, ди, мескенем. Боларны ашыга-йотлыга Николай сөйләде. Боголюбов аны раслап кына барды.

— Теге яктан кем килде, теге кем?— дидек, барыбыз беравыздан.

— Кем дип, бу тирәдә кем шулай йөзә ала?— диде Әнәс сорауга сорау белән.

— Түлке Габбас Закиров!

Геннадий моны шулкадәр нык ышанып әйтте, безнең күнелдә аз гына да икеләнү билгесе калмады.

— Кая йөри ул, ник килмәгәннәр?— диде Флера.

— Без аның белән әнә шунда,— дип, кулы белән төртеп күрсәтте Әнәс,— плотина башында очрашырга сүз куешкан идек, барып җитмәдек бит... Көткән-көткән дә, ярга чыгып утырган. Хәзер киләләр...

Ул арада Габбас белән Талия килеп тә җиттеләр. Ак йөзле кыз баладан соң нык үзгәрә диләр. Дөрес түгел икән, Талия һаман кызлар кебек. Бер дә үзгәрмәгән. Чия чәчәгемени, кайбер хатын-кызлар кершән ягынса да бу кадәр ак күренми. Талия — ап-ак. Андый күбәләкләр Тарханда гына оча, күрәмсең, барып күрә алмадым бит, авылга кайткач барсам була иде...

Дугаланып торган нәзек кашлары аның матур, ап-ак йөзен тагын да ачып җибәрә. Янәсе, мондый йөзгә тупас, калын әйбер ярамый дигән сымаграк килеп чыга. Сөрмәле күзләре Габбаска да, якты дөньяга килгән кызы Рәзинәгә төбәлгәннәр. Күзгә карап озак сөйләшми. Калын чәчен, кыз вакыттагыча, аерып үрә. Ул шул яклары белән күп хатын-кызлардан аерылып тора. Габбас ярата үзен, яныннан бер дә китми. Хәзер дә үз яныннан урын күрсәтте.

Тора-бара күзләр кызды, сүзләр куерды. Междуречинскидан, Осинникидан «Алдан»ны өйрәнергә, эшне уртаклашырга делегация киләчәк икән. Геннадий моны да әйтеп салгач, Боголюбов торып ук басты.

— Ишеттеңме, Габбани, нәрсә ди Зиновьев!— Боголюбов берәм-берәм егетләргә карап чыкты.— Безгә өйрәнергә киләләр... Ха-ха!.. Шәп бу, шәп, егетләр...

Сүз тагын куерган булыр иде, Мишка Роговцов гармунын алып уйный башлады. Гармунга барыбыз да ияртек...

Шәфәкъ алсулыгы җиргә иңгәч кенә кайтырга кузгалдык.

Шул көннән соң ике-өч көнме, бер атна узгачмы, кызым, син минем кулыма катыргы тышына ясаган рәсем китереп тоттырдың. Әтиең өстәл янында нәрсәдер сызып утыра иде, мин сиңа оекбаш бәйлим. Инәләремне итәгемә куйдым да, шул рәсемгә карап, тукталып калдым. Әтиең дә минем янга килде. Көлеп тора, үзе дәшми.

Мин, кызым, охшаттым бу сурәтне. Бер сиңа карыйм, бер әтиеңә, бер кулымдагы рәсемгә карыйм, сөенеп, шатланып карыйм... Кызым эше бит бу! Икеләнәм дә... Үзенә бер тамчы су шикелле охшатып ясаса да, үзе түгел бит бу. Габбани минем шик-шөбһәмне йөземә чыккан билгеләрдән тоемлады ахры:

— Әллә үзеңне үзең танымыйсың инде?— диде көлемсерәп.— Менә бит аерымачык күренеп тора — син, кызымның әнисе! Төсләрне каян табып бетергән диген! Шулай күрергә теләгән кызым әнисен.

Габбани китаптан укыган кебек сөйләде дә чыкты кулымдагы рәсемгә карап. Исем китеп, шаккатып утырам! Әйе, бу мин идем...

Кичен бу рәсемне пыялалап рамга куйдык. Ул хәзер кызымның баш очында, стенада эленеп тора. Өебез тагын да ямьләнеп китте. Бер стенада — бакчабыз чәчәкләре, икенчесендә — «Маугли»— кара пантера белән матур кыз, өченчесендә — бүгенге рәсем!

## 14

Әллә икебез дә эшләп йөргәнгә, әллә үзең һәвәс булдың, кызым, бәрәңге әрчергә, аш пешерергә бик яшьләй өйрәндең. Дәү әниең әйтә, кулыма эш бирми хәзер, ди, үзем-үзем, дип кенә тора, ди.

Үзем дә яхшы сизәм моны. Элек эштән кайттым исә янымда балам, итәгемдә эш иде. Хәзер Флера, Наилә апаңнар балаларын күтәреп керәләр дә, мин кул эше башкарып тик алар белән сөйләшеп утырам. Син, кызым, безгә чәй кайнатасың, аш әзерлисең. Ара-тирә генә сорап куясың: әни, капкачын ачып куйыйммы? Әни, сөт салыйммы, каймакмы? Үзең шул арада яшь балалар янына килеп, аларны сөеп китәргә дә онытмыйсың, үзең сыйпыйсың, үзең миңа карап-карап аласың, янәсе, әни, без дә алып кайтыйк инде шундый бер кечкенәне...

Бүген дә, әтиең эшкә киткәч, Наилә апаңнар керде. Сөйләшеп чәй эчтек. Ашыкмадык. Мин икенче сменага чыгам. Кичә «Юнгор», «Проводник» пластларында йөреп кайттым. Бүген әтиеңнәр янына барырга булыр. Забойлары өченче параллель штрек тирәсендә, ди. Сүзебез шул турыга житкәч, Наилә апаң сагайтып куйды үземне.

— Карале Гөлфәния,— ди бу, колагың ишетми калмасын дигән сымак итеп.— Мишка әйтә: Габбани нишләгәнен белми йөри забойда, ди. Биленә бау да бәйләтми, мичләргә дә бер ялгызы кереп-чыгып йөри, тәмам күнекте. Саклануны онытты, ди. Син әйт әле аңа, яшьтәш! Кыланма, дигән! Агишев агай пенсиягә китәргә ун көн калгач забойда басылып үлде, дигән! Мәчет кебек йорты, самолет кебек машинасы, йортында мунча хәтле сыеры басып калды. Аннан ни файда?! Хатыны, мескенем, бер ялгызы тилмерә хәзер...

— Алай куркытма, Наилә, Габбани башсыз түгел. Тиз эшләргә ярата ул, забойда әкрен кыймылдаганны жене сөйми...

— Анысы, Мишка да басып тормыйдыр да, шикләнә бит. Шикләнмәсә әйтмәс иде...

Сүз көрәштерүдән мәгънә юк иде, Наилә бу сүзне чынлап торып сөйләргә кергән. Алдан уйланган...

— Ярар, әйтермен, Наилә, әйтермен!— дидем.— Бүген үк забойларына барып житешәм, үз күзләрем белән күреп, урында кисәтермен...

Алар чыгып киткәч, өй бушап калды. Өйдә эш юк. Никтер бакчага чыгасы килми. Киендем дә шахтага киттем. Иртәрәк кайтырмын, мин әйтәм.

Жәяүләп төшеп, участокка атладым. Төп штректа ике люкогрузчик күмер төйиләр. Алар янына азга гына тукталдым да, забойга менәргә дип баскыч янына килдем. Ашыга-ашыга участок начальнигы Николай Тараканов төшеп килә. Шул көннәрдә генә, делегация килеп киткәч, Владимир Боголюбовны шахтаның баш инженеры итеп күчерделәр. Аның урынына Николайны куйганнар иде. Нишләптер, Николай мине күрмәде, әллә күреп тә игътибар итмәде, танымадымы, кызулап барып, баганада эленеп торган телефонга үрелде. Кабинетка, нарядка шалтыратадыр: кайсы забойда нәрсә эшләргә кирәклеген әйтми калмас, менгәнче үк белеп меним әле димен, үземнең колак анда, аякларым баскычтан атлый.

— Алло, алло! Шахта дежурныемы?— Тараканов үзе ашыга, сүгенеп-сүгенеп тә куя, үзе шахта дежурныена кычкыра.— Ишетәсеңме, алло! Тизрәк коткару командасын чакыр!... Габбани мичкә очты... Күмер, күмер, әйе...

Минем кулларым баскыч басмасында асылынып калды. Күзләрем күрмәс булды, колагым тонды. Әллә кая, баш миемә эчендә нәрсәдер чыжлый, кайный, ташып чыга. Шул кайнар дулкын сиңа кагылып, кызым, Гөләрия, пешеп үләрсең шикелле...

— Габбани!— дип куркынып кычкыруыма үзем дә айный төштем бугай. Тирә-юнемне капшанам: башымнан каскам очкан, билем тимер рельс өстендә. Тезем, билем ачытып сызлый. Башым әйләнә. Аның саен Николай мине күтәрергә азаплана.

— Гөлфәния, Гөлфәния!— ди өзек-өзек сулап.— Тынычлан, я, тыныч бул, дим!

Кемнәрдер килеп мине күтәрә башлагач, үз аягыма торып бастым.

— Николай, әйт, кайсы мичтә!— димен шашарга җитешеп.
Ул арада Роговцов, Габбас төп штрекка сикереп төштеләр...
— Люкта күренмиме?.. Гәүдәсе чыкмадымы?...
Икесе бергә тагын чабып менеп киттеләр.
Сменада кем бар, барысы да әле өскә, әле аска чаба... Мәш килә халык...
— Күмер беренче параллельдән узды, күренмиме?— дип кычкырды берәү, штрекны яңгыратып. Әйе, бу Әнәс тавышы иде.
Выелдап электровоз килеп туктады. Шул вакыт зур кара капчыкны җилкәсенә аркылы салган кебек итеп, баксычтан Әнәснең төшкәне күренде. Бу — Габбани гәүдәсе иде...

Мин штректагы шпаллар өстенә сузып салган Габбани янына килеп аудым. Аерым-аерым сүзләрне генә ишетәм, берни аңламыйм.
— Әз генә пульсы бар...— Врач тавышы бу!
— Яхшылап төрегез... Тизрәк, комбинатка...— Боголюбов әйтте моны.
Безнең вагонны уклоннан тарттырып күтәргәндә ашыгыч ярдәм машинасы көтеп тора иде.

Габбанины травматология больницасына алып киттеләр. Өйгә кереп тормадым, комбинатта өстемне генә алыштырдым да шахта автобусында больницага киттек. Монда Боголюбов, Әнәс, Мишка, Николай Тараканов, Габбас, Геннадий, Габрахман ага белән эти дә килеп җиткән — мине көтеп алдылар...

Һәркайсы аптыраулы, һәммәсенең йөзе качкан. Агарынып киткәннәр. Боголюбов өнсез калган бу төркемгә җан кертергә теләгәндәй, сорап куйды. Сөйләшми тору да ярамый иде.
— Әнәс, кайдан таптың Габбанины?— диде.
— Беренче параллельгә җитәрәк, аркылы-торкылы буралар арасында ята...
— Эзләп йөрерсең бит, ә!— диде Шахта бабай әкрен тавыш белән.— Күмерне төяп бетерерсең, кая бу дип, тәки эзләрсең...
— Шулай була язды да... Күмер китте, күренмиме?— дип аска кычкырам, нәрсәдер сизенгәндәй, штректагы мич авызына чабам. Утны турылап, өскә карасам — ул...

— Рейка белән генә сузылып төртик, бәлки китәр, дип күпме әйтеп карадым,— ди Мишка Роговцов.— Көлде генә... Син нәрсә, Миша, кереп кысылган мичкә хәтле күмерне күрмисеңме әллә, ди. Рейка түгел, чүки-чүки кәйләң сынып бетәр, ди. Мичкә керде китте... Бер-ике суктымы икән, дөбер күмер ташкыны! Дудкага сикерде сикерүен Габбани, тотына гына алмады, ялтырап лампочкасы күренеп калды...
Мин әти күкрәгенә башым куеп, һаман сулкылдап, елап барам. Күз яшемне тыя алмыйм. Өрлектәй ирең тиктомалдан әрәм булсын әле...
Мине беркем дә юатмый. Бу хәлдә килеш юатуның бер тиенемә дә ярамаганлыгын барысы да аңлыйлар.
Ак халатлар кигереп, барыбызны да палатага керттеләр. Бераздан Габбани янында ялгызым утырып калдым. Бер гөнаһсыз ап-ак йөзләремә хәсрәт сарысы шул сәгатьләрдә суга башлады, кызым!
Бер караватт булып, тулып ята Габбани, бәгырькәем. Аякларына урын җитмәгән дә, караватт башын төшереп, өстәл кебек ясап аякларын шунда салганнар. Ап-ак җәймәгә төреп, өстенә калын, җылы простыня япканнар. Ичмасам, бер мышнасын иде, һич югы, бер күзенең керфеге кыймылдасын иде. Күңелем булып китәр иде. Исәнме ул, үлеме ул — беркем бер сүз әйтми. Сәгать саен сестра укол кадап чыга. Укол энәсе төрткәндә, башта әллә нишләп, өшеп куя идем, хәзер боларын курыкмый карыйм. Авыртуга селкенмәсме, күзләрен ачмасмы Габбани, дим. Ә аның сулу алганы да беленми. Маңгаена борчак-борчак тир тамчылары гына бәреп чыга. Мин аларны һаман саен сөртә торам.

Бер тәүлек узды...

Ике...

Өч...

Мин очраган һәр врачның кулына асылынып елыйм, ник уянмый ул, ник терелтмисез, дим.

Йомшак кына юаталар, аңына килә алмый әле, менә-менә күзләрен ачар, дип палата ишеген шыпырт кына ябып чыгып китәләр.

Җиде...

Сигез...

Тугыз көн узды. Габбани каралып көя бара, җанкисәгем, үлүләрең шушы микәнни соң дип, тәгәрәп-тәгәрәп елыйм; кемгә, нәрсә сүз кушарга белмим! Нигә соң, бәгърем, безне ташлап китәргә булдың инде болай, безне кара кайгыларга салып, дип тәкърарлыйм. Соңгы минутларыңда бердәнбер кызыңа күз тутырып карый да алмыйча дөньядан күченүеңмени соң, Габбани күгәрченем? Үзеңне үз җаныңдай якын күреп, сөеп тә туя алмаган япь-яшь хатыныңны ташлап китәсеңмени, Габбани багалмам? Йөрәгем өзгәләнә. Йөрәгемдә ут яна. Акылдан язуым шушы, күрәсең!

Шулай өзгәләнгән чагымда палатага әни белән әти килеп керделәр. Йөземне-битемне күрүгә әни дә елап җибәрде.

— Хәле ничек, кызым?— ди шыпырт кына, үзе идәнгә чүгә бара.— Бик бетеренгән...

Әти Габбани янына йөгереп диярлек килде.

— Улым...

Ул да кулъяулыгы белән безгә күрсәтми генә күзләрен сөртте.

— Әйбәтләнер, кызым, бөтенләй күтәрелеп бәрелмә әле син,— диде әти, мине юатырга тырышып.— Коломыцев бер елны ун көн аңына килә алмыйча ятты да, әле дә эшләп йөри. Габбани да терелер алла бирсә, таза кеше, сәламәт кеше.

Әтинең муенына асылып тагын бер тын елыйсым килеп китте. Бусы инде өметсезлек белән дә түгел, яратып, үз итеп, якын итеп. Үз вакытында яхшы киңәше өчен... Ничектер, күңел җиңеләеп китте, югыйсә, күтәрә алмаслык авыр иде.

— Бигрәк тә кызганыч бит, әти!..— дидем, бернинди дә сүз таба алмагач.

— Кемгә җиңел дип беләсең? Әниеңә җиңелме, көне-төне синең өчен ут йота. Миңа җиңел дисеңме?.. Ул кызың акылдан шашмаса ярый инде... Кемнәрдәндер ишеткән, кемдер сөйләгән үзенә... «Әти!»— ди дә кычкырып елый. «Әти!»— ди дә кычкырып уяна.

— Юатып торган булабыз да бит, үзең дә бер кайтып күренеп кит! Ул бит зур кыз хәзер, безгә генә ышанмый...

— Аңына килсен инде, әти! Кайтып сөендерермен... Барыгызны да...

...Унөченче көнне Габбани аңга килде. Бер генә минутка... Әкрен генә кыймылдатып, күз кабакларын күтәреп карады. Күзләре тоныкбер нәрсәне дә күрми, буп-буш иде. Аннары алар әкрен генә йомылдылар... Шул да миңа әйтеп бетергесез көч бирде. Башта мин селкенми дә карап тордым. Күзләре йомылуга врач янына чаптым.

— Ачылды, ачты... Күзен ачты!— дидем сулышыма буылып.

Ә алар, берәү генә түгел, бишәү-алтау палатага керделәр. Тыңладылар. Әллә нияр белән йөзенә, маңгаена, күкрәгенә сызып карадылар, өстенә салкын су бөркеделәр. Аннары берьюлы ике-өч төрле укол ясадылар да, өстенә йомшак одеал ябып: «Йокласын!» дип чыгып киттеләр.

«Йокласын!» дигәч, миңа да җиңел булып китте. Ул бит, әле ярты мәет иде, берни дә белми иде. Баш мие нинди газаплар белән эшлидер бу чакта, беркем дә белеп бетерми кебек. Врачлар белә. «Йокласын!» диләр бит. Белмәсәң, ничек әйтәсең ди мондый сүзне. Бер мизгел аңга килгәч, хәл алыр өчен баш мие билгесез вакытка янә бер тын кала, күрәсең.

Ике-өч сәгатьтән соң Габбани кабат күзләрен ачты. Мин тынымны алырга куркып тордым. Нәрсә эшләргә икәнен дә белмим, сүз дә куша алмыйм. Ә Габбани гел миңа караган шикелле тоела, нәрсәдер көтә, сөйләтәсе килә кебек, сөекле кызы Гөләрияне сорый сыман.

Үз-үземне белештермичә йөзенә иелдем дә, учларым белән җиңелчә генә яңакларын кысып, күзләренә туп-туры карап пышылдадым:

— Габбани!

— Гөлфәния!— диде Габбани. Әйе, баскан урынында җир йотсын әгәр, шулай исемем белән дәште. Әкрен, бик әкрен әйтте ул, бәлки ул шыпыртның да иң шыпырты әйтелгәндер, үз колагым белән ишеттем: «Гөлфәния!»— диде.

— Габбани!

Шулай әйттем дә, шашынып ике күз алмасын да кат-кат үптем.

— Кабат күзең йомма инде, Габбани бәгырем! Авыр булса да карап тор, Габбани җанкисәгем!

Үзем күзләрен үбәм, үзем телемә ни килсә, шуны тезәм.

— Гөләрия!— диде Габбани.

Икенче сүзе шул булды.

Кызымның теле башта: «Әт-тә!»— дип, аннары: «Ән-нә!» дип ачылса, үлем белән тартышып ятучы иремнең теле дә, күңеленә иң якын кешеләре исемен атап: «Гөлфәния» һәм «Гөләрия!»— дип ачылды.

Габбани хәлсез иде. Ул башка бер сүз дә дәшмәде. Бары тик күзләрен тутырып миңа карый да, аңлап бетерә алмыйча тирә-юнен күзәтә. Ул әле ике аягы, биле, оча сөяге сынык булуын да, кендегенә тикле таш шикелле гипска катырып куюларын да белми. Ул хәлсез генә түгел, аңсыз, хәрәкәтсез ятуын да белми... Ә мин сөйләдем дә сөйләдем аңа. Үзем еладым, үзем маңгаеннан сыйпадым, үзем үптем, саташкан кеше шикелле көлеп-көлеп тә куйдым (бусы — Габбанинең күзләре ачылуга шатлануым иде!), ләкин моны Габбанига сөйләп аңлата белмәдем.

— Биктимергә, әти-әнигә хәбәр итимме?— дидем аннары, Габбанига беренче соравым шул булды.

— Юк...— диде Габбани авыр гына.

Шул вакыт палатага врачлар кереп тулды.

Шул көнне мин беренче тапкыр өйгә кайттым.

— Кызым, әтиең дәшеп калды, кичен әтиең янына барабыз!— дип сине сөендердем.

## 15

Әтиеңне күргәч, син, еламадың, кызым! Минем шуңа исем китте. Син аны әле генә йокысыннан уянгандыр, дип уйладың кебек. Габбанинең безне күргәч торып утырмавына да, иягенә кадәр ап-ак простыняга уранып ятуына да исең китмәде, туп-туры янына килдең дә:

— Әти, кай җирең авырта?— дидең.

— Авыртмый, кызым! Торырга гына ярамый...

— Мин сине сагындым... Куркып беттем...

— Мин дә сагындым, кызым... Озак килмәдең бит...

— Алып килмәделәр, әти! Терелгәч барырсың диделәр.

— Инде терелдем, кызым! Көн дә килерсең, яме?..

Син дәшмәдең, кызым. Әтиеңә тутырып караган килеш тавыш-тынсыз утырдың. Үзең учларың белән әтиеңнең чәчләрен сыйпыйсың, күзләрең әтиеңнең йөзе буйлап күкрәгенә, караваттан чыгып торган аякларына төшә. Ике атна буе әти-әнинең юатып яшәве файдага булган. Күңелеңне төшермәгәннәр. Рухыңны саклаганнар. Син Гөләрия, ничектер, олыгаеп, уйчанланып та киткәнсең кебек. Йөзеңдә уен-мазар, шатлыккөлүнең әсәре дә юк. Зурлар кебек, олылар кебек уйчанланып утырыр-

сың. Әллә, балакай, өйдәге тормышның калын башын үз җилкәңә салырга җыенуыңмы, сабырлык белән көч туплавыңмы?! Без сине пар канатлар өстендә тормышка әкренләп кенә алып кертергә җыена идек. Хәлеңнән килгән эшне үз яныбызда башкаруыңа сөенеп туя алмый идек. Үзәкләрне өшеткән бу салкын җил исте, кызым! Яшьлегеңдә кырау гына сукмасын...

Габбани кашларын җыерып, авыртуын басарга, селкенергә тырышып карады. Ләкин ул, өстенә таш бастырып куйган кебек, селкенерлек димим, кыймылдарлык хәлдә дә түгел иде. Шуны сизенепме, әллә юлбарыстай җитез егетнең балалар хәкеменә калып ятуына гарьләнүдәнме — Габбанинең күзләрен яшь элпәсе томалады. Юк, ул моны сиздерергә теләмәде, эчкә йотарга тырышты. Нишләсен, куллары гәүдәсенә бәйләп куелмаган булса, бәлки ул күз яшен тиз генә сөртеп алып, кызына күрсәтмәс тә иде, куллар да бәйле. Яшьләре, ирексездән, күз кырыеннан мендәренә тәгәрәп төште...

— Әтием!..— дип син, балам, шунда Габбани өстенә капландың. Сиңа бу минутларда бернинди үгет тә ярдәм итә алмый иде. Чын ярату белән әтиеңә караган саен кайнар яшьләрең түгелде генә... Дүртебез дә еладык. Ләкин истә калганы, синеке белән әтиеңнеке булды.

Дәү әниең белән син кайтып киткәч, кызым, Габбанинең сызлануы көчәйде генә. Күзләре йомылды, үзе аның саен ыңгыраша. Маңгаен тотып карыйм: ут кебек яна! Берни белми янып ята. Кеше шундый утларда януга да түзәр икән.

Габбанинең болай сызлануы ай буена туктамады. Бер айдан соң аякларына яңадан операция ясадылар. Сызлавы басыла төште кебек. Аз гына ашый да башлады. Вакыты-вакыты белән ике-өч сәгать йоклап та ала. Көне-төне селкенми дә бер урында яту никадәр генә туйдырмасын, эчке сызлавы адәм түзәрлек булса, Габбани ыңгырашмады. Хәле җайлана төште исә, миңа өйгә кайтырга куша:

— Гөлфәния, кайтып Гөлриягә булыш, кичен килерсең,— ди.

Мин көн саен диярлек өйгә кайтып килә башладым.

Бер кайтуымда, комбинатта баш инженер Владимир Боголюбов белән очраштык. Эшләрнең барышы белән кызыксынып, бүлеккә барган идем. Шуннан чыгышлый очрады бу.

— Гөлфәния, ну, хәлләр ничек анда, Габбани нишләп калды?— диде дә бу, минем җавапны ишеткәч, яхшысынмыйча гына әйтеп куйды:— Атнага бер тапкыр участокларыңны әйләнеп чыгарга тырыш инде, Гөлфәния, яме?!

— Шуның өчен килдем дә...— дидем.

Габбанинең дуслары — шахта начальнигы Семен Прокопьевич Рябыкиннан алып, бригаданың забойчыларына кадәр — бер көн дә Габбанины ялгыз калдырмыйлар. Шахтадан ике-өч кеше көн саен килә. Ләкин эш турында беркем, бер сүз ләм-мим иде әле. Баш инженер искә алды бүген. Күрәмсең, инде вакыттыр. Шулай кирәктер. Ир-ат кирәксезгә хатын-кызны борчымас, белеп әйтә торгандыр. Болай да минем өчен маркшейдер эшен Габбас үтәп йөри икән. Участок начальнигы урынбасары булган өстенә, Николай Тараканов кебек ялны белмәс кешенең беренче кулы булуы өстенә! Юк, гел-гел алай булмас, бүген үк төшеп менәрмен шахтага. Боголюбов минем уйларны алдан белгән сыман:

— Ашыгыч түгел, Гөлфәния, бусына өлгерербез! Габбанины кара...— дип, шахта дежурные кабинетына кереп китте.

...Шахтага төшкәч тә, мин турыдан-туры Николай Тараканов участогына киттем. Анда Габбасны да күрермен, эш тәртибен бераз аңлашырбыз... Аннан да битәр... Габбани вакыйгасы булган урыннарны, күңелем тартмаса да, бер карап әйләнермен. «Алдан»да эшләр гөрләп бара дип сөйлиләр, забойларны карап чыгармын...

Елмая-елмая Габбас килеп басты яныма. Энәс, Мишка, Гололобов чолгап алдылар. Алар минем хәсрәтемне яхшы беләләр, Габбаниның хәлен дә белеп торалар, шуңа да, гел-гел кара кайгыны искә төшермәс өчен, дөньяда бернинди үзгәреш тә булмаган сыман сөйләшергә тырышалар. Соңгы вакытта бу бик сизелә иде. Әле бүген дә Габбас минем белән исәнләшкәч:

— Гөлфәния! Лаваларында кичә генә булдым. «Алдан»да да тәртип. Планны егерме көндә «суктылар». Эш кәгазьләреңне җайлый барам. Боголюбов та мактый. Син, Габбас, әллә кайчангы маркшейдер икән, ди.

— Рәхмәт, Габбас, рәхмәт!..

Мин рәхмәтемне әйтеп бетермәдем, Энәс җиңемнән тартып, забойга таба күрсәтте.

— Гөлфәния!— диде, башы белән мич ягына ымлап.— Беренче штректа забойны туктатабыз хәзер. Төп штрекны озаграк саклау өчен...

Боголюбов хәзер, баш инженер булгач, забойны тәмам үзгәртергә өлгергән...

— Билгә бау да кирәкми хәзер,— диде Мишка Роговцов.— Котым очып бетә иде...

— Дудкаларны да киңәйттек, ешайттык, Гөлфәния!— диде Гололобов, балаларча беркатлылык күрсәтеп.— Кысыла-кысыла аммонитым, капсүлләрем белән шартламасам ярый, дип йөри идем.

Әйе, «Алдан»га кереп йөри торган юллар чыннан да, ешая төшкән иде. Дудкалар болай якын булса, мөгаен, Габбани да мичкә очмаган булыр иде... Бәхетсезгә — вакытсыз диләр, дөрес күрәмсең! Алай дисәң, Габбани бер дә бәхетсез түгел иде...

Забойны карап, сөйләшеп йөргәннән соң мин кайтырга булдым.

— Габбанига сәлам...

— Габбани күңелсезләнмәсен...

— Габбани янына иртәгә барабыз...

— Габбанига китаплар укы...— дип, шунда дүртесе дә берәр сүз әйтергә тырышты. Чыннан да, нишләп минем башыма бер дә килмәгән әле бу: китап укып Габбанины юатырмын, үзем дә юанырмын...

Кичен мин Габбани янына Тукай, Такташ китапларын кыстырып бардым. Аларны күргәч, Габбани көлемсерәп куйды.

— Өр-яңадан башлыйбызмы, Гөлфәния!— диде.

— Беренче битләреннән...

Иң башлап мин Габбанига забойдагы үзгәрешләрне төкми-чәчми сөйләп бирдем. Аннары, Гөләрия кызым, син ясап биргән төсле картинаны әтиеңә күрсәттем.

Үзебезнең өйдәге аквариум иде бу. Егерме чиләк су сыешлы зур аквариум иде. Габбани: «Күл бу, үрдәкләр генә җибәрәсе»...— дип көлә иде. Кызым исә: «Диңгез бу, әтием диңгезе...» дип шатлана иде. «Диңгез булгач, суы булгач, балыксыз булмас инде. Кая барсагыз, шуннан балык алып кайттыгыз: кызыл, кара, ак балыклар дүртәр-бишәр генә йөзсә дә, эреләр, бармак буйлылар. Ләкин яшел урман өчен алангдагы чәчәкләр, вак куаклыклар табигый булган шикелле, аквариумда да вак балыклар үрчетеп тагын да матурлыйсы бар икән әле. Бусын да эшләгәч, аквариум төбендәге ак ком өстенә су үләннәре утырттыгыз. Су өстендә дә яшел үсемлекләр йөзә. Менә шуларны рәсемгә төшереп алгансың, кызым, күзне иркәләрлек итеп ясап куйгансың. Аквариум — үзе бер тормыш. Өйдәге үзгә бер тормыш! Шахта да шулай, кызым: шахтада белмәгән башка кешеләр өчен, үзгә бер тормыш! Хәзерге космос шикелле. Җир асты эшенең очы-кырые күренми әле...

Габбани карап туймады картинаңны. Мин аны палатаның ак стенасына элеп куйдым.

Кеше җаны кеше ышанмаслык газапларга да түзә икән. Габбани дүрт ай буе такта караватт өстендә йөзтүбән ятты. Астында юка киез, өстенә одеял ябам. Мендәр-фәлән ярамый. Бил, оча сөяге сынуның газабы шушы икән: бер кыймылдамый айлар-төннәр буе йөзтүбән яту.

Хәтеремдә, без яшь чакта эти (әни кушуы буенча) чебеш әнкәсе буласы килгән тавыкны тотып, аякларын бергә кушып бәйли дә, шул җептән чөйгә асып куя иде. Мескен тавык, кешеләргә яхшылык теләгән изге тавык, бер тәүлек буе шулай йөзтүбән асылып тора. Бер тәүлектә кибә, суына, гайрәте кайта иде. Чәйдән төшкәч тә кая ул йомыркалар өстенә утыру, ояның янына килми, бу елда ул турыда уйлап та карамый, бичара. Бер тәүлектә бит бу...

Габбани йөз егерме ике тәүлек йөзтүбән ятты. Биле генә булса иде икән... Аяклары сөяк ялгана башлаган урыннан шешеп чыга. Бөерендә дә нәрсәдер бар, дип шикләнәләр.

Врачлар — антка тугрылыклы халык, авыруның үзенә тормыш вәгъдә итәләр. Соңгы сәгате сукканда да, кешенең үзенә үләсен әйтмиләр. Әмма туганнарына, якыннарына дөресен әйтәләр. Мин моны Габбани янында үзем ятмасам белмәс тә идем...

Тау эшләре мастеры Токмашевның әнисен больницага салдылар. Кара көеп ябыккан, мескенем. Тәнендә тиресе дә сөяге... Хәлвә түгел бал куйгач та үрелеп капмый. Көннән-көн сүнә бара... Токмашев көн дә килеп йөри. Әнисен өзелеп ярата. Нәрсә әйтергә, ни китерергә белми! Мин Токмашевны күптән беләм. Габбанилар участогында эшли. Көндәлек тормышта галәмәт кешелекле кеше ул. Габбани янына кергәндә дә, балалар кебек аяк очларына гына басып керә. Авыруның күңеленә саксыз бәрелмәмме дигәндәй, тартынып кына сөйләшә. Үзенең кызгануы-яратуы йөзенә бәреп чыга. Әз генә кысыграк күзләре гел Габбанига карап елтырый. Кара тут йөзенә куе кызыллык йөгерә. Алтайлыларга гына хас гадәтенчә, хатын-кызга күтәрелеп, озаклап карап тора белми. Ә әнисен бага... Бер гөнаһсыз елтыр кара күзләре белән озаклап карый. Ни әйтергә белмәгәч, ишек, тәрәзәләр янына килеп: «Их, их!» — дип кабатлый. Врач булмаганына үкенә, ахрысы. Врачлыкка укырга теләгән ул. Әнисе җибәрмәгән. Шуңа үкенеп бер сөйләгәнен хәтерлим.

Врачлар да яраталар Токмашевны. Бер көнне якын иткәндәй булып кына серне чиштеләр: әниендә яман шеш авыруы, диделәр. Ашказанында булгач, өч-дүрт айдан да озак тормас... Операция ясауда мәгънә юк, вакыты узган, дип дөресен әйттеләр. Моны үзенә белеп торырга, авыруга бер дә сиздермәскә куштылар.

Табан аслары шешенеп чыккач кына Токмашев әнисен өенә алып китте. Бер атнадан улының муеныннан кочаклап үлгәнен ишеттек мескенкәемнең...

Врачларның серне чишүләре дә, үлемне юраулары да дөрес булды. Габбаниның бөерендә нәрсәдер бар, дип шикләнүләрендә хәзер минем шигем юк. Алар миннән серне бик яшермиләр дә. Мин тәмам үз кешегә әйләнеп барам. Ләкин операциягә ашыкмыйлар...

Ашыгыр ара да юк. Бил, оча сөяген ялгап дүрт ай йөзтүбән яткannan соң, уң аягына кабат операция ясап, аны герләр белән тарттырып, аякны караватт башына асып куйдылар. Дүртме-бишме ай шулай ятты Габбани.

Дүртме-бишме... дип, белмәгән кеше кебек сөйләнәм, кызым. Авыру янында, больницада ята-ята акылдан язам, ахры. Әтиеңнең гер тагылган аяк авыртулары йөрәгемне кисә, үземә күчә кебек. Тора-бара, чыннан да, шулай булды. Сул аягымның, рельска бәрелеп авырттырган аягымның

тез астына борчак кадәрле генә биз төртте. Үзе кызыл булып кына тора, үсми дә, бетми дә. Тишелеп эренләми дә. Үзе атлаган саен авырта. Габбани янына бер керүендә хирургка әйттем моны. Хирург карады да: «Иртәгә иртән кисеп ташларбыз бизеңне, операциягә әзерлән»,— диде. Минә сиңа телең бик кычытса: авыртмаган башка тимер тарак! Авыртыр, сызлар иде дә бетәр иде әле, борчак кадәре нәрсәкәйне, операция дигән була докторы да.

Борчак кадәре бизне кисеп ташлагач, бер айга якын больница караватында яттым үзем дә. Авыртмый да үзе, йөреп китеп тә булмый. Бастың исә сызлый. Сызлавы янбашыма, билемә күчте. Гел сырхау булып яттым. Кызым, мәктәптән кайттың исә, син безнең янда булдың.

— Әнием, тереләсеңме инде... Үтәме?!

— Әтиемә Лев Толстойны алып килдем...

— Әнием, тәрәзә төбендәге тамчылы гөл дә, яран да чәчәк атты... Ал, кызыл, ак чәчәкләр...

— Әнәс абый әти янына бүген килербез, диде...

Синең, кызым, безнең янда булуың, күңелне бер башка үстереп җибәрә. Тик сиңа, япь-яшь көеңә, бу кадәре тормыш йөге кагылуы гына күңелне рәнҗетә. Ә син, кызым, яшьлек белән үзең белмисең генә...

Син кайтырга җыенганда палатага Әнәс, Флера, Мишка, Наилә килеп керделәр. Дүртесе дә ап-ак халаттан. Зәңгәр күктән җиргә иңгән аккошлармыни?!

Хәзер палатага элеккечә, телсез шаһитлар шикелле коелып килеп кермиләр. Сөйләшә-сөйләшә, елмая-елмая керәләр. Мишка палатаны шәрран яра, теле ни сөйләгәнне колаклары ишетми.

Озак сөйләшеп утырдык. Сүз ара сүз чыга. Палатадан шахтага күчә. «Алдан»га килеп терәлә.

— Забойны шартлатканда мич өстен ачасыздыр бит?— диде Габбани.

— Шартлатканда гына...— диде Әнәс.

— Дудкаларны да ешайттыгызмы?

— Өч метр саен диярлек...

— Молодец, Владимир Александрович!— диде Габбани, баш инженер Боголюбовны мактап.— Шул арада докторлык диссертациясе язарлык эшләр башкарган...

— Докторлык дигәннән... Мине дә Казанга, институтка чакырып хат җибәргәннәр бит әле.— Әнәс бармак очлары белән чәчен төзәткәләп, Габбанига таба иелә төште.— Аспирантура бетергәндә язган эшемне тулыландырырга кушалар...

— Синең нәрсә иде әле анда?

— Трактор, автомобиль һәм авыл хуҗалыгы машиналарының гидросистемалары...

— Кызыклы тема...

Габбани янә елмаеп куйды. Сизеп торам, билеме, аягымы әрни, куллары белән эченә еш-еш басып ала, үзе берни белдермәскә тырыша.

— Кызыклы дип, Габбани, кызык кына да түгел инде ул. Авыл хуҗалыгының үз проблемалары туа тора. Шахта шикелле үк мәңге үсештәге проблемалар... Аны бер, ике, ун кеше генә чишеп бетерә алмый...

— Эшләп калырга, Әнәс дус, мәңге үкенмәслек итеп эшләргә...

Габбаниның хәле авырайды. Моны иптәшләре дә сизенделәр. «Озаграк утырдык, ахры»,— дип кайтырга җыендылар.

...Ике аягына, биленә кат-кат операцияләр ясап, аптырап беткәннән соң, Габбаниның оча сөяге өстеннән ярып, эчен ачтылар. Мин, ни эшлиләр тагын дисәм, оча сөяге ялганышларын, бөерләрен караулары булган икән. Аякка йөреп китә алмавына аптырыйлар иде врачлар. Кан басымы гел югары тора. Дару эчкәч, уколдан соң вакытлыча гына төшә. Аннары тагын кинәт күтәрелә. Габбаниның күзләре томалана башлый,

йөрәге еш-еш тибә. Шунда да сер бирми үзе: яңадан туу шома гына бармас бит, ди.

— Терелеп чыккач, ике аягыңның берсен шахтага бастырсам...— дип әллә йөзенче тапкыр кабатлавым инде, бу юлы да көлде генә.

— Авырган бере кача башласа, шахтада кем эшләр?

— Авырмаганнары эшләр...

— Лев Толстой алай димәгән шул... Мә әле, укы әле!— дип кулыма кызым Гөләрия алып килгән китапны сузды. Кызыл карандаш белән сызып куйган урынын укырга куша. Анда болай язылган иде:

«Гомер буе өзлексез борчылу, авыр хезмәт, көрәш, югалтулар — болар бер генә секундка да алардан читкә тайпылу мөмкинлеген уйламаска тиеш булган зарури шартлар. Намуслы яшәр өчен ашкынырга, буталырга, азапланырга, ялгышырга, башларга һәм ташларга, яңадан башларга, яңадан ташларга, өзлексез көрәшергә һәм мәхрүмлекләр кичерергә кирәк. Ә күңел тынычлыгы — рухи намуссызлык ул».

Укып чыктым. Габбанига карап шаккатып калдым. Минем бу даһи язучының бөтен китапларын да укып чыкканым бар, ләкин мондый урыны никтер хәтеремдә калмаган. Кеше хәлен кеше белми, үз башына төшмәсә дип, тикмәгә җырламыйлар, күрәсең. Мин Толстойны башта кызык өчен, гыйбрәт өчен, тормыш өчен, культурам үссен өчен генә укыганмын икән! Габбани белән бу хәл булгач, инде аның шахтага эшкә кайту-кайтмау мәсьәләсен алга куйгач, Толстой, әниләр ышана торган пәйгамбәрләрнең бөтенесеннән дә өстен булып, зур бер алтын һәйкәл булып күз алдыма килеп басты. Бер абзацта — тулы бер китап. Габбани, әллә кызым Гөләрия кызыл белән сызып куйган бу урынны укыдым да шаккаттым...

...Ике елдан соң үз аягында йөреп өйгә кайттык.

...Кайту шатлыгы айлар узган саен сары сагышларга күмелә барды. Габбани кырау суккан роза гөле кебек күзгә күренеп шиңде, сулды. Тамагына ашамас булды. Беркем белән сөйләшми башлады. Якты дөньяга аяк атлап чыкмады.

— Габбани!— димен икәү ялгыз гына калган чакларыбызда.— Аны беркем белмәс, уйлама, боекма...

— Болай булганчы, үләсе калган...

Әйе, үз күз алдымда Габбани шулай диде. Тетрәнеп куйдым. Һәр секунд, һәр минут, һәр сәгать, һәркөн саен үлем белән көрәшеп ятканда да мондый сүзне кабатламаган Габбани шулай диде бүген. Ир-ат өчен ирлеген югалтудан да зур кайгы юк, күрәмсең. Врачларның «бөере, бөере» дип шикләнүләре дә шул булган икән. Тик турысын ярып үзенә дә, миңа да әйтмәделәр генә. Авырту, сызланулары белән Габбани аны үзе дә сизмәде.

...Бер елдан соң коры тәнендә жаны гына калган Габбани Мәскәүгә китеп барды. Медицина фәнни-тикшеренү институты каршындагы клиникада сигез ай буе дәваланды. Баруга операция ясадылар үзенә. Каршы алырга Мәскәүгә үзем бардым. Күрешкәч тә үз күзләремә үзем ышанмый тордым. Яшь тай кебек биеп кенә йөри Габбанием. Бит алмалары кызарып тулышкан. Муеннары түм-түгәрәк булып, тиресе тартылып тора. Чиертсәң — кан чыгар, валлаһи! Каен дегетедәй соргылт-карасу күзләре егет чагындагы кебек өздереп, матур итеп карый. Вәт, димен, яшьлегемә кире кайтыр идем, кире кайта торган юл булса, дип белеп җырламыйлар икән, димен. Яшьлегеңә кире кайткансың ич, Габбани, димен.

Көлә генә Габбани.

Үземне сабый баланы кочкан шикелле итеп күкрәгенә күтәрде дә, зырылдатып әйләндерде.

— Берәр жирең авыртыр, нишләвең бу, Габбани, чү, җуләрем!

— Берәр жирем... авыртыр...— диде дә бу, караваt астыннан ике потлы гер сөйрәп чыгарды.— Менә санап бар! Профессорга да әйттем: Гелфәния килгәч, ич башта йөз илле мәртәбә гер күтәреп күрсәтәм, дидем.

— Бер... ун... егерме...
Мин саныйм, ул кутәрә.
— Утыз... илле... алтмыш...
Туктарга исәбе дә юк.
— Җитмеш... туксан... йөз...

— Кыланма шулкадәр, Габбани, ташла!— димен.

Үзе гер күтәрә, үзе герен һавага чөйгән арада минем белән сөйләшеп-сөйләшеп ала:

— Кызым сагынып беттеме?...
— Бүген үк кайтыгыз, дип калдымы?..
— Бөтенесен сөйлим, гереңне куй, зинһар,— дим.
— Йөз кырык... йөз илле...

Саный-саный телем арыды, валлаһи. Уенда да юк. Һаман күтәрә... Беләк мускуллары Биктимердә баз казыган чактагы кебек бүртелеп-бүртелеп чыга.

— Йөз алтмыш... йөз җитмеш... Ташла, Габбани, җитәр!

Герен куйды бу.

— Синең хакка гына куйдым,— ди, үзе сөлге белән тирен сөртә, үзе сөйләнә.— Көн саен ике йөз мәртәбә күтәрәм. Ун километр чабам. Биш-алты тапкыр су керәм...

— Йөгер дә, чап та, гереңне генә бу кадәр дуамал күтәрмә, Габбани...

— Һе, әллә шахтада җиңел булыр дисеңме...

Без озаклап сөйләштек, алып кайтасы әйберләрне чемоданга тутырдык. Габбани язуларын алырга китте. Шул чакта мин, рәхмәт әйтеп чыгыйм дип, профессор кабинетына кердем. Мин Менделеевныкы хәтле сакаллы, олы яшьтәге бер профессор янына керәм дип барсам, безнең почмак өстәледәй кечкенә генә өстәл артында Габбани яшендәге бер ир утыра.

— Ә-ә, Габбани хатыны сез алайса...— дип, каршыма ук килде бу.— Саубуллашканда менә нәрсә әйтәсем килә, Гөлфания. Исемегез шулай бит, ул көн саен сөйли иде. Хәтеремдә саклана...— Искиткеч ачык кеше булып чыкты бу яшь профессор. Үзе җиңелчә генә елмая, үзе сөйли.— Габбани бик таза шахтер. Күпне күргән, күпне татыган. Ул хәзер таза, сәламәт. Үзендәге һәр әгъзасы ракета двигателе кебек карусыз эшләр. Гомере буе эшләр... ну, бусын үзеңә генә әйтәм, балага узмассың!...

Мин бу мөлаем профессорга рәхмәтләр әйтеп чykканда кулына чемоданын тотып Габбани көтеп тора иде.

## 17

Без кайтып төшкән көн синең туган көнең кебек булды, кызым! Дөнья кояш нурларында коена иде. Күк зәп-зәңгәр иде. Безелдәп умарта кортлары оча. Алма бакчасында җылы, тәмле ис бөркелә. Бакчабыз тулы чәчәкләр. Алар арасында бердәнбер ымсындырып торган алсу чәчәк — ул син, Гөләрия кызым! Минем өчен генә түгел, әтиең өчен дә... Шул чәчәкне сагынып кайттык без. Әтиең бөдрә чәчләреңнән, алсу яңакларыңнан сыйпап, сөеп туя алмый. Син әтиеңә җыелган рәсемнәреңне күрсәтәсең.

— Охшаткан бит, ә?— Габбани рәсемне миңа сузды.— Әнкәй белән әткәйне ясап куйган...

— Эти! Мин анда эни белән сине ясарга теләгән идем дә, бу җәйдә бер дә өйдә утырмадыгыз шул...

— Инде бакчада өчәүләп утырырбыз, кызым!

Габбаниның шул сүзне әйтеп бетерүе булды, ишектән этиләр, Шахта бабайлар килеп керде. Ул китте күрешү, кочышу! Әнәс, Мишка, Флера, Наилә кереп китте. Ул да түгел, Мишка duслардан сөенче алырга чыгып йөгерде. Аңа ияреп Боголюбов, Габбас, Николай, Геннадий кайттылар. Сүз иярә сүз чыгып, Боголюбов, үзе дә сизмәстән, Габбанины эшкә кыстый башлады.

— Әнәс китә, Габбани! Давай, бригаданы алып кал!— диде.

— Габбани, сине көттек, бригаданы ал!— диде Тараканов та.

— Син кайтмыйча Әнәсне җибәрми тордык, Габбани, коллективны кулыңа ал!— диде Зиновьев.

Габбани ни әйтергә белми утыра. Әнәс институтка китә икән, Казанга күченә икән дигән имеш-мимешләр ишеткәләгән идем, тәгаен белмәгәч, ул турыда Габбанига сөйләмәдем. Үзем дә ышанып бетмәдем. Флера әйтер иде, югыйсә...

— Мин бит, егетләр,— ди Габбани әле һаман көтелмәгән яңалыктан зиһенен җыя алмыйча,— дүрт елдан бирле шахтаны онытып бетергәнмен...

— Онытмыйсың...— диделәр барысы да берьюлы.— Шахта онытылмый ул...

— Әйе!— диде Шахта бабай.— Ятсаң да, торсаң да шахта гел истә...

— Иртән дә, кич тә...— диде эти.

— Гел истә...— диде Габбани. Табындагыларның күзе аңа текәлде.— Туган җир кебек, гел үзенә тарта!

...Башкалар таралышкач та Әнәс китәргә ашыкмады, Габбани янында калды. Икәүдән-икәү сөйләшеп утырдылар.

— Әнәс китә икән шул,— диде Габбани, өйгә кергәч.— Бүген контейнер заказать итәргә барган. Эш биргәннәр үзенә, институттан...

— Флера нишләп әйтмәде микән?

— Шул көндә генә телеграмма алганнар. Әнәс үзе дә белмәгән...

— Сөенәме Әнәс!

— Юк! Китәсе килми, ди...

— Шулай шул инде,— дидем мин дә,— бер ияләшкән җирдән... Балалары монда туды, монда үсте дигәндәй...

Кызым, син шым гына безне тыңлап тордың да өйдән чыгып чаптың.

Габбани, озын отпускадан соң эшкә җыенгандай, шахта киемнәрен кичтән үк әзерләп куйды. Ә иртән — Әнәс, Габбани, Мишка — өчәү бергә эшкә киттеләр. Мин маркшейдерлар кабинетында аз-маз эшләр караштыргач кына участокка бардым. Забой шартлатылган, мич күмер белән тулы иде.

Мин «Алдан»ны карадым да, мич тишеп үтүче проходчиклар янына киттем. Проходчиклар шул ук участокта, «Алдан» забое өчен мич үтәләр иде. Әллә авышлык градусын билгеләмәгәннәр, әллә бурмашинист скважинаны бораулый башлаганда игътибарсызлык күрсәткән, әллә бу урында ташкүмер катламы үзе юнәлешен үзгәрткәнме — проходчиклар породага килеп төртелгәннәр. Минем шуны карыйсым бар иде. Карап киңәшләшкәч, рәхәтләнеп эшләрләр: бездән күрсәтмә алгач, эш барып чыкмаса да, аларга уртача хезмәт хакы түләнә.

Мич авызына килсәм, чупырдап су агып ята. Кап-кара су. Штрекка күмер апарасы ага.

— Саграк кайнашыгыз, менәм!— дип кисәттем проходчикларны.

— Ә, Гөлфания, мен-мен, курыкма!— дип, ишеткәнлекләрен белгерттеләр проходчиклар.

Трап куеп тормаганнар, бурага тотына-баса забойга күтәреләм. Аяклар тая, кул шуа. Бөтендөнья пычрак, юеш. Су таммаган, су акмаган урын юк. Бөтен җирем лычма су булды. Үзем менәм, үзем тиргим проходчикларны.

— Сезне соң гел мастер өйрәтеп торсынмыни? Трап куярга кирәк икәнен белмисезмени? Моннан бит теләсә кемнең таеп китеп, төп штрекка кадәр очуы мөмкин! Хәерсезләр. Кеше турында да уйламыйсыз, үзегезне дә онытасыз...

— Нәрсә бар, Гөлфания, болай түгел идең бит, әллә Габбани кайткач ачуланыштыгызмы?— диләр, юри минем сөйләгәнне ишетмәмешкә салынып.

— Нәрсә бар дип, бер дә авыз ерып торасы юк! Сезнең өстегездә резина кожаннар, су үтми. Ә минеке чүпрәк куртка! Манма су булдым. Траплар да тезмәгәнсез... Йөрешле түгел бит.

— Куябыз, Гөлфания, бүген тезәбез... әле унбиш метр гына үттек бит...

Ул арада яныбызга участок начальнигы урынбасары Габбас менеп житте.

— Трап сузарга дип нарядта әйтелдеме сезгә?! Әллә менә хәзер Гөлфания белән икәү тезә башлыйкмы, сез карап торыгыз...

Проходчиклар ләм-мим дәшми, икесе дә балталарын тотып түбән төшеп киттеләр. Өч-дүрт минуттан аларның шак-шок кадак какканы ишетелде...

Габбасның да бөтен җиреннән салкын су ага. Ул миңа карый, мин аңа. Икебез дә сер бирмибез. Болай озак тору мөмкин түгел иде.

Габбас күмер төяүчеләр хәлен белеште дә, телефон трубкасын алып, участокка наряд тапшыра башлады:

— «Алдан»ны шартлатырга... Аммонит?.. Ун килограмм алсын... Мичке куарга... Су, су!.. Тизрәк!.. Норманы?.. Маркшейдер белән карадык... Үзгәртербез...

Минем тешләр тешкә бәрелә. Шул килеш шурфка менмичә, Габбасның наряд тапшырганын көтеп торам бит. Инде борылып китәм дисәм, Габбас җиңемнән тартты:

— Китмә, Гөлфания! Бергә...

Ул диспетчерга шалтыратып «пассажир вагоны» сорады.

— Әйдә атлый торабыз, электровоз каршы очрар,— диде.

— Китсәнә, Габбас, шул юеш кием белән җилгә каршымы?!

— Хәзер электровоз килә дим бит, шалтыраттым ич...

Күп тә үтмәде, электровозның сары утлары җемелдәп куйды.

Комбинатка кайтып, кайнар суда юынып чыккач кына эчкә җылы керде.

Әтиең белән забойда атна-ун көн эшләп йөргәннән соң Әнәс абыеңнарны Казанга озаттык, кызым! Әйберләрен контейнерга төяп алдан җибәргәннәр иде, яннарында вак-төяк төенчекләр, чемоданнары гына.

Әнәсне озатырга бер без белгән дуслары гына түгел, бөтен шахта җыелды. Барак яны сабантуе кебек гөжләп тора. Халык автобусны сырып алган. Һәркемнең кулы тәрәзәгә сузыла, һәр сузылган кулда чәчәк бәйләме. Әнәс хушлаша алган кадәресе белән хушлашып, диңгезче тельняшкасының чабуларын рәтләп, автобуска килеп кергәч кенә шофер моторны кабызды.

Әнәс автобус тәрәзәсеннән башын тыгып, барак янында җыелып калган халык күмелгәнче кулъяулыгын болгап барды. Борылышта урынына утыргач кына күзләрен сөртеп алды.

## 18

Бу кыш, бу җәй безнең тормышта эзсез узды дип булмый, кызым! Дөрес, көндәлек ыгы-зыгы белән сиздерми генә узды ул. Мин шул эшемдә — һаман маркшейдер булып йөрим. Әтиеңне, Николай белән Габбас димли торгач, тау эшләре мастеры итеп күчерделәр. Забойдан күчәргә үзе теләмәде. Бригадасы да зур. Бөтен бер участок забойчылары. Күмере «Алдан» ысулы белән алына торган катламда лава, щитовой, комбинированный алымнар кулланып эшләү проектын әзерләп, шахта начальнигы Семен Прокопьевичка кергәч, әйткән Габбанига:

— Эшләп күрсәт, Габбани! Бөтен бер сменаны үз җаваплылыгыңа аласың да эшлисең. Участок начальнигы моңа риза, шулай бит, иптәш Тараканов! Баш инженер Боголюбов баш өсте дип тора, шулай бит, Владимир Александрович!

— Шулай...

— Риза...— дип тегеләре баш каккannar.

— Эш нәрсәдә терәлеп калды, Габбани!— ди шахта начальнигы.— Бригадаңны иң булдыклы егеткә тапшыр да сменаны кабул ит. Бергәбергә эшләрбез...

Әнәс абыең китеп, бер ел үткәч, Габбани забойчылар бригадасын Борис Шестопаловка тапшырды. Борис — яшь-яшь егет килеш бригадада эшләде. Штангист егет иде. Куллары корыч. Спорт мастеры. Укытучы кыз Валяга өйләнгәч, аңа Әнәсләр квартирасын бирделәр. Быел җәй генә нәни кызлары туды. Мишка белән Борис бер сменага йөриләр. Хәзер Габбани сменасында.

Әтиең алардан канәгать. «Щитовой забойда менә дигән егетләр!» ди. Кышын әтиеңнең кандидат стажы тулды... Коммунистлар партиясенә алдылар үзен...

Бу җәйдә син, сигезенче классны тәмамлап, художество-педагогия училищесына укырга кердең. Конкурс зур булды. Анысын үзең беләсең, кызым! Минем сүзем ул хакта түгел, конкурстан сине йолып алган рәсемдә.

...Шул бүлмәнең олы тәрәзәсе буенда киң, озын бер өстәл. Өстәлнең тәрәзә ягындагы почмагында яран гөле кызыл чәчәк ата. Өстәл артындагы урындыкта буй-буй сызыклы матрослар тельняшкасы кигән берәү утыра. Маңгай чәче коелган. Түбәсенә кадәр тап-такыр. Калын иреннәре кысыла төшкән. Уйга чумган, күрәсең. Чиста итеп кырылган яңакларына, бит алмаларына алсулык иңгән. Коңгырт күзләре эзләнүчән. Терсәгенә кадәр сызганган кулларына логарифмик линейка тоткан. Нәрсәдер исәпли. Өстәл кадәрле ялтыравыклы кәгазьгә нииндидер катлаулы сызым сызылган. Аска: «Яшь галим» дип язып куйгансың, кызым!

— Әнәс абыең бит бу!— диде әтиең рәсемне күреп.

— Әнәсен Әнәс тә, бөдрә чәче кая?

— Әни! Чәч коела ул, я агара,— дидең син, кызым.— Әле генә бөдрә ул. Картайгач менә шулай калачак... Нигә, Әнәс абыйга батмыймы чәчсез...

— Болай бик килешле дә, кызым, Әнәс абыең үзе күргәч, чәчсез калдырган димәсме?!

— Әти, бу портрет бит. Өстенә карап язмаган, әз генә фантазия куштым инде. Миңа менә шулай кебек тоела ул...

— Мин, кызым, сиңа Мәскәү профессоры турында сөйлим әле. Әтиең яшендә. Чәче дә коелмаган, күзлеге дә юк, үзе яшь-яшь. Чәчен ясасаң ни була иде соң?

—Ул, әни, фотокопия була. Андый әйбер конкурска бармый.

Сүз бу якка авышкач, мин бәхәсләшмәдем. Шахта сызымы булса, әлбәттә, мин тиз генә бирешмәс идем. Үн төрле вариантын сызып күрсәтер идем.

«Яшь галим»нең фоторепродукциясе шәһәр газетасында басылып чыкты. Астына: «Гөләрия Яруллина эше» дип язылган иде.

Шул рәсем сине училищега алып керде.

Габбани көлә. Безнең «Яшь галим» кайларда йөри икән, ди.

Япь-яшь егет килеш Таһир Зимагулов та шахта җирен сагына. Аның көн аралаш хаты килә. Хатларын синең исемгә адреслый, кызым. Син безгә кирәк сүзләрне генә әйтәсең, укырга бирмисең. Бүген телеграммасы килде. «Гөләрия! Уңышларыңа сөенәм. Таһир» дип, дүрт кенә сүз язган. Училищега керүең белән котлаган! Кичәге хатында, Казан авиация институты студентларының төзелеш отрядында Урта Азиягә эшкә китәм, дип язган. Таһир күз алдында кеше булып бара. Инде менә институтның беренче курсын бетерергә өлгергән.

Габбани сменасы «Красный Углекоп» шахтасының игътибар үзәгендә. Әле кайчан гына сменага өч йөз тонна күмер бирсәләр, забойчыларны музыка уйнап каршылыйлар иде. Хәзер җиде йөз, сигез йөз тонна күмер төйиләр. Участокта комбинированный ысулны үзләштерү ныгый бара. «Алдан», щит, лавалар эшли. Забойчылар бермә-бер артты. Һәр забойның үз эш нормасы. Норма тигез каралгач, теләсә кем, теләсә кайсы забойдагы забойщик белән ярыша ала. Урын процент чыгарып билгеләнә. Артык «кызып» китмәсеннәр өчен забойчыларга күз-колак булу да кирәк. Монда ветераннар ярдәмгә килде. Габдрахман абзыйны да забойда очраттым мин бүген. Лавада борт, клетка, сәндерәләрне тикшереп йөри. Бер дә ашыкмый.

— Тарт, забойга хәтле, яхшылап тарт сәндерәңне!— ди бер забойчыга.— Үзең егылмаска әйбәт булыр... Мин дә: очып китсәм, кайда эләгеп калырмын икән, дип куркып йөрмәм...

Мин көлеп куйдым. Лампочка утын күкрәге буйлап югарыга юнәлтте дә бу:

— Кайсысы пырхылдый анда, төш әле монда, төш! Әллә цирк күрсәтәләрме...

— Габдрахман абзый, мин бу, Гөлфәния!— дидем, ничек тә Шахта бабайның ачуын чыгармаска тырышып.

— Син булсаң да төш!..

— Хәзер төшәм...

Менә мин аның янында: көлү түгел, суларга да кыймый торам. Сөмсере коелган бабайның. Забойда эленке-салынкы эшне яратмый ул, белеп торам. Миңа сөйләгән булып, забойчыны битәрли, мине дә чеметеп-чеметеп ала.

— Син— маркшейдер, мин — пенсиядәге карт, әйдә, икәү тартып куйыйк инде бу сәндерәләрне, ә?— ди Шахта бабай, забойчыга яны белән басып.— Ул күмер бирсен. Без аның эшен эшлик. Икенче юлы, син дә, Гөлфәния кызым, забойдан шыелдап кына шуып узып кит! Берни күрмә. Үзләре эшләрләр әле... Николай да шулай узсын, Габбас та, Габбани да... Әтиең белән мин килеп эшләрбез әле. Син күрмә... Ул күреп тә эшләмәсен... Шулай куйыйк мәсьәләне...

— Юк, Габдрахман абзый, мин күрсәм кисәтмичә узмыйм...

— Габдрахман абзый, эшлим мин аны, өлгертә генә алмадым...

Без икебез дә акланырга тырыштык.

Шахта бабай забойны, завал ягын карый-карый, әкрен генә аска шуышты. Шунда бер тын алып:

— «Алдан»да булдыңмы, Гөлфәния кызым, Габбани нәрсә эшләтә анда?— диде.

— Шпурлар бораулыйлар иде, корганнардыр инде, Габдрахман абзый.

— Әтиең андамы? Шунда киләм дигән иде.

— Әти?! Юк! Күрмәдем, Габдрахман абзый...

— Килеп житмәгәндер алайса... Мин шунда киттем. Очрашырга сүләшкән иек...

Шахта бабай сөйләнә-сөйләнә штрекка кереп югалды.

Ветераннар сүзе тау-техника инспекторы сүзеннән дә болайрак. Асфальт юлда шоферлар өчен ГАИ сержантлары сыман... Тау эшләре инспекторы кайчан атнага, кайчан айга бер забойга килә, ә пенсионерлар көн саен... Саклык чарасы күрмичә забойга тотынасы булма! Аларның сүзе шул. Забойда травма алулар да бишләтә кимеде... Үзем дә бер аягымны атлаганчы тирә-юньгә биш карыйм.

...Быелның көзе дә башка еллардан үзгә килә, кызым. Җәй кебек җып-җылы. Сентябрь үтте. Агачлар яфрак коймаган әле. Бер дә Себер димәссең. Әни әйтмешли, Ташкент күчеп киләме әллә? Күз ашыктырмагач, бакчадагы эшләребез дә шул көе. Көньякка күченеп китүче очар кошлар да ашыкмыйлар. Сыерчыкларны көтүләре белән үзем күрдем. Тәрәзә каршындагы тополь кәүсәсенә бәйләп куйган сыерчык оябызга алты-җиде сыерчык килеп кунды. Үзебезнекеләр, җан кисәкләрем... Саубуллашырга килгәннәр... Китүләредер инде...

Уналтынчы октябрьда Габбанига кырык яшь тулды. Көн кояшлы булды. Болыт әсәре кереп кояшны капламады. Янибызда шул кояш нурына коенучы алсу чәчкә булып, кызым, син утырдың. Тьфү-тьфү, күз генә тимәсен. Йөзеңдә матурлыкның, яшьлек нурының арта барган чагы...

***

Кызым, Гөлзрия, кәгазь барысын да күтәрә, диләр. Шулай да бу язмаларны мин туктатырга булдым. Мин аларны этиең авырып яткан авыр һәм хәвефле вакытта алып бардым, үзем өчен яздым. Ә сиңа мөрәҗәгать итеп язуым эшне җиңеләйтү өчен иде. Чөнки язганда күз алдымда гел син дә этиең басып торды. Ак кәгазьгә мин күңелемне бушаттым, кешегә сөйли алмаганны сөйләдем, элегрәк булган хәлләрне, матур тормышыбызны искә төшереп юандым. Шушы шөгыль авыр чакта миңа ныклык һәм түземлек бирде.

Этиең савыгып, безнең арага кайткач, күнегелгән гадәт буенча, язмаларны дәвам иттем. Аның кызык ягы да бар икән: үз тормышыңны кәгазьгә төшерә башлагач, аны икенче күз белән күрәсең, кайбер нәрсәләрне аңлыйрак төшәсең. Шулай да бу эш вакыт сорый, сиңа, этиеңә, гаиләбезгә багышланырга тиешле вакытымны ала иде. Шуңа күрә туктатырга булдым. Хәер, аның хәзер кирәге дә калмады шикелле, инде этиең сау-сәламәт, җимертеп эшләп йөри, күгебез якты...

Шушы арада үзем генә өйдә калган чакта тагын әлеге язмаларны актарып утырдым. Башта яндырырга да уйлаган идем, аннан соң аңладым: мин, үзем дә сизмәстән, анда бик күп күңел җылысы түккәнмен икән. Ул җылының сиңа да барып ирешүен телим. Сиңа, рәссам буласы кешегә, кызым, кеше күңелен аңлап яшәү кирәк. Укыганда бәлки үзең өчен кайбер гыйбрәтле нәрсәләр дә табарсың...

*Җәмит Рәхимов — үзен тулысынча диярлек эшче темасына багышлаган язучы. Ул әдәбият мәйданына алтмышынчы елларда басылып чыккан очерк китаплары белән килеп керде. Аларда сугыштан соңгы авыл тормышы сурәтләнде, нефть якларында барган үзгәрешләр чагылды. «Алтын чыккан җирләрдә», «Кобзарь — Тукай кунагы», «Якташым», «Батырлык чакрымнары» исемле китаплар республикабыз тормышының документаль сәхифәләре булдылар.*

*Бай тормыш тәҗрибәсе, күп һөнәрләрне үзләштерү, нефть һәм газ хуҗалыгы предприятиеләрендә оператор, электромонтер, мастер, инженер булып эшләү, шушы мохиттә яшәү язучыга соңгы елларда зуррак күләмдәге проза әсәрләре язарга мөмкинлек бирде. Аның «Девон хәбәрчесе», «Өлешемә тигән көмешем», «Тәвәккәл таш яра» повестьлары дөнья күрде.*



*Шушы елның январь аенда язучыга илле яшь тула. Без аны әдәбият сөючеләр һәм журнал укучыларыбыз исеменнән котлыйбыз, яңа иҗат уңышлары телибез.*

*Бу санда укучыларга язучының яңа хикәясен тәкъдим итәбез.*

## Җәмит Рәхимов

# БУРЫЧ

**хикәя**



Бик арып кайтса да, бу төндә йокысы йокы булмады Гафурның. Кичке чәйдән соң мич артындагы аралыкка, инде күптән кирәге беткән балалар караватына чумәшеп, изрәп киткән иде китүен. Әмма чирек сәгать тә үтмәгәндер, кемдер зур якның ишеген каерып ачты, нидер карады, эзләде дә, гөрселдәтеп кире япты. Шуның артыннан ук улы Гыйсмәтнең бер дә тартынмыйча сөйләгәне ишетелде:

— Нәрсә, безнең пенсионер йоклыймы? Төшендә дә шул бурычы белән саташа торгандыр әле...

Гомер-гомергә, ире йоклаган сәгатьләрдә шыпыртлап сөйләргә гадәтләнгән Банат улының бу тупаслыгына түзмәде:

— Чү, юньсез, тел тидермә атаңа!— диде.

Шуннан йокысы качты Гафурның. Яңадан оеп китмәмме дип, әйләнеп-тулганып карады, мендәрен дә әйләндереп салды. Аптырагач, торып, ут яндырмый гына чишенде, карчыгы җәеп куйган йомшак урынга — киң агач караватка менеп ятты. Әмма башка көннәрдәге кебек ансат кына изрәп китә алмады.

Ә бит бүгенге йөрүенә караганда, кайтуына урынга аварга, иртәнгә кадәр бер кымшанмый йокларга тиеш иде ул. Шушы мәшәкатьле дөньяда алтмыш биш ел яшәү дәверендә илнең әллә кайсы төбәкләрен таптады, сугышта һәр аягына җәрәхәт алды, аннан соң, нефтьтә эшләгән чакта да, скважиналар арасында бик күп сукмаклар салды Гафур. Шул хәлсезләнебрәк калган аяклары белән язгы пычракта нинә җиде авыл арасын үтте. Кайберләренә юлаучы машиналарга утырып барды баруын. Шулай да күбесе олы юлдан читтәрәк иделәр шул.

Бер уйлаганда, һаман дөнья куып, үзенә мәшәкать арттырып йөрисе юк та бит. Йорт-җире шәһәр читендәге шушы урынга ямь биреп тора — авыл клубы хәтле алты почмаклы йорт, шуңа кушып кирпечтән салынган кухня, курчак өедәй җыйнак абзар-кура. Артта ап-ак чәчәктә утырган алмагач бакчасы! Үзе бер хозурлык, үзе бер куаныч. Учын тутырып пенсиясен ала, исәнлеге дә әле, шөкер, типсә тимер өзәрлек. Тормыш көйләнгән.

Тик менә яхшы тормышның да уңайсыз яклары бар шул. Калада яшәп тә, авыл сыман мал-туар асраучылар белә ул кыенлыкны. Ашату өчен печәнен, саламын хәзерләүне әйтүе түгел, юк. Акчасы барга нәрсә ул хәзерге заманда печән?! Телисең икән, сатып ал. Инде тазалыгың бар икән, скважиналар тирәсендә үзең йолкы, чап, киптер. Кайтаруы да әллә ни мәшәкатьле түгел. Гозер итеп промыселга барсаң: «Ә-ә, Гафур абый!» дип, теләсә кайсы машинаны биреп җибәрәләр. Хикмәт шунда ки, көтүче табуы бәла хәзер. Яз җиттеме, шәһәр кырыендагы терлек-туар асраучы халык хафага кала: каян гына көтүче табарга да, бу мәшәкатьле эшкә кемне генә күндерергә? Инде ни генә уйлап, ни генә кыланып бетмәде поселок халкы. Малларны чиратлап үзләре көтеп тә карадылар. Алай да барып чыкмады. Көтү шимбә яисә якшәмбе көннәрдә генә чыкса, бер хәл иде дә бит, сыерлар көн саен ашарга сорыйлар шул. Халыкның исә күбесе нефтьтә — производствода эшли. Көтүгә чират җитте дип эштән калып булмый ич инде. Аптырагач, зурзур хак вәгъдә итеп, тирә-як авыллардан көтүче ялладылар. Ачуым бер килмәгәе, хакын министр окладына җиткерделәр бит инде, былтыргы көтүченең айлыгы җиде йөз сумнан артык иде. Алай да эшен ахырына кадәр җиткермәде теге, җәй уртасында көтүен ташлап авылына кайтып китте.

Нәрсәсе генә бардыр инде, көтүне алмый бит халык. Электән калган гадәт буенча һаман да түбән эш итеп карыйлар микән әллә. Хикмәт башкада шул, баеды, бөтәйде халык, нинди генә эштә эшләмәсен, мул итеп акчасын ала, сменасы бетүгә киерелеп ял итә. Ул гына да түгел, отпускага чыгып, илнең әллә кайсы затлы төбәкләрен карап йөри. Күрә торып шушы мәшәкатьле эшкә кем алынсын, ди.

Тәмам гаҗизләнгәч, шәһәрдә эшсез йөрүчеләрне эзләп карадылар. Таптылар да. Әмма яңа көтүчеләре я эчкече, я йокысын ача алмаган бер сөрхәнтәй булып чыга торды. Соң инде, Яшел Түбә кебек нефть каласында юньле кеше эшсез ятамы?!

Шушы хафа язның язында килә мал-туарлы халыкка. Быел менә тагы кар эреп бетәр-бетмәс аякка басты урам комитеты. Гафурлар капка төбенә җыелып, кич саен шул хакта киңәштеләр. Олау-олау сүз сөйләнде, берсеннән-берсе хыялый фикерләр әйтелде, булачак көтүчегә елдагыдан да зуррак хак билгеләнде. Тик аңа карап көтүче табылмады. Шуннан пенсионерлардан өч кешене сайлап алдылар да, авылларга чыгарып җибәрергә булдылар. Олы юллардан читтәге ераграк авылларны үзе сайлап алды Гафур. «Ул тирәләргә әле промысел җене кагылып өлгермәгән, халык та акча белән шаярырга күнекмәгән, зур хакка теләүче табылмый калмас»,— дип фикер йөрттеләр.

Карлар эреп, аяк асты былҗыраган чак иде. Юлга дип гадирәк киенде Гафур: промыселдан соңгы тапкыр алып та, эшкә киелми кал-

ган спецовкасын — эшкә кия торган костюмын, май таплары белән бизәкләнгән кәжәнен кидс, көн суыта дип, башына иске бүреген элде. И шулар белән хур булды да. Симун аланы дигән керәшен авылына барып керүгә, урам буй коймасын яңартып яткан бер кеше — очлы иякле, бөтен битен ак төк баскан дәдәй туктатты үзен. Исәнлек-саулык сорашып, бер папирос яндырып җибәрүгә, сорап куйды бит керәшен дәдәй:

— Көтү алырга җөрүең түгелдер бит?

Кинәт кенә башына суккандай, аптырады да калды Гафур: шадра битенә кызыллык йөгерде, тирән-тирән өч буразнадан торган маңгаена тир бәреп чыкты, эчкә баткан күзләрендә уртәлү очкыны ялтырап китте. Керәшен дәдәй үзен юри котыртадыр сыман тоелды аңа.

Шаяртмый икән, битен ак төк баскан бу агайда да шул кайгы икән. Симун аланы халкы да елның елында көтүче таба алмый аптырый булып чыкты. Көнозын шушы хакта сөйләшеп йөри торгач, мәгълүм булды: бу эшне чын-чыннан яратып, гомере буе көтү көтүчеләр дә бар икән авылларда. Тик алары да хуҗалык көтүен түгел, колхоз-совхоз малларын алалар икән. Нигә дисәң, колхоз-совхозлар аңа, хезмәткә түләүдән тыш, утынын-печәнен хәзерләп бирә, кирәк икән, яңа өй дә салып кертә.

Өметсезләнеп, күңелсезләнеп, ут алганда гына кайтты Гафур калага. Тәмам арып-талчыгып, каефсезләнеп үзләренең урамына килеп кергән генә иде, каршысына кордашы Ясәви очрады. Гафур кебек үк дөнья күргән пенсионер ул Ясәви. Бизмәнгә салып карасаң, Гафурдан артыграгын да күргәндер әле. Гафур да гизде дөньяны гизүен: Донбассында да булды, Себердә дә, Төньякта да. Мәгәр үз теләге белән йөрде, йөрәге кушкан җиргә барды. Ясәви исә кәбестә шулпасының сыеграгын эчкән бугай — заманында нинди дер хилафлык эшләп ун ел утырып чыккан, ерак тайгада урман кискән. Ирекка чыккач та туган якларына кайтырга ашыкмаган, өйрәнгән, күнеккән җирендә зур акча алып эшләгән, пенсиягә чыккач кына бу якларга кайтып төпләнгән. Акчаны карчыгы Мәһирәнең иске оек балтырына төеп тутырып кайткан, дип сөйлиләр. Хак сүздер, Яшел Түбәгә килеп төшүенә, бораулау идарәсендә баш бухгалтер булып эшләгән Кәрамның чиркәү кадәр өен сатып алды, гараж салды, аңа сөт төсле «Жигули» кертеп бикләде. Үзе гомердә рульгә утырасы булмаса да, модадан калмыйм, диюедер инде. Озак еллар буе казна шулпасы чөмереп, салкын якларда эшләвенә, яшәвенә карамастан, чиертсәң каны чыгарга торган йөзле, киң җилкәле, карсак кына бәндә үзе. Кешегә тиз генә ачылып китмәс, бусагасыннан теләсә кемне атлатмас, йомык, серле кеше. Тормыш юлы карарак, шик-шөбһәлерәк андый бәндәләрне өнәп бетерми Гафур. Әмма дөнья булгач, шуларның ишеген шакырга да туры килә икән. Әнә бит бүген дә, каршыга килеп җитүе булды, исәнлек-саулык сорашу юк, көтүче кайгысы юк, һич көтмәгәндә әйтеп салды бит:

— Бурыч ничек, Гафур күрше!

Моңа каршы ни диярга дә белмәде Гафур, җавап сүз таба алмыйча аңгыраеп калды, шадралары кызарды, маңгай буразналарында тир бөрчекләре күренде.

— Тагы берәр ай булса да сабыр ит инде, Ясәви туган,— диде ул, бар сабырлыгын, көчен җыеп.

Шул очрашу, һич көтмәгәндә әйтелгән шул бер авыз сүз исенә төшеп, йөрәген кузгатып җибәрде. Хәзер көтмә инде йокы дигәнне. Болай да тынгысыз йөрәккә җитә калды. Гафур урыныннан кубып, кием шкафы янына килде, балалар күрмәсен дип, иң артка — карчыгы Банатның үтүкләп куйган чүпрәкләре астына ук яшереп куйган «Север» пачкасын капшап тапты. Янә караваты янына килде, тәрәзәне сыза гына ачып, папирос кабызды.

Я инде, ни дип бурычка керде шул комсыз Ясәвигә? Их, бар иде аның үзе кебек саф хезмәт юлы үткән кордашлары! Мәгъсүмнәр, Андрейлар бар иде. Биш йөз сум акчадан тора торган кешеләр идемени. Кирәк икән меңен дә биреп торган булырлар, биш ел узса да, «әҗәт» дип авыз ачып сүз кушмаслар, үз җаең белән китереп биргәнне көтәрләр иде. Иртәрәк китеп бардылар шул. Һаман да әлеге сугыш галәмәте инде, яз-көз җитте исә яралары кузгалып сызланалар иде, бахырлар. Ә бу куркуль тыңгы бирмәячәк болай булгач, әнә ич: «Кара аны, Гафур күрше, суд бусагасын таптарлык ясама»,— дип калды. Акча биргәндә юкка гына имзалык сорамаган икән. Уенга исәпләп кенә язып биргән шул язуны матчасына кыстырып саклыйдыр әле. Иллә дә сабырсыз кеше икән. Дүрт айга биш-алты тапкыр искә төшергәндер инде. Шулай да бүгенге кебек үк аяк терәп сораганы юк иде әле...

Гафур тәрәзәне киереп ачты да, сүнгән төпчеген сәрви агачлары арасына чиертеп җибәрде, аннан юрганын башыннан ук бөркәнеп тагын ятты. Йокы алмый аптыраганда гел шулай итә ул. Тик бүген алай ятуның да файдасы тимәде, башы тәүлек буе йоклап торган кешенекедәй аек иде.

...Яңа ел якынлашып килгән көннәр иде. Шимбә кичләренең берендә улы Гыйсмәт бәләкәй генә буйлы, тузгыган башлы бер кыз ияртеп кайтты. Йөрәге әллә нишләп китте Гафурның «Өйләнергә йөрүе микәнни?» дигән уй үтте башыннан. Моңа кадәр бер дә сүз кузгатканы юк иде ләбаса. Шул мизгелдә үк уйлап та алды. Өйләнсә ни, бик вакыт. Солдаттан кайтканына ел була инде. Буе дисәң буе, чибәрлеге дисәң чибәрлеге бар. Нишләп дуадак каз кебек каңгырып йөрсен әле ул?! Әнә бит башы матчага тияргә тора, җилкә дисәң, әтисенеке кадәр икә. Озынрак чәчен артка тарап салган да, кабартма иренле авызын ерып тора. Яратадыр шушы курчакны, әнә бит зур көрән күзләрен алмый шул нәмәрсәдән. Вакыт, бик вакыт. Өйләнсен генә. Малайны башлы-күзле итәргә дип, күптән кассада саклап тоткан акчасы да бар. Ил-күз алдында хурлыкка калмаслар, боерган булса.

Карчыгы Банат эшнең нидә икәнен иреннән алда сизенгән, күрәсең, каушый төшеп, болай да гөлт итеп торган өстәл өстен сөртеп алды, зур яшел чәйнеккә краннан су агызып, газ плитәсе өстенә куйды, буфеттан конфет-хәлвә ише нәрсәләр чыгара башлады. Гафур исә нишләргә белми аптырап калды, сүз башлар иде, улыннан узып бу хакта тел тибрәтергә базмады. Эш юктан эш дигәндәй, башкаларга сиздермәскә тырышып кына, булачак киленне күзәтергә тотынды. «Кечкенә дә — төш кенә, дигәндәй, үзе чибәр нәрсә булырга охшый»,— дип фикер йөртте карт. Болай да бәләкәйдән булмаган күзләре сөрмә тартканлыктан тагы да зур зәңгәр, тирән булып күренә. Печтеки генә почык борыны да үзенә килешеп тора. Елмаешкан алсу иреннәре арасыннан тыгыз ак тешләре күренә. Матурын матур да бит, характеры ничектер әле. Әнә күршедәге Сарбаевның килене дә чибәр, кычыткан чыпчыгы кадәр генә. Шулай да ирен дә, каенатасы белән каенанасын да гармунсыз биетә.

— Менә, әти, танышыгыз, Эмма була бу. Минем дус кыз,— диде Гыйсмәт, әтисе белән әнисенең аптырашып торуын күргәч.— Педучилищеда укый, икенче курста.

Яшьләр өйләнешү турында сүз кузгатмадылар, шаяра-көлә чәй эчтеләр дә, киенеп-ясанып, киногә дип чыгып киттеләр. Алар артыннан ишек ябылуга, сорап куйды Гафур:

— Сиңайтәм, Гыйсмәтнең кәләше маржа-мазар түгелдер бит?

Картка аны-моны сиздермәсәләр дә, Банаты барысын да белә икән.

— Буламы соң. Өммегөлсем атлы бала,— дип куйды Банат һәм кабат өстәлен җыештыра башлады.

Башка сүз булмады. Кызның егет өенә тикмәгә генә килмәвен яхшы белсә дә, бу вакыйгага артык игътибар итмәде Гафур. Беткәнмени: үпкән-кочкан — җилгә очкан.

Шулай да икенче көнне иртән улына әйтми түзмәде Гафур:

— Чын-чынлап башлы-күзле булырга уйласаң, бик тә сабыйга йөз тоткансың, улым. Җитмәсә, укый диден бугай.

— Ул хакта сөйләшергә соң инде, эти,— диде Гыйсмәт, гадәтенчә тупасрак итеп.— Без инде язылыштык.

Менә сиңа иске авыздан яңа сүз. Бу ни булып чыга инде? Киңәш юк, сөйләшү юк, тот та өйлән, имеш. Эченнән генә шулай тиргәнде Гафур, ләкин кайтарып сүз әйтмәде. Хәзерге яшьләр шулайрак шул инде, бер бездән генә калмаган. Шулай да:

— Туй-мазар ясый торгансыздыр бит?— дип сорап куйды.

— Яңа ел кичендә дип әйттем.— Бетте-китте дигәндәй, Гыйсмәт өйдән үк чыгып китте.

Эшләрен бетереп, Банат та бу якка керде, аяк очларына гына басып карават янына килде, юрганны ачып, песи сыман гына ире янәшәсенә елышты.

«Йокларсың монда»— дип куйды Гафур эченнән генә, иртә таңнан сыерыңны куарга көтү булмасын, урамга чыгуыңа Ясәви: «Бурыч ничек», дип теңкәсенә тисен. Бөтен туган-тумачалары, якыннары ни әйттеләр: «Бетер инде сыерыңны, Гафур, җәфаланма, кибеттә мае, сөтекатыгы бар ич»,— диделәр. Тәки тыңламады бит шулар сүзен. Әй, алар соң ни белә? Ишегалдында, абзар-кура тирәсендә сыер исе аңкып тормагач, тормышның ни яме? Аннан соң бакчага тирес тә кирәк бит әле. Акчага да таба алмыйсың аны хәзер, кадерен беләләр авылда ашламаның.

Менә изрәп китәм, менә онытылам дип ятканда миенең әллә кай җирендә тагы туй мәшәкатьләре кузгалды. Йокысы шундук ачылып, тәмәке тартасы килгәндәй булды, папиросын үрелеп алып, яндырып җибәрмәкче иде, карчыгын уятудан шикләнеп, ниятеннән кире кайтты. Аркасына әйләнеп ятты да, күзләрен тәрәзәнең зур өлгесенә, пыяла артында сизелер-сизелмәс кенә чайкалган ботакларга төбәде.

Туй дигәннән, аның үзенә туй шау-шуын татырга туры килмәде. Әй, ул кара сугыш елларында туй кайгысы идемени. Ерак Төньякта ашыгыч рәвештә салынып яткан тимер юл төзелешендә эшли иде ул чакта Гафур. Шунда үзе кебек үк туң җир чабып йөрүче Банат белән танышты. Ах-вах итми, «сөям» дип вәгъдәләр бирми генә бер-ике ай йөрделәр дә, бер көнне эштән соң Гафурның бараактагы бүлмәсенә бергә кайттылар. Саргылт гәзит кәгазе өстенә икесенең паек ипиен турап салдылар, иреннәрен пешерә-пешерә алюмин кружкадан кайнар су эчтеләр. Өлкән улы Мисхәт белән кызлары Гөлсинә дә зур расходлар чыгармыйча, ничектер тыныч кына башлы-күзле булдылар. Кешедән ким яшәмиләр тагы, гөр итеп бишәр бала үстереп яталар.

Хәзер шул заман башка. Зур туй ясап, шау-гөр итеп өйләнешәләр яшьләр. Карап-карап торганы бар, дүртәр-бишәр машина белән төшерәләр киленне. Гафур алай ук зурдан купмас кубуын, шулай да тирәкүрше, туган-тумача каршында сер бирмәскә иде исәбе. Шуңа да, Гыйсмәт өйләнсә дип, саклык кассасында җиде йөз сум акча тотты. Нинди генә кыен чагында да, кагылмады ул акчага. Тузылыр сәгате шушы ел башында суккан икән.

Бер көнне яшьләрне каршына утыртып сорады Гафур:

— Туйга кемнәрне вә күпмерәк кеше чакырабыз, улым?

— Мин барлык дус-ишләрне дәштем инде,— диде Гыйсмәт, бер дә исе китми генә.

— Бик әйбәт, бик әйбәт,— диде ата, улының кинәшсез эш итүенә хәтере калуын йөзенә чыгармаска тырышып.— Дус-иш дигәннән, алар икәү-өчәү дә, унау да була...

— Минекеләр илледән ким булмас.

Монысына да аны-моны әйтмәде Гафур, киленнән дә туган-тумачаларын, якыннарын чакырырга кирәклеген күздә тотып, Өммегөлсемгә борылды:

— Синең яктан кемнәр булачак инде, кызым?

— Минем әти-әниләр еракта, Түбәндә үк, килеп йөри алмаслар,— диде Өммегөлсем, йөзендә борчылу әсәре сиздермичә.— Мин дә шул дус-ишне, группадагы студентларның барысын да чакырдым.

Шуннан телсез калды Гафур. Менә сиңа мә! Болай булса, җиде йөз түгел, мең дә җитмәс боларга. Әле бит туган-тумачаларны да дәшми ярамас. Баш түбәсендәге пеләшен кулы белән ышкый-ышкый озак уйланды Гафур, карчыгы белән дә киңәште. Әмма «Әҗәткә алып торырга кирәк» дигәннән дә яхшырак карарга килә алмады. Шулаен шулай да, тик кемгә кагылырга? Белә Гафур, өлкән улы белән кызында запас акча юк. Ике семьяга бер дистә бала үстереп яталар, үзләре килеп егылмаса бик шәп инде. Бергә эшләгән кордашларыннан Андрей белән Мәгъсүм дә узган ел аллы-артлы үлеп киттеләр. Әҗәткә зур сумма сорап теләсә кемгә ничек кагыласың инде? Шул рәвешле озак баш ватканнан соң шакыды ул Ясәви ишеген.

Туйдан тукмак та калмый, диюләре хак икән. Җыелды кеше, җыелды. Чакырылмаган егетләргә хәтле килде. Өйнең ике ягындагы бөтен әйберләрне чыгарып, тирә-күршедән җыеп өстәлләр тутырырга туры килде. «Бер кичкә, кер мичкә» дигәндәй, анысына түзделәр инде. Кунакларның әрсезрәкләре икенче, хәтта өченче көнне дә китми йөдәттеләр бит әле.

Чыдады, барысына да чыдады Гафур. Әйдә, гел-гел туй булмый, әкрен генә бар да җайланыр, бурыч та түләнер, дип фикер йөртте. Ләкин әҗәт дигәнең түләнергә ашыкмады. Үзе эшләгән чагындагы кебек көрәп премияләр алмый шул. Дөрес, экскаваторчы булып алганнан бирле акчаны мул төшерә Гыйсмәт — ике йөз илледән дә ким чыкмый. Ике ай эшләгәнен керт тә бир Ясәвигә. Тик әҗәткә исе китми Гыйсмәтнең: гыйнвар аенда хатынына затлы пальто күтәреп кайтты, аннан өйдәге мебельләрне яңартасы итте. Өйләнгәнче ни әйтте үзенә, аз-азлап булса да кассага сала бар, диде. Тыңламады бит, үзе киендә һаман. Җитмәсә, чуртыма кирәкмәгән япон магнитофоны сатып алды. Менә йөр инде хәзер уынып.

Түзде-түзде дә, малай үзе аңламагач, сабыры төкәнде Гафурның, иртәгә акча аласы кичкә сүз катты Гыйсмәткә:

— Әҗәтне түлисе иде бит, улым?!

— Долг не волк, в лес не убежит,— диде Гыйсмәт русчалатып. Әллә чынлап әйтте, әллә шаяртты.

Юк, шаярмаган ахры, бурычны түләү хакында авызын ачып сүз кузгатмый. Соң ни уйлый икән бу башсыз? Ничек соң әле болай гамьсез булып үсте бу малай.

Сабырлыгы калмады Гафурның, карчыгын бимазалап булса да, урелеп тагын папиросын алды, ачык тәрәзәгә нелеп, шырпы сызды. Тәк, нишләргә кала соң әле? Иртән иртүк Гыйсмәт белән ныгытып сөйләшергәме? Алай итсә кызып китүеннән курка. Йөрәге бер җилкенсә, үзен-үзе тыя алмый торган гадәте бар. Әллә ниләр әйтеп ташларсың,

тиле. Яшь килен алдында җәнҗал кубарып, көлкегә калуың бар. Файдасы тисә бер хәл иде әле. Сөйләшсәң дә, тавышлансаң да, нәтиҗә булмаячак ич. Өченче көн генә кемнәндер өч тәгәрмәчле мотоцикл сөйрәп кайткан, юньсез. Җитмәсә, җиде йөз сум ди бит шул иске нәмәстә. Вәт башсыз, ни кылана. Аңардан сорашмый шул Ясәви, һаман синең җанга тия. Да-а-а, болай булгач тынгы бирми инде ул, өйгә үзе үк килеп йөдәтә башлар. Шуннан эшне килен дә сизми калмас, күңелсезлек китәр. Нишләргә соң? Кияү белән олы малайга сугылыргамы? Булмас, бала үстергәндә каян килсен аларга запас акча, хәләл хезмәт хакына гына яшиләр бит.

Тышта күзгә күренеп яктырды, ачык тәрәзәдән салкын томан керәп, тәнне чиркандыра башлады. Гафур абзый тәрәзәне япты да, кабат мендәренә ауды. Күңелсез уйлары исә таралмады да таралмады. Шулай борсаланып күпме яткандыр, кисәк кенә уена килгән фикердән сикереп торып китә язды. Туктале, бар бит ул әҗәтне кайтарып бирерлек акча! Аны ансат кына алу юлы да бар! Урам комитеты председателенең сандыгында ята ич ул акчалар. Тәвәккәлләргә генә кала. Нигә? Көтү көтүнең ни гаебе бар, хәзер ул абруйлы эш. Җитмәсә, берьюлы ике куян ата: бердән, көтүче табыла, халык иркен сулап куя, икенчедән, Ясәвинең бугазы тыгыла. Аннан сәламәтлек өчен файдасын әйт әле син аның. Кайчан йөрер идең көнозын сахрада!

Иртән, автобуслар беренче рейска чыкканда, кулына өч-дүрт метрлы резин шланг тоткан Гафур ишле генә көтүне шәһәрдән басуга, кайчандыр үзе эшләп йөргән скважиналар рәтенә алып чыгып китте. Бу вакытта әле күпләр уянмаган, шул исәптән улы Гыйсмәт белән килене Өммегөлсем верандада саф һавада изрәп йоклыйлар иде.

Камил Кәримов

# КӨЗНЕҢ СОҢГЫ ТӨНЕ

хикәя



Солдат, туган авылына кайткач, иң әүвәл югары очтагы сөйгән кызының өй каршыннан үтеп китә. Кайтуы турында хәбәр тизрәк таралсын дип, ике урам чатындагы бердәнбер кибеткә дә килеп керә. Кибет ишеге төбендә: мин сине таныйм бит, дигәндәй, каравылчы Сиражи абзыйның кәҗә хәтле эте өреп кала. Көндез һәркемнең дусты да ул, төнлә генә менә туганнарын да танымаганга сабыша, берәүне дә кибеткә якын китерми. Сиражи абзыйны бу эткә исеме белән дәшми диләр,— башкалар отып калмасын, янәсе. Юкса, исемен бик матур итеп әйтсәң, эт халкы дошманына да койрык болгый, имеш.

Солдат үзенең җыйнак һәм тыйнак хатында: иртән өябез, көндез төзәбез, кич йөгерәбез, төнлә сакта торабыз дисә, һич икеләнмәгез — улыгыз стройбатка эләккән. Чик буенда хезмәт итүчеләр, туган авылларын сагынсалар, көтмәгәндә генә берәр батырлык эшләп күрсәтәләр дә ун көнлек ял алалар. Ә стройбатта хезмәт итүче егетләр авылны сагынса, кайтып күрергә теләсә, икеләтә күбрәк өяргә, тизрәк төзәргә, җитезрәк йөгерергә, сакта уяурак торырга тиеш була.

Салих та авылын бик сагынып кайтып килә. Солдат кеше иң әүвәл туган авылын, икенче булып әнисен, аннан әтисен, дүртенчедән әби-бабасын сагынырга тиеш. Йоласы кушканча инде. Тик, сер итеп кенә әйтсәк, солдатка иң кадерле нәрсә әнисе, аннан туган авылы, аннан кала сөйгән кызы, шушы тәртипчә әтисе, әби-бабасы һ. б. Салих авылга кайту белән сөйгән кызының өй турына килгән икән, монысын инде һәркем үзенчә аңласын.

Бер ел гына түгел, гомер буе югалып торган диярсең, капкадан керүгә, үзгәрешләр көтеп, күз карашы белән кая барып бәрелергә белмәде Салих. Бар да искечә. Капкалар чүгеп, ишегалды бераз тарайган сыман, чуар тана бозау ияртеп йөргән була, алмагачлар иңгә киңәйгән, миләшләр буйга күтәрелгән, ботакларында шул ук, узган елгы чыпчыклар — берән-сәрән очып төшкән соңгы яфракларны кызганып утыралар.

Самавыр каршысындагы рамда элек ике солдат рәсеме иде, хәзер бабакае белән әтисе янына Салихның фотосын да куйганнар.

— Салих, улым, кайтып җиттеңме?— дип, әни кеше үзенең «сабыен» кочаклап алды. (Маңгаенда җыерчыклар арткан бугай.)

— Хәзер Армиягә кайтмаска дип китү юк,— дия-дия әтисе белән дә кул кысыштылар.

— Урыныңа ышанычлы кеше калдырдыңмы, Салихҗан? Син анда чакта тынычлап йоклый идем!— Бабакай «бәләкәченең» чәченнән сыйпады.

Самавыр янында: әйе, юк, белмим, соңыннан сөйләрмен әле, дип утыра торгач, ун көнлек ял тагын ике сәгатькә кимеде. Салих нәрсәдер исенә төшеп, кинәт кенә «смирно!» басты. Әнисе нидер сизенеп:

-— Ашыкма инде улым, кояш та баемаган бит әле,— дигәч, Салих:

— Урамда баетам мин аны,— дип, ашыгып чыгып та китте.

Көннәр суынып, әрәмәлек, җәйләү-болыннарга кар сарылгач, авылда җыелып күңел ачу урыны бер җирдә генә кала — ул да булса, ике бураны кушып салган агач клуб. Кысан дигән кеше юк, яше тулып өйләнешүчеләрдән урын бушый, аларга алмашка мәктәпне тәмамлаучылар өстәлә тора. Гел шулай...

Көзнең кышка отчет биргән чагы. Пыр тузынып йөргән кар бөртекләре кичке салкында түбәләргә, бүрәнә өсләренә, агач кәүсәләренә куналар. Көзнең соңгы киче шәме янып беткән бүлмә эчедәй караңгыланды. Рәсем-мазарда күрсәләр, көзге төн диярләр иде моны.

Уң кулың сул кулыңны табалмаслык, караңгы төшсә дә, Салих Дилбәрне эзләп тапты әле.

— Бер ел буе үпкәләшеп йөргән кеше төсле булдык, күрешеп сөйләшә алмагач...— дип башлады сүзне Салих.

— Хат языштык ич.

— Хат нәрсә ул? Тукта, мин әйтәм, Дилбәрем көтә белә микән, кайтып белим әле.

— Белдеңме инде?

— Белерсең сине. Армиягә хәтле дә борын чөеп йөрдең.

— Үзең ич, өйләнергә йөрдең дә курыктың. Башта хезмәт итеп бетер, мин беркая да качмам. Карале, Салих, ул стройбат дигәнең берәр төзелеш конторасымы соң?

— Хәрби сер!

— Абау. Мылтык тотарга өйрәтәләрме хет? Әллә кулыгыз кирпечтән бушамыймы?

— Өлгерәбез, тегесенә дә, монысына да.

— Авырмы?

— Бер өйрәнгәч әллә ни түгел. Ике ел үтә дә китә ул. Менә безнең бабай патшага егерме биш ел хезмәт иткән әле.

— Шул тазалыгы белән йөз дә ун яшькә җитә алды да инде.

— Мин башкасын әйтергә теләгәнием, бабайны әбиебез егерме биш ел көткән дип... Әни әтине биш ел көтеп торган, нинди еллар дигән әле!.. Ә менә мине нибары ике генә ел көтәсе.

— Кирәксә, артыграгын да көтәрбез анысы, исән-сау кайт кына.

Шушы сүзләрдән соң ничек инде таң атканчы йөрмәскә?!.

Дөрес, таңны каршылау дигән сүз ул җәйдән калган нәрсә. Көз көне шәфәкъ белән таң арасы эш көне кадәр. Тик бүгенге очрашуның вакытта гаме юк.

Көзге төннең миче ягылмаган, бер урында гына басып торсаң, Дилбәрне туңдыруың бар.

Авыл чите иркен лә ул, теләсәң күпме гашыйкны да сыйдыра. Көзнең уңышы амбарларга күчеп бетте. «Кавышырбыз» дигән вәгъдәләрнең үтәлер чагы. Парлар-ярлар бер-берсенә чытырдап ябышкан, тыкрык саен алар, өянке куләгәсеннән дә килеп чыгалар, инеш ярында да чүкердәшәләр. Егетләр — ярсу, кызлар — иләс-миләс.

— Я, нихәл яшәп ятасың, мин югында бик күңелсез булмадымы?— диде Салих, сүз уңае гына Дилбәрне шинеленең сул канатына төреп.

— Бик күңелле яшибез. Ишетмисеңмени?! Тыңлап кара...

Чынлап та авыл урамы тынычлыгын җуйган, әле бер, әле икенче яктан җыр ишетелә, кушымта рәвешендә генә хәтәррәк сүзләр дә өстәлә.

— Әллә көн саен шулаймы?

— Бүген колхоз акча өләште, получка. Ышанасыңмы, юкмы, кассир: «Бүген колхозчылар уникe мең сум акча алдылар»,— дип әйтә ди, кичкә инде кибетебездә байтак аракы сатылган.

— Мин киткән арада бөтен авыл эчүгә сабышмагандыр ич?

— Туйлар вакыты. Быел кияүгә чыкмаган кыз калмый да бугай инде.

— Син дә китеп барма тагын.

— Кеше ярлары кемгә кирәк?!.

— Дилбәр, кайнар кеше син, баскан җиреңдә кар эри.

— Һи, җүнләп яумаган карың белән.

— Явачак, бүген көзнең соңгы төне, аннан кыш башлана. Язы да җитәр, җәе дә үтәр, бөтенләй кайтыр чагым да җитәр.

Йолдызларны болыт йотты, күк йөзе ябык, баш очында гына карлы-буранлы кыш эленеп тора сыман. Җилләр ашыгып-ашыгып авылның төньягыннан көньягына суык кучереп йөри, алар күбрәк искән саен шинель канаты Дилбәрне ныграк кыса.

Этләр өрә дә, капкалар ябыла, Дилбәр аларны барлап тора.

— Рәшидәләр капкасы... Сәрия дә кереп китте... Төне суык булгач, Тәнзиләне дә озак тотмадылар... Минзифалар йөри әле. Әниләренең рөхсәте юк икән, туйны язга калдырырга кушалар ди, үгетли-үгетли кызны туңдырып бетерә инде. Әһә, әнә алар да хушлаштылар. Урамда без генә калдык...

Дилбәрнең соңгы сүзләре суыктан калтырабрак ишетелде. Сагынган күңел сусавын басар өчен барыбер көзнең соңгы төне генә җитмәс. Алда әле, икәүләшеп аттырасы таңнар — җылы таңнар! Авыл тирәли җиде тапкыр әйләнеп, Дилбәрләрнең бакча турысына килеп җиткәч, адымнар әкренәйде, әйтер сүзләр түгәрәкләнде, иреннәр җылынды... Дилбәр шинель эченнән Салихның куен җылысын алып китте.

Эт өрде, капка ябылды.

Армиягә киткәнче булса, Салих хәзер: бүгенге салкынны да җиңдек дип, үкчәсе пәлтә итәгенә тигәнче өй җылысына чабар иде. Иренмәгән кызлар мәзәк өчен генә бер сынап карасыннар: егетләре капканың теге ягында калгач нишләрләр икән?.. Ләкин Салихка килешеп бетмәс шул, ни дисәң дә солдат кеше, үзенең кемлеген һәр адымында тоярга тиеш!

Авылның яртысын үтеп, ике урам арасындагы мәйданга җиткәч, Салих кибет тәрәзәсендә шәм ялкыны кадәр генә ут шәүләсе күреп алды. Ай яктысында әлеге шаян ут кисәге бәлки сизелмәс тә иде, ләкин төн чем-кара, очкын гына чәчрәсә дә күрше авылдан күренерлек. Салих туктап калды, атласаң да саграк кыланырга кирәк. Шул чак бабакаеңның үгет-нәсихәтләре искә төште: «Дошман күрсәң, артыңа карап өлгер — камалышта түгелсең микән?» Юк. Тирә-як тып-тын, кеше-кара сизелми, димәк, кибет тәрәзәсендә ялт иткән нәрсә каяндыр килеп сирпелгән фонарь яктысы гына түгел.

Нишләргә? Иң якындагы өйгә барып әйтер идең, кем белә, бәлки ялгыш күренгәндер. Ул чагында иртәгә үк бөтен авыл, авылга кушылып Дилбәр дә көләчәк үзеннән.

Салих кибеткә терәп салынган такта сарайга килеп сыенды: күз-колакка чалынырлык хәрәкәт сизелми. Ул стена буйлап ишек ягына елышты. «Хәвеф каршында коралсыз калма»,— ди торган иде коман-

дир. Кесәдә пәке йөртә торган гадәте юк, кул чыныктыргыч резина гына бар. «Учыңа шырпы кабы кадәр генә нәрсә кыссаң да, йодрыгың биш килоға авыраячак»,— дия идең, рәхмәт, иптәш командир!..

Салих кибет ишегенә шулкадәр якынайды ки, хәтта бөҗрага эленгән асылмалы йозак та беленерлек иде инде. Димәк, ишек тә бикле. Получка юган агайлардай, туган йорт җылысына ашыксаң да ярый иде дә... ләкин төненә күрә күңелнең тынгысыз һәм сизгер чагы. Әтиең нәрсә ди: «Күзеңә ышанмасаң, тыңлап кара, колагың алдаса, кулың бар...» Әйе шул, кибет эчендә сөйләшәләр! Бәлки тынып торулары да Салихның аяк тавышларын ишеткәннәндер әле.

«Ниткән кеше йөрсен бу вакытта, әйтәм ич, бу авылның этләре күп...»

Шушы минутта Салихны бабакае, әтисе, командиры — өчесе бер булып күзәтеп торалар, киңәш бирәләр төсле:

«Ышанычлы урынга урнашмыйча, дошманга үзеңне сиздермә... Кирәккә-кирәкмәскә күкрәгеңне утка куярга ашыкма, дошман синең гомереңхакына тормый ул... Үзеңне соңгы мизгелгәчә сиздермәскә тырыш...»

Салих инеш ягына караган стена буенча китте. Һәм ни күрсен! Аяк астында каравылчы Сираҗи абзыйның эте хәрәкәтсез ята иде. Менә ни өчен өрмәгән икән ул. Агулаганнар! Ә Сираҗи абзый, этенә ышанып, кайдадыр йөри бугай, бар аның ул гадәте. Авыл җирендә төннәр тыныч ди торгандыр инде.

Кибетнең бер почмагы «авызын ачып тора», бүрәнә арасын домкрат белән каерганнар да кибет эченә юл салганнар. Моннан эчтәге сөйләшүләр дә ныграк ишетелә:

«Әллә каян эзләп азапланма, шикәр капчыкларын селке, беләсең ич инде, гадәттә шунда яшерәләр алар».

Болар акча эзләп интегәләр икән. Дилбәр байтак сумлык сатканнар дигән иде, ул кадәр акчаны икәүләп эзләсәң дә таманга туры килә шул, мал белән мавыгып, домкрат янында сакта калырга да онытканнар.

Домкратны кул белән генә күтәреп булмый, монтажкасы да бардыр... Әйе, ул да урынында. Инде һөҗүмгә күчәргә вакыт.

Салих ювелирларча төгәллек белән домкратта калган монтажканы тартып алды. Хәзер домкратка шундый итеп сугарга кирәк — бүрәнә арасына кысылган җиреннән атылып чыксын да, кибет почмагы авызын япсын. Һәм бер генә сугарга, икенче тапкыр кизәнергә өлгермәссең. Кибет эчендәгеләрнең кулында ни барын кем белгән?!

Домкратның очып төшүе булды — бүрәнә арасы олы капкын булып гөрселдәп ябылып та куйды. Эчтәге ләгән шалтыраган тавышлар, сүгенүләр, стенага тибенүләр Салих өчен бер мәлгә мәзәк тоелды, рәхәтләнеп көләсе килде. Ләкин һәртөрле мәзәк кыска булырга тиеш, ә бүгенгесе озаккарак сузылырга охшый. Караклар эчтә калды. Шуннан?! Хәзер нишләргә? Ярдәм өметләнеп берәрсенә йөгереп килсәң — өйләрнең иң якын дигәне дә моннан илле метрлар бардыр. Җитмәсә тәмле йоклы вакыты, тәрәзәләрен шакып йокысыннан уятканчы, хәлне аңлатканчы... караклар әллә кай төштән чыгып сызарлар — куып тот аннан син аларны... Кычкырыргамы? Кем ишетсен, тәрәзәләр ике катлы — кышны көтәләр. Ишетеп уянганы да исерекләр авазы гына дип, икенче ягына борылып ятар. Аннан соң, солдат егеткә «Каравыл!» кычкыру килешмәс тә, бәет чыгарулары бар. Киңәшләре колак төбендә ишетелеп торган бабакае, әтисе белән командиры да әллә кая гына юкка чыккандай булды, гүя без сине күп өйрәттек инде, үз башыңа төшкән сынауны ничегрәк үтәп чыгарсың икән диләр.

Чара бер генә: Салих каракларны качырмыйча төне буе кибетне каравыллап чыгарга тиеш, таң аткач берәр әмәле табылыр әле. Сәгатьнең якты циферблаты төнге берләр тирәсен күрсәтә. Түзәргә! Көтәргә!

Салих бүрәнәгә колагын куеп тыңлап карады. Сырпаланалар...

«Домкратны юньләп куймагансың».

«Әйтерсең лә беренче тапкыр гына, моңарчы сынатканым булдымы?»

«Алайса ничек, очып чыкканмы?»

«Чыкылдаган тавыш ишетелдеме?! Сугып төшерделәр аны».

«Ник соң ультиматумнары ишетелми?»

«Димәк... Бер генә «калай әтәч»нең эше бу. Акчаны эзлә. Безне тотардай тозак юк әле ул...»

Җиргә кар коела башлады. Кар яуганда җил уйный да уйный инде ул. Салихка шинель якасын күтәреп, фуражкасын батырып киюдән гайре ни калсын...

Кибет эчендә көндез күргән товарларны күз алдына китереп карады Салих. Авылда башка кибетләр юк, азык-төлеге дә, тимер-томыры да шушында сатыла. Караклар нәрсәгә ябышыр икән?.. Тәк. Авылга дефицит товар бик тәтеми инде, көндездән хәтерләвенчә, балта ише кирәкле әйберләр күзгә чалынмаган иде.

Суык белән көрәшүнең бер генә чарасы кала: кибет тирәли йөгерергә... Көткәндә вакыт бик әкрен үтә диләр, йөгергәндә дә шулай икән ул. Хәлдән тайганчы йөгерергә ярамый, дошман белән якалашырлык көч тә калырга тиеш.

Әйләнә-тирәне күзәтеп утыру өчен түбәдән дә җайлы урын юк. Салих сарай өстенә сикереп менде, аннан түбәгә үрмәләде. Түбә текә түгел, сандык капкачы кебегрәк ябылган, калай дисәң дә — аяк шумый. Буран муенга кар тутыра башлаган иде, морҗаны кочаклагач эчкә җылы керде. Салих морҗа авызына колак салды. Сөйләшәләр.

«Тик йөгерсен теге».

«Колагың тонды мәллә, түбәдә йөри бит ул! Эзлә син, эзлә. Тоз ящигын шәпләп кара, андый зур акчаны өенә алып кайтмагандыр».

«Чыгып сызу ягын карасак?»

«Курыкма, тәрәзә коткара безне. Син тап кына. Эзлә, тизрәк эзлә. Мин утны өзеп куям, ишек өстендәге звонок чәрелди күрмәсен. Эзлә, актар...».

Ашыкмыйлар, һаман эзлиләр болар.

Морҗа җылысыннан йокыга тала башлаган иде, кинәт тәрәзә пыяласы коелган тавышка айнып китте Салих. Карлы түбә буйлап шуышып тәрәзә турысына килде ул. Кайсы чыкса да, өстенә сикерергә. Монтажка белән берсен сугып ексаң, икенчесе белән көч сынашуы җиңелрәк булыр.

Ләкин тәрәзәдән чыгып качуы да алай ансат кына түгел, тимер рәшәткәне каерасы бар икән әле.

«Бу нәмәрсә кәнфит ящигы ачудан башкага бармый».

«Без паники! Каеруыңны бел, кадаклап кына куелган ул».

Салих тәрәзә кырыендагы ящиклар өеменә барып төште, егылып түгел, махсус. Тегеләрнең берсе тәрәзә рәшәткәсен ике куллап каермакчы иде, уң кулының бармакларын монтажка яндырып алганны сизми дә калды. Нык авыртты, ахрысы, коймага кысылган кәҗә төсле кычкыра.

«Улама, бер бармак өзелгәнгә госстрах та утыз сум гына түли. Акча эшләү җиңел түгел, бу кадәресен бигрәк тә».

Җикеренсә дә, үз бармакларын кызганды, рәшәткәгә үрелмәде. Салих бу минутта тегеләргә психик атака ясап алды:

— Тәрәзәгә тыгыласы түгел, ябылуга күнегә торыгыз. Җинаятегезне зурайтмагыз. Әле дә тәрәзә ватканыгыз өчен бераз өстәмичә калмаслар.

Тегеләрнең чаярагы Салих сүзләреннән хурланды бугай.

— Салага бит әле син! Безне буш кул белән генә тота алмассың!

— Әйтүем дөрес булсын, тыгылсагыз башыгызны ярам!

Каракларбер мәлгә тынып калдылар, пышым-пышым киңәшеп карадылар... Вакыт тагын да акрынрак үтә башлады. Буран да көчәя. Кеше-кара күренми. Тавыш-тын юк, этләр дә, буранны өнәмичә, ышыкка качтылар. Ярсудан кысып тоткангамы, тимер салкыны уч төбенә үтте, бармаклар тимердәй булып тыңлаусызга әверелделәр.

— Туңасыңдыр, мә, җылынып ал, бездә запас җитәрлек,— диде елак тавышлысы һәм, Салихны үчекләгәндәй, ватык тәрәзә аркылы бер шешә аракы сузды.

Салих тәрәзә каршысына ук килеп басты.

— Кулыңны сузма, юкса!..

Елак тавыш фуражкалы, шинельле кеше күреп бөтенләй каушап төште.

— Милиция ич бу!

— Тинтәк,— дип кырт кисте чаярагы,— солдат белән милиционерны бутагач...

— Ярый, безне җиңдең дә ди. Телисеңме, сиңа да өлеш чыгарабыз...

— Миңа солдат акчасы да бик җиткән, урламасам да...

«Каптык... Эчик хет рәхәтләнеп. Акчаларны аска җәй. Соңгы бәйрәмебез булсын...»

Алар бүтән тыпырчынмадылар. Иректәге соңгы сәгатьләрендә күңел ачып калырга исәпләре... Хәер, нык бүрәнә стена, рәшәткәле тәрәзә, бикле ишекне исәпкә алганда, ректә дип әйтеп булмый инде боларны.

Тагын берәр сәгатьтән эш кешесе уяныр чак җитә. Салкын буран гына менә, караклар белән бер сүзгә килгәндәй, Салихны, өшетеп, посттан алмакчы. Карлы җил туп-туры ялангач биткә килеп бәрелә. Тез буыннары йомшарга тора, кулдагы монтажка, хәлсез бармаклардан котылырга теләп, җиргә таба шуыша. Хәрәкәт, бары тик хәрәкәт кенә коткара ала, йөгер, сикер, бие, чүгәләп-чүгәләп ал, туктама гына!..

Ә караклар күңел ача, кызганыч тавышларын яшерергә тырышып, акырып-бакырып җыр сузалар...

Ниһаять, кибетнең рәшәткәле тәрәзәсеннән яңгыраган бозык җыр авазына, чакырганны да көтмичә, фермага эшкә дип чыккан авылдашлар җыела башлады...

* * *

Үпкәсенә салкын тидергән кешене ун гына көндә дәвалап өлгерә алмыйлар икән. Салихның отпускысын озайттылар.

Дилбәр көн дә больницага килә, авыл белән больница арасын өйләре белән клуб арасына да күрми. Очрашуларының берсендә Салих: «Кыш дип тормабыз, больницадан чыгу белән бергә таң аттырырбыз»,— дигән иде. Дилбәр каршы дәшмәде: «Түлке, җылырак киенеп чыгарсың»,— дип кенә куйды.

Тукайның 100 еллыгына

# УРАЛЬСКИДА ТУКАЙ УРЫННАРЫ




**Уральск шәһәре, Почиталин урамы, 66 нчы йорт.**
**Җизнәсе Галиәсгар Госманов торган бу йортка Габдулла Тукай 1895 елда килеп төшә һәм 1900 елга кадәр яши.**

*Тавил Хаҗиәхмәтов рәсеме.*

# ТУКАЙ — ПУБЛИЦИСТ

Тукайның публицистик иҗаты һәр җәһәттән игътибарга лаеклы: идея-тематик яктан да, кулланылган формалары белән дә, теле-стиле белән дә. Аның публицистик иҗатында без иң элек ул чорның елъязмасын күрәбез. Халык массаларын, аның алдынгы вәкилләрен дулкынландырган бер генә кискен проблема да, бер генә вакыйга һәм факт та публицист игътибарыннан читтә калмый. «Аның иҗатын һич икеләнүсез гасыр башындагы милли тормышның энциклопедиясе дип атарга мөмкин. Ләкин шагыйрьне бер татар дөньясы алдында торган мәсьәләләр генә борчымый, ул бөтен Россиядә, хәтта бөтен дөнья күләмендә барган вакыйгаларны иңләргә омтыла» [1]. Профессор М. Хәсәновның бу нәтиҗәсе Г. Тукайның публицистик иҗатына да тулысы белән, бәлки әле күбрәк дәрәҗәдә дә, карыйдыр.

Шушы хәл Тукай чыгышларының географик колачын гына түгел, ә аларда күтәрелгән мәсьәләләрнең төрлелеген билгели. Профессор М. Гайнуллинның «Татар публицистикасы һәм матур әдәбияты күтәргән мәсьәләләрнең даирәсе киң иде: патша самодержавиесенә, социаль һәм милли изүгә каршы көрәш, мәгърифәтчелек идеяләрен һәм халыклар дуслыгы идеяләрен тарату, алдынгы рус культурасының һәм көнчыгыш гуманист шагыйрьләренең иң яхшы традицияләрен пропагандалау» [2] дигән нәтиҗәсе Г. Тукай публицистикасына да нигезләнгән дип расларга мөмкин. Бу мәкаләдә шагыйрь публицистикасының тәнкыйди рухына тукталабыз.

*

* *

Г. Тукай публицистикасында һәм ул җитәкләшкән матбугат органнарында төп юнәлешләрнең берсе — үз чорының социаль җәмгыятен, халыкка каршы юнәлгән яшәеш формаларын, аларны гәүдәләндерүче «кара көчләрне», «сорыкортларны», изүче сыйныф идеолог-апологетларын фаш итү. Эксплуататорлык җәмгыятен, аның бозыклыкларын тәнкыйтьләү, халыкны талаучыларның, аны бөлгенлеккә, караңгылыкка, наданлыкка дучар итүчеләрнең чын йөзен ачу демократик һәм революцион-демократик (аеруча социал-демократик) матбугатның төп пафосы ул. В. И. Ленин мирасына мөрәҗәгать итсәк, без анда рус революцион-демократларының публицистикасына һәм матбугат эшчәнлегенә, иң элек крепостнойлык строена һәм буржуаз тәртипләргә каршы аяусыз көрәш алып барганнары өчен, югары бәя биргәнлеген аңлыйбыз.

Г. Тукай публицистикасындагы тәнкыйть тә әнә шул зур ташкынга килеп кушыла. Анда иске җәмгыятьне тәнкыйтьләү иҗтимагый мөнәсәбәтләрне, изү-изелү механизмын фаш итү линиясе буенча да, изүче сыйныфларның конкрет яисә «гомумиләштерелгән» вәкилләрен һәм апологетларын утлы табага бастыру линиясе буенча да бара. Тәнкыйтьнең өлгергәнлеген, фәннилеген һәм тирәнлеген тәэмин итүдә әлеге моментның зур әһәмияте бар. Мәгълүм ки, В. И. Ленин, мәсәлән, народник публицистларны сүз атакасын эксплуататорлык мөнәсәбәтләре системасына түгел, ә изүче сыйныфларның аерым вәкилләренә генә юнәлткәннәре өчен тәнкыйть итте. Ул аларның крепостной правоны эксплуатациянең мәгълүм формаларын, мәгълүм антагонистик сыйныфларны, мәгълүм политик, юридик һәм башка тәртипләрне китереп чыгаручы хуҗалык итү оешмасы формасы итеп түгел, ә алпавытларның властьтан явыз ният белән файдаланулары һәм крестьяннарга карата гаделсезлек күрсәтүләре дип сурәтләүләрен зур җитешсезлек дип санады.

Г. Тукай публицистикасын күздән кичерсәк, аның әлеге кимчелектән азат икәнлеген күрербез, димәк, иске җәмгыятьне фаш итүдә югарырак баскычта торганлыгын икърар итәрбез. Дөрес, сан ягыннан алганда Г. Тукай публицистикасында изүче сыйныфларның конкрет яки «гомумиләштерелгән» вәкилләрен тәнкыйтьләү өстенлек итәдер. Ләкин, беренчедән, мондый мәсьәләне сан гына хәл кылмый. Икенчедән, публицистиканың предмет һәм метод үзенчәлеген онытмыйк. Публицистика, кагыйдә

[1] Хәсәнов М. Интернационализмның җанлы традицияләре. Казан, 1980, 137-б.
[2] Гайнуллин М. Татарская публицистика и литература начала XX века. Казань, 1983, 7-б.

буларак, конкрет шәхесләр, документаль фактлар һәм күренешләр белән эш итә, дөньяны танып-белгәндә, күбрәк хосусыйдан гомумигә бара. Бу закончалык Г. Тукай иҗатында да чагыла. Шуңа күрә хикмәт аның шәхсиләштерелгән тәнкыйтьне иҗтимагый мөнәсәбәтләрне фаш итү белән бергә куша белүендә, беренче линиянең гомумиләштерү көчендә.

Г. Тукайның публицистик теле тәнкыйть сүзе белән ачыла. Аның беренче әсәрләре үк татар журналистикасында сатира ташкынының юл ярып агып китүенә сәбәп булды. Халыктан чыккан, халыкны яраткан, аңа хезмәт итүне төп максат итеп куйган әдип-публицист эксплуататорлык җәмгыяте шартларында, халык массаларының революцион аңы уяна башлаган вакытта сатираны корал итмичә булдыра алмый иде.

«Кыямәт көне» исемле фельетонына, исеменнән үк күренгәнчә, ул дини мифологияне нигез итеп ала. Мифология буенча, дөнья беткән көнне барлык кешеләр, кубарылып, исән чакта кылган гамәлләре өчен җавап бирергә тиешләр. Г. Тукайның дини мифологиягә мөрәҗәгать итүе тикмәгә генә түгелдер. Чөнки бу аның иҗатында бердәнбер очрак түгел. Без дини мифология сюжетларын һәм геройларын аның байтак әсәрләрендә очратабыз. Күрәсең, Г. Тукай укучыларның аң-белем, хәбәрдарлык дәрәҗәләрен, нинди әсәр-кыйссалар укып үскәннәрен истә тоткан. Соңрак ул үзе болай дип яза бит: «Ул кыйссаларны 20 миллион Русия мөселманнары һәммәсе укымасалар да, 10 миллион Идел буе татары бары да укыган инде, хәтта күңелдән бикләгән» (4, 133—134) [1]. Димәк, әдип-публицист үзенең фикерләрен халыкка ул гасырлар буе тәрбияләнеп килгән формаларда җиткерә. Тарих тәҗрибәсе шуны күрсәтә: аерым чорларда, аерым халыкларда, хәтта революцион идеяләр дә дини формага төреп пропагандаланырга мөмкин. «...Кромвель һәм Англия халкы үзләренең буржуаз революциясе өчен,— дип язды К. Маркс,— бик борынгы дин китапларыннан күчереп алынган телдән, дәртләрдән һәм иллюзияләрдән файдаландылар» [2]. Димәк, әдип-публицистның, укучыларның хәзерлек дәрәҗәләрен исәпкә алып, үзенең революцион тәнкыйть фикерләрен дини риваятьләр кысасында җиткерергә омтылуы аклана. Ләкин Г. Тукай бу «кысалар» белән бик иркен эш итә; еш кына очракта дингә, аның мифологиясенә карата «әхлаксызлык» күрсәтә. Дини риваять һәм кыйссаларны дөнья хәлләрен һәм аның идарәчеләрен мыскыллау өчен файдалану шуны раслый. Әйтик, «Хаҗи» исемле памфлетында Г. Тукай үзенең герое Исмәгыйль Габидин дигән хаҗины төшендә кеше кыяфәтендәге алла белән очраштырып сөйләштерә. Дин кануннарыннан чыгып бәя биргәндә, моннан да гөнаһлырак һәм кәферрәк эш юк. Әйтергә кирәк, Г. Тукай атеизмының бер үзенчәлеге бу, безнеңчә.

«Кыямәт көне»нә әйләнеп кайтыйк. Автор дөньяда явызлык кылып йөргән бәндәләргә кыямәт көне оештыра. Кемнәр соң алар, явызлар? «...Ялганчылар, гамәл сатып ашаучылар, шәкертләр хакын ашаучы муллалар, үзләре яхшы аңлап җитмәгән нәрсәне балаларга укытып, ислам балаларының гомерен ашаган хәлфәләр, милләтне ялкауландырып, фәкыйрьләндереп зәһәрләгән ишаннар — тәрәкъкыйгә дошманнар, барлык һимmәтләрен, һәммә гайрәтләрен трахтирларда, мәйханәләрдә генә күрсәткән байлар, халыкны һәртөрле чирмеш, керәшен сүзләренә Коръәннән артык иман китерткән карчыклар, өшкерүче-төкерүчеләр...» (3, 9). Аларның гаепләре нәрсәдә? Г. Тукайча, алар динне хурлаганнар, мөселманлыктан көлгәннәр, галимнәрне танымаганнар, туры сөйләгәнне кысканнар, изгәннәр, шәкертләрне иң түбән теләнчедән дә яман күргәннәр. (3, 9). Әйе, Г. Тукай дөньядагы реаль хәлләрне яхшы аңлый: анда тигезсезлек, гаделсезлек яши. Моңа явызлар гаепле. Шул явызлар аркасында милләт алга бармый, йоклап ята. Әнә шул явызларны акылга утыртасы, кыямәт көне белән куркытасы-өркетәсе бар: акылга килсеннәр. Бу әле җәмгыятьне сыйныфларга карап бүлү түгел. Г. Тукай аны абстракт нигездә бүлә: бер якта — явызлар, кара йөзләр, сорыкортлар, икенче якта — «дөньяда вакытта кул берләме, тел берләме дине исламның, милләте мөхәммәдиянең алга баруына тырышучылар, мәдрәсәләр-мәктәпләр салып та, шәкертләрне үзләренә габид ясамакны теләмәгән байлар...» (3, 9), ярлылар.

Икенче публицистик әсәрендә — «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы»-

---

[1] Г. Тукай әсәрләреннән өземтәләр дүртенче басма буенча бирелә. Җәяләр эчендәге беренче сан — томны, калганнары битләрне белдерә.

[2] Маркс К., Энгельс Ф. Сайланма әсәрләр. 2 томда. 1 т., Казан, 1949, 232—233 бб. (татар телендә).

да — Г. Тукай халыкның гасырлар буе йоклап килгән һәм йоклавыннан файдаланып, аны изгән, талаган явыз көчләрне кыямәт көнендә түгел, ә фани дөньяда җавапка тартырга чакыра. Ә чакыру тоны ифрат катгый һәм зәһәр. «...Милләтнең һушы китеп, гакылсыз ятканда, милләтне ашаган, кабыргаларын тишкән оятсыз ак башлы кargaларны, кәкре башлы, яшел яки сары гәүдәле Бохара козгыннарын куып җибәрик. Тагы да ул кортлар вә ул козгыннарның милләтне ни рәвештә ашаганнарын рәссамнар хезмәте илә милләтнең үзенә күрсәтик, милләтне аларга каршы ачуландырыйк, чәчләрен аягүрә торгызыйк; борынгы кыйлган эшләре өчен милләт аларны аяк астына салып изсен, һич дөньяга килмәгән кеби итсен; каргаларны муенныннан кысып, борынгы ашаганнарын карылдатып чыгарсын: шулай бит! Андин соң Бохара чапаны эченә төрелгән хәйләкәр төлкеләрне чапан җиңеннән өстерәп көзге каршысына китерик: көзгегә каршы авызларын каерып ачыйк та, милләткә көзгедән канлы авызларын күрсәтик; милләт күрсен, ашаганнарына инансын, икенче мәртәбә та кыямәт алданмасын» (3, 13).

Күренә ки, Г. Тукай халыкны алдап, изеп яшәүчеләрне фаш итү өчен әллә никадәр публицистик алымнар куллана. Иң элек йокы образын. Мәгълүм тарихи сәбәпләр аркасында социаль үсештән артта калган бөтен бер милләтнең хәлен йокы хәле итеп күз алдына китереп бастыра ул. Һәм бу образ татар публицистикасында торгынлык, артталык символы булып Тукай чорында да, аннан соң да, безнең көннәрдә дә шактый еш файдаланыла. «Шәрык уяна» исемле нәсерне хәтергә төшерик. Ф. Әмирхан бөтен бер континентның колониаль хәлен йокы хәле итеп гәүдәләндерә.

Милләтне йоклатучы һәм ул йоклаганда аны кимереп ятучы динчеләрне ничек сынландыра Тукай! Бер очракта ул аларны ак башлы (ягъни чалмалы) карга белән чагыштыра, икенче очракта кәкре башлы, яшел яки сары гәүдәле козгын итеп күз алдына китереп бастыра, өченче очракта кортлар дип хурлый, дүртенчесендә чапан эченә төренгән хәйләкәр төлкегә тиңли.

Шул рәвешле, Г. Тукай үзенең публицистикасындагы тәнкыйть рухын халык җилкәсен кимереп ятучы әрәмтамакларга — надан, комсыз, кадимче руханиларга каршы юнәлдерә. Бу юнәлеш аның иҗатында гомумән дә кызыл җеп булып сузыла. Дин әһелләренә, клерикалларга ташлануның сәбәпләре күп төрле. Иң төп сәбәп — алар иске җәмгыятьтәге изүче сыйныфларның мәнфәгатьләрен гәүдәләндерәләр. Феодаль җәмгыятьнең социаль структурасындагы өстен катлауларны нәкъ менә феодаллар һәм дин башлыклары тәшкил итә. Соңгылары буржуаз сыйныфы барлыкка килгәч тә аның мәнфәгатьләрен дә яклый башлыйлар. Алар эксплуататорлык җәмгыятенең идеологлары, апологетлары, аңа аңлы төстә хезмәт итүчеләр дә. Бу — бер. Икенчедән, изү-изелүгә корылган җәмгыятьтә (аеруча феодал җәмгыятьтә) дин әһелләре идарәчеләр сыйныфы белән кушылып беткән була. Изүче сыйныфлар мәнфәгатен чагылдыручы һәм яклаучы рәсми законнар шәригать кануннары белән ныгытыла. Димәк, клерикализмга каршы тәнкыйть уты ачу — изүче сыйныфларга, идарәче катлауларга каршы каләм сугышы ачу ул.

Г. Тукай дин әһелләрен, кадимчеләрне, урта гасырчылык тарафдарларын гомумиләштерелгән образлар йөзендә дә, конкрет шәхесләр йөзендә дә камчылый. Әле генә сүз барган әсәрләр — гомумиләштерелгән образлар аша тәнкыйтьләү мисалы. Андыйлар Г. Тукай иҗатында ахырга таба да очрый, («Авыл бае ишан хәзрәт хозурында», «Хаҗи», «Төш күрдем», «Логатьләр», «Ну-ну-ну», «Сабын ашаганнар», «Ике хәзрәт һәм извозчик»).

Революциягә кадәрге журналистикада гомумиләштерелгән образ-шәхесләр байтак күренә. Моның сәбәбе, күрәсең, изү-изелү мөнәсәбәтләре хакимлек иткән җәмгыятьтә халык массаларының аяныч хәле өчен аерым шәхесләр, аерым кимчелекләр түгел, ә иҗтимагый система гаепле булуын аңлаудан килә. Әмма Тукайда искелек тарафдарларының, дин әһелләренең конкрет образлары да — бөтен бер галерея. Гомумиләштерелгән образлар аша да, индивидуаль образлар аша да ул аларның наданлыгын, алдакчылыгын, икейөзлелеген, шәхси мәнфәгатьләрен алгы планга куюын, корсак хакына динен дә, илен дә сатып җибәрергә әзер торуын, динчеләрнең байлар тәлинкәсен ялап гомер кичерүен сурәтли. Алар — антогонистик сыйныфларга бүленгән җәмгыять, социаль мохит, иҗтимагый тәрбия бозган бәндәләр. Г. Тукай ае-

рым алганда дин әһелләрен байларга сәдакага бәйлелектән котылдыруның бер юлын тәкъдим итеп мәкалә язып та чыга. Мәсәлән, ул руханилар арасында хезмәт бүленешен тормышка ашырып, аларга эш хакы бирү тәртибен кертүне таләп итә («Муллалар» — 3, 159—162). Янәсе, шушы юл муллаларны байларга сатылып йөрүдән коткарачак, янәсе, аларның һәркайсы үзенә беркетелгән вазифаны башкарып, халыкка файда күрсәтә алачак. Ү. Гимадиевның, «Уклар» журналының руханиларга каршы көрәштә тарихи чикләнгәнлектән, каршылыклардан азат булмавын искәртеп, «анда ислам диненең реакцион сыйнфый характеры ачып бирелми. Әле «сафландырылган» дин хөкем сөрсә, татар халкы тизрәк алга китәр иде, дигән иллюзияләр дә очрап куя»[1], дигән нәтиҗәсе, әлбәттә, Тукай публицистикасына да карый. Ләкин, ничек кенә булмасын, руханилар, кадимчеләр Г. Тукайның бөтен иҗатында һәрвакыт үтә зәһәр тәнкыйть объекты булды.

Ләкин тарих мәйданына үрмәләүче, үзенең социаль асылын күрсәтеп өлгергән, һәм үтә астыртын, үтә яшертен эш йөртүче, милләтне алга җибәрү хакында авыз суы корытып байтак зыялыларны үзләре турында ялгыш фикергә китергән буржуа вәкилләрен һәм аларны тудырган шартларны, мохитне Г. Тукай бик тиз танып ала. Бу — аның әлеге дә баягы, халык белән өзелмәс бәйләнештә булуыннан, революция вакыйгаларының һәр сыйныф һәм аның партиясенең социаль йөзен, эш-гамәлләренең асылын, сүз белән эшнең берлеген яки бер-берсеннән аерылуын тиз ачып бирүеннән, революцион рухлы шагыйрь-публицистның политик сизгерлегеннән килә. Г. Тукайның революцион-демократлыгы буржуаз тәртипләргә, капиталистларга, аеруча аларның сәүдәгәр төркеменә, шушы сыйныфның идеологларына каршы аяусыз сугыш ачуы белән яңа баскычка күтәрелә. Аның иҗатында мондый тирәнтен үзгәрешләр килеп чыгуга революцион вакыйгалар, буржуазиянең шул вакыйгаларда үз-үзен тотышы һәм коммунистик пропаганда, большевикларның, аерым алганда Х. Ямашев, Г. Сәйфетдинов, шулай ук Г. Колахметовларның турыдан-туры зур йогынтысы сәбәп була.

Феодаль һәм буржуаз тәртипләрнең бергә үрелеп Россия җәмгыятенең кеше табигатенә каршы юнәлгәнлеген, шәхесне бозу өчен иң «яхшы» шартлар тудырганлыгын ачык аңлый иде Тукай. Әлеге җәмгыятьне ул әнә ничек сурәтли: ишан һәм муллалар мәчетләргә кереп, ачыктан-ачык капиталга табына, алланы оныта, капитал шомлыгыннан һәр мөселман исламга кире эшләр эшләргә мәҗбүр була, кызлар зинага, сәүдәгәрләр ялганга, мөхәррирләр алдауга, шагыйрьләр әллә нинди кешеләрне мактауга көчләнә, ике мулла, көндәш хатыннар шикелле, исламият кушмаган рәвештә мохасәдәсен[2] шул капитал өчен исламиятне, инсаниятне[3] бер якка ташлый (3, 197). Үз чоры җәмгыятенең антигуманистик асылын бу кадәр дә көчле, бу кадәр дә төгәл, бу кадәр дә усал итеп тагын ничек әйтеп бирергә мөмкин! Әлеге сыйфатламада К. Маркс һәм Ф. Энгельс «Коммунистлар партиясе манифестында» буржуаз җәмгыятькә биргән бәяләмә чалымнары юкмыни! Без анда В. Белинский, А. Герцен, Н. Чернышевскийларга хас әрнүле һәм нәфрәтле авазлар ишетмибезмени!

Г. Тукай кулланган публицистик һәм әдәби чаралар гаять күп төрле, берсеннән-берсе тапкыр, берсеннән-берсе очлырак уклы. Әйткәнебезчә, беренче әсәрләрендә үк ул кызыклы алымнар куллана (җир йөзендә этлек кылганнар өчен теге дөньяда кыямәт көне оештыра, йокы образын эшкә җигә). Г. Тукай журналистикада киң урын алган хәбәр жанрын сатира эшенә җигә. Газета барлыкка килүнең беренче көннәреннән үк киң кулланыла торган кыска хәбәр жанры мәгънәсе белән түгел, ә тышкы формасы белән генә үз вазифасында китерелә. һәм бу форма карагруһчыларны дөмбәсләү өчен файдаланыла. Казаннан бер хәбәр: «Бер ломовой извозчик муллалыкка урын эзли. Яхуд мөәзинлеккә. Татар гәзитләрен яхшы укый. Сүгенергә бик оста. Адресы: редакция гәзит 17 нче октябрь». Монда «17 октябрь союзы» дигән монархистик партия члены, «Бәянхел-хак» исемле клерикаль газета редакторы, ачып чыккан карагруһчы Әхмәтҗан Сәйдәшев хурлык баганасына беркетелә. Казаннан икенче хәбәрдә кадимчеләр җыела торган Печән базары тирес белән чагыштырылып, анда ак башлы гөмбәләр, ягъни чалмалы руханиларның үсеп китүен һәм аларның яңа фикерле газе-

---

[1] Гыймадиев Ү. Сатира коралы белән. Казан, 1977, 43-б.
[2] Мохасәдә — көнләшү.
[3] Инсаният — кешелек.

ғалардан куркуын белдерә (3, 33). Башка шәһәрләрдән «килгән» хәбәрләрдә дә конкрет кешеләр һәм күренешләр утка тотыла.

Публицистик әсәрләрендә Г. Тукай пародия алымына да еш мөрәҗәгать итә. Бу алым белән ул черегән җәмгыятьнең конкрет вәкилләрен, партияләрен, күренешләрен фаш итә. Аның иҗатында, башка революцион-демократик һәм социал-демократик рухлы әдип-журналистларныкындагы кебек үк, буржуаз милләтчеләрне һәм аларның политик партиясе «Мөселман иттифакы»н камчылау әһәмиятле урын тота. Бу очраклы хәл түгел. Чөнки буржуазия мәнфәгатьләрен яклаучы бу партия һәм аның членнары милләтне алга җибәрү турында лыгырдыйлар, Европага хас яңалыкларны күтәреп алган булалар һәм шул рәвешчә үзләре хакында прогресс тарафдарлары дигән тәэсир тудырырга маташалар. Ялтыравыклы сүзләрдән, хәйләкәр кыланулардан аларның чын максатларын аерып алу, халыкка каршы асылын абайлау һәм шуны әсәрләрендә гаять зур көч белән тәнкыйть итү Г. Тукайның гражданлык батырлыгы саналырга хаклы. Ул милләтчеләрне һәм аларның политик союзы «Мөселман иттифакы»н «Шартлар» исемле иң революцион, иң өлгергән әсәрендә утлы табага бастыра. Анда нәкъ менә пародия алымы кулланыла. Ул политик партия программаларына хас кыска һәм форманы өлге итеп ала да шуларга буржуаз милләтчеләрнең асыл карашларын, сүз чүбеннән арындырып, чынбарлыктагыча салып чыга. «Мөселман иттифакы» партиясенең программасы капма-каршы эчтәлек ала. Әлеге партиянең әгъзасы буласың килә икән, 10 нәрсәгә иман китерергә тиешсең: байлык, җирлелек, алпавытлык, кодакодачалык һ. б. (3, 196). Болар барысы да «миллилек» тамырыннан ясалган. Шул рәвешле, Г. Тукай «милләт», «халык» дип авыз суы корытучыларның изүче сыйныфлар табына торган шартларга һәм алар урнаштырган тәртипләргә иман китергәнлеген раслый.

Г. Тукай игълан формасын пародия итеп куллана. Күрәсең, моның үз мәгънәсе бар. Мәгълүм ки, газета-журналлар дөньяга килгәннән бирле һаман күбрәк урын даулый бу төр материал. Игълан, инде әйтелгәнчә, изүче сыйныф матбугатының төп керем чыганагы, нәширләрнең баю чарасы, матбугатны сәүдә объектына, экономик бәйлелеккә дучар иткән хикмәт. Ләкин шул ук вакытта игълан үзенең гамәли булуы, көндәлек ихтыяҗларны үтәве белән укучының игътибарын җәлеп итә. Г. Тукай, күрәсең, игъланның әнә шул үзенчәлекләрен исәпкә алган. «Алырга ашыгыңыз» исемле әсәре — моңа дәлилле мисал. Исеме үк: «Игълан бит мин»,— дип кычкырып тора. Язылыш манерасы белән дә ул игъланны нык хәтерләтә. Әсәр Звериноголовскида аптека ачылуын хәбәр итә. Имеш, анда «сукырайта торган, баш авырттыра торган, эч күптерә торган, сару кайната торган вә башка төрле дарулар сатыладыр». Шунда ук сәйдергеч имнәре, боздыргыч тылсымнары, «Бәянел-хак» гәзите һ. б. Аптекачылары да тузга язмаган әкәмәтләр — «хаҗи исеме таккан бер мосафир [1], фатир сахибәсе [2], татар микробы, өй корткасы». Сатып алучыларга шарт бар: алар сакаллы сабый һәм надан булсыннар, сатучылар сүзенә ихлас күңелдән ышансыннар. «Хилафынча булса, мәзкүр [3] дарулар әсәр итмәячәктер» (3, 138).

Г. Тукай кире герой монологын шигъри әсәрләрендә дә, публицистикасында да бик яратып куллана. Әйтик, классик дәрәҗәдә оста башкарылган «Ысулы кадимче» сатирик поэмасы. «Бюрократлар нәсихәте» дигән бәләкәй фельетонда власть ияләре — түрәләр исеменнән сүз йөртелә. Ә сүз изелгән халык өчен иң кирәкле нәрсәләр хакында бара. Сатирик парчаның беренче юлы ук, мәгънәләре белән бөтенләй пар килмәстәй ике сыйфатны янәшә куеп, бюрократларның халыкка нинди мөнәсәбәттә торуларын күрсәтә. «И гыйззәтлү өтелгән халык!» Мондый хурлыклы һәм мыскыллы мөрәҗәгатьтән соң инде халыкның иң тирән мәнфәгатьләренә кагылган мәсьәләләрдә бюрократларның нинди позициядә торачаклары үзеннән-үзе аңлашыла. Чыннан да, алар крестьяннарга җир бирүгә каршы. Ни өчен? Түрәләрнең җавабы менә мондый: «Җир бирелсә, элгәредән күп мәртәбә фәкыйрь булмакыңыз ихтимал» (3, 139). Кешеләргә тигезлек бирергә дә ярамый. Ник? Җавап әзер: «Әгәр халыкка тигез хокук бирелсә, инсанның кадере бетәчәк». Әнә шулай түрәләрнең үзләренә сүз биреп,

[1] Мосафир — юлчы.
[2] Сахибә — дәвалаучы.
[3] Мәзкүр — шул.

Г. Тукай аларның халыкка мөнәсәбәттә никадәр тәкәббер, никадәр түбәнсетеп карау сыйфатларын калкытып куя. Алар теләсә нинди тузга язмаган сәбәбен тапсалар табарлар, әмма халыкка файдалы эш эшләмәсләр. Мондый нәтиҗәне автор халыкның үз мәкале белән беркетеп куя. «Бюрократларның бу сүзе әбиләрнең: «Май ашама, сукыр булырсың»,— дигән сүзләренә бик охшый икән» (3, 139).

Г. Тукайның публицистик әсәрләрендә искелек тарафдарларын фаш иткәндә сүзлек формасы сатира максатларында бик оста файдаланыла. Ул теге яки бу сүзне һәм исемне ала да аңа үзенчә аңлатма бирә. Бу аңлатмалар гаҗәеп үткен һәм тәэсирле. Мәсәлән, ул «Төрле хайваннар тугърысында бераз мәгълүмат» әсәрендә исемнәрне (кайберләрен ул үзе ясый. Бу — мөстәкыйль сатира чарасына әверелә) китереп, аларның хуҗаларына үтергеч характеристика бирә. Җитмәсә Г. Тукай аларны хайваннарга охшата, ә хайваннардагы халык фикерендә урнашкан сыйфатларны, әлбәттә инде, тәнкыйть утына тотылган шәхесләргә юллый. Гомумән, сүзгә һәм исемгә сүзлектәгечә аңлатма бирү — башка халыклар журналистикасында да кулланыла торган сатирик һәм юмористик алым. Мәсәлән, Д. Фонвизинның «Собеседник» журналында урнаштырылган «Рус сүзлеге тәҗрибәсе» исемле әсәре шушы формага корылган. Ул — фактта синонимик тәгъбирләр «сүзлеге». Шушы форма аша Д. Фонвизин рус тормышындагы тискәре күренешләрне тәнкыйть утына тота. Г. Тукай куллануында сүзлек алымын пародиянең бер төре дип тә карарга мөмкин. «Гаҗәп түгелме?», «Лөгатьләр», «Төрле хайваннар турында бераз мәгълүмат», «Словарьдан фал ачу», «Матбугат каһарманнары», «Кеше-хайваннар», «Хатыннарның русча, татарча кушаматлары», «Хәзер җиләк-җимеш вакыты» исемле әсәрләре нәкъ менә сүзлекне пародия итү алымына корылганнар. Аларның һәркайсында теге яки бу тискәре күренешкә, яисә гомумиләштерелгән образга һәм конкрет шәхескә карата күп очракта бер җөмлә белән үткен характеристика бирелә. Күренешенә һәм шәхесенә карап я ул сатирик характерда, я юмористик рухта була. Берничә мисал китерик. «Җиләк-җимеш вакыты»нда «карбыз» сүзенә менә нинди аңлатма бирелә: «Пуришкевич вә әтбагының башы. Эче тулы кара орлык» (4, 212). Эре алпавыт, Дәүләт думасының иң реакцион депутаты һәм аның иярченнәренең карагруһлыгы, башларының шовинистик фикерләре белән тулы булуы ифрат образлы итеп әйтеп бирелгән.

«Мәсҗед — муллаларның өч ишекле кибете» (3, 255). Формасы белән сүзлек мәкаләсе. Ә мәгънәсе бөтенләй башка. Анда муллаларның мәчет кебек изге йортны халыкны алдап сәдака җыю өчен дин сату урынына әйләндерүләренә ишарә ясылып ята.

Ул кулланган сатирик һәм юмористик алымнар болар белән генә чикләнми. Без аның иҗатында көлкеле җыр, табышмак, мәкаль һәм әйтем, мәсәл, эпиграмма, мәзәк, әкият һ. б. таба алабыз. Ә инде сүз һәм тәгъбирләрнең сатирик һәм юмористик мөмкинлекләрен ничек итеп мул һәм уңышлы кулланганлыгын әйткән дә юк.

Г. Тукай изү-изелү мөнәсәбәтләре тудырган тискәре күренеш һәм шәхесләрнең татар дөньясында гына түгел, башка милләтләрдә дә яшәп килүләрен һәм халыкны тигезсезлектә, хокуксызлыкта, фәкыйрьлектә, наданлыкта тотуның төп сәбәбе икәнлеген күрә.

Ул кара көчләрнең кулга-кул тотынышып эш итүләрен, халыкны изү мәсьәләсендә һәрчак берләшүләрен яхшы аңлый. Шуңа күрә тәнкыйть угын татар карагруһларына, милләтчеләренә генә түгел, ә башка милләт, шул җөмләдән, рус реакционерларына да юнәлтә. Укның бик зәһәре эре капиталист, октябристлар партиясен төзүче, аның башлыгы, өченче дәүләт думасы председателе, соңыннан ак эмигрант А. И. Гучковка эләгә. Фельетон шушы «эшлекленең» бер нотыгы җәһәтеннән язылган. Газеталарның хәбәр итүенә караганда, Гучков үзенең чыгышында хөкүмәт сүз иреге бирүдән курка, хөкүмәт җәберли, дип зарланган, имеш. Нәрсә, әллә Гучков хөррият тарафдарларына әйләнгәнме? — дип сорау куя Г. Тукай. Юк, кая ул! Чикләвек юкадә. Публицист, чеп-чи монархистның сулланып алу сәбәбен аңлату өчен, татар тормышыннан гыйбрәтле бер мәзәк китерә. Хәлфә бер баладан аның холкын сынар өчен исемләп-исемләп таныш шәкертләргә сугыйммы дип сорый. Шәкерт сугарга куша. Ә чират үзенә килеп җиткәч, сукма, дип ялына. Башкаларга сугарга ярый, ә аңа — юк. Хикмәт шунда, алар беркөн әлеге шәкертне үчекләгәннәр, кимсетүле сүзләр әйткәннәр икән. Алар-

дан үч алырга мөнә дигән форсат. Өченче дәүләт думасы председателе А. И. Гучковның гамәлләре нәкъ менә шул шәкертне хәтерләтә. «Үзе, әүвәлге Думаларда уңнарның да уңрагы булып, бөтен хөррият вә иркенлекләргә каршы барды. Үзенә хилаф партияләргә, шәхси дошманлыклар өчен, аларны мөмкин кадәр егарга тырышты. Һәм әллә нинди явыз тәкъдир аркасында эшенә муаффәкъ тә булды» (4, 41—42).

Ә хәзер хөкүмәт-хәлфә Гучков-шәкертнең үз аркасына тамыза башлаган. Аның хөкүмәт сүз ирөге бирми дип еламсыравы шуннан килә икән. Г. Тукай халыкның үтә тапкыр мәзәгенә ассоциация рәвешендә буржуаз партия һәм аның типик вәкиле Гучковларның принципсызлыгыннан, икейөзлелегеннән, эгоистлыгыннан көлә. Халык мәзәгенә ассоциация ясау — гомумән, Г. Тукайның байтак әсәрләрендә кулланылган алым.

«Гаҗәп түгелме?» исемле фельетонда Г. Тукай Россиянең эчке эшләр министры, Беренче рус революциясен канга батыручыларның берсе, кара реакционер П. Н. Дурновоны дурной вә дурак дип, патша генералы, 1905—1907 елгы Беренче рус революциясен рәхимсез бастыручыларның берсе А. Н. Каульбарсны кан эчүче юлбарыс дип атый. Г. Тукай әлеге җаһилларның исемнәрен уйната. Дурноводан дурной һәм дурак сүзләрен китереп чыгара, Каульбарс фамилиясен ярым калька ясап ерткыч җанвар белән чагыштыра. «Ник болар үзләренең чын исемнәре берлә генә исемләнмиләр икән! Барыбер ялган исем такканлыклары мәгълүм бит инде!» — дип (3, 192) нәтиҗә чыгара.

Г. Тукайның сатирик әсәрләрендә, инде алда күренгәнчә, В. М. Пуришкевич утлы табага бастырыла. Аеруча аның Россиядәге азчылык милләтләргә кимсетеп каравы, аларны изүне көчәйтү политикасы тарафдары булуы, шовинистлыгы игътибар үзәгенә алына. «Кемнәрнең ни дисәң котлары чыга?» дигән әсәрендә ул Пуришкевичның: «Русиянең барча гайре рус әһалисе [1], вә хосусән [2] яһүдиләр, руслар илә бер хокукта булып, чын Русия гражданнары булдылар инде» дисәң», (3, 259) коты чыгуын ассызыклый. «Китмибез!» дигән мәшһүр әсәренең шул Пуришкевичларның шовинистик политика үткәрүләренә каршы язылуын да исәпкә алсак, тәнкыйтьнең колачы тагын да киңәеп китә.

Г. Тукай публицистикасында халыкара реакциягә һәм аның вәкилләренә дә өлеш чыга. Инде телгә алынган «Кыямәт көне» әсәрендә ул әлеге гарасат көне вакытында җиһанны баскан гасый [3] халыкларны эзли. Халык димәктән, ул дәүләтләрне күздә тота, билгеле. Англия хөкүмәте үткәргән колониаль политикага ук ата.

Төрек солтаны, үз халкын иң явыз кысуларга дучар иткән диктатор Габделхәмиткә Тукай аю кушаматын сылап куя (3, 191). Әйтергә кирәк, Габделхәмит аның байтак әсәрләрендә җәзалаучы булып сурәтләнә. Иран шаһы, революцион хәрәкәтне бастыручы Мөхәммәдгали дә Тукай каләменә эләгә (4, 133).

Шул рәвешле, Г. Тукай, татар журналистикасында беренчеләрдән буларак, үз чоры җәмгыятенең гаделсезлеген, кешелексезлеген, халыкка каршы юнәлгәнлеген төрле сатирик алымнар һәм формалар кулланып камчылый. Бу җәһәттән ул Россиядәге алга киткән халыкларның журналистлары белән бер сафка күтәрелә. Әлбәттә, Г. Тукай алпавыт-буржуаз җәмгыятен эшчеләр сыйныфы карашыннан чыгып чын фәнни нигездә фаш итүгә кадәр күтәрелә алмый. Әмма аның усал һәм үтемле тәнкыйте гаять зур эз калдырды.

Г. Тукайның эксплуататорлык җәмгыятен тәнкыйть утына тотуы үзмаксат түгел, бәлки халыкны үзе яши торган шартларга төшендерү чарасы, шул шартларга һәм алар тудырган канечкечләргә нәфрәт тәрбияләү, хезмәт ияләрен изелүдә, торгынлыкта һәм наданлыкта тоткан властьларга каршы ризасызлык, көрәш ихтыяры уяту чарасы ролен уйный. Шуңа күрә дә Тукай тәнкыйте халык массаларының революцион аңын уятуга һәм формалаштыруга хезмәт иткән. Бер үк вакытта Г. Тукай публицистикасының (һәм гомумән бөтен иҗатының) тәнкыйди рухы — аның халыкчанлыгын, халык мәнфәгатьләрен гәүдәләндерүен күрсәтүче көчле дәлил.

**Флорид ӘГЪЗАМОВ,**
тарих фәннәре кандидаты.

[1] Гайре рус әһалисе — руслардан башка халыклар.
[2] Хосусән — бигрәк тә.
[3] Гасый — гөнаһлы.

## Марсель Зарипов

# КҮҢЕЛЛӘРГӘ ЮЛ ЯРГАНДА

Мин кечкенәдән пароходлар яки поездлар туктала торган урында яшәүче кешеләрдән көнләштем. Зур шәһәрләр белән тоташтырырдай ышанычлы юлы булмаган авылдагыларны исә һәрчак кызгана идем. Андый җирдә көн итү элек-электән авыр иде; әлбәттә, хәзер дә җиңел түгел. Киресенчә, мул тормыш яхшы юлга булган ихтыяҗны арттырганнан-арттыра бара.

Кызганычка каршы, мин үскән поселок халкы да юлсызлыктан җәфалана иде. Бер карасаң, гаҗәп: шунда менә дигән спирт заводы эшли, юллары юк. Уйлана торгач, моның серенә төшендем мин. Заманында бу заводны Стахеев фамилияле бай салдырган. Ул, спиртны озату өчен кирәкле юллар турында кызыксынудан бигрәк, чималының арзан булачагын чамалаган. Зур дөньядан шактый еракта яшәүче крестьяннар бөтен ашлыкларын юк кына бәягә Стахеев заводына тапшырганнар. Ары китәргә юл юк, ә сатарга кирәк.

Октябрь революциясеннән соң завод дәүләт карамагына күчә. Аның продукциясенә ихтыяҗ зур. Казанда синтетик каучук заводы төзелгәч, спирт бигрәк тә күп кирәк була башлый. Аралар гына ерак. Петровка поселогы белән Казан арасы, әйләнечләрен дә кертеп исәпләсәң, биш йөз чакрымнарга тула. Ничек барып җитәргә?! Шуңа күрә спирт заводы Чаллы пристане һәм Бөгелмә станциясендә үзенең ике базасын булдыра.

Бөек Ватан сугышы елларында спирт тагын да кирәгрәк нәрсәгә әйләнде. Ул чакта икмәкнең ни дәрәҗәдә кадерле икәнлеген кабатлап тормыйм. Әмма завод барыбер шул ризыктан спирт кууын туктатмады. Чөнки моны фронт таләп итә иде, яу кырындагы госпитальләрдә яралыларны дәвалау өчен һәм, гомумән, җиңү өчен шулай кирәк иде. Спирт заводының хезмәте тулысынча Бөек җиңүне якынайтуга багышланды. Колхозлар исә яннарында шундый завод булуга шатланалар. Ул эшләмәсә, мең бәла белән өлгерткән игенеңне, бәрәңгене кая ташыр идең? Аралар ерак. Машиналар юк. Атлар арык. Юллар начар.

Әмма аның спиртын да ташыйсы бар бит әле. Башка чакта бу эш белән кышын гына шөгыльләнәләр иде. Сугыш исә спиртны өзлексез сорап кына торды. Кайчак хәтта заводка якын гына җиргә кечкенә бер самолет төшә, берничә фляга спирт тутыра да очып китә торган иде.

Синтетик каучук заводлары да спиртны бик кирәксенәләр. Безнең гаскәрләр Берлинга якынайган саен, резинага ихтыяҗ арта: дошманны көпчәксез машина белән куа бармассың бит инде! Солдат-

ларның итегенә дә олтан күп кирәк! Кирәк! Шул «кирәк» дигән тәшенчә поселокны өзлексез җилкендереп торды. Атлар да фронтка китеп беткән иде инде. Үгезләрне, сыерларны җиктеләр. Мичкәләргә спирт тутыралар, аларны пломбалыйлар, мал өчен печән төйиләр дә, озын кәрван булып, станциягә юл алалар. Кар явамы, буран котырамы, чатнама суыкмы — ул хакта сөйләшеп тору да юк. Чөнки кирәк, фронтка кирәк! Юлда төн куналар. Өшегән чаклары да була. Арыйлар да. Олау ияләре үзләре күп араны җәяү үтәләр. Йөктәге спирт кына тиешле урынга җитсен! Аңа гына зыян салырга ярамый. Ярамый, чөнки ул җиңү өчен кирәк!

Җәен эшләр бераз җиңеләя төшә иде. Заводның тонна ярым, өч тонна тарта торган берничә машинасы бар. Сугышка яраксыз искемоскы машиналар алар. Җәен шулар хәрәкәткә килә. Машина әрҗәләрен мичкәләр белән кичтән тутырып куялар. Бер мичкәгә — ягулык. Анысы да — бензин түгел, завод калдык-постыгы, альдегид дигән сыеклык. Караңгылы-яктылы юлга чыгалар. Барырга да, әйләнеп кайтырга да кирәк бит! Төнлә йөрүдән куркалар иде, чөнки машиналар адым саен ватыла, четерекле урыннардан үтүе — әҗәл белән бер: иске күперләр бар, тау менәселәр дә шактый, яңгыр яуса, эшләр бөтенләй начар...

Ул еллар инде бик еракта калды. Тормышыбызда күпме матур үзгәрешләр. Сугыштан соң ук, 1946 елда — Баулы тирәсендә, аннары Ромашкинода нефть ятмалары ачылды. Җир астындагы байлыкка ирешү исә җирнең өстендә яхшы юллар таләп итә иде. Нефтьле районнардагы колхоз-совхозлар, үз кесәләреннән бер тиен дә чыгармыйча гына асфальт юлга тиенделәр.

Бераздан Түбән Кама төзелеше канат җәйде. Мондагы нефтехимиклар нефтьтән, безнең тормыш ихтыяҗларын истә тотып, әллә ниләр ясыйлар. Мәгълүм ки, яңа шәһәр, зур заводлар салына икән — юллар да сузыла.

Шул рәвешле, бездәге тормыш-көнкүреш хәлләре тамырдан һәм зур тизлек белән үзгәрә башлады — калейдоскопта рәсемнәр генә алмаша диярсең! Бу үзгәрешләрнең тизлеген аңларга мөмкин: атом чоры, космос һәм лазер дәвере нәкъ шундый күз иярмәслек тизлек таләп итә. КамАЗ кебек гигантның берничә ел эчендә сафка басуы да Татарстан төзүчеләренең үз чорына лаек иҗанлеген раслады. Автомобиль берләшмәсе ихтыяҗлары Кама ярында өр-яңа ак кала барлыкка китерде. Анда ярты миллионга якын кеше яши. Шәһәрдә куәтле ТЭЦ, гидроэлектростанция салынды. Бу төбәктәге тормышның алга китүенә әйбәт юллар этәргеч ясады. КамАЗ машиналары Вятка, Кама елгаларында яңа күперләр булдыруны таләп итте. Тиздән хәтта Идел аша да яңа күпер салыначак.

Эшләребез әнә шулайрак тора. Миңа аеруча кадерле булган Петровка поселогының да, спирт заводының да юллардан кайгысы китте. Шоп-шома асфальт буйлап Кама ярына барасың киләме, Бөгелмә станциясенәме — рәхим ит! Машинаңны капка төбендә кабызасың, кирәк урынга җиткәч кенә сүндерәсең. Вәссәлам!

Шулай да минем күңел түрендә әле дә булса юлсызлыктан интегүчеләрне кызгану хисе яши иде. Чөнки юлсызлык хәлләре табигать тудырган каршылыкларны җиңәргә болай да күп көч сарыф итүче авыл халкын тәмам чарасыз калдыра. Кызганычка каршы, андыйлар бүгенге көндә дә байтак. Унберенче бишьеллык башына Татарстанның 816 колхоз-совхозыннан 683 есендә генә күтәртелгән нык юллар бар иде. Бетон яки асфальт түгел, каты өслек белән капланган юллар. Аларга коеп яуган яңгыр да, көннәр буе дулаган кар-бураннарың да хафа сала алмый. Шул ук вакытта ел саен юлсызлык ки-

тергән зыян йөз илле миллион сумнан артыграк иде. Бу сан республикабызның юллар төзүгә тота торган чыгымыннан зуррак. Сүз дә юк — юл салу бик кыйммәт, тик юлсызлык аннан да кыйммәткәрәк төшә. РСФСРның Автомобиль юллары министры Алексей Николаев үзенең «Неделя» газетасына биргән интервьюсында (№ 12, 1983 ел) мондый саннар китерә: «...Кара туфраксыз якларда үз өлкәсенең үзәк шәһәренә бара алмый интегүче — алтмыш район, район үзәгенә юл салынмаган мең дә сигез йөз колхоз-совхоз бар», — ди. Авылларда йөргәндә аның олы дөнья белән тоташканмы-юкмы икәнлеге әллә каян күзгә ташлана. Күңелдә, ихтыярсыздан, геологлар ник кенә бу якта да нефть тапмадылар икән, анысы булмаса, башка берәр матдә эзләсеннәр иде, дигән уй туа — юл салырга сәбәп чыгар иде, ичмаса! Икенче яктан, ни өчен соң аралашу өчен иң кирәкле чара булган юлларны төзү-төземәү төбәкләрнең нинди байлык бирүенә бәйләп кенә планлаштырыла? Җирендә файдалы казылма табылмаган яки зур заводлар эшләмәгән кешеләргә юл кирәкмимени соң?!

Хәер, монысы — хискә бирелүдән, кайнарланып әйтелгән сүз. Эшлекле рәвештә исәпли башласаң, мәсьәләнең җитди яклары да күп. Автомобиль юллары салу — шактый катлаулы, кыйммәтле шөгыль. Юлның да төрлесе бар. Бар халыкара әһәмиятле юллар. Андыенда машиналарның берничәсе рәттән бара ала, магистраль уртасында бүлү сызыгы уздырылган була. Юлның өсте, әлбәттә, бетон яки асфальт белән шомартыла. Нигезе дә тиешенчә ныгытыла. Беренче категорияле мондый трассаның бер километрын салу бер ярым-ике миллион сумга төшә. Хикмәт акчада гына да түгел. Бу төр юлның бер километры 850 тонна цемент, 180 тонна металл, 490 кубометр агач, 22 мең кубометр таш, 1700 кубометр ком таләп итә. Монда мин трассадагы күперләргә, тоннельләргә, тукталыш җайланмаларына китә торган кирәк-яракны да кушып исәплим.

Безнең авылларга мондый затлы юлның хаҗәте юк. Гади генә, мөмкин кадәр арзанрак юл салынса да, авыл кешесе мең риза. Елның теләсә кайсы фасылында үтеп йөрерлек кенә булсын!..

* * *

Көннәрдән бер көнне миңа ул елларда ТАССР Министрлар Советы председателе постында эшләүче Гомәр Исмәгыйлович Усманов шалтыратты. Исәнлек-саулык сорашканнан соң өр-яңа хәбәр әйтте.

— Апас районында юллар сала башладылар, — ди. — Үз көчләренә ышанып, барысы бер булып тотынды. Әйбәт эшләрен мактап, башкаларны да кызыктырырлык итеп шул хакта язарга иде!

— Очлап чыга алырлармы соң?

Соравымның мәгънәсе шактый тирәндә иде. Күз алдымнан Апасның, аз гына яңгыр яуса да, басар җае калмый торган чокыр-чакырлы юллары үтте сыман. Ничек тигезләп бетерерләр? Материалын кайдан табарлар? Вакытлары да юк — язгы чәчүне түгәрәкләп өлгермисең, печәнен кайгыртырга кирәк, анысына урак тоташа, көзге чәчү килеп җитә. Крестьянга, юл салу өчен, аерым вакыт бирелмәгән, бирелмәячәк тә.

РСФСРда район үзәгенә ышанычлы юл белән тоташмаган алты мең колхоз-совхоз бар. Бу бит ялкаулыкка гына бәйле хәл түгел. Мәсьәләне чишү өчен тәвәккәллек белән бергә бик зур чыгымнар да, кул көче дә кирәк. Боларның барын да колхоз-совхозлар үзләре генә башкара алырлармы?

Совмин председателе:

— Башкарачаклар! — ди, тулы ышаныч белдерә. — Менә күрер-

сез! Мин яңа гына шуннан кайттым. Шәп эшлиләр. Берәүнең дә ярдәмен көтеп тормыйлар. Үз көчләренә ышанып тотынганнар!..

Барып күрәсем килә башлады. Язарлык материал булырмы-юкмы, алдан әйтүе кыен, шулай да карап кайтуның зарары тимәс. Киттем. Поезд Иделне кичте. Вагон тәрәзәсеннән тигез, киң басуларны карап барам. Көтүлекләр, авыллар, Зөя суы. Зөянең үзе белән рәттән сузылган шаулы Иделгә каршы агуы уйларымны апаслылар башлангычына китереп бәйләде. Боларда гомуми агымга каршы барып маташмыйлар микән, дим. Ата-бабалары риза булып яшәгән шартларга каршы чыгып, берәүдән дә ярдәм-фәлән көтеп тормыйча, үз көчләре белән генә юллар сала башлаганнар!

Бу фикерләремне ачыктан-ачык Халык депутатларының Апас районы Башкарма Комитетының ул вакыттагы председателе Абделхәй Хәйрулловка да әйттем.

— Нишләп алай булсын?— диде ул.— Гомер-гомергә юлсызлыктан интеккән халыкның такыр юл сала башлавы — агымга каршы бару буламыни?! Безнең халыкта элек-электән зур эшкә өмәләр җыю гадәте яши. Без шуңа охшаш гадәтләрне яңачарак иттереп, тагын да баетырга гына алындык...

Апас — зур район, озынлыгы йөз егерме километрга сузыла. Аның мәйданындагы йөз иллеләп авылда йөз меңләп кеше яши: игенче-механизаторлар, терлекчелек осталары, тегүчеләр, укытучылар, врачлар, сатучылар, төзүчеләр, өлкәннәр һәм сабыйлар... Һәрберсенең үз шатлыгы, үз кайгысы дигәндәй, моңарчы һәммәсе ни барына риза булып яши биргән, хәтта юлсызлыктан да канәгатьләр шикелле. Уйлабрак карасаң, бу үзе — агымга каршы торып азаплану лабаса! Юлсыз тормыш — тормышмыни соң ул?!

Әлбәттә, район халкы бу хәлне үзе теләп, сорап алмаган. Юлларны төзәтү, яңа, яхшы юллар булдыру һәр җыелышның үзәгенә куелган: «Юлсызлыктан котылыйк!», «Юллар — тормышыбызның артериясе!», «Юллар — сакчыллык чарасы» кебек дөп-дөрес сүзләр бер чыгыштан икенчесенә күчеп йөргән.

Сугыштан соң утыз биш еллап вакыт узган. Бер кеше гомеренә тиң. Сугыштан соң туган балалар тормыш хуҗаларына әйләнгәннәр, ирләр акыллы аксакаллар урынын алганнар, әмма юллар мәсьәләсенә үзгәреш кермәгән. Моның сәбәбен аңлатырга була. Бәлки, бу якларда да, нефть-фәлән табылмасмы әле, безгә дә юл салып бирерләр иде, дип көткәннәрдер. Аннары, КамАЗ кебегрәк берәр корылыш башлануына өметләнгәннәрдер. Өметсез — шайтан, диләр бит. Ләкин, үзең кул кушырып утырганда, нинди өмет тормышка ашсын соң?! Өметнең андые — рәшә белән бер: җил генә исеп үтсә дә юкка чыга.

Апас районы кешеләрен кул кушырып утыручылардан санамыйк. Юк. Район гел үсештә, алга омтылышта булды. Хуҗалыклар эреләндерелде. Хезмәт механикалаштырылды. Район ел саен 130 мең тонна — ашлык, 30 мең тонна — сөт, 6 мең тонна — ит, 80 мең тонна — бәрәңге, 15—20 мең тонна — яшелчә, 70 мең тонна шикәр чөгендере җитештерә. Хуҗалыклар елына бер миллион йөз мең тонна йөк ташыйлар.

Мондый зур байлык булдыручы районның уңышсыз якларын күрәсе дә килми. Тик тора-бара экономистлар мәсьәләнең икенче ягын да ачыклыйлар: шушы алымнарга таянып кына яшәсәләр, якын киләчәктә дәүләт планын үтәү-үтәмәү шик астында калачак. Унынчы бишьеллыкта апаслылар йон планын гына төгәл тутырдылар. Калганнары: ашлык, ит, сөт, бәрәңге, шикәр чөгендере — барысы да өзелде. Бу хәл шактый тирәннән уйландыра башлый. Оештыру эшләрендәге хаталарны, кешеләрдә киләчәккә ышаныч югала баруны сизеп ала-

лар. Күп бәлаләрнең башы юлсызлыкка килеп тоташуын да чамалыйлар...

Тигез юлдан машиналар очып кына үтә сыман, эш тә тизрәк йомгаклана. Тизлек дигәнең авыл җирендә бигрәк тә кирәк. «Бер көнең ел туйдыра» кебек гыйбрәтле әйтемнәр нәкъ менә шул хакыйкать нигезендә килеп чыккан. Барыннан да әһәмиятлерәк тагын бер нәрсә бар әле: юлларның ниндилеге кешеләрнең кәефен үзгәртә, аларның эшкә мөнәсәбәтен, ата-баба җирен олылау-олыламавын, читкә киткитмәвен, кыскасы, иртәгәге көнгә карашын билгели.

— Безнең шуннан да артыгракка түзәр чама калмаган иде инде,— ди Хәйруллов. Апаслылар башлангычын, үзенчә, кыска гына аңлатты да бирде ул.— Теләкләрнең бик көчлесе, ихтыяҗның кырыслыгы безне яхшы юллар турында хыялланып утырырга түгел, аларны сала башларга мәҗбүр итте.

Без Хәйруллов белән бергә районның бөтен якларын гизеп чыктык. Күз алдында тракторчыларның, экскаваторчыларның, шоферларның, бульдозерчыларның фидакарьлеге аркасында нык, киң, ышанычлы юллар күтәрелә. Бу кешеләр моңарчы бөтенләй башка эш үтәгәннәр. Уртак ихтыяҗ, уртак тырышлык һәм акыллы җитәкчелек аларның әр-яңа осталыкларын ачкан, бөтен көчләрен бердәм максатка юнәлткән. Бу якты омтылыш хәтта безнең машинаның тизлегенә дә тәэсир итте кебек. Очтык кына! Юк, юллар бик әйбәт булганнан түгел, аларның әйбәте әле салына гына башлаган, күңелләр күтәренке иде, сәфәр шунлыктан уңышлы бара. Кешеләрнең һәр тарафта тату рәвештә гомуми эшкә ябышып ятуларына шатланып хәтта Җир шары үзе дә тизрәк әйләнәдер кебек тоела иде.

— Элегрәк бу хакта ник уйламадыгыз икән соң сез?— дип сорыйм.— Юллар, аралашу чарасы буларак, барлык эшнең башы бит инде.

— Анысы шулай. Тотынырга тәвәккәллек җитмәде. Уйлый башласаң, зиһеннәр чуалырлык нәрсә бит ул. Бер тотынгач, шулкадәр мавыктырды, тизрәк азагын күрәсебез килә.

Хәйруллов башта колхоз председателе булган. Аңа халык хуҗалыгының күп тармаклары белән якыннан танышырга туры килгән. Бүгенге эше аннан нәкъ шул сыйфатларны таләп итә дә.

— Тотынмый ярамый иде,— дип, ул тагын сөйли башлады.— Көннәрнең берендә үз хәлебезгә читтәнрәк торып күз ташлаган идек тә хәйранга калдык: тормыш яныбыздан выжлап үтә, без, байтак юлларыбыз читенә басып, аңа кул болгап кына утырабыз кебек...

— Мондый нәтиҗәгә килер өчен берәр этәргеч булгандыр инде,— дим.— Мөгаен, ул чакта районга юл салу материалларын көтелгәннән күбрәк биреп ташлаганнардыр?

Хәйруллов кул гына селтәде.

— Алырсың артыгын! Тиешлесеннән бер уч ком да арттырмадылар. Халыкның сабыр савыты тулып ташыды — тәвәккәллекнең төп сәбәбе шул. Хәзер юлсыз яшәү мөмкин түгел. Быел кырык чакрым салабыз, киләсе елга тагын шул кадәр. Аннары автобуслар җибәрү турында уйларга исәп. Беләсезме: бездә гомере буе автобуска утырмаган агайлар бар, әйтсәң, кеше ышанмас.

— Шулайдыр да бит, һәр нәрсәнең җае бар, ботканың да мае бар, дигәндәй, монда коры теләк белән генә ерак китеп булмый.

— Бездә май юк дисезме әллә?— Хәйруллов хәтта үпкәләп тә куйды бугай.— Районда — утыз хуҗалык. Аларда биш йөз автомобиль, меңләгән трактор белән бульдозер тупланган. Оештыр гына! Маеңны чыгарып бирәләр алар!..

Мин мәсьәләнең төрле якларына кагылып карадым, әмма апаслыларның бу көтелмәгән тәвәккәллекләре хакында яза башларга төп

бер этәргеч таба алмадым. Уйлап карасаң, кешеләрнең бу энтузиазмын күккә чөеп мактарга бөтен мәгълүматларым да бар иде, җитәрлек иде — күңел ышанмады. Үзең дә ышанмаган хәлне укучыларга тәкъдим итсәң, алар ышаныр идемени?! Юк, әлбәттә.

*
* *

Ни өчен ышанмавым аңлашылса кирәк. Минем уемча, кешеләр бик файдалы эш башлаганнар. Теләкләре изге, әмма ләкин коры теләк белән генә ерак китеп булмый. Табигать игенчегә ашлык үстерүдән тыш күпме генә вакыт бирә соң? Чәчү белән урып-җыю арасында бер ай-ай ярым чамасы. Ярый. Быел алар шуннан бик оста файдаланып калдылар, кырык чакрым юллары әзер. Киләсе ел нинди булыр бит әле? Теләкләре яңадан да кабынырмы? Беренче елда әле алар район үзәгенә якын хуҗалыклар белән эш иттеләр. Ерактагы колхоз-совхозлар һаман интегә. Кечкенә авылларга салынасы юллар күпме?! Фермаларга, мастерскойларга ничек барыпирешерләр?! Андыйларны да кушып исәпләсәң, хуҗалыкларның үзендә әле тагын өч йөз километрлап юл күтәртергә кирәк.

Бу — бик җитди мәсьәлә. Апас районы соңгы ун ел эчендә юл төзү планын гел өзә килде. План әллә ни зур да түгел иде әле, шул да үтәлмәде. Инде бер җәй эчендә, бар куәткә көчәнеп, кырык чакрым юл салганнар икән — «ура!» кычкырырга ашыкмыйк!

Апаслылар юл салырга тотынган, дип кенә материал, транспорт-фәлән артык бирелмәде. Бердәнбер «Нефтеснаб» оешмасы гына аларның транспортын ягулык белән өзлексез тәэмин итеп торды. Калган мәшәкатьләрнең барысын да алар үз көчләре белән җиңеп чыгарга тиешләр иде. Башлап җибәргәндәге кайнарлыклары эшнең азагына кадәр җитәрме?! Алдан ук мактап куеп, эшкә зыян китерергә дә мөмкин бит. Урынсызга мактау, юк хатаны тәнкыйтьләү кебек үк, шактый куркыныч нәрсә. Без еш кына, фәләннәр әнә нинди йөкләмә алды, дип берәүләрне күккә чөябез, ә йөкләмә тормышка ашырылмый кала. Азмы андый хәлләр?!.

Шуңа охшаш каршылыклы уйлар тәэсирендә мин апаслыларның матур башлагычы хакындагы язманы шактый вакытлардан соң гына төгәлләдем. Бу чакта алар, инде йөз чакрым юлны салып, бөтен колхоз-совхозларын район үзәге белән тоташтырганнар иде. Әле алда да тырышасылары бар. Тик хәзер күңел бу кешеләрнең юлга кагылышлы эшләрен матур иттереп төгәлләп куячакларына тирәннән ышана.

*
* *

Юл салу бурычы — апаслылар өлешенә тигән халык төзелеше. Бу — аларның үз БАМнары. Мин моны бөтен җитдилеге белән әйтәм. Колхозга яки аерым бер совхозга олы дөнья белән ике арада ныклы юл булдыру, нәкъ дәүләткүләм мөһим мәсьәләне хәл итү кебек үк — зур эш. Язгы чәчүне түгәрәкләп куялар да, тургай җырын тыңлый-тыңлый, юл сала башлыйлар. Моңа ирешү җиңел булмагандыр. Мин хәлнең материаль ягын алмыйм әле. Гомер-гомергә бу шөгыльдән читтә торган крестьяннарның психологиясен җиңеп, аны шуңа тарту, бу эшне аның ихтыяҗына әйләндерү бик кыен булгандыр, мөгаен. Чөнки дөньяда кеше күңеленә үтеп керүдән дә авыр нәрсә юк. Бөек Эйнштейн әйткән: «Атом төшен бүлгәләргә мөмкиндер бәлки,— дигән,— әмма кеше психологиясен үзгәртеп булмаячак». Эйнштейн, атом бомбасы шартлау хәбәрен ишеткәнчегә кадәр, атомның тарка-

луына ышанмаган. Инде шундый кешедән дә әлеге сүз чыккач, башкаларга ни кала?!

Апаслылар, аларның җитәкчеләре исә кешеләрне моңарчы башларына да кереп чыкмаган өр-яңа шөгыльгә иләндергәннәр. Эшкә тотынуга ук вак таш кирәк. Бу яңалыкка кадәр юлга җәя торган ташны Уралдан ташыганнар. Идел аръягында андый материал юк дип исәпләнгән. Авыл аксакаллары исә район мәйданындагы инеш буйларын кабат тикшерергә киңәш биргәннәр. Озак та үтми, тау итәкләрендә, иске ермак буйларында сигез карьер эшли башлый. Әлбәттә, Апас ташы беренче категорияле магистральләр өчен ярамас та, бәлки, әмма авыл йөген генә алар рәхәтләнеп күтәрә ала.

Мин бу төзелешнең бөтен тармаклары белән таныштым. Бу урында аның мөһим якларын тәфсилләбрәк күрсәтергә кирәктер дип уйлыйм. Бу мисалда партия һәм совет органнарының, административ идарәләрнең үз ихтыярь белән генә дә ниләр башкара алуы, халыкны җитәкли белгәндә, ниләргә сәләтле икәнлеге күренә.

Юлның беренче тармагы район үзәгеннән Ульянково белән Надеждино авылларына, икенчесе — Олы Кайбыч белән Багаевога, өченчесе Чирмешән белән Дәүләкигә сузыла. Кулда булган техниканы шул якларга бүлгәләсәң, беренче карашка, шактый зур көч булып күренгән мең ярымлап машина, шактый зәгыйфь төркемнәргә тарала да бетә. Шуңа күрә техниканы төп өч удар колоннага туплыйлар. Һөҗүмгә!

Бу фикер бик дөрес кебек. Шулай да аңа каршы төшүчеләр табыла. Районның иң ерак чигендәге Надеждино авылына урнашкан «Татарстанга — 50 ел» колхозы председателе Илдар Нурмөхәммәтов, мәсәлән, һәр колхоз үз территориясендәге юлны үзе ясасын, дигән тәкъдим кертә. Аны да аңларга мөмкин. Колхоз җәй буе көчен түгәчәк, көз җиткәндә, Надеждино тирәсендә һичнинди дә яңалык булмаячак. Икенче җәйдә дә шул ук хәл. Надеждинога кайчан килеп җитәр соң ул шәп юл?! Көчең сарыф итеЛә, байлыгың чыга тора, отыш юк.

Нурмөхәммәтов кебек фикер йөртүчеләр тагын да була. Шунлыктан аларны да ышандырырлык чара эзлиләр. Районның барлык хуҗалык җитәкчеләре штабка җыелалар. КПСС район комитетының I секретаре Хәмит Хәйретдинов һәм Халык депутатларының район Советы Башкарма Комитеты председателе Абделхәй Хәйруллов кагнашында уздырылган бу киңәшмәдә юлның һәр чакрымын кайчан, ничек салу турында ныклы график төзелә. Һәм шул график намус белән үтәлеп бара. Басым ясап әйтергә кирәк: эш агымында берәүне дә җавапка тарттырырга, шелтәләргә туры килми. Күрәсең, юлсызлыктан җәфа чиккән кешеләргә нәкъ менә шушы башлангыч кулай булган.

Алай да берсендә тавыш чыга. Тукай исемендәге колхоз мәйданында эшләгәндә, җыелма колонна составына кертелгән «Комсомол» колхозы тракторчылары үз өлешләрен башкармыйча китеп баралар. Мөһим сәбәбе дә булгандыр, билгеле, тик бу районда хуҗалык җитәкчеләренең вәгъдәләренә ышану көчле. Берәү дә: «Ник?» — дип сорап тормый. Эше бетмәгән юл кала бирә. Көз җитә. Кыш килә. Юлның өзек турысына «Комсомол» колхозы председателе Рифкат Хисамовның исем-фамилиясен язып кадаклыйлар. Һәр машинаның шоферы, әлеге чокыр-чакырлы турыдан үткәндә, Хисамов фамилиясен төрледән-төрле килешләрдә телгә алып уза. Бичара Хисамов ел фасылларының иң көйсез чагында калдык эшен түгәрәкләргә мәҗбүр була.

Соңгы елларда һәр эшнең үз осталары, үз оешмалары барлыкка килде. Хәзер, егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз, дип, бөтен эшкә

бер кешене йолыккалау гадәте бетте. Игенче икән, ул басуда, башка эшләр белән «Сельхозтехника», «Сельхозхимия», «Мелиорация», «Дорспецстрой» кебек күп санлы оешмалар шөгыльләнә. Аларның исә үз җитәкчеләре бар.

Апаста юл салу башлангач, хәтта бу оешмаларның хезмәткәрләре дә район җитәкчеләренә хөрмәт белән карыйлар, үз өсләренә бурыч алырга да карышмыйлар: таш табуда да, машиналар, кешеләр булдыруда да ярдәм итәләр, өмәләрдә катнашалар...

Һәр әйбернең юл чыгымнарына бәйле рәвештә кыйммәте арта барганлыкны барыбыз да аңлый. Агыйделнең аръягында бер энәгә — бер сыер, дигән әйтем тикмәгә генә телдән-телгә йөрми. «Азык-төлек программасы» да, авыл юллары мәсьәләсен үзәккә алып, бер дә юкка сүз кузгатмый. «Программа»ның бу пунктын авыл тормышын белгән һәр кеше бик хуплап каршылады. Әмма хуплау гына аз, монда җиң сызганып эшләү кирәк. Эшенә исә һич вакыт җитми: әле чәчү, әле печән, әле урак — берсе артыннан икенчесе, өченчесе тезеп куелган. Артык вакыт каян табасың? Ә шул ук сорауны икенче якка әйләндереп карамыйлар: юлың булмагач, чәчүлегеңне ничек чыгарырсың, уңышыңны ничек ташырсың? Барысына да иң әүвәл юл кирәк бит!

Һәр файдалы эш, хуплау тапкан кебек үк, артка каеручыларны да өскә калкытып чыгара. Апаста уртак фикергә килүгә үк, Казанга дәгъва җибәрүчеләр дә табыла: «Коткарыгыз, тиешсез эш тагалар!» янәсе.

Берсендә Хәйрулловка ашыгыч хәбәр китерәләр. «Дорспецстрой» тресты җитәкчесе җибәргән. «...Әгәр дә мәгәр безнең автотранспортны үз эшеннән бүләсез икән, бөтен машиналарыбызны Казанга чакыртып алачакбыз...»

Хәйруллов телефонга ябыша.

— Юллар булмагач, төп эшегезне ничек башкарырсыз соң?— Килешик!

Монысы белән аңлашып кына җиткәндә, «Татмелиоводстрой» начальнигы килеп төшә,— таш карьерына куелган техникасын алып китмәкче.

— Безнең үз эшебез дә — муеннан!— ди ул.

— Юлсыз җирдә нишләмәкче буласыз?

Шулай итеп, берәм-берәм күп кенә оешмалар белән аңлашырга туры килә. Өченче җәй азагында йөз илле километр юл салынып бетә. Әлбәттә, техниканың күплеген искә алганда, эшнең тизлеге әллә ни мактанырлык түгел. Көнгә бер чакрым чамасы юл сузганнар. Тик ул чакрымнарның ниндилеген белмәгән кеше генә бу эшне азсыныр. Мин, укучының вакытын алмас өчен, нинди ермаклар, түбәнлекләр, сазлыклар күмелгәнлеген санап тормыйм. Күпме җир актарылганына да, никадәр кара туфрак сыдырып алынганлыгына да тукталмыйм. Шул арада биш миллион сумлык эш башкарылганлыгын гына әйтәсем килә. Бу — хуҗалыкларның өстендәге төп бурычтан тыш башкарылган хезмәт! Кеше, ачык максаты булганда, әнә нинди фидакарьлеккә сәләтле! Алар бит шул ук вакытта җирен дә сөргән, терлек тә үрчеткән, бәрәңгесен-чөгендерен дә үстергән. Боларның барысын да: «Тиздән бездә такыр юл булачак!» — дигән шатлыклы яңалык рухландырып торган.

1981 ел Апас районына әллә ни зур уңыш китермәде. Дөрес, алар бу елда да көчләрен кызганмадылар, тик табигатьнең холыксызлануы уздырыбрак җибәрде. Монда һич тә, боларның юл салып азаплануы эшкә хилафлык китерде, дияргә урын юк. Чөнки шул ук уңышсызлык асфальт юлда утырган хуҗалыкларны да уратып үтмәде.

Аннан соңгы елда ашлык уңышы гомер күренмәгәнчә шәп булды: бөртеклеләрне апаслылар ике йөз мең тоннага якын җыеп алдылар, 1983 елда, ашлыктан тыш, сөт житештерү дә алга китте, аны утыз алты мең тонна саттылар. Моңарчы шикәр чөгендерен алу үзәккә үтә иде. Бу елда аны бишенче октябрьга түгәрәкләп куйдылар.

Планнар кечерәйтелмәде. Киресенчә, үзгәрешләр һаман үсү, арту ягына гына булды. Әмма аны үтәү җиңеләйгәндәй тоелды. Авылларның йөзе яктыра төште. Көнкүреш хезмәте күрсәтү йортлары, яңа өйләр күбрәк салына башлады. Яңа йортта яшәүләре дә башка бит ул!

Юл салырга тотынуларының өченче җәендә мин кабат Апас киңлекләре буйлап сәфәр чыктым. Хәйруллов белән икәүләп. Юл өч тармаклы, дигән идек. Без барлык хуҗалыкларны район үзәге, Казан һәм Ульяновск шәһәрләре белән тоташтыручы шул өч тарафта да булдык. Ашлык өлгереп килә иде инде. Машиналар трассадан киткәннәр. Механизаторлар комбайннарын, чапкыч җайланмаларын көйләп куйганнар. Юллары нык. Вак таш тигезләп түшәлгән. Инде юл төзүнең үз кешеләре акрынлап кына асфальт та җәя башлаганнар.

Бер яктан, тынычлап калсаң да ярый шикелле. Хәйруллов исә ул хакта уйламый, аны яңа фикерләр канатландырган.

— Моңарчы юл кирәк иде. Хәзер юл буена яңа тормыш иңдерми ярамый,— дип башлады ул.— Күпер салуны көтеп торган урыннар бар, машина тукталышлары кирәк, ял базалары, пионер лагерьлары... Авылларыбыздагы яңа өйләрне дә, киң урамнар ясап, матур иттереп салырга өйрәнәсе бар әле. Бригадалар арасына, фермаларга юллар салачакбыз. Уйларга да куркыныч кебек, ә тотынмый ярамый. Азрак ярдәм дә итсәләр, башкарыр идек әле...

Шулай ул: бер яңа эш икенчесен, өченчесен тартып чыгара. Тик мин ышанам: аларын үтәү иң беренчесенә караганда җиңелрәк булыр. Ник дигәндә, хәзер кешеләр үз көчләренә ышанганнар инде. Алар хәзер, кулга-кул тотынып тәвәккәлләгәндә, теләсә нинди эшне дә башкарып чыгачакларын алдан ук белеп торалар.

Юлларның төрлесе бар. Бетоны бар, бар асфальты, олы юл бар, бар тар сукмак. Аларның күбесе сине еракка алып китә, икенчесе туган-үскән йортыңа кайтарып кертә. Иң кирәге һәм иң авыры — минемчә, үз юлыңны табудыр.

Мин хәзер, апаслылар фидакарьлеген күргәч, юлсыз авылларда яшәүчеләрне элеккечә кызганмыйм инде. Ачыкларга тырышам: болай азапланып яшәүдә алар бары тик үзләре генә гаепле түгелме соң?

# ЕГЕРМЕДӘГЕЛӘР

*Шул яшь чагым, юләр чагым*
*Кайтырсың микән тагын?!*
Халык җыры

*Алтыдагы — алтмышта.*
Халык әйтеме

Яшь шагыйрьләр Ләис Зөлкарнәев белән Рҗаил Зәйдуллинның «Балачак күге» һәм «Кояшлы күзләр» дип исемләнгән беренче китаплары басылып чыкты. Бу китапларда безнең егерме яшьлек замандашларыбызның хис-кичерешләре, уй-фикерләре.

Егерме яшьлекләр... Алар үзләре кеше, шәхес буларак кемнәр? Кешелек үзәкләре, күңел дөньялары кайсы елларда, нинди шартларда формалашкан аларның?

Тулаем бу буынны һәм аерым алганда исемнәре атап кителгән ике яшь шагыйрьне ныграк аңлар өчен башта әнә шул сорауларга җавап эзлик. Аларның — егерме яшьлекләрнең — туу һәм үсү елларына, тормыш юлларына күз салыйк.

## Бәхетле чорның баласы булып...

Алар — бүген егерме яшьтәгеләр — алтмышынчы еллар башлангычтын дөньяга килделәр. Ә алтмышынчы еллар исә бик күп авырлыклар кичергән безнең илебез халкы өчен төрле яктан матур, бәхетле еллар булды.

Ни өчен шулай дибез?

Чөнки бу чорда, бөтен кешенең иң зур куанычы булып, инде икенче дистә имин, тыныч еллар дәвам итте. Тыныч тормыштагы тырыш хезмәтнең нәтиҗәләре дә мул күренде: илебез халкы, ниһаять, иркенләп яши һәм авыз тутырып ипи ашый башлады. Киләчәккә тагын да гүзәлрәк хыяллар торгызды, планнар корды. Аның яшәү көче артты, тормышка булган өмете, ышанычы үсте.

Илебезнең рухи тормышы да бу елларда яңа биеклеккә күтәрелде. Халык дигән бөек көчне хасил итүче гади кешеләрнең кадере һәм бәһасе артты, аңа игътибар көчәйде. «Бөтенесе совет кешесе өчен!»— дигән олы максат шул елларда реаль рәвештә тормышка ашырыла башлады.

Алар — бүген егерме яшьтәгеләр — әнә шундый матур елларда дөньяга килделәр. Чын мәгънәсендә бәхетле чорның бәхетле балалары булып... Ә бит, ныклабрак уйлап карасак, үтә тынгысыз һәм гаять гаугалы бу Җир шарында бәхетле чор тормышының бәхетле баласы булып туу үзе үк күпләр көнләшердәй вакыйга түгелме соң?! Чыннан да, бөтен кешегә дә, һәр буынга да эләкми торган бөек бәхет бит бу!.. Бу-

генге егерме яшьтәгеләр кичкенәдән үк нәкъ шундый бик сирәк эләгә торган бәхетне татып үстеләр.

Ә аларның үсмер чаклары җитмешенче елларга туры килде. Җитмешенче еллар — социаль һәм экономик яктан безнең илебез өчен ышанычлы адымнар белән тыныч үсү еллары булды. Шул ук вакытта бу чорның үзенчәлеге дә бар. Ул елларда илебездә галәмне өйрәнү аеруча көчәйде, шәһәрләшү процессы үзенең иң югары темпын алды, төрле милләт халыкларының үзара аралашуы нык үсте, кеше кулында техника бик күбәйде, информация алмашу тизлеге үтә кызу үсте.

Әле генә санап кителгән үзенчәлекләр алар барысы да җитмешенче еллар кешесенең яшәү сферасы киңәю, аның кинлеккә омтылуы хакында сөйли иде.

Ләкин без бик яхшы беләбез — киңлеккә омтылу процессы ул озак дәвам итә алмый, ул үзе генә яши алмый. Философия өйрәтүе буенча да тормышның нигезен һәрчак капма-каршы көчләрнең үзара тәэсир итешүе, хәрәкәте тәшкил итә. Биредә дә, кеше яшәешенең киңлеккә омтылуына каршы тенденция рәвешендә, җитмешенче елларда икенче бер омтылыш көчәя башлады.

Җитмешенче еллар кешесе һаман зуррак дикъкать белән үзенең чын һәм табигый асылы турында, бөтен дөньяны иңләгән шушы яңа хикмәтләр арасында үзенең кем һәм нәрсә булуы хакында, каян килүе һәм кая баруы, бүгенге хәле, үзенең мәңгелек юлына тугрылык саклый алуы (яисә алмавы) турында уйлана башлады. Бу — эчкә, тирәнгә, үзәккә омтылу тенденциясенә охшаган күренеш иде.

Җитмешенче елларда илебезнең фән һәм культура өлкәсендә, әдәбият-сәнгать дөньясында аерым темаларның, проблемаларның зуррак игътибар белән һәм үтә актив төстә тикшерелүе, өйрәнелүе нәкъ әнә шуны раслады. Табигать һәм кеше, тарих һәм замандаш, халыкның борынгыдан килгән гореф-гадәтләре һәм бүгенге тормыш — үзләренә аеруча зур игътибар туплаган темалар якынча шундыйлар иде.

Ул елларда һәм хәзер дә илебездә иң популяр булган әдипләрнең иҗатын гына карагыз. Ч. Айтматов, В. Распутин, В. Белов — алар барысы да әнә шул хакта дулкынланып язалар. Ә үзебездә Г. Бәширов һәм Ә. Еники иҗаты. Татар укучысы өчен алар — рухи сабак бирүнең олы мәктәбе!

Юк, болар барысы да әдәби күренеш кенә түгел иде. Болар — халыкларның аңында барган тирән һәм көчле процессларның чагылышы иде.

Илебез халыклары яшәешенең төрле өлкәләрендә нәкъ әнә шул елларда кеше өчен иң газиз булган уйлар, мәсьәләләр, проблемалар өскә чыкты, үзәккә куелды. Алар — кешенең ышанычлы һәм перспективалы таяну ноктасы — ныклык тамырын эзләве иде. Хәзер һәм киләчәктә дә бик тә кирәкле яшәү суты бирердәй чыганак эзләү иде бу. Ул ышанычлы чыганак, ул тамыр замананың катлаулы юлларында — югарыда санап үтелгән тенденцияләр арасында, киңлеккә омтылу тенденцияләре арасында — адашмау һәм ышанычлы төстә алга бару өчен кирәк иде.

Шулай итеп, җитмешенче елларның рухи яшәешен бер яктан кешенең киңлеккә омтылуы белән, ә икенче яктан, киресенчә, ниндидер бер үзәк нокта, тамыр эзләү — тарихка, табигатькә игътибар көчәю белән билгеләргә мөмкин.

Бүген егерме яшьтә булган егетләр, кызлар менә шушындый елларда формалаштылар. Иҗтимагый тормышның югарыда санап кителгән тенденцияләре, әлбәттә, аларга тәэсир итте. Бу елларда калыплашкан яшьләр сау-сәламәтрәк һәм чибәррәк булып, белемле, эрудицияле булып үстеләр. Гомумән, без күрергә теләгән гармоник үсештәге шәхесләр иде алар.

Әлеге буынның туу еллары да, үсү чоры да материаль яктан бай, житеш, мул тормышка туры килде, дидек. Ул елларда совет халкы әле моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә бай яши башлады, дидек. Менә шул муллык яшьләргә ничек тәэсир итте соң? Аларның шәхесендә ничек, ни рәвешле чагылды ул?

Әйдәгез, бу мәсьәләгә дикъкать беләнрәк карыйк.

Бу буынга кадәр туган балалар, яшүсмерләр — аякка басу белән диярлек тормышны төзү, ни дә булса эшләү, ясау, төзәтү процессына кушылып китәләр иде. Шулай итеп аларда башта ук төзү, эшләү дәрте кузгала иде, шундый инстинкт эшли башлый иде. Гаиләдәге бөтен атмосфера әнә шуңа этәрә, шул тойгыны көчәйтә иде.

Ә хәзер егерме яшьлекләр буыны, әйтеп узуыбызча, житеш, мул тормышлы чорда туды. Алар бик кечкенә яшьтән үк үзләрендә эшләү, төзү, ясау дәртен көчле итеп тоя алмадылар. Алар алдында инде бик күп әйбер әзер хәлдә иде. Бик күп нәрсә инде алар алдында тезелеп үк диярлек тора иде. Һәрберсе: «Мине ал!», «Мине ал!»— дип.

Һәм аларда бик кечкенәдән үк алу, ия булу, үзеңдә булдыру инстинкты, дәрте уянды, шул эшли башлады. Төзү, эшләү дәрте урынына — алу, ия булу инстинкты көчәйде. Дөньяның тагын да кызыграк, күзне кызыктыра торганрак, кыйммәтлерәк, баш әйләндергечрәк бизәкле әйберләрен күргән саен — бу тойгы, бу дәрт ныграк үсә, тернәкләнә барды.

Бүгенге яшьләрнең кайберләрендә күреп без бик тә аптырый торган «потребительство» авыруы әнә шулай таралды...

Юк, кабатлап әйтеп үтик: әлеге күренеш бу буында бик күп әйбәт сыйфатлар белән бергә яши. Шушыңа карап кына алар хакында начар уйларга һич тә ашыкмыйк!

Ләкин, инде бу турыда сүз чыккач, бүгенге егерме яшьлекләрдә һәм соңгы елларда тормышка аяк баскан бүтән буыннарда да шактый сизелгән тагын бер үзенчәлек хакында да онытмыйк. Ул түбәндәгеләрдән гыйбарәт.

Кечкенәдән үк, яшьтән үк яшәешнең тетрәндерерлек, драматик күренешләре белән чагыштырмача азрак очрашу аларның эчке дөньясын — хис, кичерешләр дөньясын — чагыштырмача азрак хәрәкәтләнүчән, тынычрак, пассиврак итте. Аларның күңел дөньясы бераз соңлабрак житлекте... Шул ук момент тагын бүтәнчәрәк тә чагылды. Кечкенәдән үк тормыш каршылыклары белән азрак очрашу, алар белән азрак бәрелешү, ул каршылыклар аша үз көчеңне түгә-түгә, шуның нәтиҗәсендә чыныга-чыныга үсү юлы җиңел булу — аларның шәхесен йомшаграк, чыныкмаганрак, инфантильрәк итте. Без көткән нык шәхес формалашу процессы шактый озынайды. Әнә шуңа күрә соңгы елларда безнең арабызда сакаллы сабыйлар — утызга, кырыкка житсә дә үзбаш яши алмаган, дөнья көтә алмаган, үзе генә житди итеп фикер йөртә алмаган егет кисәкләре шактый очрый башлады...

Ә бу яшь шагыйрьләрне иҗатчылар буларак тәрбияләгән татар шигърияте әлеге елларда ниндирәк хәлдә иде — ничегрәк яши иде соң?

Үз сафында тормышның зур сынауларын үткән өлкән буын шагыйрьләре булган, төпкә җигелеп урта буын шигырь осталары иҗат иткән, алтмышынчы елларда җилләп-давыллап тулы бер отряд яшь шагыйрьләр килеп кушылган татар шигърияте, әлбәттә, бу елларда да бер урында таптанмады, үсте, алга барды. Житмешенче еллар татар поэзиясе халыкка, укучыга поэма жанрында да, аерым шигырьләр рәвешендә дә бик күп һәм гүзәл үрнәкләр бирде. Алтмышынчы еллардагы рухи һәм шигъри яңарышның матур нәтиҗәләре булып ул елларда поэзиябездә сүзнең кадере арту, аның мөмкинлекләре күбәю һәм шулар нәтиҗәсендә шигъри әсәрләрнең тәэсир көче үсү күзәтелде.

Инде житмешенче еллар башлангачтын поэзиягә килгән яңа буын шагыйрьләр бу матур сыйфатларга яңаларын өстәргә тиешләр иде. Татар шигъриятен яңа кан, яңа төс, яңа җил белән җанландырып җибәрергә тиешләр иде... Юк, болай катгый итеп «тиеш» дип әйтү ул яңалыкка сусаган күңелнең капризы гына түгел. Әлеге мәсьәләне тулырак күзаллау өчен табигатьтән бер чагыштыру китерәсе килә. Үсеп утырган агач һәр елны яшь, яңа яфраклар чыгара. Бу аның терелеге, үсүе билгесе генә түгел. Бу — яңа, тере организмга, кирәкле иң беренче шарт та. Үзенең әнә шул яп-яшь, йоп-йомшак, өр-яңа яшел яфраклары белән, шулар ярдәмендә, агач үзенең үсүе өчен бик мөһим булган эшне башкара. Шигърият дөньясына кайтсак, анда да шулай. Яшь һәм көчле сәләтләр — иң беренче чиратта шигъриятькә яңа кан булып килеп керәләр, аны баеталар.

Житмешенче елларда шигъриятебез, кызганычка каршы, үзенә андый көчле этәргеч, стимул ала алмады. Тагын да югарырак үсеш өчен иң кирәкле сыйфат — яңа көчләр хисабына эчке хәрәкәт көчәеп алу — бу елларда күзәтелмәде. Ә бит хәрәкәт ул — һәрбер үсешнең нигезе, башы. Әгәр дә без тарихка борылып карасак күрәбез: үсеш көчле булган еллар һәрвакыт активлык белән, кешеләрдә фикер һәм хис кайнавы белән, яңа рухи биеклекләр өчен көрәш белән аерылып тора.

Әнә шундый көчле дулкын булмау ул елларның яшьләр шигъриятен шактый төссезләндерде, сүрәнәйтте. Бигрәк тә житмешенче елларның икенче яртысында рифмаланган һәм шома такмаклар «шигырь» дип еш басыла башлады. Аларның фикере дә, хисе дә бик чамалы иде.

Нәтиҗәдә, яшь буын шигырь сөючеләрдә ризасызлык сизелде, аларның шигъриятькә күпмедер дәрәҗәдә игътибары кимеде. Сиксәненче еллар башында «Татарстан яшьләре» газетасы алып барган «Шигырьне кем укый?» исемле дискуссия моңа иң ачык мисал булды.

Бүген без иҗатларын күзәтә торган яшь шагыйрьләр әнә шул чорда шигырь мәктәбен уздылар. Житмешенче еллардагы татар шигърияте, андагы атмосфера алар өчен бердәнбер дип әйтерлек иҗади тәрбия мәктәбе иде.

Житмешенче еллар тормышының һәм шул еллар шигъриятенең тәрбиясен алып алар бәйгегә — иҗат дөньясына килеп керделәр.

## Бәйгегә чыккач...

Егерме яшьлек шагыйрьләр бүген үзләрен бәйгедә итеп тоялар. «Мин ярдә! Ат өстендә беренче кат. Талгын гына аккан каным, уян!» — дип яза Ркаил Зәйдуллин. Ә аның яшьтәше Ләис Зөлкарнәев бу фикерне тагын да киңәйтә төшә һәм: «Бәй өченмени ат — бәйге өчен!» — ди. Икенче бер шигырендә шул ук Л. Зөлкарнәев үз буынын бәйгедә итеп күзаллап: «Соң көнгәчә — шушы бәйге. Соң көнгәчә — тантана!» — дип тә белдерә.

Әйе, ике яшь шагыйрь дә бүгенге тормышта үз буыннарына туры килгән олы җаваплылыкны дөрес аңлыйлар. Чыннан да, хәзерге егерме яшьлекләргә илебез, халкыбыз бик зур өметләр баглый.

Һәм яшьләр сынатмыйлар. Иң җаваплы, иң авыр урыннарда алар матур-матур эшләр белән яшьлекнең, комсомолның, үзләренең биографияләрен язалар. Бөек Ватан сугышы чорында бик күп яшьләр мәктәп эскәмиясеннән туп-туры фронтка киткән кебек, бүген дә безнең бик күп яшь замандашларыбыз урта мәктәпне тәмамлау белән иң җаваплы, иң авыр урыннарда, мөһим төзелешләрдә эшли башлыйлар. Егетлек үрнәкләре күрсәтәләр. Яшәешнең күп ситуацияләрендә егет булырга өйрәнәләр.

Ике яшь шагыйрь үз буыннарының трибуны, җырчысы буларак вазифаларын ничек үтиләр? Алар өчен бәйге әнә шул бит инде — иҗат. Әйдәгез, аларның шигырьләренең эченәрәк керик. Анда кем, нинди шәхес яши? Ул нәрсә тели, кая омтыла? Һәм иң мөһиме: бүгенге тормышта ул үзе нинди конкрет эш башкара — нинди проблемаларны хәл итәргә тырышып яши?

Яшь шагыйрьләрнең китапларын ачабыз. Ләис Зөлкарнәев яза: «Әнкәм кебек халкым! Мин — кәүсәңдә Яңа шыткан нәни ылысың», «Бу бәйгенең йолалары Бабайлардан калганча», «Җылынырга урын эзләп йөрим Борынгылар торган төбәктә», «Аяз күктә урак ае булган Һәр калкулык — бабам кабере!»

Ркаил Зәйдуллин яза: «Буразнадан бәреп чыккан нәсел, Җан асрыйм бик гадәти якта, Тарту көчен җиңүчеләрне дә Күз алдына китерә алмыйм хәтта», «Син, язмыш, аерма бу телдән, Бу җирдән аерма», «Иманым нык, шул ук сезнең иман! Таңнарыма чыгам, кичеп төнне... Нигә һаман тыныч түгел күңел: Сезнең дәвамы мин, сезнекеме?»

Әйе, үткәнгә — үзеңнең һәм үз халкыңның үткәненә булган игътибар ике яшь шагыйрьдә дә көчле. Алар иҗаты өчен әнә шундый дөрес нигез, бәрәкәтле туфрак тудыруда, югарыда әйтеп үтелгәнчә, җитмешенче еллар рухи атмосферасы зур роль уйнады. Ул елларда чынбарлыкның үзендә бу тенденция көчле иде. Аннан соң тагын бер сәбәп. Яшь шагыйрьләр — икесе дә авыл егетләре. Ә авыл җирендә безнең халкыбызның олы кешегә булган хөрмәте бик зур. Яшьләр, әлбәттә, кечкенәдән үк аны тоеп үскәннәр. Шул тойгы тагын да көчәеп аларның иҗатына да саркып кергән. Өченче бер сәбәп: икесе дә урта мәктәп бетерү белән шәһәргә килеп югары уку йортында белем ала башлаганнар. Илнең, халыкның ерак үткәне белән танышканнар. Танышу вакытында үзләре өчен бик дулкынландыргыч хәлләргә юлыкканнар. Аларның күңелләрендә шигъри кичерешләр туган.

Яшь шагыйрьләрнең үткән белән ныклы бәйләнешне тою хисе, аңлау җебе әнә шулай хасил булган. Бу — алар өчен һәм, гомумән, яшь буын өчен дә, хәтта һәр кеше өчен дә үтә мөһим фактор. Чөнки кешенең, кешеләрнең ныклыгы әнә шул бөек бәйләнеш чылбырында үз урынын табудан, үз вазифасын аңлаудан һәм аны тормышка ашырудан тора.

Әнә шул олы чылбырга, олы чыганакка тоташа, ялгана алу — яшь шагыйрьләрнең зур бәхете!

Ә бу тоташу аларга һәм аларның иҗатына ниләр бирә соң?

Иң беренчедән — алар, әле үз тәҗрибәләренә ия булмаган егерме яшьлекләр, үткән буыннар, өлкән буыннар яшәеше мисалында, шул нигездә үзләре өчен бик мөһим нәтиҗәләр ясыйлар. Бу — алар өчен бик олы рухи тәҗрибә мәктәбе.

Ләис Зөлкарнәевнең «Гармунчы бабай» шигырендәге карт бабай менә нәрсә ди:

Онығымның малаена
Әманәтем — моңым бар.

Гармунымны тотмаса да,
Моңымны отсын бала.
Борынгы моң онытылса,
Көйсез була замана.

Әйе, яшь шагыйрь карт кешенең йөрәк түрендә йөргән иң кадерле сүзне генә табып әйтми, бу — безнең һәрберебезнең йөрәк түрендә дә йөрергә тиешле сүз!

Ркаил Зәйдуллинның «Төш» исемле шигыре дә өлкәннәр тормышыннан.

Пышылдады агай калтыранып:
Коточкыч төш керде, коточкыч төш.
Беренче кат мондый курку минем.
Ахры, кабәм, акылымнан язам.—
Кара урман килде өскә шаулап,
Сытып китә иде уянмасам.

Үз гомерендә әллә никадәр агачны еккан карт урман кисүченең бу куркыныч төше аша яшь шагыйрьнең нинди нәтиҗә ясавы ачык. Бигрәк тә шигырьнең соңгы юллары — «Әйт ике сүз, нинди дарулар бар? Нинди дару урман каргышына?»— укучының үзәгенә үтәрдәй булып яңгырый.

Үткәннәр белән тыгыз бәйләнеш яшь шагыйрьләрнең шигырьләрендә үзен даими сиздереп тора. Ркаил Зәйдуллин шигырьләрендә ул «богауланган Бруно» булып та «Петербург зинданында яткан телсез Батырша» булып та, «Лашманчылар» булып та керә һәм яшьлекне бөек идеаллар хакына тынгысыз эшкә, көрәшкә рухландыручы шигъри образлар ролен үти. Бруно хакындагы шигырьдәге түбәндәге юллар, һичшиксез, яшь шагыйрьнең зур уңышы:

Әмма кабат өстә калырмын мин
Барлык ваклыгыннан бу дөньяның —
Чәлпәрәмә, чәлпәрәмә килеп
Күккә сибелер җаным.
...Йолдызларга багып мәхзүн җанны
төшерерсез искә,—
Галәм өчен яратылган затның
Кабере-дә өстә!

Ә Ләис Зөлкарнәев җирдәге тормышны, яшәешне бер тоташ агым итеп тоя. Аның шигырьләренә бик тә мәгънәле булып гасырлар белән гасырларны тоташтыручы образлар: җил, давыл, ат килеп керә. Әнә шулай итеп бер яшәү стихиясе туа. Чорлар белән чорларны бәйләүче бер нык чылбырда үзен мөһим божра итеп тою яшь шагыйрьгә гаять зур җаваплылык йөкли. Ул моны яхшы аңлый. Шигырьне йомгаклаучы түбәндәге сүзләр шул хакта сөйли:

Ярсып, һаман мин шигырьләр язам...
Һәр чор өчен җаным борчуда.
Кратер эзләп типкән вулкан кебек —
Бәгырем,
Исем эзлә, эзлә бу чордан!

Яшь шагыйрьләр әнә шулай итеп үзләренең лирик геройларын гәүдәләндерәләр. Ул герой тормышның, яшәешнең дәвамлы булуын, өзлексез бербөтенлеген тоя. Ул — үткәннәр каршында да, бүгенге көн һәм киләчәк өчен дә бертигез дәрәҗәдә җаваплы.

Ә шулай да һәр чорның бик конкрет яшәеше бар. Кеше әнә шунда намуслы гомер итү аша гына мәңгелек юлына чыга ала. Безнең яшь шагыйрьләрнең лирик геройлары бүгенге көндә ничек, ни рәвешле яши?

Аларның әсәрләрендә бүгенге көннең шактый драматизмы чагыла. Ләис Зөлкарнәев үзенең бер шигырен ятим малайга багышлый. Ул болында печән чаба. Куллары кабарып, канланып бетсә дә — чаба.

Яшь шагыйрь аны тирәннән ача һәм шигыренең соңгы строфасын болай тәмамлый:

Эндәшүчең булса икән:
«Улым, кил, җитәр инде».
Зур чалгысын читкә ташлап,
Берсүзсез китәр иде...

Күрәсезме — эти кеше әйтергә тиеш булган һәм әйтелмәгән дүрт сүз шигырьгә нинди тәэсир көче бирә! Яшь шагыйрь ул сүзләрнең көчен һәм моңын нечкә сиземли, шигырь строфасында аннан уңышлы файдалана.

Ә Ркаил Зәйдуллинда бүгенге көннән килгән нindирәк ноталар ишетелә?

Менә ул картайган эт язмышын яза. Бабай белән оныгы кичкырын аны авыл читенә алып чыгалар... «Мылтык тавышы кырда, Бабай канәгать — куллар шәп!.. Оныгы карап тора».

...Кузгалалар өйгә таба,
Дәшмиләр, никтер читен...
Кайталар җуеп
Дөньяның
Күзләре дымлы этен.

Әлбәттә, яшь шагыйрьләрнең икесе дә үз күңелләренә авыл тормышыннан, үзләренең балачагыннан кереп, сеңеп калган күренешләрне күбрәк язалар. Бу бик аңлашыла, чөнки аларның егерме яшькә кадәр гомеренең иң зур өлеше әнә шунда үткән. Ләкин әкрен генә булса да яңа тормыш — инде шәһәргә килеп яши башлагач туган моңнар да китапларда чагыла. Р. Зәйдуллинның «Чияләр» исемле һәм Л. Зөлкарнәевнең «1981! Январь» шигырьләре шуны раслый. Ләкин әле алар бик аз...

Егерме яшь... Йөрәкләрдә мәхәббәтнең гөрләп чәчәк аткан чагы...

Мәңгелек бу хис турында яшь шагыйрьләрнең һәркайсы үзенчә җырлый:

Күзләреңне миннән яшермә син:
Килер үлем —
Тынар дәртле йөрәк.
Гомер безгә тик бер тапкыр килә —
Сөелергә һәм сөяргә кирәк!

(Р. Зәйдуллин).

Яшьлек диган болынлыкта
Матур чәчәк тапкан чак.
Көлеп торган шул чәчәккә
Чыклар булып тамган чак.

(Л. Зөлкарнәев).

Аларның мәхәббәт җырларында — яшьлекнең бөтен гүзәллеге дә, күңелгә моңсулык бирә торган күренешләре дә... «Иртән торсам, бөтен дөнья үзгәргән. Иң гаҗәбе үзгәргән күрше кызы — Тәнзилә... Мин дә үзгәргәнмен... Теләкләрем бүтән — бер биисем килә, бер җырлыйсым... Һәм елыйсым килә аз гына... Иң гаҗәбе — эндәшәсе килә Тәнзиләгә — күрше кызына». (Р. Зәйдуллин). «Очкын миңа түгел, сиңа тигән. Ах, мин аны нигә күрмәдем!— Бер караусыз төнге учак сыман, Янәшәмдә янган йөрәгең...» (Л. Зөлкарнәев).

Әйе, биредә әле нәкъ егерме яшькә кадәргеләр мәхәббәте: ул барысыннан көчле, ул бөтенесеннән югары, ул хисләрнең иң сафы, тугрысы... Күлер вакыт һәм егермедәгеләрнең әле хәзергә күбрәк гомуми билгеләр беләнрәк кенә гәүдәләнгән бу олы хисе конкретлаша, ачыклана төшәр. Әнә шуның белән ул хис тагын да тирәнәер, аның укучы өчен мәгънә яңалыгы, кадере артыр...

Без яшь шагыйрьләр иҗаты тудырган лирик герой белән кыскача танышып чыктык. Аның кем булуын, ничек яшәвен күрдек. Бүгенге шигъри бәйгедәге яшь шагыйрьләр үзләренең мөһим уй-хисләре, кичерешләре белән безнең күңелдә дә эз калдырдылар.

Әйе, бәйге дәвам итә... Ә без тагын бер сорауга җавап эзләп карыйк: аларның «талант» дип аталган шигъри атларының аерымлыклары, үзенчәлекләре нәрсәдә соң?

Ләис Зөлкарнәев шигырьләре. Анда яшәешнең гомумиләштерелгән, мәгънә ягыннан киң масштаблы күренешләренә күбрәк игътибар ителә. Яшь шагыйрь укучыда әнә шундый уй-фикер, кичереш тудырырга тели. Сәнгать чаралары белән безнең күңел дөньябызны шуңа алып килә. Беренче китаптагы бик күп шигырьләр раслый моны. Бигрәк тә «Качышлы уйнау», «Билгесез борынгы көйгә», «Купты күңел...» шигырьләр. Икенче итеп аталган шигырьдә яшь шагыйрь мондый күренеш тасвирлый:

Җилдән җиләс үлән булсаң
Җил сине карга төрә шул
Җил сине карга төрә...

. . . . . . . . . . . . . .

Тибеп-тибеп бозлы карны
Далада болан йөрә шул
Ачыккан болан йөрә...

Менә бу шигырь яшь шагыйрь иҗатында киң чагылган бер сыйфатны иң калку итеп гәүдәләндерә. Анда нәфис һәм тәэсирле итеп язылган шигъри күренеш тә бар, ул күренештәге һәр зат, һәр әйбер зур мәгънә катламнарына да ия. Шигырь үзе дә борынгы бер җыр кебек тыңланыла, ишетелә. Чыннан да, автор аңа исемне бик дөрес куйган. Ә киңрәк планда караганда бу шигырь һәм моның кебек бүтән әсәрләр яшь шагыйрьнең үзенең борынгылардан калган көйне отып калганлыгын тагын бер мәртәбә раслап торалар.

Шушы ук яшь шагыйрьнең бераз гына икенчерәк характердагы, ләкин барыбер әле генә әйтеп кителгән сүзләрне раслаучы бүтән шигыренә тукталыйк. Ул ике генә строфадан тора.

Купты күңел — кабынды җил куакларда.
Мин очамын, янып оча яфраклар да.
Таны мине, аралап ал, аралап ал —
Яфрак та мин, җил-җиләс тә, җисмем барда...

Җиргә сыенып мин тынармын, җил дә тынар.
Салмак кына күмеп китәр онытылу — кар.
Күмсә дә кар — аралап ал, аралап ал,—
Туфракта мин, һавада мин — миндә җан бар...

Иң әлек шигырь безгә үзәк өзгеч моңы белән тәэсир итә. Бик тә урынлы булып кабатланып килүче «аралап ал, аралап ал...» сүзләре ул моңны тагын да көчәйтә һәм анда үлем дигән бөек трагедия белән

өмет дигән бөек ышанычның кеше күңелендәге газаплы көрәше авазлары яңгырый башлый... Аралап ал, аралап ал... Әйе, бу сүзләрдә юкка чыгуның төпсез упкыны дәһшәте дә, аның авызыннан суырып алырга кушучы, үтенүче тавыш та... Боларны тоя, ишетә алу — яшь шагыйрь өчен мәртәбә.

Ләис Зөлкарнәевнең гомумиләштерелгән, киң масштаблы мәгънәләр хакында күбрәк язарга тырышуын тагын шул раслый — аның шигырьләрендә табигатьнең төрле-төрле күренешләре бик актив кулланыла. Җил дә, яңгыр да, кар да, тынлык та, офыклар да, күләгә дә, көй дә, сандугач та — һәрберсе яшәешнең яңа бер ягын ачып җибәрә. Юк, алар катып калган, статик хәлдәге һәм күп шигырьләрдә күренеп инде укучыны туйдырып бетергән таныш рәсемнәр түгел. Алар аша яшь шагыйрь кешеләр яшәешен чагылдыра, кеше күңелен ача. Менә аның яшь кыз белән чагыштырып бирелгән «Кыска яңгыр» дигән шигыре.

Килә текә генә атлап.
Адымы еш һәм тыгыз.
Таждан тажга басып килә
Нәзек кенә кыз.

. . . . . . . . . . . . .

Туктала да кызулый ул,
Балкып китә тезләре!
Гүзәллеккә таң калыпмы,
Гөлләр җиргә тезләнде...

Һәр шигырьдә әнә шулай җанлы тормыш, яңа яшәеш.

Боларның барысын йомгаклап шундый нәтиҗәгә килергә мөмкин: Ләис Зөлкарнәев өчен әйләнә-тирәдәге тормыш, чынбарлык, табигать күренешләре — беренчел әһәмияткә ия. Аларны үз хәлендә, ничек бар шулай күргәннән, тойганнан соң ул аларны шигъри күңеле аша үткәрә. Ныклы чынбарлыкның гомумиләштерелгән мәгънәләрен биргән матур шигырьләр әнә шулай пәйда була...

Хәзер инде Ркаил Зәйдуллин шигырьләренә мөрәҗәгать итик. Аларга иң хас сыйфат — ярсу. Хисннең, кичерешнең ярсуы. Тик кенә, тыныч кына тора алмавы. Шуңа күрә ул «йөрәк яна», «җаным шаша», «дөрлим, дулкынланам», «еладым», «гарасатлар», «давыл» шикелле сүзләрне еш куллана. Бу яшь шагыйрь, беренче чиратта, кайнар, ярсу хис белдерергә тырыша. Күбрәк шуңа басым ясый, шуңа ышана. Ул күтәренке рухта, тавышны шактый күтәреп, пафос белән язарга ярата. Укучыга шулай итеп тәэсир итәргә омтыла.

Мин янам,
шатланам,
газапланам,
Гаҗәп түгел — дөнья бу!
Карап тора миңа күзләр —
Йөзләрендә тук елмаю.

. . . . . . . . . . . .

Тик җирәнсәм кемнәрдәндер,
Кичерегез —
Йөзләрендә тук елмаю.

Әйе, безнең алда нәкъ менә егерме яшьлек шәхес. Шигырьдә аның хис кайнавы да ачык, ул фикерен дә ярып, хәтта ялангач ук итеп әйтә. Әмма урыны-урыны белән «Нарасый өзгән алмада Яна ике теш эзе.

Безме соң бу, безме...» кебек юллар очрап куя. Алар әсәрдә логик эзлеклелеккә күбрәк игътибар кирәклеге хакында сөйли.

Әлбәттә, без тукталган бу момент күпмедер дәрәҗәдә яшьлек белән аклана. Хис-тойгының ачыграк, калкурак һәм исемләрәк була баруы еллар белән бергә килер. Тик аңа хәзер үк игътибар итмичә ярамый.

Ачык, калку хисләр Р. Зәйдуллинның байтак шигырьләрен көчле тәэсирле итә. Минә Пермь якларына баргач язылган «Тайга моннан башлана икән бит...» дигән шигырь:

> Елмаям да кәгазь-каләм эзлим,
> Шушы урман, һәм сез, һәм бу сазлык
> Акрын гына миңа әйләнгәндә
> Шигырь язмау язык бит ул, язык.

Биредә инде дөнья белән очрашкан вакытта туган ап-ачык һәм көчле хис! Яшь шагыйрьләрне олылыкка алып бара торган ышанычлы сукмак та әнә шуннан үтә түгелме соң инде!

Әйе, минә шушындый уңышлы шигырьләре белән бу ике яшь шагыйрь сиксәненче еллар башында әдәби җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итте. Минә шул елларда алар әдәби бәйгегә килеп керделәр.

Ә хәзер яшь татар шагыйрьләренең иҗади бәйгесендә бу ике яшь шагыйрь кайда бара? Соңгы елларда шигърияткә килгән яшьләр фонында караганда аларның шигырьләре үзләренең нинди сыйфатлары белән аерылып тора?

Беренчедән — хиснең һәм фикернең табигыйлектән ераклашмаган хәлдә тыгызлыгы, экспрессивлыгы, көчле тәэсире белән. Соңгы елларда яшьләр шигърияте нәкъ менә шушы сыйфатлар җитешмәгәнгә — бик күп шигырьләр озын һәм көпшәк булганга күрә — укучыларда ризасызлык тудыра башлаган иде.

Икенчедән — дөньяны ерак һәм якын перспективада да букбөтен итеп күрү, тою булганга. Күпләр вак күренешләр, артык әһәмиятсез кичерешләр һәм фрагментар фикерләр белән мавыкканда, мондый бербөтенлек тойгысы укучыга бик кадерле иде. Әнә шул юл белән укучыга олы фикерләр килә ала иде.

Өченчедән — шигырьләрдәге ихлас һәм нәфис мәхәббәт лирикасы белән. Аларның шигырьләрендәге ихласлык бик күп очракта кыюлык, яңалык булып яңгырады. Әһәмиятле тирәнлекләр ачты, укучының мәхәббәт тойгысын баетты.

Дүртенчедән — бу ике яшь шагыйрь бүтәннәрдән шактый югары дәрәҗәдәге шигырь культурасы белән аерылып торды. Алар үзләренең иң уңышлы әсәрләрендә тирән хиснең, олы фикернең һәм нәфис форманың бер нечкә моңга әверелүенә ирешә алдылар.

Менә шушы һәм тагын башка уңай яклар бу ике яшь шагыйрьне яшь татар поэзиясе бәйгесендә күз алдына чыгарды. Алар игътибар үзәгенә элэктеләр.

Ә бәйге дәвам итә...

## Иң кыены, иң җаваплысы...

Яшь шагыйрьләргә хәзер — иҗади бәйгегә килеп кереп халык игътибарын җәлеп иткәч — сынатмау өчен, укучының ышанычын аклап чыгу өчен бик күп көч куярга туры киләчәк.

Ни өчен аларга бик күп көч куярга кирәк дигән таләпне куябыз?

Бусы да алар туып үскән һәм без соңгы елларда яшәгән чорның үзенчәлеге белән бәйле. Әйе, алар туып үскән чор, чыннан да, бәхетле, матур чор. Ләкин һичничек тә тормышның үсеш каршылыклары бет-

кән, юкка чыккан чор түгел. Социалистик җәмгыятебезнең үсешен өйрәнүче галимнәр соңгы елларда күрсәтеп үткәнчә, үсеш каршылыклары хәзер тормышның эченәрәк кучкәннәр, күп яктан нечкәргәннәр, рәвешләрен алыштырганнар. Гомуми үсеш һәм коммунистик идеал өчен көрәш хәзер тормышның өске катламнарында гына түгел — ә эчтәгерәк, тирәндәгерәк көчләр белән, тенденцияләр белән дәвам итә.

Безнең яшь шагыйрьләребез хәзер әнә шул, шактый тирәндә яшәгән каршылыкларны тоярга, аңларга һәм үз иҗатлары белән прогрессив көчләргә булышырга тиешләр. Ә бу миссия, яхшы беләбез, аларга бер дә җиңел булмаячак.

Тагын бер мөһим момент. Шәхси тормыш юлы, биография мәсьәләсе.

Өлкән һәм урта буын әдипләр инде күптән үк, алдан ук кисәтә килделәр. «Яшьләрнең шәхси тәҗрибә багажлары торган саен сайрак була бара, алар әдәбиятка һаман саен җиңелрәк юлдан киләләр. Бу — әдәбият, иҗат өчен хәвефле күренеш!»— диләр иде алар.

Әлеге мөһим моментның иҗат өчен кыенлык тудыруы Р. Зәйдуллин белән Л. Зөлкарнәевка кадәр булган буыннарда да инде нык кына сизелә иде. Уйлап чыгарып яисә каяндыр укыганнан чыгып кына «әсәрләр» язу моннан алдагы буыннарда да бар иде инде. Менә хәзер, сиксәненче елларда, язучының үз биографиясе мәсьәләсе безнең әдәбият алдына бөтен җитдилеге белән килеп басты. Яшь шагыйрьләрнең беренче китаплары шул хакта сөйли.

Яшь шагыйрьләрнең беренче китапларында алар үзләре тормышта тап булып, шул нигездә әйбәт шигырь туган яңа күренешләр аз. Р. Зәйдуллин китабында алар менә нинди күренешләр: карт этне алып чыгып аталар, асфальтка чия түгелә, тал тамырын кисәләр, карт урманчы төш күрә, бер бабай ишек ясый, малай бозау белән хушлаша һәм — бетте. Л. Зөлкарнәевтә — ятим малай печән чаба, карт аучы бүре суга, ятим калган йорт, алданган кыз һәм шулай ук нокта куябыз.

Шәхси тормыш тәҗрибәсе аз булгач, әлбәттә, башка чыганак эзләргә кала. Һәм яшь шагыйрьләр укыган, ишеткән буенча күп язалар. Ә бу нәрсә аларны бик сирәк очракта гына уңышка алып килә. Күп очракта ике төрле уңышсызлык килеп чыга. Артык гомуми, конкрет хисе, тәэсире булмаган шигырьләр һәм икенчел шигырьләр — яңа хисе, фикере булмаган, әдәбиятта инде әйтелгән мәгънәне кабатлауга корылган шигырьләр. Андый шигырьләр ике китапта да шактый күп. «Җиңү көне», «Каен кызы», «Туйлар», «Ялгыз торна», «Батырша», «Шагыйрьләрнең каберләрен эзлим», «Чит җирдә», «Озатмагыз»— болары Р. Зәйдуллин китабында. «...Бетәшми тын»..., «Башлар гына түгел»..., «...Нинди юләр»..., «Бар дөньяның ямен»..., «Күзгә туйлар»— ә болары Л. Зөлкарнәев китабыннан.

Әйткәнебезчә, мондый шигырьләр күп булуның сәбәбе бер генә — үзендә, үз күңелендә җанлы тормыш күренешләре аз булу.

Менә без әкренләп бөтен җепләр бергә төйнәлгән ноктага килеп җиттек. Яшь шагыйрьләргә бүгенге тормышның эчкәрегә кучкән нечкә каршылыкларын тою һәм аңлау өчен дә иҗатчы буларак яңа материалга аптырамас өчен дә — шәхси биография кирәк.

Шәхси биография. Бу нәрсә дигән сүз? Аңа ия булу өчен күнегелгән яшәү рәвешеңне, укуыңны яисә эшеңне ташлап, башкаладагы тормышыңны калдырып каядыр еракка — БАМга яисә Уренгойга китәргә кирәкме?

Билгеле, яшь чагында дөнья күрү, төрле җирдәге төрлечә яшәешне күрү — анысы беркемгә дә комачаулый торган әйбер түгел. Аның зыяны тимәс.

Әмма, минемчә, тормыш нигездә бер ул. Ә менә аңа мөнәсәбәт төрлечә була. Актив яисә пассив була. Берәүләр тормышның иң үзәк конфликтлары эчендә яшиләр, җирдә кешеләр арасында матур мөнәсәбәтне күбәйтү өчен тырышалар. Ә икенчеләр бу төп көрәштән читтә калып, үзләрен тылда итеп сизәләр. Рухи көрәшләрнең тылында.

Бүгенге шагыйрь өчен нәрсә иң мөһим?

Планетабызда бара торган бер бик зур көрәшнең — олы Намус көрәшенең — бер солдаты, бер көрәшчесе итеп тою!

Безнең яшь шагыйрьләребезнең баштарак күреп киткән бик яхшы сыйфатлары бар: алар үзләрен буыннан-буынга килгән бер һәм өзелмәс сафта көрәшче итеп тоялар. Бусы бик яхшы. Ачыграк күзаллау өчен кәгазьгә сызып карасак бу — вертикаль буенча берлекне, бердәмлекне, дәвамлылыкны аңлау булыр. Үткәнне, бүгенгене һәм киләчәкне тоташтыручы бер сызык, бер җеп булыр.

Менә хәзер аларга икенче бер бөек бәйләнеш җебен дә аңларга һәм үзләренең реаль яшәешләрендә тоярга кирәк. Бүген җирдә яшәгән намуслы кешеләрнең матурлык өчен, кешелекле мөнәсәбәтләр урнаштыру өчен барган көрәшенең дә бер икәнен һәм бербөтен икәнен тоярга кирәк аларга. Планетабыздагы әнә шул бөтен көрәшләр сыйнфыйлык дигән ныклы җеп белән бергә тоташкан. Бу — тырыш хезмәт белән намуслы яшәүчеләрнең бер һәм бердәм сафы. Сызымга төшереп карасак — горизонталь буенча — ягъни бүгенге көннең төрле җирдәге, төрле илдәге намуслы кешеләрен бергә тоташтыручы сызык, җеп булыр бу.

Менә шул олы бәйләнешне тою, аңлау бүгенге көрәшчеләрнең һәркайсына көч һәм дәрт биреп тора. Үзләренең әнә шул бер һәм бердәм фронтта икәнлекләрен белү вакытлы яисә урыны-урыны белән очраучы уңышсызлыкларга карап кына аларның күңелен төшерми, иманын какшатмый. Бүген планетабызда бик күпләр әнә шул гаять киң колачлы көрәшкә кушылып үз эшләренең зурлыгына, үз гомерләренең мәгънәлегенә, аның янар йолдыз сыман балкып торуына ирешәләр.

Безнең яшь шагыйрьләр хәзер менә шушы зур хакыйкатьне белергә, аңларга һәм үз тормышларында чынга ашырырга тиешләр.

Алай гына да түгел. Әгәр дә алар үзләрен планетада бара торган бүгенге олы көрәштә бер көрәшче итеп тоймасалар — алар шәхес буларак үсә алмаячаклар һәм аларның иҗатлары да зурлык, киңлек таба алмаячак.

Бүгенге иҗатчының үзенә һәм язганнарына чын Олылык, чын Киңлек яулау юлы әнә шул юнәлештә генә!

**Мансур ВӘЛИЕВ.**

# ТАТАР ШИГЪРИЯТЕ КҮГЕНДӘ...

Соңгы вакытта татар әдәбиятында хатын-кызларның активлыгы күзгә ташлана. Безнең өчен куанычлы хәл бу. Өр-яңа иҗади көчләр хәзер әдәбиятыбызны, культурабызны үстерүдә үзләреннән лаеклы өлеш кертәләр дигән сүз бу. Хатын-кызлардан безнең өлкән прозаик Ләбибә Ихсановабыз, роман язу дәрәҗәсенә күтәрелгән Мәдинә Маликовабыз, башка прозаикларыбыз, шагыйрәләребез бар. Саҗидә Сөләйманова поэзиясе татар әдәбиятында иң яхшы үрнәкләрнең берсе санала. Әлерәк кенә татар шигърияте күгендә Нурия Измайлова дигән йолдыз балкый башлады. 1983 елда без «Казан утлары»нда Фәүзия Бәйрәмованың «Болын» дип аталган шигъри повестен укып сөендек.

Бу арада матбугат битләрендә яңа бер исем күзгә чалына башлады. Ул да булса — Эльмира Шәрифуллина. Мәсәлән, «Казан утлары»ның 1984 елгы өченче санында аның берничә шигыре басылган. «Татарстан яшьләре»нең 29 мартта чыккан санында шулай ук Эльмира Шәрифуллина шигырьләренә киң урын бирелгән. Шагыйрәнең иҗатына киләчәктә аның каләмдәшләре дә, тәнкыйтьчеләр дә игътибар итми калмаслар дип уйлыйм. Хәзергә мин үземнең кайбер фикерләрем белән уртаклашмакчы булдым.

Шигырьләрнең күпчелеге сөю-мәхәббәт, аерылышу, юксыну турында языла. Адәм баласының һәркайсы ярата, моңлана, сагышлана белә. Бер-береңне ярату, табигатьне, тормышны һәм тормыштагы барлык матурлыкны, барлык яхшыны ярату сәләте безгә тумыштан бирелгән. Ләкин тумыштан бирелгән һәр нәрсә безнең барыбызда да бер үк дәрәҗәдә көчле, түгел. Бары шагыйрь генә үзенең нечкә, катлаулы күңел хисләрен, тойгыларын сүз ярдәмендә укучыга-тыңлаучыга дөрес итеп, төгәл итеп җиткерә ала. Шагыйрь «кулында» гап-гади сүз тылсым көченә ия була. Шул тылсымлы сүзләр аша без шагыйрьнең хисләрен үзебезнеке кебек итеп тоябыз. Шагыйрь белән безнең арада рухи туганлык, бердәмлек барлыкка килә. Хис, тойгы белән чыныктырылган сүз ярдәмендә шагыйрь безне чын мәгънәсендә үзенә буйсындыра ала. Югары сәнгать дәрәҗәсендә иҗат ителгән шигырьнең көче шунда.

Эльмира Шәрифуллина да сөю-мәхәббәт, аерылышу, сагышлану турында яза. Ләкин аның сөюе, сагышы, кайгысы башкачарак. Аның күңел хисләре башка бер генә шагыйрьнекенә дә охшамаган.

Кайчагында шагыйрәнең (шагыйрьнең) кемне уйлап сагышлануын да белеп булмый — әллә ул ир кешене ярата, әллә хатын-кызны.

Ә менә Э. Шәрифуллина шигырьләренең адресаты ачык. Аның барлык уйлары, хисләре, барлык омтылышы бер генә кешегә — «гашыйк диңгезче егеткә» юнәлтелгән. Ләкин — ул инде юк.

Шәүләң йөри көн дә, төн дә,
күз алдымда буй-сының,—

ди шагыйрә «Эзлим» шигырендә. Мондый чакта аңа беркем, берни ярдәм итә алмый.

Кагылмагыз! Зинһар кагылмагыз!
Чит йөрәкләр безгә ягылмагыз!..
Изге килеш, тугры килеш гомер —
Күз алдымда торсын зәңгәр эңгер!

Шулай итеп, шагыйрәнең лирик герое үзенең ихлас мәхәббәте белән, горурлыгы һәм кайгысы белән бездән, сездән һәм дөньядагы барлык мәшәкатьләрдән югары күтәрелә. Мондый олы җанлы хатынның сафлыгына, бөеклегенә сокланмый мөмкин түгел.

Шагыйрә көчәнми, кыланмый. Аның хисләре көчле һәм табигый. Шәхси фаҗига,

бер яктан, кайгы-хәсрәт, сагыш һәм ятимлек алып килсә, икенче яктан, аңа шигырьдә, иҗатта бар көченә балкып китәргә рухи көч биргән. Бу дөньяда тол калган хатыннар да җитәрлек, ятимлек турында язылган шигырьләр дә юк түгел. Ләкин бу хакта шундый көчле итеп, шундый тәэсирле итеп язучылар күп түгел. Монда шуны гына әйтергә була: Эльмира Шәрифуллина чын талантка ия булмаган булса, күрәсең, хәтта шәхси фаҗига да аны шагыйрә ясый алмаган булыр иде.

Шагыйрә сүзнең көчен, мәгънә нечкәлекләрен яхшы сиземли. Шулай да, бу әле аның шигырьләре бар яктан да камил дигән сүз түгел. Эльмирага һәр очракта сүзнең ачык һәм аңлаешлы булып яңгыравына ирешергә кирәк. Әлегә аның шигырьләрендә кытыршырак тоелган яисә авыррак аңлашыла торган сүзләр, юллар очрый.

Мәсәлән:

Каныктың ла, дөнья, билләһи дип,
өйрәндең дип, күңел китергә...

кебегрәк юлларны тиз генә аңлап-тоеп булмый.

Эльмира Шәрифуллинага карата минем бер шигем дә бар. Әйтик, сагыш, кайгы, юксыну кайчанга кадәр дәвам итәргә мөмкин? Эльмираның үзе өчен ул, ихтимал, гомергә барыр. Ләкин шигърияте күз алдында тотып фикер йөртсәк, моның бер чиге булырмы яисә хисләр ташкыны киләчәктә башкачарак юнәлештә ага башлармы? Кыскасы, шагыйрә, үзенә якын темадан читләшкән очракта да, ирешкән югарылыгында кала алырмы?

Менә шуңа күрә Эльмира Шәрифуллина алай-болай сүрелеп, тынычланып, тәсселәнеп калмасын, киресенчә, татар шигърияте күгендә өзлексез балкып торсын иде дигән теләк белдерәсе килә.

**Нурихан ФӘТТАХ.**

# ТИРӘН ФИКЕРЛЕ ӘСӘР

Нурихан Фәттах, «Әтил суы ака торур» һәм «Сызгыра торган уклар»ны бүләк итеп, гаять зур эш эшләде. Менә хәзер яңа авторның яңа әсәре — «Кубрат хан». Романның «Хәтер белән мәхәббәт—үлемсез, мәңгелек»— дигән сүзләре игътибарны җәлеп итә. Өстисе килә: хәтер ул кешенең, халыкның әхлакый тәҗрибәсен буыннан буынга тапшыручы бердәнбер күпер. Хәтер югалу — кешенең, аның тарихының югалуы. Тарихсыз халыкның бүгенге көне дә, киләчәге дә юк.

Әмма «Кубрат хан»ның мөһимлеге аның тарихи роман булуында гына түгел. Язучы, борынгы материалдан файдаланып, бүгенге проблемаларны күтәреп чыга.

Һәр заманда бар халыкларны дулкынландырып килгән проблема — тынычлык өчен көрәш — романның үзәк темасы. Сугыш мәсьәләсенә роман персонажлары төрлечә карый.

Әсәрнең төп идеясен Илбарыс уйлануларында тоя укучы. Орыш һәрчак якыннарны аера, бар изге нәрсәне таптый. Кояш астында һәркемгә дә урын җитәрлек. Мул тормышны кылыч түгел, хезмәт китерә.

Роман моннан тыш та бик мөһим мәсьәләләргә җавап эзли, укучыны уйландырырлык җитди сораулар куйгата.

Мәсәлән, җәмгыятьтә идеология ролен алыйк. «Яңа йола яңа дәүләт төзегәндә кирәк». «Иң камил йола — гадел хан, гадел император. Дәүләт башлыгы яман кеше икән, аның өчен йола чаршау гына». «Аллаларның алласы — акыл булыр»... Бу сүзләрне, әлбәттә, бәхәссез хакыйкать дип әйтә алмыйбыз. Автор аларны төрле персонажларыннан әйттерә дә. Аларның кайсы менә без кабул итәрлек булмавы кызыксыну тудыра, уйландыра. Аннан соң бу фикерләр теге яки бу персонажның дөньяга карашын ачыклау өчен характерлы деталь булып тора.

Әнә, кече кавхан Азакның кем икәнен бер әйтем аңлата: «Ил каласын барысы тик биш сыйфат бизәр, ди: гадел хөкемдар, бай базар, оста имче, су юлы, бай күрше».

Укытучы Константин: «Ришвәт халыкның дәүләткә булган ышанычын югалта, гаделне кимсетә, яманга юл ача». Әңгәмәдән соң Кубрат хан аңлый: Константинны юкка гына иленнән сөрмәгәннәр.

Кубрат ханның горурлыгы аның уенда күренә: «Болгарларның эчке эшләрен болгарлар гына хәл итә ала».

Чор сулышын тегәл тасвирлау өчен язучы телебезнең байлыгыннан иркен файдалана. Яңа сүзләр эзли, үлә башлаганнарына җан бирә. Менә берничә сүз: җыенбаш, шәкел, корбән, очлым, йырмач, нефтә, мая, битек, айбалта, атчабар, төптимерче, алостаз, албагу һәм башкалар. Без алар урынына башка сүзләр кулланырга яратабыз. «Мая»га тавык астындагы йомырка гына кала. Гаскәр «резервта», ашлык «запаста» булып чыга... Авторның кала, тау, су исемнәрен дә тарихи мәгънәдә кулланырга тырышуы мактауга лаеклы: Тимер капка, Биләмҗир, Патшакала, Кияүкала... Әмма бу мәсьәләдә Мөсәгыйт эзлекле түгел. Хорезм, иберия, угор, сарацин кебек сүзләргә дә бүгенге транскрипцияне тагу дөрес булмас кебек. Бигрәк тә «Рось» термины шикләндерә, чөнки төрки телендә сүз башында «р» авазын куллану ят нәрсә булган. Ләкин бу кытыршылыклар уңай тәэсирне кимәтә алмыйлар.

Уңай тәэсир әсәрдәге вакыйгаларның, геройларның тирән фикерлелегеннән, ышандыру көченнән туа. Әйтик, төптәңре Ирсан — хыянәтче. Ләкин ул уңган алып, оста политик, акыллы киңәшче дә. Әйтик, аның кыр кәҗәсе белән аны куучы эт турындагы сөйләгә генә дә ни тора?! Аның хыянәтен аклап булмаса да, аңлап була.

Нәфис әдәбиятта очраклы детальләрнең яшәргә хакы юк. Һәр детальнең геройны сурәтләр өчен, аның кылган эшләрен аңлатыр өчен мәгънәсе булырга тиеш. Мәсәлән, Симай карт белән очрашыр алдыннан хан күзгегә карап, үз кыяфәтенә бәһа бирә. Ул үзен карый, ә укучы аның кем икәнен сизә.

«Идеаль дәүләт юк», — ди укытучы Константин. Идеаль әсәр язу да мөмкин түгелдер. Әмма бу очракта, әле тиешенчә өйрәнелмәгән Бөек Болгар тарихына кагылганда, аеруча саклык кирәк — укучының һәр фактны тарихи дөреслек дип кабул итүе дә мөмкин ич, дип әйтәсе килә. Чөнки, «биредә яшәгән халыклар тарихын белсә бары тик әкрен генә искән җилгә дә пышылдап сөйләшә башлаган кылганнар беләдер, шуңа әле булса башларын чайкап утыралардыр кебек. Алар, үткәнне бүгенгегә ялгап, һаман мең еллар элеккечә тирбәлеп чайкалалар».

Болары инде Мөсәгыйт сүзләре!

**Айрат ИБРАҺИМОВ.**
Ульяновск.

БЕР СОРАУГА — БЕР ЖАВАП

# ТАРИХТАН — КИЛӘЧӘККӘ

**Сорау:**

— «Казан утлары» журналының 1984 елгы 8—10 нчы саннарында М. Хәбибуллинның «Кубрат хан» романы басылып чыккан иде. Бу әсәр укучыларда һәм әдәби җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уятты. Роман уңаеннан беренче тәэсирләрегез, фикер һәм теләкләрегез белән уртаклашсагыз иде.

**Әбрар Кәримуллин**, филология фәннәре докторы:

— Иң беренче сүзем шул — романны тиз укылып бетмәсен дип әкренләп, тәмләп кенә, урыны-урыны белән кире кайтып укыдым. Ул гаять мавыктыргыч язылган, чын мәгънәсендә сәнгать әсәре булып чыккан.

Болгарлар һәм гомумән төрки халыкларның үткәне, бигрәк тә Урта гасырларда яшәеше, тарихтагы урыны, хәле әлегә бер яклы, эзлексез генә тикшерелгән. Язучының ялгыш фикерләр тозагына эләкмәве, сиземләве, акны карадан аера белүе сөенечле күренеш. Әсәрдә сурәтләнгән заманның рухы, халыкның тормышы, фикри яшәеше дә ышандыра.

Романда мин Кара диңгез һәм Азов буе Бөек Болгар чорын дөрес аңлау һәм аңлатуны күрәм. Төркиләр белән Византия мөнәсәбәте гаять ышандырырлык чагыла.

Кайбер килешеп бетәсе килмәгән урыннар да бар. Әйтик, романда болгарлар өчен йортларны, коралларны, төрле бизәнү әйберләрен нигездә греклар гына

ясый. Һәрхәлдә, болгар җирендәге ул йортларны грек мастерлары кул астында болгар кешеләре төзегән. Болгарлар, һичшиксез, талантлы осталар да булган.

Волгар дәүләтендә төрле телләрдә сөйләшәләр дигән фикер дә очрый романда. Шул ук вакытта хәзәрләрнең, аннан Эске Кирмәндә дә төрки телдә сөйләшүләре бик дөрес язылa. Урта гасырдагы халыклар тарихын тикшерүче кайбер тарихчылар Болгар дәүләте төрле халыклардан торган дип, бер телнең төрле шивәләрен аерым тел итеп кенә түгел, ул шивә кешеләрен аерым халык итеп карарга тырышалар. Урта гасырда төрле телләрдә сөйләшкән халыкларны берләштереп йөзәр ел яшәгән дәүләтләр Көнчыгыш Европада, Кара диңгез, Идел буйларында юк, булмаган. Шуңа күрә Кубрат хан төзегән Болгар дәүләтенең төп, абсолют күпчелеге, нигездә, бер телдә сөйләшкән, төрки булган.

Минемчә, романны китап итеп бастырганда менә шушы ике моментны искә аласы иде.

**Нури Арсланов**, шагыйрь:

— Тарихка бәйләнгән вакыйгаларны, шәхесләрне ачып күрсәткән әсәрләрнең дөньяга чыгулары тәрбияви яктан да бик әһәмиятле. Бу юлда Нурихан Фәттах башлап җибәргән кыю адым ерак узганнарыбызның заманча мәгънәсен ачты.

«Кубрат хан» романы белән Мөсәгыйт Хәбибуллин безгә бер кадәр якынрак тарихыбызны — Бөек Болгар дәүләтенең төзелү чорларын һәм шул дәүләтнең мөстәкыйльлеген саклау өчен көрәш дәверен тәфсилли. Әсәрнең төп максаты — Кубрат хан яшәгән чорны дөрес сурәтләү, безнең заман укучысының күз алдына аның зур шәхесен бастыру, шул сурәт колачында тулы бер халыкның трагедиясен җанландыруны куйган. Һәм, бәхетебезгә каршы, автор моңа ирешкән дә.

Бик файдалы, бик кирәкле роман.

Әсәрнең язылышында әллә ни тарихи ялгышлар, хискә бирелеп күпертүләр күренми. Болгар халкының әлек-электән интернационалистик рухы дөрес бирелгән. Гомумән, романның эчтәлеге, сюжет агышының тигез һәм ышандыргыч булуы күңелне җәлеп итә.

**Флүн Мусин**: филология фәннәре докторы:

— Мөсәгыйт Хәбибуллинның бу яңа романы мине, әле барыннан да элек, фәнни яктан җәлеп итте. Мәгълүм ки, соңгы вакытта туган халкыбыз тарихының чишмә башын, ягъни аның каян килеп чыгуын ачыклауга игътибар артты. Ул галимнәрне генә түгел, укучыларның киң катлауларын да кызыксындыра. Чөнки моңа кадәр бу мәсьәләгә төрле карашлар, кайчак бик ялгышлары да яшәп килде.

«Кубрат хан» романын мин шушы катлаулы һәм күпкырлы мәсьәләне ачыклау юлында язучы кешенең бер әзләнүе дип карыйм. Шул ук вакытта бу әсәрнең тарихчы галимнәр өчен шактый гыйбрәтле факт булуын да әйтәсе килә.

Романда сурәтләнгән тарихи чорга М. Хәбибуллинның татар әдәбиятында беренчеләрдән булып мөрәҗәгать итүе, табигый, әсәргә билгеле бер эз салган. Мин авторның мәгърифәтчел омтылышы көчле булуын күздә тотам. Әйе, әсәрдә хәзерге укучыны Кубрат хан иленең гореф-гадәтләре, йолалары, гомумән, яшәү рәвеше белән таныштыруга зур игътибар бирелә. Шуңа да бу һич тә семья-көнкүреш романы гына түгел. М. Хәбибуллин аны шул заманның бик җитди мәсьәләләрен һәм процессларын чагылдырган киң социаль-тарихи полотнога әверелдерә алган. Шундый фонда илләр һәм халыклар арасындагы киеренке мөнәсәбәтләр белән аерым геройларның шәхси тормышы, уй-кичерешләре үзара үрелеп бирелә. Икенче төрле әйткәндә, без шул легендар заманнарда ук ил язмышы белән шәхес язмышының тыгыз бәйләнгән булуларын күрәбез. Үзе тасвирлаган чорның төрле-төрле сыйнфый катлауларына мөрәҗәгать итеп, аларның дөньяга карашларын, кәсеп-гамәлләрен чагылдырып, М. Хәбибуллин, минемчә, шул заман җәмгыятенең күпкатламлы һәм киеренке яшәешен безгә җиткерә алган.

**Гамирҗан Дәүләтшин**, тарих фәннәре кандидаты:

— «Кубрат хан» романы әдәби яктан мавыктыргыч итеп язылган. Эчтәлегенең киеренкелеге белән ул укучыны әсәр тәмамланганчы үзенә тартып тора. Романдагы төп образлар үзләренең омтылышлары, уй-хисләре белән шактый тулы канлы рәвештә күз алдына килеп басалар.

Романның идея-политик яңгырашы бүген дә бик актуаль — халыклар, илләр арасындагы иминлек, үзара хезмәттәшлек мәсьәләләре. Романда художество чаралары ярдәмендә үткәрелгән бу идеяләр бик тә вакытлы яңгырый. Бу әсәр укучыларда туган илгә, халкыбызның үткәненә игътибарлылык, бирелгәнлек, интернационализм һәм патриотик хисләр тәрбияләүдә дә сизелерлек өлеш булып тора.

М. Хәбибуллин, сурәтләнгән чорның, төбәкнең катлаулылыгына, четереклелегенә һәм тарих, археология фәннәрендә җитәрлек дәрәҗәдә ачыкланмаган булуына да карамастан, шактый уңышлы тарихи әдәби әсәр иҗат итә алган.

Әмма шуны әйтергә кирәк, тарихи чыганаклар нихәтле генә бай булмасын, галимнәр дә тарихи фактлар арасындагы бушлыкны логик фикерләү, гипотеза, интуиция, хәтта нигезләнгән хыял ярдәмендә тулыландыралар.

Билгеле, тарихчы буларак, кайбер мәсьәләләрдә язучы белән бәхәскә керәсе килә. Әйтик, ул чорда шул төбәкләрдә яшәүче болгарларның классик дәрәҗәдә күчмә халыклар булуын онытырга ярамый. VI гасырдан (греклардан) калган Фанагория шәһәренең Бөек Болгар дәүләте берләшмәсе башкаласы булуы(?) гына болгарларны әле утрак халык итми. Романда шул чордагы Азов, Кавказ, Идел буйларының этник картасы шактый каршылыклы тәэсир калдыра. Болгарларның, шул исәптән Кубрат ханның да без яшәгән төбәкләргә инде VI—VII гасырларда ук килеп-китеп йөрүләрен дә конкрет дәлилләүче мәгълүматлар, кызганычка каршы, хәзергә билгеле түгел.

Әлбәттә, боларның барысын да әдәби әсәр закончалыклары белән аңлатырга мөмкин. Ләкин романның «Кубрат хан» дип аталуы һәм бу шәхеснең тарихта конкрет яшәү, идарә итү елларының билгеле булуы, анда сурәтләнгән вакыйгаларның, тормыш-көнкүрешнең, шәхесләрнең шул вакыт рамкаларына сыюын таләп итә. Билгеле, бу — язучы өчен гаять зур кыенлыклар китереп чыгара.

Күрсәтелгән кыенлыкларга, аерым җитешсезлекләргә карамастан, мавыгып укырлык, рухи, тәрбияви азык булырлык роман язылган.

**Ибраһим Нуруллин**, филология фәннәре докторы, профессор, ТАССР-ның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты:

— Татар әдәбиятында тарихи жанр чагыштырмача иртә — XX йөз башында ук тәпи йөреп киткән иде. Татарларның милләт булып формалашып җитүе белән бәйле иде бу. Тарихи әсәрләр арасында демократик күзлектән карап язылганнары булган кебек, буржуаз милләтчелек белән сугарылганнары да байтак иде. Егерменче елларда тарихи жанр ныгып буй үстерергә теләде. Игътибар күбрәк тарихның сыйнфый көрәш кискенләшкән «кайнар нокта»ларына юнәлде.

Кырыгынчы еллардан соң әдипләребез Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышыннан күп еракка китми башладылар.

1970 елда Н. Фәттах бер мең ел артка чигенеп язылган «Этил суы ака торур» романын дөньяга чыгарды. Моннан соң әдип бу якка таба килер дип өметләнсәк тә, ул эраның теге ягына ук атлап чыгып, төркиләрнең бик борынгы бабалары тормышын язып күрсәтте. Нурихан — Нурихан булып кала дигәндәй, бу ике әсәрнең дөньяга килүе сәбәбен язучының шәхси үзенчәлегеннән генә дә эзләргә мөмкин булыр иде. Тик менә М. Хәбибуллинның аларны бер-берсенә тоташтыра торган күпер булып калыккан «Кубрат хан» романы бүтәнчәрәк уйларга мәҗбүр итә. Тарихи жанрның кабат ишек шакуы түгелме бу, татар халкының үткәнен һәм бүгенгесен дөресрәк аңлау һәм аңлату ихтыяҗыннан тумаганмы ул әсәрләр?

Роман турында әле сүз күп булыр. Хәзергә мин гади укучы сыйфатында гына шуны әйтә алам: әсәр укыла. Мең дә өч йөз ел элек искән дала җилләре борынга бәрелгәндәй, кылычны кылычка орган тавышлар ишетелгәндәй була, шул вакытның гореф-гадәт һәм йолалары күз алдына килеп баса, дәрәҗә сөю һәм дәүләт мәнфәгатен үзендә каршылыклы рәвештә берләштергән Кубрат ханның ышандыргыч сыны калка.

Борынгы тарихыбыз турындагы беренче әсәрләр маҗаралы роман булып һәм азмы-күпме романтизм буяулары белән ялтырап дөньяга килделәр. Күрәсең, бу табигый һәм котылгысыз хәл. Тарихи жанр киләчәктә, кырыс реализмга таба хәрәкәт итсә, тагын да әйбәтрәк булыр иде, дип әйтәсе килә.

# ИКЕ ӘДИП ДУСЛЫГЫ

Совет халкының фашист Германиясен тар-мар итүенә, бу авыр сугышта җиңүгә ирешүенә 40 ел тула. КПСС Үзәк Комитетының «Совет халкының 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүенең 40 еллыгы турында»гы карарында әйтелгәнчә, Советлар Союзы өчен ул азатлык сугышы, гадел сугыш иде. Бөек Җиңүгә барлык совет халкы кебек, Татарстан хезмәт ияләре, иҗат интеллигенциясе, шул исәптән республикабыз әдипләре шактый зур өлеш керттеләр. Алар, мәкерле дошманга каршы автомат һәм каләм тотып, Ватаныбыз азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен яу кырында көрәштеләр.

Быелның январь аенда фронтовик әдип Шәйхи Маннурның, ә 1986 елның февралендә Советлар Союзы Герое, патриот-шагыйрь Муса Җәлилнең тууларына 80 ел тула. Алар — чордаш һәм кордаш каләм осталары, якын дуслар. «Язучыларга һәм әдәбиятка карата булган караш һәм фикерләребезнең уртак булуы, бер-беребезне бик яхшы аңлавыбыз мине бик шатландырды»[1],— дигән иде М. Җәлил Шәйхи Маннурга язган бер хатында. Аларның иҗат дуслыгы «чын күңелдән булган шәхси дуслык һәм сердәшлек белән бәйләнгән»[2] була.

Бу язма — Муса Җәлил белән Шәйхи Маннурның иҗади дуслыгы, фронтовик әдипләрнең эшчәнлеге турында.

•
• •

Ике арадагы бу дуслык ике шагыйрьнең Мәскәүдә татарча чыга торган «Эшче» «Коммунист» газеталары редакцияләрендә журналистлык эшчәнлегендә, 1932—1933 елларда ук башланып китә.

СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни архивының М. Җәлил фондында утызынчы еллар ахырында Шәйхи Маннурның Мәскәүдә яшәүче Җәлилгә язган берничә хаты саклана. Ш. Маннурның 1938 елның 17 сентябрендә аңа язган хатыннан өзекләр китерәбез. Ул Татарстан Совет Язучылар союзы бланкасына язылган.

«Муса дускай!

Сезнең һәр өчегезгә безнең һәр икебездән сагынычлы сәлам. Хатыңны алып укыдым...

Т. Шевченконың нәрсәләрен тәрҗемә итүне якын арада хәл кылабыз. Тәрҗемәне сиңа җибәрербез.

М. Лермонтовның да юбилее якынлаша. Аны тәрҗемә итәргә башларга кирәк. Бәлки аның турында журналга бер мәкалә дә язарсың?..

Син сораган нәрсәләрне ашыгыч җибәрәм (либретто планы һәм соңгы глава шигырь). Либреттоны мин ташлап торган идем, әгәр үтә алса, мин аны бөтен көчемне куеп эшләр идем һәм, бөтен кимчелекләреннән арындырып, яхшы бер әсәр булу хәленә җиткерер идем!..

Коллектив поэманы бүген тәмам итеп, журналга җибәрәбез. Сиңа да бер данә җибәрербез...

Сәлам белән Маннур. 17/IX-38»[3]

Менә 1938 елның 8 октябрендә Ш. Маннурның М. Җәлилгә язган икенче хатыннан өзек:

«...Бу хат белән сиңа яңа үтенеч бар: Шевченко комиссиясе (председателе мин дип мактанып куярга да ярый), «Катерина» исемле поэмасын тәрҗемә итүне Әхмәт Фәез белән сезнең икегезгә тапшырды. Бу хатны алгач та урталай бүлеп алыгыз да эшли башлагыз. Срогы 10 декабрьда. Шулай итеп, әнә шул вакытка без сездән яхшы сыйфатлы тәрҗемә көтеп калабыз. Юбилей көннәренә карата Шевченко турында газе-

---

[1] Муса Җәлил. Әсәрләр, дүрт томда. Өченче том. Казан, 1976, 513 б.
[2] Шунда ук, 525 б.
[3] Тел, әдәбият һәм тарих институтының фәнни архивы, 10 ф., 4 тасв. сак. берәмлеге 9, 62 бит.

та-журналларда гына язып калмыйча, 5 табаклы аерым җыентык та чыгарабыз. Бу нәрсә правлениедә бүген расланды...»[1]

Ш. Маннур хатында либретто турында сүз бара. М. Җәлил 1935-1938 елларда, Мәскәүдә дәүләт консерваториясе каршында Татар студиясенең әдәбият бүлеге мөдире булып эшләгән чорда бик күп шагыйрьләрне, шул исәптән Шәйхи Маннурны да либреттолар язуга тарта. Ул Ш. Маннурның «Бозлар актарылганда» исемле поэмасы буенча язылган либретто планын нигездә яхшы дип таба. «Ул либретто,— дип яза М. Җәлил,— сюжетның уңышлы төзелүе, вакыйгаларның ифрат көчле бирелүе, язылган өлешенең әдәби матур эшләнүе турында мин үз фикеремне ачык әйткән идем инде. Мин ул вакытта күрсәткән җитешсезлекләр (натурализм элементлары, артык картиналар һ. б.) эш процессында бик җиңел төзелә торган әйберләр»[2].

Студия белән Казанга кайткач, «Мин театрда яңа план һәм масштаб белән эшли башлаячакмын. Билгеле, бу эштә мин иң башлап сезгә — язучы дусларыма таянам... Кыскасы, Казанга кайткач дәртләнеп һәм бераз курка-курка барам. Ләкин синең кебек дуслар булу көч кертә»[3],— дип язды М. Җәлил Ш. Маннурга.

Муса Җәлил каләмдәшенең иҗат уңышларына сөенә, кирәк чакта аңа якын киңәшче дә була белә. Татарстан совет язучылары җыелышында, 1940 елның 7 декабрендә ясаган отчет докладында ул болай ди:

«Шәйхи Маннур татар поэзиясендә үзенең күп кенә поэмалары һәм лирик шигырьләре белән күренекле урын алды. Аның шигырьләренә җылылык, лиризм, ялкынлы дәрт һәм садәлек хас... «Гайҗан бабай», «Меңнән бер кичә», «Елмаюлы кояш турында» төсле көчле образлы әсәрләрен үрнәккә алырга кирәк була.

Соңгы елларда Ш Маннур зур иҗат активлыгы күрсәтте. «Котан батыр», «Олаучы малай» поэмаларын, «Вахитов» пьесасын һәм шигырьләр язды»[4].

Татарстан совет язучылары союзының башлангыч партоешмасы секретаре Нур Баян имзасы белән 1940 елның 3 маенда Ш. Маннурга бирелгән характеристикада мондый юллар бар:

«Ш. Маннурның төп жанры — лирика. Ләкин аның тарафыннан югары поэтик осталык белән язылган күп кенә әйбәт поэмалар иҗат ителде. Бу поэмалар арасыннан «Туганлык», «Гайҗан бабай», «Меңнән бер кичә», «Карлыгач» һ. б. күрсәтергә мөмкин. Ш. Маннур әсәрләренең төп темасы — яңа кешенең, хезмәткә, тормышка, яңа, коммунистик мөнәсәбәтләр тууы ул... Ш. Маннур татар совет әдәбиятын үстерү эшендә зур хезмәт куйды, шуның өчен ул СССР Верховный Советы Президиумы тарафыннан Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде»[5].

Ш. Маннур әсәрләрендә яңа җиңүләргә рухландыручы партиягә, илебезнең чәчәк атуы өчен фидакарьлек күрсәткән хезмәт батырларына дан җырлый.

* * *

Инде фронтовик әдип Шәйхи Маннурның Бөек Ватан сугышы елларындагы эшчәнлегенә бераз тукталыйк.

Шагыйрь Бөек Ватан сугышы елларында да актив иҗат итә. Аның бу чор иҗаты совет халкының, солдатларыбыз һәм офицерларыбызның сугыш кырларында күрсәткән батырлыгы, аларның Гитлер яуларын җиңүгә көчле омтылышлары, илебез өстендә җиңү таңы атачагына тирән ышаныч белән сугарылган. Әдип, Муса Җәлил кебек, сугыш башлануның беренче көннәреннән совет кешеләрен изге көрәшкә чакыра. Немец фашистларына нәфрәт яудырган «Үз башына» исемле шигырен яза. Ул «Кызыл Татарстан»да 1941 елның 27 июнендә басылып чыга:

Бер уч туфрагы газиз булган,
Изге кочагында Ленин туган
Ватаныма — бөек анама,
Батыр халкым сарай салганда,
Күзе тонган фашист туп атты...
Изге көрәш, изге сугышка!
Кабахәтләр җирдә калмасын!
Кабат килеп агу салмасын
Безнең матур, тыныч тормышка!

Аның «Кызыл Татарстан» газетасының 1941 ел, 6 июль санында дөнья күргән «Саубуллашу» шигыре дә, дошманның мәкерлеген сурәтләү белән бергә, совет солдатын гайрәтле, көчле һәм батыр булырга, илбасарларны тар-мар итәргә өнди. 1941 елда

---

[1] Тел, әдәбият һәм тарих институтының фәнни архивы, 10 ф., тасв. 4, сак. бер. 9, 63 бит.
[2] Муса Җәлил. Әсәрләр, дүрт томда. Өченче том, 514 бит.
[3] Муса Җәлил. Әсәрләр, дүрт томда. Өченче том, 522 б.
[4] Шунда ук, 264 бит.
[5] КПССның Татарстан өлкә комитеты партархивы. 1211 ф., 1 тасв. 2 эш. 10 б.

шагыйрьнең «Әй, күтәрел, халкым!», «Син нәрсә бирдең», «Тизрәк җиңү өчен!», «Тәгәриләр» кебек шигырьләре басылып чыгып, укучылар тарафыннан җылы каршылана.

Ш. Маннур «Кызыл Татарстан» газетасының махсус корреспонденты сыйфатында сугышның беренче айларында республикабыз районнарына командировкага чыга, колхоз басуларыннан игенчеләрнең фидакарь эшләре турында мәкаләләр яза.

Бераздан Ш. Маннур үзе теләп Бөек Ватан сугышына китә.

М. Җәлил Шәйхи Маннур белән Мәскәүдә очраша. Мәгълүм ки, М. Җәлил Марьино-Минзәлә хәрби политработниклар курсын өлкән политрук дәрәҗәсендә тәмамлагач, командование тарафыннан эшче-крестьян Кызыл Армиясенең политик идарәсе (ПУРККА) карамагына җибәрелә. Ш. Маннур да Казаннан шул Политик идарәгә җибәрелгән булган.

М. Җәлил 1942 елның 12 январенда рус телендә язылган хатында (ул матбугатта басылмаган) болай дип хәбәр итә: «Без направление белән безне көткән учреждениедә (ягъни политик идарәдә) булдык, анда безнең эшләребез турында сөйләштек, шунда ук Маннурны да очраттык. Шул ук көнне Маннур белән Ә. Фәйзидә кундык»[1]. Әлбәттә, дәһшәтле көннәрдә өч мәшһүр шагыйрь-дусларның очрашуы алар тормышында, иҗатында зур эз калдыргандыр.

Әлегә билгеле булмаган тагын бер документ китерәбез. Сүз анда Ш. Маннурны Кызыл Армия сафларына чакыру турында бара. Ул 1942 елның 19 январенда эшче-крестьян Кызыл Армиясенең Политик идарәсенең баш начальнигы исеменә язылган.

«...Татар телендә,— диелә анда,— поэзия белән шөгыльләнгән иптәш Маннуров рус телендә очерк һәм хикәяләр яза ала.

СССР Язучылар союзы Президиумы секретаре А. Фадеев иптәш Маннуровны армия матбугатына җибәрергә тәкъдим итә һәм Маннуровның анда файдалы работник булачагын күрсәтә.

Иптәш Маннуров үзе дә армия матбугатына җибәрүне үтенеп сорый. Сезнең күрсәтмәгез буенча хәзер Маннуров чакырылды һәм Мәскәүгә килде.

Иптәш Маннуровны РККАга чакырырга һәм 61 нче армия газетасы редакциясенә әдәби сотрудник хезмәтенә билгеләргә тәкъдим итәргә»[2].

Ш. Маннур «Сугышчан чакыру», «Алга, дошман өстенә» һәм «Ватан бәхете өчен» дигән фронт газеталарының хәрби корреспонденты булып хезмәт итә. Коммунистлар партиясе сафына алына, Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр белән бүләкләнә.

Гвардия капитаны Ш. Маннуровны «Сугышчан хезмәтләре өчен» медале белән бүләкләү турында «Бүләкләү листы» саклана. Түбәндә шушы документтан бер өзек китерәбез:

«Иптәш Маннуров 1944 елның февраленнән «Ватан бәхете өчен» дигән дивизия газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли. Февраль-март айларында Витебск янында барган һәм соңгы сугышларда, бигрәк тә Березино елгасын кичкәндә һәм Борисово шәһәрен азат иткәндә, иптәш Маннуров, оештыручы-корреспондент буларак, зур сәләткә ия булуын күрсәтте... Аның мәкаләләре сугышчыларны өйрәтә һәм сугышчан батырлыкларга туплый...»[3]

Ш. Маннуров «Сугышчан хезмәтләре өчен» медале белән бүләкләнә.

Шул ук архивта гвардия капитаны Ш. Маннуровны Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләү турында «Бүләкләү листы» да бар. Анда болай диелә:

«Иптәш Маннуров, дивизия газетасының әдәби хезмәткәре буларак, сугышның төрле шартларында подразделениеләрдә була, сугыш геройларының тәҗрибәсен өйрәнә, аны оператив һәм оста итеп газетада яктырта. Сугышучы подразделениеләрдә ул батырлык һәм кыюлык күрсәтә. Иптәш Маннуров иптәш Шелховский батальонында булган вакытта аның геройларының сугышчан эшләрен газетада һәм листовкада киң яктыртты. Иптәш Маннуров инициативасы буенча дивизиядә хәрәкәт иткәндә станоклы пулеметтан ату тәҗрибәсе киң таратылды. Иптәш Маннуров сугыш кырында Көнчыгыш Пруссиягә һөҗүм итүче геройларыбыз турында махсус листовкалар өчен күп кенә кыйммәтле оператив материаллар оештырды. Личный составны сугышчан батырлыкларга туплауда бу материалларның ярдәме зур булды... Иң катлаулы сугыш шартларында Маннуров үзен батыр һәм кыю тота...»[4].

Ул Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.

Бу елларда әдипнең күп кенә мәкаләләре, фронт язмалары, очерклары һәм шигырьләре әлеге газеталарда һәм «Кызыл Татарстан»да бер-бер артлы басылып тора.

Авторның егерме меңчеләр сафында Мөслим районына килеп колхоз төзешкән, аннары ак финнарга каршы сугышларда катнашкан, Бөек Ватан сугышында каһарманнарча көрәшкән рота командиры лейтенант С. Садретдинов турындагы, егерме сугышчы бе-

---

[1] Г. Ибраһимов исемендәге институтның фәнни архивы, 10 ф., тасв. 4, эш 16, 1 б.
[2] Бу документ СССР Оборона министрлыгының үзәк архивында саклана.
[3] СССР Оборона министрлыгының үзәк архивы, 33 фонд, 690155 тасвирлама, 3094 эш, 266 б.
[4] СССР Оборона министрлыгының үзәк архивы, 686196 тасв. 6460 эш, 76 б.

лән лейтенант Глинков һәм Саратов егете политрук Хәсән Хаҗиморатов хакындагы, Тукай районының Шәкәнеч егете — отделение командиры сержант Гобәйдулла Хисмәтуллинның 200 фашистны пулеметтан дөмектерүе, Медногорск егете снайпер Мортаза Мәхмүтов турындагы очеркларын тирән дулкынлану белән укыйсың. Хәрби журналист «Егерме баһадир» дигән очеркында болай дип яза:

«Туган илләренең, ата-аналарының һәм балаларының азатлыгын чын күңелләре белән сөйгән арслан егетләр әнә шулай каһарманнарча һәлак булалар. Совет халкы һәм Бөек Ватан аларның данлы исемнәрен һәм искиткеч гүзәл баһадирлыкларын гасырлар буе йөрәгендә саклар, мәңгегә онытылмый торган асыл җырлар тудырыр!»

Редакция 1942 елның 8 июнендә Ш. Маннурга — каләмдәшенә җылы мөнәсәбәт һәм әдипне тирән ихтирам итүен белдергән хат яза:

«Сәләх Садретдинов турында язылган хат газетабызның 1942 нче елның 24 март санында басылып чыкты һәм укучылар аны яраттылар...

«Урманда» исемле бишенче хатны 8/VI-1942 алдык. Без хәзер газетаны 2 битле итеп чыгарабыз. Шуңа да карамастан, Маннур хатларына газетада урын бар. Чөнки алар урынны үзләре яулап алалар»[1].

Әдипнең бер хатында «Гайҗан бабай» поэмасының икенче кисәге — «Гайҗан бабайның бүләге» язылып бетү һәм аны газетада бастыру өчен җибәрүе турында сүз бара. Авторның бу иҗат җимеше «Кызыл Татарстан»ның 1943 ел, 27 мартында басылып чыккан.

Бөек Ватан сугышы башланып, берничә ай үтүгә, фронтка ярдәм йөзеннән илебездә патриотик хәрәкәт киң колач ала. Илебез, шул исәптән Татарстан хезмәт ияләре фронттагы сугышчыларыбыз өчен җылы киемнәр, төрле бүләкләр җыйлар, танк колонналары, авиаэскадрилья, бронепоездлар төзү өчен акчаларын бирәләр. Кайберәүләр шәхси средство һәм акчаларына самолетлар ясаталар.

Ш. Маннур әлеге поэмасында шушы хәрәкәтне дулкынландыргыч итеп тасвирлый, Гайҗан бабай авызыннан сөйләтеп, болай ди:

Безнең уллар тизрәк җиңсен өчен,
Бер самолет бүләк итәбез.
Бар бердәнбер лачыныбыз безнең,
Гадел-Котдус аның исеме.
Гайрәтле бер татар егете ул,
Саф йөрәкле халык нәселе.
Безнең шушы уртак бүләгебез —
Корычканат аңа бирелсен,
Ул күкләргә гизеп шуның белән,
Ярманнарның көлен китерсен.

«Гайҗан бабай бүләге»— фронтовик шагыйрьнең зур иҗат уңышы. Гайҗан бабай образы авыр сугыш елларында патриотизм үрнәге күрсәтү белән бик тә табигый яңгырый. Ш. Маннур әлеге поэмасын 1947-1948 елларда дәвам иттереп, сугыштан соңгы чорда — илне җимереклектән торгызу, колхозларны яңадан ныгыту чорында батырлык күрсәткән — кырларда мул уңыш үстергән Гайҗан бабай белән — «Гайҗан бабайның алтын көшеле» белән тәмамлый.

Әдип, дәһшәтле елларда ут эченнән торып, окоп-блиндажларга дошман пулясы һәм снарядлары явып торган шартларда иҗат итте. «Совет әдәбияты» журналы, «Кызыл Татарстан» газетасы редакцияләренә бер-бер артлы сугышчан очеркларын һәм фронт язмаларын, поэтик әсәрләрен җибәрә. Аның «Җиңүчеләргә сәлам» дигән шигырьләр җыентыгы да сугыш елларында басыла. Орденлы шагыйрьнең бу китабына кергән әсәрләре Ватаныбызның фашист үләтеннән чистартылачагына, дошманның җиңеләчәгенә зур ышаныч белән сугарылган. Тәнкыйтьче Хәсән Хәйринең 1943 елның 13 мартында газетабызда әлеге җыентыкка карата рецензиясе бирелгән:

«Маннур бүгенге хәлләрне,— дип яза ул,— һәр яңалыкны, сугыш чорында туган вакыйга, фактларны күрә һәм шагыйрь йөрәге белән сизә... Ленинград халкының, Москваны саклаучы каһарманнарның батырлыкларын, совет халкының бердәмлеген җырлый...

Маннурның хәзерге шигырьләрендәге төп тема, төп мотив — мәхәббәт һәм нәфрәт. Безнең Ватаныбызга, туган халкына, Кызыл Армиягә, совет халкының батыр улларына һәм кызларына мәхәббәт һәм дан җырлый шагыйрь. Безнең изге җиребезне таптап, чәчәк аткан авыл, шәһәрләребезне яндыручы һәм бөек культурабызны, иркебезне җимерергә теләүче немец вәхшиләренә мең ләгънәт, нәфрәт һәм уч яңгырый».

---

[1] Татарстан АССРның үзәк дәүләт архивы, 4921 фонд, 1 тасвирлама, 10 эш, 112 б.

Әдипнең фронтта иҗат иткән шигырьләренең шактый өлеше газетада һәм «Совет әдәбияты» журналында беренче тапкыр дөнья күрәләр. «Кызыл Татарстан» газетасында 1942 елгы «Безнең кызлар», 1943 елгы «Сагыну җыры», 1945 елгы «Ерактан хат» кебек шигырьләре — шундыйлар. Аның шул елларда редакциягә җибәрелгән әсәрләре һәм хатларының 20 дән артык кулъязмасы Татарстан АССРның үзәк дәүләт архивында саклана.

* * *

Ш. Маннурның Бөек Ватан сугышы чоры иҗаты М. Җәлил, Ф. Кәрим, Н. Баян, Г. Кутуй, М. Максуд, Ә. Фәйзи, С. Хәким, Г. Хуҗи, Ә. Исхак һәм башка әдипләрнең әсәрләре белән авазлаш. Фронтовик әдип ил белән, халык белән бергә атлады, уртак язмыш кичерде. Аның әсәрләрендә туган халкына дан, дошманнарга нәфрәт һәм үч яңгырый.

Татар совет әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен Ш. Маннур 1957 елда «Почет билгесе», 1975 елда Халыклар Дуслыгы орденнары белән бүләкләнде.

Якын дусты һәм каләмдәше — илебезнең легендар улы Муса Җәлилнең якты истәлеген гомере буе ул күңел түрендә йөртте. Ш. Маннур герой-шагыйрьнең батырлыгын гәүдәләндергән «Муса» романын иҗат итте. «Минем тарафымнан иҗат ителгән бу роман,— дип язды ул кереш сүздә,— Мусаның поэтик һәм гражданлык батырлыгына гаять тирән ихтирам, хөрмәт билгесе».

Ш. Маннур, дусты М. Җәлил кебек, Бөек Ватан сугышы елларын чагылдырган әсәрләре белән бай әдәби мирас калдырды.

**Шәмси ХАММАТОВ,**
тарих фәннәре кандидаты,
**Касыйм ТӘХАУ,**
СССР Журналистлар союзы члены.

# ЯШЬЛЕК ИСТӘЛЕГЕ

Арчада узган хәрби комиссия мине кавалериядә хезмәт итәргә яраклы дип тапты һәм Минск шәһәрендә торучы 7 нче атлы дивизиягә җибәрде.

Минск шәһәренә озак бардык без. Шул юлда, икенче бер вагонда Шәйхи Маннур дигән шагыйрь дә булуын ишетеп, аның янына киттем. Мин аның шигырьләрен азмы-күпме укыган идем, рәсемен дә күргәнем бар иде. Маннурны күрү белән таныдым, кулымны сузып исем-фамилиямне әйттем. Минем исем мең дә бер Габделхакның берсе иде аның өчен. Әмма фамилиягә игътибар итте, «Мәхмүд Максудның энесеме әллә?»—диде. Шушы ерак юлда байтак вакытны бергә уздырдык.

Минск шәһәренең вокзал алды мәйданында саубуллаштык без. Маннурны элемтә батальонына, мине 38 нче полкның 1 нче эскадронына җибәрделәр. «Эскадрон» сүзе матур яңгырашлы сихри бер сүз иде безнең өчен. Бер-беребезне табышырга сөйләштек.

Солдат һәм авыл кешесе кибән эчендәге инәне дә таба ул. Солдат тормышына азме-күпме иялəнгəч без дә табыштык.

Сүз уңаенда Минск шәһәре турында бер-ике сүз әйтмәү гөнаһ булыр иде. Бу шәһәр безне үз уллары шикелле якын итеп каршылады, һәм бу якынлык, җылылык, армия сафларыннан китканче кимемәде. Шәһәр предприятиеләре хәрби частьлар өстеннән шефлык иттеләр. Безнең эскадронның шефы республика газетасы «Звезда»ның типографиясе иде.

Вокзалдан казармалар ягына атлаганда безнең өчен сәер бер күренешкә очрадык. Трамвайга дип рельс салганнар да вагоннарны ат белән тарттыралар. Строй белән баручы булачак солдатлар кычкырып көлеп алдылар. Чөнки алар Казан трамваен күргән егетләр. Аларның үзләреннән дә көләрлек иде югыйсә: кайсы камалы бүрек, кайсы эшләпә, күбесе оек-чабата кигән бу яшьләргә читтән карап тору гаҗәп сәер тойгылар уяткандыр. Ай узу белән, без барыбыз да бертөрле киенгән, бер төсле, бердәй хезмәтле кешеләргә әйләндек. Минск шәһәре дә көннән-көн үсә,

үзгәрә, матурлана барды. Безнең килүебезгә бер ел тулганда, Белоруссия башкаласының киң урамнары буйлап чын трамвайлар йөгерә башлады.

Бер ел бик ансат әйтелсә дә, алай ансат узмый икән. Кечкенә малай чактан ук ат өстендә йөргән авыл егетләре өчен дә «джигитовка»лар шактый авыр бирелә. Бер төрен ярыйсы гына башкарасың, икенче төрендә шапылдап җиргә төшәсең. Аттан бер тапкыр да егылмаган солдат очратмадым мин. Моның ахыры, гадәттә, командирларның җиңелчә ачулануы һәм бер-ике каты сүз белән тәмамлана.

Озак та узмады, Маннурны дивизия штабының бер бүлегенә писарь итеп күчерделәр. Кызыл кирпеч йорттагы сыңар тәрәзәле озынча бер бүлмә Маннурның торагына әйләнде. Бу бүлмәдә карават белән өстәл һәм бер урындыктан башка җиһаз юк иде. Мин анда күп тапкырлар булдым, хуҗаның калай чәйнегеннән байтак «кипәтүк» эчтем. Маннурның: «Әйдә, кипәтүкләп алыйк»,— ди торган гадәте бар иде.

Маннур Белоруссия язучылары белән элемтәгә керде һәм язучылар союзы журналында үзенең ике шигырен бастырды. Шигырьләрнең подстрочнигын Маннур үзе эшләде, тәрҗемәне кайсыдыр белорус шагыйре башкарды. Шул ук вакытта Маннур Мәскәүдә чыга торган «Эшче» газетасына да языша иде. «Эшче»нең бер санында фотомонтаж урнаштырылганы хәтеремдә. Мылтык сурәте эченә «Эшче»нең солдатхәбәрчеләре куелган. Мылтыкның үзәгендә — түтәдә — Маннур рәсеме. Бу вакыйга аның өчен болытлар арасындагы «тәрәзә»дән кояш нурлары сибелгәндәй шатлыклы булды.

1929 елның көзендә без Минск шәһәре белән саубуллашып, Мәскәү аркылы Казанга юл тоттык. Бер вагонда, янәшә урыннарда, пассажирлар белән бергә идек бу юлы. Мәскәүдә ике-өч көн тордык. Мин Мәхмүд абыйда кунак булдым, Маннур редакцияләргә йөрде, иске танышлары белән очрашты.

Безнең юллар Донецк якларында да бергә булды.

Анда баргач Маннурга укытучылыкка керү дә мөмкин иде, әлбәттә. Ләкин ул үзенең Маннур булуын әйтмәскә сорады, производствода эшче батырлардан сабак алырга — тәрбия алырга теләде. 1930 елның язында «Эшче» сотруднигы Вил Садри Донецкига килгәч кенә, Маннурның Маннурлыгы ачылды. Аны заводтан алып, Гладковка руднигына укытучы итеп җибәрделәр.

1930 ел җәендә Донбасска Һади Такташ килде. Бу вакытта Донецк округындагы татар укытучылары Макеевка шәһәрендә курс-конференциягә җыелганнар иде. Такташ, Донецкига килеп җитү белән, Макеевка тирәсендәге шахталарга юнәлде. Аны зурлап каршыладылар, махсус очрашулар, кичәләр уздырдылар. Мәктәптәге зур залда Такташ белән очрашу, аның «Мокамай»ны берәү дә кабатлый алмаслык гүзәл укуы әле дә күз алдыма еш баса. Шул килүендә Такташның Маннур белән берничә кат озаклап сөйләшүе хәтеремдә. Укучы өчен бу яңалык булмас булуын, бу турыда Маннур «Агымсуларга карап» китабында әйткән. Әмма ул китапта Такташның Маннур «эченә җылы кертүе» турында сүз юк. Такташ киткәч Маннурның үз авызыннан: «Такташ эчкә җылы кертте, миңа караш яхшы якка борыла бугай»,— дигән сүзләрне ишеттем.

Такташ Макеевкадан Ростовка китте. Без аны вокзалга кадәр озата бардык. Рәткә биш-алты кеше басып, солдатларча тәртип белән, җырлап бардык...

...Мәскәүдә «Ударниклар» журналында эшләгәндә көннәрдән бер көнне бүлмәгә Маннур килеп керде. Ул «Днепрострой»дан килгән. «Эшче» редакциясенә алмакчы булганнар. Тик тору урыны гына юк һәм булуы да билгесез икән. Мондый чакта дус кешегә кем булышмый? Клязьмага алып киттем. Карчыгым Әминә белән киңәштек тә, бүлмәгә тагын бер карават куярга булдык.

Мәскәүдә эшли башлагач Маннурның күңеле күтәрелеп китте, канатлары җәелде. Җәелмәслек тә түгел, киңәш өчен дә, бәхәс өчен дә мөмкинлек туды, Мәскәүдә Муса Җәлил, Әхмәт Фәйзи, Мәхмүд Максуд, Әхмәт Ерикәй һәм башка әдипләр яшиләр, эшлиләр. Ул аларның кайсылары белән күбрәк аралашкандыр, әйтә алмыйм, чөнки мин сигез сәгать эшләү өстенә тагын дүрт сәгать укый да идем. Шулай да Мәхмүд Максудның шәхси архивында Шәйхи Маннур хатлары күп булуын беләм. Димәк, аларның арасы ерак булмаган.

Якшәмбе көннәрдә, бәйрәмнәрдә Мәскәүдәге иптәшләр килгәли иде. Кунаклар да уртак булды. Бүлмәдә эшләү өчен мөмкинлек юк иде. Шунлыктан эшлисе эшне (язу-сызуны) редакцияләрдә бетерергә тырыша идек. Дачада шахмат уйнау, Клязьма суына коенырга йөрү — ял көннәренең эше шул була иде.

1932 елның көзендә мине Мәскәү өлкәсендәге Касыйм районына (хәзер Рязань өлкәсе) колхоз төзелешенә җибәрделәр. Ул арада карчыгым укуын тәмамлап, Казанга эшкә китте. 1933 елның көзендә мин дә Казанга кайттым. Бу вакытта Маннур педагогия институтында укый башлаган иде. Ул Куйбышев һәм Профсоюзная урамнары чатындагы гомуми торакта яшәде. Тырышып укыды ул. Шахматтан башка нәрсәгә вакыты да калмый иде шикелле. Миңа Казанда эшкә урнашырга кирәк иде. Маннур:

— Радиокомитетта Туфан эшли, аның белән сөйләшеп кара әле,— дигәч, радиога бардым. Туфанны укыштыргалаган булсам да, үзе белән таныш түгел идем. Хәсән ага ачык йөз белән каршылады. Комитет председателе Хисмәтуллин дигән иптәш янына алып керде. «Соңгы хәбәрләр» редакциясенә редактор кирәк икән, икенче көнне үк эшли башладым. Ул чакта Казанда торак мәсьәләсе авыр иде. Без карчыгымның апасы белән җизнәсе канаты астына сыендык. Аларның торак мәйданы үзләре өчен дә киң түгел. Шулай да без керү белән тарайды дип зарланмадылар. Маннур әледән-әле безгә килеп йөри иде. Бервакыт чәй янында:

— Тәрҗемәгә «Карабугаз» дигән әсәр алган идем, срогында бирә алмыйм, әз генә булыша алмассызмы?— дип сорады.

Исмәгыйль Хисаметдинов һәм мин булышырга булдык. Икебез бер табак чамасы тәрҗемә иттек. Маннур безнең тәрҗемәне тикшереп алды. Соңыннан безгә гонорар китерде. Баҗай, бу эшнең асылына бәя биреп:

— Аның вакыт юк дигән сүзенә башта ук ышанмадым, ул бит безнең экономия чүмәләсенә терәк куярга гына тырышты,— диде.

1939 елда Маннур Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде.

— Котлыйм, соңгысы булмасын,— дидем.

— Бу зур бүләкне барыбыздан элек Шәриф ага Камалга бирергә иде,— диде Шәйхи. Ул чын-чынлап уңайсызланган шикелле күренде.

Маннурның теләгәне булды, озак та үтмәде, Шәриф Камал Ватаныбызның иң зур бүләге — Ленин ордены белән бүләкләнде.

Инде менә безнең танышу һәм аралашуга илле елдан артык вакыт узган. Бу вакыт эчендә күп вакыйгалар, шулар эчендә шактый авырлары да кичерелде. Аларның барысын кәгазьгә теркәү мөмкин түгел.

...Китап шүрлегендә Маннур әсәрләре тулысынча диярлек сакланган. Менә «Муса», менә «Агымсуларга карап», менә «Чын сөю бармы?» «Агымсуларга карап»ның титул битендә:

«Әминә белән Хак дусларыма.

Безнең матур да, борчулы да, моңсу да яшьлекнең бер истәлеге булсын бу китап.

Зур ихтирам белән Шәйхелислам дәю белгәйсезләр —

14.II—75» дип язылган.

Шәйхи Маннурның:

Кичләрдәме
Яки иртәсенме
Килсәм әгәр синең хәтреңә,
Сыңар чәчәк ташлап китәрсеңме
Ерактагы ялгыз кабремә?..

— дигән юллары бар. Бу истәлегем менә шул чәчәк булсын.

**Хак МАКСУД.**

# БӘХЕТ КИТЕРҮЧЕ ОСТАЛЫК

*Азат Аббасовка 60 яшь*

Музыка дөньясының тылсымнарын ул бала чактан ук ача башлады. Туган йортында җыр тынып тормады. Күңелгә ятышлы торучы көчле баска ия булган әтисе татар халык җырларын эчке бер хозурлык белән башкара иде. Һәм Азат та җырчы булырга хыялланды. Атаклы башкаручыларның граммофон язмаларын, бигрәк тә Ф. Шаляпин җырларын ул йотлыгып тыңлады, күңелендә музыканың иң кирәкле бер ихтыяҗга әверелә баруын тойды.

Гомер агышына реаль тормыш үз төзәтмәләрен кертә: Казандагы 2 нче урта мәктәпнең 7 классын тәмамлагач, Азат авиация техникумына укырга керә. Һәм 1943 елда махсус белем алган егет заводта конструктор булып эшли башлый. Шулай да күңеленең иң тирән катламнарына кереп урнашкан җыр аңа беркайчан да тынгылык бирми. Нота серләрен әле белеп җиткермәүгә карамастан, һәртөрле ария һәм җырны ул бик тиз отып ала һәм шундук җырлап та бирә. Һәм менә бервакыт Азат әтисенең дусты — атаклы композитор Салих Сәйдәшев алдында җырларга җөрьәт итә. Әлеге «беренче имтихан» 1944 елда була. Нәкъ шушы вакытта П. И. Чайковский исемендәге Мәскәү консерваториясенең милли опера студиясенә укучылар сайлап алу башлана. Егетнең җырлавын сокланып тыңлаган Салих абыйсы аңа менә шушы студиягә барырга киңәш бирә...

Мәскәү консерваториясен уңышлы тәмамлаганнан соң Азат Аббасов Казанга кайта һәм үзенең иҗат биографиясен Татар дәүләт опера һәм балет театры белән бәйли. Инде хәзер аларны бер-берсеннән аерып та булмый. Әлеге театрда ул йөзгә якын партия башкарды. Аларның күпчелеге — төп рольләр. Ничаклы образ! Бер-берсенә охшамаган геройлар... Кайчак гаҗәпләнеп тә куясың: артист аларны сәхнәдә кабатланмас рәвештә калку итеп гәүдәләндерүгә ничек ирешкән?!

Чыннан да, А. Аббасовның репертуары күпкырлы. Рус, татар һәм чит ил опера классикасы спектакльләрендә дә, оперетта һәм музыкаль комедияләрдә дә ул партияләрне бердәй осталык белән башкара. Саный китсәң, тулы бер образлар галереясы. Кайберләрен күздән кичерик: Н. Җиһановның «Җәлил», «Алтынчәч», «Түләк һәм Су-сылу» операларында Җәлил, Җик, Түләк, Д. Шостаковичның «Екатерина Измайлова»сында Сергей, А. Холминовның «Оптимистик трагедия»сендә Алексей, А. Рубинштейнның «Демон»ында Синодал, П. Чайковскийның «Чародейка»сында Юрий, Дж. Вердиның «Риголетто»сында Герцог, Ш. Гуно операсында Фауст... Болар янына оперетта һәм музыкаль комедияләрдәге рольләрне дә өстәсәң, А. Аббасовның иҗат диапазоны бик киң булып күзаллана.

Лирик-драматик тенорлы артист А. Аббасов тарафыннан иҗат ителгән образлар арасында, мөгаен, лирик партияләр өстенлек итәдер. Драматик тенор өчен билгеләнгәннәре дә аз түгел. Моның шулай булуы драма театры йогынтысыннан киләдер. Татар дәүләт академия театры спектакльләрен Азат бала чактан ук яратып карады. Ә инде «Зәңгәр шәл» спектаклендә чыгыш ясау аңа актерлык осталыгын тагын да камилләшерергә ярдәм итте. Күренекле сәхнә осталары Камал III, Фатыйма Ильскаядан да ул күп нәрсәгә өйрәнде.

Заманчалык, заманча караш, замана геройларын реаль һәм калку итеп гәүдәләндерергә омтылу... Опера артисты А. Аббасов иҗатының асылын менә шундый сыйфатлар билгели. Үзенең сәнгатендә ул тормыш тәҗрибәсен, кичереш-тәэсирләрен бөтен тулылыгы белән файдалана. Шунысы да үзенчәлекле: аның өчен көчле нату-

ралар якынрак. Халкыбызның батырлыгын мөмкин кадәр тулырак ачу теләге актерны «Җәлил» операсына мөрәҗәгать итәргә этәрә. Шулай итеп Җәлил — татар халкының каһарман улы образы анык иң яраткан партиясенә әверелә. Гаять катлаулы образ булуга карамастан, артист патриот-шагыйрьне вокаль яктан да, сәхнәдәге сынланышы ягыннан да бербөтен итеп гәүдәләндерүгә ирешкән. Җырчының тавышы бөтен регистрларда да тигез, табигый агышлы булып яңгырый. Бернинди көчәнү сизелми. Партиянең төп уңышы әнә шуларда күренә. Һәм, әйтергә кирәк, Җәлил образы бер артистның иҗат биографиясендә генә түгел, ә тулаем музыкаль культурабызда күренекле вакыйга буларак кабул ителде. Бөек Җиңүнең 30 еллыгы уңаеннан үткәрелгән Бөтенроссия смотрында А. Аббасовның Җәлил партиясен башкарганы өчен РСФСР Культура министрлыгы дипломы белән бүләкләнүе дә тикмәгә генә түгелдер.

Тамашачылар хәтерлиләрдер: Х. Вәлиуллинның «Самат» операсында (беренче куелышта) төп рольне А. Аббасов башкарды. Курку белмәс Самат яна торган танктан үзенең дустын коткара һәм җәрәхәтләнгән хәлдә госпитальгә эләгә. Авыру чигенә. Фронтовик Самат яңадан сафка — тыныч тормыш фидакарьләре сафына кайта. Спектакльдә Самат-Аббасов тавышы тәэсирле яңгырый. Классик, академик җырлау стиле халык җырларын башкаруга хас стиль үзенчәлекләре белән органик рәвештә кушылып китә. Кыскасы, әлеге образ вокаль яктан да, сәхнәдәге уйналышы ягыннан да камил эшләнгән.

Уңышлы образлар, яраткан геройлар... Алар шактый. Әйтик, «Оптимистик трагедия»дән Алексей да шундыйлар рәтенә керә. Ә менә «Катерина Измайлова»дагы Сергей партиясенең А. Аббасов тарафыннан башкарылышы опера авторы Д. Шостаковичның да күңеленә хуш килә. Артист яңадан-яңа геройларга яшәеш бирә, образлар галереясын туктаусыз баета.

Опера артисты А. Аббасов массовый җырларны пропагандалауга да үзеннән зур өлеш кертә. Совет җырларын башкару өлкәсендә ул үзенчәлекле интерпретатор буларак танылды. Татар композиторларыннан С. Сәйдәшев әсәрләрен, Р. Яхин романсларын, Ә. Бакиров, И. Шәмсетдиновның массовый җырларын А. Аббасов эчке ярату һәм зур осталык белән башкара. «Наемщик», «Зәңгәр шәл» спектакльләрендәге җырлар, опералардан арияләр, шулай ук халык җырларының аның башкаруындагы язмалары бик хаклы рәвештә татар музыкаль культурасы антологиясенә кертелде. Шулай ук ул рус, итальян халык җырларын да бик яратып башкара.

Татар һәм рус тамашачылары арасында дан казанган җырчы А. Аббасовның җәмәгать эшчәнлеге дә күп тармаклы. Ул предприятиеләрдә, уку йортларында, хәрби подразделениеләрдә еш була, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге идарәсе председателе урынбасары, ВТО идарәсе члены буларак, культурабызны үстерүгә зур өлеш кертә.

...Моннан унҗиде ел чамасы элек Дербент училищеларының берсендә белем алучылар опера группасы оештыралар һәм каникул вакытында илебезнең төрле шәһәрләрендә опера спектакльләрен карап йөриләр. Соңыннан җыйнаулашып фикер алышалар, иң яхшы башкаручының исемен атыйлар. Шундый утырышларның берсендә А. Аббасов та телгә алына. Һәм бервакыт аңа Дербенттан гадәти булмаган посылка килеп төшә. Ачып караса — Кубачи осталары тарафыннан эшләнгән мөгез һәм мактау грамотасы. Ә грамотада мондый сүзләр язылган: комсомол-яшьләр советы конкурсы жюрие тарафыннан 1967 елның иң яхшы опера җырчысы булып танылган А. З. Аббасовка — кешеләргә бәхет китерүче дәртле башкару осталыгы өчен.

Кешеләргә бәхет китерүче осталык... Җәмәгатьчелек вәкилләре тарафыннан аңа менә нинди бәя бирелгән. СССРның халык артисты Азат Зиннәтович Аббасов иҗаты, чыннан да, халык исеменнән югары бәяләүгә лаеклы.

**Флера БИКЧУРИНА,**
музыка белгече.

## Читен эш

1907 елда Фатих Әмирхан «Әльислах» газетасы чыгарырга керешә. Патша власте аңа редактор булырга рөхсәт бирмәгәч, ул редакция эшендә бер дә тәҗрибәсе булмаган Вафа Бәхтияровны рәсми редактор итеп билгеләтергә мәҗбүр була.

Газета чыга башлый... Бер заман Вафа Бәхтияровтан иптәшләре сорашалар икән:

— Я, нихәл, Вафа, эшләр барамы?

— Баруын бара да, тик мөхәррир булып эшләү бик читен икән,— ди ул.

— Шулаймыни?

— Шулай шул,— ди аларга Вафа Бәхтияров.— Үзегез уйлап карагыз, ничек читен булмасын. Иртүк торып, кулъязмаларны типографиягә илтеп бирергә кирәк. Басылганнан соң гәҗитләрне, кечкенә арбага төяп, шәһәрнең бер башыннан икенче башына хәтле тартып алып кайтасың. Аннары, тирләп-пешеп, адресларын язасың. Аларны гәҗит саен ябыштырасың. Шуннан соң, тагын арбага төяп, почтага илтәсең. Почтасы кайда дисең тагы? Җәһәннәм тишегендә... Фатих белән Тукайга нәрсә аларга? Язалар да шуның белән вәссәлам! Ә син, телеңне салындырып, ломовой аты шикелле йөр... Юк, мөхәррир булу бик читен эш икән!

## Кем яна?

Шагыйрь Хәсән Туфан бер заман тәмәке тартырга шул хәтле күнеккән иде, әгәр авызында тәмәкесе булмаса, яза да, укый да алмый иде. Шулай көннәрдән бер көнне ул Аккош күлендәге дачада, тәмәкесен тарта-тарта, караватында уйланып ята да, кинәт сикереп торып, ашыгып кабинетына кереп китә. Илһам килгән була аңа. Тәмәкесен кабызып, кызу-кызу язарга керешә.

Күпмедер вакыт яза. Бакчачылардан Афзал Шамов белән Абдулла Әхмәт Туфаннар тәрәзәсеннән өерелеп чыккан төтенне күреп алалар да аның янына йөгереп керәләр. Ни күрсеннәр, шагыйрьнең верандасына ут капкан. Мендәре, юрганы, матрацы яна.

— Янасың бит! — диләр аңа.

— Нигә мин яныйм, күршем яна ич! — ди ул, язуында дәвам итеп.— Төтен алар ягыннан килә.

Абдулла Әхмәт, ачуланып:

— Бу кадәр булырсың икән, кымшанмыйсың да ичмаса! — дип кычкыра Хәсәнгә.

— Комачаулап йөрмә әле монда, болай да рифма таба алмыйча азапланам,— ди Туфан аңа каршы.

«Кызыклы хәлләр»не язучы
**А. ШАМОВ** әзерләде.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

23 октябрьда Татарстан Язучылар союзы партия оешмасының отчет-сайлау җыелышы булды. Анда отчет доклады белән партоешма секретаре Р. Мөхәммәдиев чыкты. Фикер алышуларда язучылар Г. Бәширов, С. Хәким, Г. Паушкин, Л. Ихсанова, М. Хәбибуллин, Р. Харис, Мансур Вәлиев, К. Кәримов, партиянең Бауман райкомы икенче секретаре Ф. Х. Габидуллин һ. б. катнашты.

Партия оешмасы бюросының яңа составына Т. Миңнуллин, С. Хәким, Л. Ихсанова, Р. Харис, И. Юзеев, Г. Паушкин, Р. Кәрами, Ә. Мушинский, Р. Мөхәммәдиев иптәшләр сайланды. Бюроның оештыру утырышында партия оешмасы секретаре итеп яңадан Р. Мөхәммәдиев сайланды.

Җыелышта КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова катнашты.

## СССР ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ИДАРӘСЕНЕҢ ЮБИЛЕЙ ПЛЕНУМЫ

25 сентябрьдә Мәскәүдә Кремльнең Зур сараенда СССР Язучылар союзы идарәсенең юбилей пленумы булып узды. Ул әлеге иҗат оешмасының илле еллыгына багышланган иде. Күпмилләтле совет әдәбияты, барлык иҗат союзлары вәкилләре һәм дөньяның 33 иленнән килгән кунаклар катнашкан бу зур форумда Татарстаннан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин, С. Хәким, Г. Ахунов, И. Юзеев, Э. Касыймов, Р. Вәлиев, Р. Мөхәммәдиев һәм башка иҗат оешмалары җитәкчеләре катнашты.

## «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫНЫҢ УКУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯЛӘРЕ

4 октябрьда Төзүчеләрнең техника йортында «Казан утлары» журналы редакциясе һәм авторларының Әлмәт шәһәре хезмәт ияләре белән очрашуы булды. Очрашуда журналның баш редакторы шагыйрь Р. Харис, Г. Афзал, А. Гыйләҗев, Ш. Бикчурин, Ә. Маликов, К. Булатова, Ә. Гаффар һ. б. язучылар, шәһәрнең җәмәгатьчелек оешмалары вәкилләре катнашты.

Р. Харис «Казан утлары»нда басылачак әсәрләр белән таныштырды. Чыгыш ясаучы эдипләр һәм язучылар журналның киләсе саннарында басылачак әсәрләре, иҗат планнары турында сөйләделәр. Соңыннан Татарстан нефтьчеләрен тәрбияләүдә нәтиҗәле идеологик эше һәм зур иҗат уңышлары өчен «Казан утлары» журналы коллективына В. Д. Шашин исемендәге Ленин орденлы «Татнефть» берләшмәсенең, нефть һәм газ промышленносте эшчеләре профсоюзы Татарстан өлкә комитетының Мактау грамотасы тапшырылды.

20—21 сентябрьдә Баулы районы Яңа Шалты авылында һәм Баулыдагы 14 нче номерлы урта профессиональ-техник училищеда «Казан утлары» журналының укучылар конференцияләре булып узды.

Әдәбият сөючеләр, яшь иҗат көчләре, укытучылар һәм культура эшчеләре, районның җәмәгатьчелек оешмалары вәкилләре катнашында «Казан утлары» журналында басылган һәм киләсе елда басылып чыгачак әсәрләр, бүгенге әдәбият турында төпле сөйләшү булды. Журнал укучылар алдында язучы Н. Дәүли, тәнкыйтьче Р. Мостафин һәм журналның хатлар бүлеге редакторы шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов чыгыш ясадылар, күпсанлы сорауларга җаваплар бирделәр.

2 октябрьда Брежнев шәһәренең «КамАЗ» культура сараенда «Казан утлары» журналының укучылар конференциясе үткәрелде. Биредә КамАЗчылар, күпсанлы әдәбият сөючеләр, шәһәрнең иҗатчылары җыелган иде.

Журналның баш редактор урынбасары Р. Мөхәммәдиев, журналның редколлегия члены язучы А. Гыйләҗев, Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателенең урынбасары Р. Вәлиев, Брежнев язучылар оешмасы җаваплы секретаре Р. Хәмид, Р. Мингалимов, Р. Батулла, Р. Низамиев, К. Сибгатуллин бүгенге әдәби хәрәкәтебездә журналның роле, басылган һәм басылачак әсәрләр турында сөйләделәр.

3 октябрьда Түбән Кама шәһәренең Техника йортында уздырылган журнал укучылар конференциясендә йөзләрчә нефтехимия работниклары, әдәбият сөючеләр җыйналды.

Р. Мөхәммәдиев редакция коллективының эше, журналның иҗат планнары, 1985 елда басылып чыгачак яңа әсәрләр белән таныштырды. Язучылардан А. Гыйләҗев, Р. Вәлиев, Р. Хәмид, Р. Мингалимов, Р. Батулла, Р. Низамиев, К. Сибгатуллин, Р. Хисмәтуллин иптәшләрнең чыгышын залдагылар яратып тыңладылар.

# ҖИҢҮНЕ ЯКЫНАЙТКАН ПАРАД

1941 ел, 7 ноябрь. Кызыл мәйданнан хәрби парад уза. Тигез сафларга тезелгән сугышчылар тимер ташкын булып агыла. Турыдан-туры сугышның алгы сызыгына юл тотучы әлеге колонналарда теләсә нинди каршылыкны җимерерлек көч-куәт тупланган. Ватаныбыз башкаласына якынлашкан фашист өерләрен мондый ташкын һичшиксез сытып китәчәк!..

Арабыздан яшьли киткән рәссам Константин Васильевның (1942—1976) «1941 ел парады» исемле картинасы тоташтан әнә шундый оптимистик рух белән сугарылган. Һәм тарих җиңүгә ышаныч белән узган парадның көчен раслады да: Мәскәү янында дошманның бөтен планнары чәлпәрәмә килде. Кырык беренче ел парады, шулай итеп, Җиңү парадын якынайтты.

Картинаның эшләнеше турында сүз алып барганда, иң беренче чиратта, авторның композицион бөтенлеккә ирешүен билгеләп үтәргә кирәктер. Әсәрдәге һәрбер деталь-образ бер максатка, төгәлрәк әйткәндә, бер идеягә буйсындырылган. Биредә артык сызыкларны таба алмассың. Композициягә Минин һәм Пожарский һәйкәленең силуэты кертелү исә данлы сугышчан традицияләрнең яшәүчәнлек символы буларак кабул ителә. Һәм әлеге образ шул хакта да искәртә: кылыч белән килгән — кылычтан үләр... Зәңгәрсу «салкынча» тоннар гаммасы чорның кырыс һәм фаҗигале булуын чагылдыра.

Кырык ел... Җиңү язынна соң инде шушы кадәр вакыт үтте. Һәм, әйтергә кирәк, күпмилләтле совет рәссамнары халкыбызның тиңдәшсез каһарманлыгы турында сөйләүче сынлы сәнгать елъязмасын инде менә кырык ел буе дәвам иттерәләр. Сугыш тематикасын инде менә кырык ел буе дәвам иттерәләр. Сугыш тематикасы Х. Якупов, В. Куделькин, А. Родионов, Е. Симбирин кебек күренекле рәссамнар иҗатында аеруча калку итеп гәүдәләндерелә. Моның шулай булуы табигый, чөнки алар үзләре дә фронтовиклар. Сугыш фаҗигасен үз башыннан кичерү, кичереш-тойгылар тирәнлеге, документальлек алар тарафыннан иҗат ителгән әсәрләрнең ышандыру көчен һәм тәэсирлелеген бермә-бер арттыра.

Бүгенге яшь буын өчен сугыш совет кешеләренең көчле рух, ныклы һәм кыюлык сыйфатларын бөтен тулылыгы белән ачкан фаҗигале сынау буларак гыйбрәтле. Әйтик, яшь рәссамнарга әлеге бөек тарихи вакыйганың әһәмиятен гомумиләштерелгән караштан чыгып аңлау характерлы. Аларның символик образларга һәм метафораларга күбрәк мөрәҗәгать итүләре дә әнә шуннан киләдер. Мондый үзенчәлекләрне без К. Васильевның югарыда сөйләнгән «1941 ел парады» исемле картинасында ачык күрәбез.

**Владимир РАЗУМЕЙЧЕНКО,**
Татарстан сынлы сәнгать музееның фәнни хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Ленин комсомолы исемендәге Яшь тамашачылар театрының «Иван Царевич» исемле спектакленнән (Ю. Михайлов) күренеш.

**Рөстәм МАНСУРОВ** фотолары.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ).

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)